# казан утлары

9
СЕНТЯБРЬ-1975

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

9
СЕНТЯБРЬ
1975

## Бу санда

Ә. ЕНИКИ. Гөләндәм туташ хатирәсе. Кечкенә роман . . . 3
Н. НӘҖМИ. Кайда булдым!.. Шигырьләр . . . . 51
Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Диңгез төпе. Шигырьләр . . 58

Г. АХУНОВКА 50 ЯШЬ

А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Күпне күтәбез! . . . . . . . 62
Г. АХУНОВ. Утлар яна учакта. Драма . . . . . 66

БӨЕК ҖИҢҮГӘ 30 ЕЛ

И. ВЕРГАСОВ. Кырым партизаннары. Хикәяләр 101
М. ГАЯЗ. Оясыз калган сыерчык. Шигырь . . . 122
ГИЗ-ЭЛЬ ГАБИД. «Окоп дәфтәре»ннән. Шигырьләр 124

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

Ч. ҖӘЛИЛОВА. Август көннәрендә Берлинда . . 127
Л. НЕБЕНЦАЛЬ. Муса Җәлил эзләреннән . . . . 130
И. ЗӘБИРОВ. Җәлил дусты . . . . . . . . . 135
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Җәлил. Шигырь . . . . . 141
Җ. ДӘРЗАМАНОВ. Пистолет монологы. Шигырь 142

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . 143
М. МИНШИН. Ак ефәк . . . . . . . . . . . 146

ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Р. КӘРИМОВ. Драматургиябез горурлыгы . . . 153
Т. ГЫЙЗЗӘТ. Идел буйлары. Юлъязмалар . . . 158

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. МӘҺДИЕВ. Югарыга карап фикер ит . . . . 163
Г. РӘХИМ. Киләчәккә узып барышлый . . . . . 174

КПССның ТАТАРСТАН өлкә КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ш. АСЫЛГӘРӘЕВ.** Реализм турында . . . . . . 181

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

**Р. МИНГАЛИМОВ.** Малайлар. Шигырьләр . . . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 30/V-1975 ел. Басарга кул куелды 6/VIII-1975 ел. ПФ 09027. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 90000 экз. Заказ Я-227. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1975 ел.

Әмирхан Еники

# ГӨЛӘНДӘМ ТУТАШ ХАТИРӘСЕ

КЕЧКЕНӘ РОМАН

## I



Көзге кич. Тышта җил, яңгыр. Нидер кыштырдый, дөберди, ыңгыраша. Вакыт-вакыт бу сәер тавышлар көчәеп тә китә. Мин куркынып, укый торган китабымнан аерылып, колак салып тора башлыйм. Нәрсә икән бу? Әллә безнең капкага чит кешеләр килде микән? Хәзер бик хәвефле чак бит. Шәһәрдә төрле шомлы хәбәрләр йөри. Талаулар, хәтта үтерүләр дә булып тора дип сөйлиләр. Аллам сакласын! Бигрәк тә әллә нинди буталчык, куркыныч ел булды бу унсигезенче ел!.. Ләкин менә хәзер шомлануым юкка гына икән: әлеге хәерсез усал җил котырына, имеш, шуңардан тыштагы каен ыңгыраша, шәрә ботаклары өйнең стенасына бәрелә-сугыла тырнаша. Әнә тәрәзәдән төшкән яктыда да кара ботакларның, кемнеңдер чатлы-ботлы куллары шикелле, якякка селкенгәне күренеп тора.

Тынычланып, яңадан китабыма иелэм. Ә укый торган китабым бик кызыклы булса кирәк — «Дим буенда» дип атала. Бүген генә Кәримәдән алып кайттым. Менә шуны йомшак урын өстендә, аякларымны җыеп, мендәргә таянып, аерыла алмыйча укып утырам. Миңа билгесез ерактагы Дим елгасы. Искиткеч гүзәл, имеш, аның буйлары... Менә шунда Исхак дигән карт мирзаның гаиләсе яшәгән. Аның ике улы, бер кызы булган. Аннары Фәридә исемле бер ятимә кыз да аларда торган икән. Бу кыз рояльдә бик оста уйнаган... Кыскасы, гүзәл табигать, бай тормыш, чибәр кешеләр. Әмма ләкин бу роман да бәхетсез мәхәббәт турында булса кирәк. Укый торгач, менә шул ачыла башлады. Гаҗәп, нинди генә романны укымыйм, гел бәхетсез мәхәббәт турында!.. Нигә ул алай икән?.. Әллә тормышта бәхетле мәхәббәт дигән нәрсә бер дә булмый микән?

Тәмле укуымны бүлеп, асрау кызыбыз Сабира бүлмәмә килеп керде.

— Туташ, сезне әтиегез чакыра!

— Нигә инде?

— Бер егеткә күрсәтергә.

— Куй әле шул мәгънәсез шаяртуларыңны...

— Төшкәч күрерсең! — диде Сабира ваемсыз гына һәм шунда ук чыгып та китте.

Мин аның сүзенә ышанмадым, әлбәттә. Егет, имеш! Күрсәтер безнең эти егеткә, көтеп тор! Әдәшкәч төшәргә кирәк. Иренеп кенә аякларымны салындырдым, йомшак чүәкләремне кидем, көзгегә күз салып, чәчемне рәтләштергән булдым да тар баскычтан түбән төшеп киттем. Өстемдә дә минем гади генә ситсы күлмәк иде... Шушы кыяфәтем белән, аңымоны уйламыйча, залга барып та кердем. Һәм керү белән, күзгә күренмәс диварга килеп бәрелгәндәй, шып туктап та калдым. Шаяртмаган икән ләбаса Сабира! Әтием янында, йомшак креслода яшь кенә бер егет утырып тора! Ни сәбәптер шул мизгелдә үк егетнең миңа төбәлгән зур күзләре һәм нечкә коңгырт кашлары белән мәрмәрдәй ап-ак маңгае минем игътибарымны җәлеп итеп тә өлгерде. Билгеле инде, бу хәтле дә көтелмәгән очрашудан мин бик аптырап-уңайсызланып калдым, бит очларым, кинәт ут капкандай, кызарып яна да башлады.

Әтием хәлемне аңлады шикелле, чак кына көлемсерәп урыныннан торды да гади генә итеп:

— Кызым, бу Салих әфәнде! — диде.

Егет тә, торып, сүзсез генә миңа башын иде. Мин дә аңа баш идем һәм чәч толымнарымны тиз генә аркама күчердем.

Аннары әтием егеткә карап:

— Кызыбыз Гөләндәм шушы була инде, — диде.

Егет тагын бер кат җиңелчә генә башын иде. Шуннан соң әтием миңа әйтте:

— Кызым, Салих әфәндене мин сиңа музыкадан дәрес бирер өчен чакырттым. Без инде сөйләштек, килештек — Салих әфәнде түбәнчелек белән риза да булды. Хәзер, кызым, эш синнән тора: иншалла, күңел биреп кенә музыкант әфәндедән барысын да белеп, өйрәнеп калырга тырышырсың дип ышанам.

— Рәхмәт, эти! — дидем мин тыелып кына.

— Әмма бер шартым бар, — диде ул, яңадан Салих әфәндегә борылып. — Дәрес вакытында миңа да бер читтә генә тыңлап утырырга рөхсәт итәрсез инде... Үлеп яратам үзебезнең мөселман көйләрен, ихлас!..

— Ихтыярыгыз! — диде Салих әфәнде, авыз чите белән чак кына елмаеп. Ул әтиемнең «мөселман көйләрен үлеп яратуына» ышанып бетмәде, ахрысы. Хәлбуки, әтием музыканы ярата, һичшиксез ярата, яратмаса — менә мине дә укытып маташмас иде. Әмма бу очракта аның дәрес вакытында «бер читтән генә тыңлап утырырга» теләвен, музыкага мәхәббәттән дә бигрәк, безгә күз-колак булыр өчен дип аңларга бик мөмкин иде. Салих әфәнде, әлеге яшерен мәгънәле генә итеп елмаюына караганда, нәкъ әнә шулай аңлады да булса кирәк. Билгеле инде, әтием өчен миңа да бик уңайсыз булып китте. Асылда аның әйткән шартын башкача аңлап та булмый. Шәкерт — җитеп килгән кыз, укытучы — яшь кенә егет, күз-колаксыз ярыймы соң?!

Салих әфәнде әтиемнән минем белән сөйләшергә рөхсәт сорады. Әтием рәхим итегез дигәч, ул миңа карап йомшак кына сораша башлады:

— Туташ, сез пианинода уйнарга күптән өйрәндегезме?

Аның миңа төбәлгән күксел-зәңгәр күзләренең карашыннан мин ничектер югалыбрак калдым, ирексездән тагын кызардым һәм каушабрак кына:

— Юк, күптән түгел, — дидем.

— Кемнән өйрәндегез?

— Башта үзем генә.

Пианино өстендә нота дәфтәрләре ята иде, Салих әфәнде, шуларга ымлап:

— Ләкин сез нота белән дә уйныйсыз шикелле, — диде.

— Әйе, уйныйм... әзрәк кенә.
— Нотага кем өйрәтте?
Аның бу соравына әтием җавап бирергә ашыкты:
— Күршебездә генә бер яһүдә ханым торган иде, шул бездә пианино барлыгын белгәч, кергәләп йөри башлады. Музыкага бик хирыс хатын икән, үзе кәефләнеп уйнау өстенә, минә безнең Гөләндәмне дә бик теләп өйрәтергә тотынды... Кызыгызда музыкага сәләт бар, чынлап укытырга кирәк ди торган иде. Без инде каршы килмәдек, бигрәк тә әнисе... Гөләндәм бу нота дигән язуларга шуңардан өйрәнеп тә калды. Тырышты яһүдә, әйтәсе дә юк!
— Кем ул, фамилиясе ничек? — диде Салих әфәнде, шунда ук кызыксынып.
— Ни атлы иде әле ул, кызым?
— Маргарита Яковлевна Зель... Зельберг.
Салих әфәнде аз гына уйланып торды:
— Зельберг?.. Юк, белмим, кызганычка каршы!
— Ул ханым, герман сугышы башлангач, Петербургтан сөрелгән булса кирәк,— диде әтием.— Һәрхәлдә, безнең шәһәрдә вакытлы гына кеше иде, хөррият чыккач та каядыр китеп барды.
Салих әфәнде яңадан миңа карап:
— Ноталарыгыз белән танышырга рөхсәт итегез! — диде.
Мин баш кагып кына ризалыгымны белдердем. Ул нота дәфтәрләрен берәм-берәм алып карарга кереште.
— Скрябин... Шопен... Ярый, яхшы бу... Ә бусы кемнеке? Гурилев!.. Хәзерге вакытта күп уйнала торган композиторларның берсе... Аның шушы нәрсәсен уйнап та күрсәтмәссезме, туташ?
Мин чарасыздан диярлек ул сузган нотаны кулыма алдым. Бу «На заре туманной юности» дигән романс иде. Уйнамаган нәрсәм түгел, тик шулай да Салих әфәндегә иң беренче башлап мондый авыр нәрсәне уйнап күрсәтү мине, билгеле, куркыта иде. Ләкин укытучы буласы кешем сорагач, мин, теләсәм-теләмәсәм дә, пианино каршына утырырга мәҗбүр булдым. Нотаны ачып терәп куйдым да, ничек тә каушамаска тырышып, ашыкмыйча, җайлап кына уйный башладым. Салих әфәнде миннән бер читтәрәк, пианино өстенә таянып, бик игътибар белән тыңлап торды. Моңарчы беркемнең дә әле, бигрәк тә музыкант кешенең, янымa басып, мине махсус тыңлап торганы юк иде. Шуңадыр инде, романсны уйнап чыгу минем өчен сыйрат күперен кичү белән бер булды. Ничегрәк уйнавымны үзем бөтенләй сизмәдем дә диярлек.
Уйнап беткәч, Салих әфәнде бары:
— Яхшы! — дип кенә куйды.
Нәрсә яхшы — уйнавыммы, әллә уйнап бетерүемме — мин моны аңлый алмадым. Шуннан музыкант әфәнде (әтием әйтмешли) миңа үзем яраткан берәр көйне нотасыз гына уйнарга кушты. Татарчамы? дип сорадым мин. Әлбәттә, диде ул... Менә монысы инде, оят булса да әйтергә кирәк, минем өчен шактый ук читен эш иде. Хәзергә кадәр әле минем үзебезнең көйләрне юньләп уйнарга өйрәнеп җитә алганым юк. Дөрес, баштарак кайбер көйләрне ярыйсы гына уйный идем кебек, ә менә Маргарита Яковлевнадан нотага өйрәнә башлагач, алары да онытылды диярлек. Маргарита Яковлевна нотасыз уйнаганны ни өчендер бер дә яратмый иде. Иң элек нотадан өйрәнергә, шуннан соң гына яттан уйнарга кирәк дип әйтә торган иде. Ә нотага салынган татар көйләре бездә бөтенләй юк ич, алтын бирәм дисәң дә, аларны табып булмый бит!
Көтеп торган Салих әфәндегә мин, ниһаять, бик уңайсызланып кына әйтергә мәҗбүр булдым:
— Кичерегез, татар көйләрен уйный белмим шул.
— Бер дәме? — диде ул гаҗәпләнеп.
Мин дәшмәдем, дөресрәге, ни диеп әйтергә дә белми идем.

— Юк, сез уйный беләсез, — диде ул, мине рухландырырга теләгәндәй. — Ягез әле, ягез!.. Миңа бит бары сезне ишетеп карау гына кирәк.
Әлбәттә, карышып тору килешмәячәк иде. Әмма нәрсәне, ничек кенә итеп соң, ходаем?.. Шулай да азапланып уйлана торгач, электәнрәк белгән бер көйне исемә төшереп, бик әкрен генә, бик сак кына уйный башладым. Бу «Яз да була...» дигән көй иде... Күңелемдә ачык яңгырый ул минем... Ахырда уйнап чыктым.
— Менә булды бит! — дип куйды Салих әфәнде, елмаеп кына. — Шәп уйныйсыз дип мактый алмыйм, тулаш, әмма көйне тоя беләсез. Ә бу — музыкант өчен иң кирәге, иң мөһиме!..
Шушы урында әтием тагын сүзгә кушылды:
— Безнең максат, Салих әфәнде, кызыбызны музыкант ясау түгел. Әгәр дә ки үз көйләребезне чибәр генә уйнарга өйрәнсә, без шуңа да бик канәгать булачакбыз. Сезнең ярдәмегез белән, әлбәттә!
Салих әфәнде башта иелә биреп миңа рәхмәт белдерде, шуннан соң гына әтием янына күчте.
— Әхмәтҗан абзый, Гөләндәм туташ татар көйләрен уйнарга да һичшиксез өйрәнәчәк,— диде ул, ничектер бик ышандырып.— Ә бәлки чын музыкант та булып китәр, бөтен эш аның кабилиятенә һәм сезнең теләккә бәйләнгән.
Әтием килешеп:
— Хак сүз! — диде. — Әмма анысын инде киләчәк күрсәтер, насыйп булса!
— Әйе, киләчәк күрсәтер! — дип кабатлады Салих әфәнде дә. — Ә дәресне без икенче очрашуда башларбыз... Кайчан килергә рөхсәт итәсез?
— Алдан сөйләшкәнчә, сез атнага ике мәртәбә килергә тиешсез. Бүген сишәмбе көн, тагын кайсы көн сезнең өчен уңайрак?
— Җомгадан башка көннәрнең кайсы да ярый миңа.
— Җомга — изге гыйбадәт көне, шуңа фани дөнья эшләре белән шөгыльләнергә теләмисездер инде, Салих әфәнде, шулаймы?
Әтием моны көлебрәк сорады шикелле, ләкин Салих әфәнде, бер дә аптырамастан, аңа шактый кызык кына итеп җавап бирде.
— Киресенчә, Әхмәтҗан абзый, бу көнне изге эшләрем күп минем. Мәсәлән, көндезен «Шәрык» клубында балалар өчен, ә кичен «Сәйяр» оркестрында уйныйсым бар.
— Ә шулаймыни әле, мин Сезнең ул хезмәтегезне онытта да язганмын. Кичерәсез!.. Соң, алайса, кайсы көн мәгъкуль булыр икән?.. Атна кич дисәм, ике дәрес арасы бик якын була кебек... Бәлки шимбә көн?
— Мин риза. Тик вакыты кичке сәгать биштән җидегә чаклы булсын иде. Көндезләрен бушый алмыйм.
— Безнең өчен дә бу вакыт уңай булачак, — диде әтием. — Кызым, ишеттеңме, Салих әфәнде дәрес бирергә шимбә көн киләчәк.
— Ишеттем, — дидем мин.
Әтием тагын нидер сөйли башлаган иде, ләкин минем аларга (дөресрәге, Салих әфәндегә) карап торуымны күргәч, сүзен бүлеп, әдәп белән генә:
— Кызым, син бүгенгә азат! — диде.
Мин дә әдәпнең нәрсә икәнен аңлап, кызаруымны яшерер өчен башымны иеп кенә залдан чыгып киттем. Алар әле сөйләшә калдылар.

*
* *

Үз бүлмәмә кайткач та мин тиз генә тынычлана алмадым. Хәтта мавыгып укып яткан китабыма да яңадан тотынасым килмәде. Нишләптер бу көтелмәгән очрашу мине бик дулкынландырды әле... Салих... Са-

лих әфәнде!.. Хәер, ни өчен көтелмәгән?.. Музыкадан укытучы чакыру турында безнең гаиләдә күптән сүз бара иде бит инде. Иң элек мин үзем моны бик тели идем, шулай ук әнием дә тели иде, аннары тора-бара әтием дә риза булды. Бередә шуны әйтергә кирәк, әнием минем заманына күрә алдынгы карашлы, мәдәнияткә омтылучы хатын иде. Ул бит Сембердә туып-үскән, ә Сембер Казан түгел инде — саф рус шәһәре. Ахун хәзрәт кызы булуына һәм асылда мөселманча тәрбияләнеп үсүенә карамастан, әниемә барыбер рус кызлары белән аралашырга, телләрен, гадәтләрен өйрәнергә, өй-гаилә тормышларын якыннан күрергә туры килгән. Болар барысы да аңа билгеле бер йогынты ясамыйча калмаган, әлбәттә. Мәсәлән, әнием бервакытта да йөзен ирләрдән яшерми, шулай ук абыстайлар шикелле укалы камзул, үкчәсез читекләр дә киеп йөрми. Ул европачарак киенергә ярата һәм күлмәкләрен дә бары рус хатыннарыннан гына тектерә.

Билгеле инде, әнием мине дә үзе теләгәнчәрәк тәрбия итәргә тырышты. Казанның иң яхшы, иң алдынгы мәктәпләреннән саналган Ләбибә ханым мәктәбенә укырга бирде. Бу кызлар мәктәбендә безгә, төрле фәннәр укыту белән бергә, рус телен дә укыттылар, шулай ук һәр төрле кул эшенә дә өйрәттеләр. (Мин инде рөштинең дүртенче сыйныфына күчкән идем, ләкин, кызганычка каршы, быел җәй зур пожар вакытында мәктәбебез янды да китте.) Аннары миндә җыр-музыкага күпмедер сәләт барлыгын белгәч, әнием әтиемнән, ай-ваена куймыйча, пианино да алдырды. Инде менә хәзер махсус укытучы чакырту да — асылда әнием эше. Әтием исә минем, дөресен генә әйткәндә, шактый иске караштагы кеше. Бигрәк тә тәрбия мәсьәләсендә. Ни өчендер ул, кызларга күп белү кирәкми, дигән караштa тора. Имеш, артык күпне белгән кыз бала хөрлеккә өйрәнә, ә хөрлеккә өйрәнгәч, үзенең киләчәктәге вазифасын оныта башлый. Ягъни, иренә итагатьле хатын, балаларына яхшы ана була алмый, имеш. (Ни өчен була алмый? — мин моны үзем һич тә аңламыйм). Ярый әле, әтиемнең бер «йомшак» ягы бар — ул күп кенә очракта әнием белән килешергә мәҗбүр. (Әнием бит чыгышы белән дә, тәрбиясе белән дә аңардан өстен, әтием исә «мужиктан» чыккан, тик үзенең зирәклеге һәм тырышлыгы аркасында гына зур байларның доверенные булган кеше)... Менә миңа музыкадан укытучы алу мәсьәләсендә дә эш шулайрак булды: әнием кирәк диде, әтием... Хәер, бу очракта зур бәхәс тә купмады, чөнки, әйткәнемчә, әтием үзе дә музыканы бик ярата иде.

Әмма аның укытучы итеп Салих әфәнде кебек яшь, чибәр бер егетне чакыруы бик гаҗәп иде. Мин үзем дә моны һич тә көтмәгән идем. Күрәсең, берәр могтәбәр кеше аны бик мактап әтиемә тәкъдим иткәндер инде. (Музыкант итеп кенә түгел, әдәпле, инсафлы, ышанычлы егет итеп тә; күрдегез ич, ул минем белән әтиемнән рөхсәт сорап кына сөйләште). Аннары Салих әфәнде өебезгә килеп, әтием-әнием алдында мине укытып йөриячәк. Димәк, артык хәвефләнергә урын да булмаячак. Ә миңа килгәндә инде, мин бит әле уналты яшьлек кенә кыз бала, укытучыма шәкерт кенә, минем уемда дәрес алудан башка нәрсә генә булырга мөмкин?! Шулай ич!

Шулаен шулай да, әмма ни өчен соң мин Салих әфәндене күрү белән бу кадәр коелып төштем? Каушау һәм нәрсәгәдер куану шул ук мизгелдә икесе берьюлы диярлек минем җанымны биләп тә алды — нидән бу, нидән?.. Кинәт каршымда бик чибәр егет пәйда булганга күрә генәме?.. Әйе, яшерә алмыйм, залга килеп керүемә аның чибәрлеге минем күземә ташланды: бик чиста ак йөзе, сөйкемле генә чокыраеп торган ияге, җыйнак-тулы иреннәре, кечерәк, әмма килешле генә борыны, бигрәк тә ак мәрмәрдәй шома маңгае белән як-якка ишелебрәк торган коңгырт чәчләре — болар барысы да сокланып каратырлык иде. Мин инде аның күксел-зәңгәр күзләре турында әйтеп тә тормыйм. Бер генә тапкыр күтә-

релеп карадым, шунда да ул күзләр әллә тирәнлеге, әллә уйчанлыгы белән мине әйтерсең йотып алды.

Ләкин менә хәзер, тынычлана төшкәч, бер нәрсә гаҗәпләндерә әле мине: бу хәтле үк дулкынлануыма шул Салих дигән егетнең беренче карау белән күземә ташланган чибәрлеге генә сәбәп булды микәнни?.. Алай дисәң, минем бит инде моңарчы да чибәр егетләрне күргәләгәнем бар иде, әмма аларның берсе дә мине бер үк вакытта каушап калырга да һәм ниндидер билгесез куаныч кичерергә дә мәҗбүр итмәде иң! Димәк, моның сере чибәрлектә генә түгел. Юк, түгел! Ә нәрсәдә соң?.. Бу хәлнең бөтен яшерен серләрен мин әле белмим, белмим... тик шуны гына беләм: чибәрлектән башка тагын... ничек кенә дип әйтергә? — сүзен таба алмыйм, ходаем!.. Тукта, таптым шикелле: нәфислек! Әйе, әйе, нәфислек!.. Беләсезме, Салих әфәнденең бөтен кыяфәтеннән, килеш-килбәтеннән, торышыннан, хәтта сөйләшүеннән бик зат кешеләргә генә хас үзенә бер нәфислек сизелеп тора иде. Ул — нәфис кеше!.. Менә нинди кешегә ходай мине һич көтмәгәндә юлыктырды.

## II

Әйтелгән көнне, билгеләнгән сәгатьтә Салих әфәнде миңа беренче дәресен бирергә килде. Бу урында шуны әйтеп китим әле: ул килер алдыннан мин, үземә калса, мөһим генә бер мәсьәләне чишәргә тырышып баш ваттым: миңа нишләргә — залга төшеп көтеп торыргамы, әллә булмаса, ул килгәч кенә төшәргәме? Шәкерт булгач, мин үз урынымда, ягъни пианино янында көтеп утырырга тиешмендер инде. Ләкин шул ук вакытта мин бит әле туташ кеше, димәк, Салих әфәнде килгәч кенә төшсәм дә гаеп булмас шикелле... Хәтта, дөресрәк тә булыр. Һәм мин бу юлга шулай иттем дә — ул килгәч кенә залга төштем.

Без баш иешеп кенә исәнләштек. Әтием анда иде инде, аяк өсте генә сөйләшеп торалар иде. Салих әфәнде, әдәп саклап булса кирәк, минем яныма килергә ашыкмады, тик береаздан гына әтиемнән дәресне башларга рөхсәт сорады. «Рәхим итегез!» — диде әтием һәм үзенең сары бәрхет тышлы йомшак креслосына барып утырды. Дәрес беткәнче ул шунда безне тыңлап утырачак. Кыен хәл!.. Бигрәк тә Салих әфәндедән яхшы түгел — арканда кемдер күзләрен текәп утырсын әле!.. Ләкин ул, бу хәлгә бер дә исе китмәгәндәй, тыныч кына минем яныма килде, кулындагы төргәген пианино өстенә куйды һәм миңа утырырга тәкъдим итте. Үзе дә урындык алып, аз гына читкәрәк урнашты.

Мин аның беренче сүзен көтәм — укытучым дәресне нәрсәдән башлар икән?.. Әлбәттә, иң элек музыка турында, гомумән, нидер сөйләр инде. Ләкин ул сүзен бик гади генә итеп башлады:

— Туташ,— диде әдәп белән генә,— сез инде нота танысыз, пианинода яхшы гына уйныйсыз. Шуңа күрә мин бүгенге дәресне турыдан-туры үзебезнең халык көйләрен уйнарга өйрәтүдән башламакчы булам. Сез каршы түгелсездер бит?

Укытучым миннән әнә шулай дип сорады — бу гаҗәп иде! Һәм мин кыюсыз гына «юк» дидем инде.

— Алайса, мин сезгә башта берәр көй уйнап күрсәтим. Рөхсәт итегез!

Мин читкәрәк авыштым, ул күчебрәк утырды. Уйный башлаганчы миңа болай диде:

— Татарда көйләр бик күп. Алар нигездә барысы да биш тавышлы ладка корылганнар, әмма мелодияләре белән бер-берсеннән нык аерылалар. Әйтик, «Тәфтиләү» бар, «Алмагачлары» бар, икесе дә пентатоникага нигезләнгән, ә аермалары нинди! Берсендә — тирән моң-сагыш, икенчесендә — дәрт, шатлык... Халык күңеле әнә шундый инде ул, ту-

таш, — иң нечкә кичерешләренә дә көен-җырын таба белә!.. Без әле аларның төрлесен өйрәнербез, ә хәзергә уйнар өчен берәр җиңелрәген алыйк. Мәсәлән, «Туган тел»не! Сезгә дә ул таныштыр... Мәрхүм Габдулла абый Тукай сүзләре белән аны хәзер бөтен мәктәпләрдә җырлыйлар.

— Без дә хор белән җырлый идек, — дидем мин кыюланып,

— Минә бигрәк тә яхшы... Элек бу көйне «Анам кабере янында» дип йөртәләр иде. Тукай сүзләренә җырлана башлагач, ул әйтерсең яңадан туды — авыр хәсрәтле көйдән якты рухлы көйгә әйләнде дә куйды. Исеме дә «Туган тел!»

Чынлап та, шулай икән шул!.. Әмма Салих әфәнденең моны ничектер балаларча сөенеп әйтүе миңа тагы да хикмәтлерәк булып тоелды. Мин ирексездән аңа борылып карадым, ә ул, шуны көткәндәй, күзләрен тутырып миңа карап тора!... Бер генә секундка икебез дә уңайсызланып калгандай булдык. Аннары ул тыйнак кына:

— Инде тыңлагыз! — диде, уйнарга җыенып.

Ул, утырган җиреннән турая биреп, башын күтәрә төште, югары карап, аз гына уйланып торды һәм бер иңбашын сәер генә селкетеп куйды да кулларын клавишлар өстенә салды. Мин шунда ук аның кулларына игътибар иттем — ак, нәфис, җыйнак кына куллар! Бармаклары бик озын да түгел, ләкин ыспай-нечкәләр. Менә ул матур бер хәрәкәт белән кулларын әз генә күтәрә төште дә ашыкмыйча йомшак-җиңел генә итеп уйный да башлады. Кулларына бөтенләй карамый да кебек, акчарлак канатыдай, алар клавишларга тиеп-тиеп кенә алалар төсле, ә шулай да көй кирәк урында көчәеп, кирәк урында гына әкренәеп, өзлексез-тигез генә ага иде.

Менә ул уйнап бетерде, музыка тынды, ә көй — ни гаҗәп! — һаман дәвам итә кебек. Салих әфәнде үзе дә шуңа колак салгандай аз гына тынып торды, аннары кулларын клавишлар өстеннән сак кына алды да җиңел генә сулап:

— Менә шул! — дип куйды.

Аның уенына бәя бирү минем өчен, билгеле, бик читен, бәлки хакым да юктыр әле, тик шуны гына әйтәсем килә: Салих әфәнде бик табигый, бик садә, ихтимал шуңадыр, бик үтемле итеп уйнады. Хәтта тын гына утырган әтием дә әйтмичә кала алмады:

— Күркәм, бик күркәм, Салих әфәнде!

Салих әфәнде исә көлемсерәп кенә, гүя җавапсыз калмас өчен генә:

— Рәхмәт! — диде һәм миңа борыла төшеп, сүзен дәвам иттерде: — һәр музыкант үзенчәрәк уйный, туташ, чөнки көйне дә ул үзенчәрәк ишетә. Шуңа күрә мин сезгә нәкъ менә минем төсле уйнагыз дип куша алмыйм. Ләкин көйне сез дөрес отып алырга тиешсез. Моның өчен башта нотага карап, нота буенча уйнарга кирәк булыр... Менә мин сезгә «Туган тел»нең үзем язган нотасын да китердем.

Ул пианино өстенә куйган төргәген сүтеп, шуннан ноталар чыгарды һәм арадан берсен алып миңа бирде.

— Инде сез уйнап карагыз!

Мин күчебрәк утырдым да ике битлек кенә нотаны алдыма ачып куйдым.

— Ашыкмагыз, башта яхшылап карагыз,— диде Салих әфәнде.

Мин нота билгеләренә күз йөртеп чыктым — көйне «укып» булырлык иде. Инде уйнарга җыенып, кулымны клавишка салгач кына, Салих әфәнде тагын миңа төзәтү ясады:

— Терсәкләрегезне үзегезгә кысмагыз, иркен генә тотыгыз. Менә шулай. Гомумән, уйнаганда иркен, табигый утырырга кирәк.

Моны миңа Маргарита Яковлевна да гел әйтә торган иде, кулныбармакларны ничек итеп дөрес тотарга, дөрес йөртергә — барсын да

күрсәткән иде. Беләм инде, беләм, ә шулай да менә үзем дә сизмәстән терсәкләремне янтыгыма кысам. (Әлеге оялчан кызлар гадәте!) Мин әз генә каушый төштем, башлый алмыйчарак тордым. Салих әфәнде, шуны сизеп, миңа әкрен генә көйләде: «Ля-ля-си-ля-фа-диез...» һәм мин тәвәккәл генә башлап киттем. Көй гади генә, көй бик таныш та, шуңа күрә мин аны бозмыйча-нитмичә диярлек уйнап та чыктым шикелле... Ләкин Салих әфәнде ни өчендер бер сүз дә әйтмәде, тик яңадан игътибар беләнрәк кабатларга кушты. Мин тагын бер кат уйнап чыктым. Шуннан соң гына ул әйтте:

— Болай дөрес кенә уйныйсыз, туташ. Тик көйнең агышына ныграк колак салыгыз. Нәкъ нотада язылганча уйнарга тырышыгыз. Ритмны төгәл саклагыз. Бу сезгә аңлашыламы?

— Аңлашыла, — дидем мин.

— Әлбәттә, күп кабатларга кирәк әле. Киләсе дәрескә хәтле сез инде аны күңелдән уйнарга өйрәнегез. Бу минем сезгә беренче сабагым булсын. Аннары менә нәрсә әйтәсем килә: уйнау техникасын камилләштерү өчен сез иске күнегүләрне дә яңартырга тиешсез. Теге ханым сездән төрле күнегүләрне күп уйнаткандыр, билгеле. Менә шуларны яңадан кабатларга кирәк. Беләсезме, музыкада осталыкка бары көн-төн өзлексез уйнау аркасында гына ирешеп була. Башкача мөмкин түгел... Ә сездә Черни «Этюдлары» юкмы?

— Юк шул, таба алмадым.

— Алайса, мин сезгә аны китерермен. Техниканы баету өчен бик файдалы булачак... Ә хәзер «Туган тел»не тагын бер кат уйнап күрсәтим әле. Әйткәнемчә, миннән күчерү өчен түгел, ә дөрес ишетеп калу өчен... Кай төштә салмак-әкренрәк, кай төштә югарырак-көчлерәк — шуларга игътибар итегез!

...Бөтенләй башка шул!.. Ул уйнаганда көй әйтерсең үзенең иң табигый, иң дөрес яңгырашын таба, — башкача уйнау мөмкин дә түгелдер кебек. Бик ачык, бик төгәл һәм бик җиңел дә шикелле... һәм аның артыннан ук уйнап карыйсы да килә — бәлки нәкъ ул уйнаганча чыгарып булыр иде... Хәер, бу үз-үзеңне алдау гына. Чын музыкантны кабатлап буламы соң?! Аның үзеннән остарак кеше дә моны эшли алмас иде. Шулай да мин яңадан игътибар беләнрәк, каушамыйчарак уйнап чыккач, Салих әфәнде үзе дә канәгатьләнеп калгандай булды:

— Менә күрдегезме! — диде ул, минем өчен куангандай. — Дөресрәк тә, төгәлрәк тә уйнадыгыз бу юлы. Димәк, кулың белән уйнаганны күңелең белән ишетергә генә кирәк икән, туташ!

Юатыр өчен генә әйтсә дә, аның бу сүзләре минем рухымны бердән күтәреп җибәрде. Белмим, бүтән эштә ничектер, әмма музыкада аз гына өметләндерү дә гаять әһәмиятле, чөнки музыкага өйрәнүче өчен үз-үзеңә ышану һава шикелле үк кирәк ул.

Әнә шулай узды безнең беренче дәрес. Салих әфәнде, миңа тагын бер мәртәбә «Туган тел»не яхшы гына өйрәнергә һәм гомумән күнегүләрне ешрак кабатларга кушып, китәр өчен урыныннан торды.

Әтием дә урыныннан торып:

— Салих әфәнде, ашыкмагыз әле, — диде. — Хәзер чәй әзерлиләр. Чәй эчеп китәрсез!

— Рәхмәт, Әхмәтҗан абзый! — диде Салих әфәнде түбәнчелек белән. — Миңа китәргә вакыт.

Әтием яңадан: «Юк, чыннан да» дия башлагач, ул кыстамагыз дигән сыман ике кулын күтәрә төшеп, кабатлап рәхмәтен белдерде дә, миңа борылып, башын иде:

— Хушыгыз, туташ! — Һәм җиңел адымнар белән ишеккә таба юнәлде. Әтием аны озата чыкты.

*
* *

Мин үз бүлмәмә күтәрелдем. Кәефем бик әйбәт иде. Бүгенге дәрес, миңа калса, бик уңышлы үтте. Һәрхәлдә, мин канәгать, бик канәгать!..

Салих әфәнденең бөтен әйткәннәрен аңлавы җиңел иде, һәр әйткәне ничектер үзеннән-үзе күңелгә кереп, хәтергә сеңеп бара иде. Миңа мөгамәләсе дә йомшак-игътибарлы иде — бер генә тапкыр да ул борчылуын яки кәефсезләнүен сиздермәде.

Аннары махсус тыңлап утырган этием дә канәгать калгандыр дип уйлыйм. Салих әфәнде үзен бик әдәпле һәм нәзакәтле тотты ич!.. Әмма юри түгел, ә бик табигый рәвештә — күрәсең, ул үзен шулай тотарга гадәтләнгән инде.

Нәфис кеше!.. Әйе, нәфис, әмма бу нәфислек аның тышкы кыяфәтендә, үз-үзен тотышында гына түгел, эчке дөньясында, табигатендә үк бар булса кирәк — менә шуны сиздем мин бүген... Шул ук вакытта ул үз дәрәҗәсен бик саклый да белә икән. Яшь кенә булса да, этием белән әнә ничек үзен иркен-тигез тотып, хәтта беркадәр өстенлек тә сиздереп сөйләште.

Минем әнием нәсел тикшерергә бик ярата. Ата-анасы, нәсел-ыруына карап, ул кешеләрне гадәттә «затлыга» һәм «затсызга» бүлеп йөртә. Менә мин дә уйлыйм: бу чибәр егетнең эти-әнисе кемнәр икән, нинди гаиләдә, кем кулында үскән ул?.. Берәр хәзрәтнең мәхзүме, зур байның улы, әллә учитель баласымы? Әмма ләкин байныкы да, хәзрәтнеке дә булмаска тиеш, чөнки әнием моны күптән белеп, миңа ул фәлән купецның яки фәлән хәзрәтнең улы дип әйткән булыр иде. Аннары андый гаиләдән чыккан егетнең гади музыкант булып, театрда эшләп йөрүенә ышануы да читенрәк. Әллә берәр бөлгән морзалар нәселеннән микән?.. Юк, булмас, монысына күңелем бөтенләй ышанмый. Хәер, нигә баш ватарга, ни әһәмияте бар моның?.. Кем баласы гына булмасын, Салих әфәнде дөньяга килгәндә үк чын зат иясе булып туган, минемчә... Кыскасы, мин аңа гаҗәпләнәм, сокланам һәм... сөенәм, ни өчен икәнен үзем дә ачык кына белмәстән сөенәм!..

## III

Үтә вакыт. Менә өченче... бишенче, алтынчы дәрес тә үтеп китте. Шулай итеп, безнең дәресләребез билгеле бер эзгә төште. Салих әфәнде атнасына ике мәртәбә вакытыннан бер минут та соңга калмыйча килеп җитә, төгәл ике сәгать минем белән шөгыльләнеп утыра һәм, дәрес беткәч, артык бер минут та тормыйча, китеп тә бара. Әтием бер-ике тапкыр аны дәрестән соң чәйгә калырга да кыстап карады, ләкин ул һаман, «вакытым юк, эшем күп» дигән булып, рәхмәтен әйтеп, калудан баш тартты. Әлбәттә, эше күптер инде, чөнки, оркестрда уйнау өстенә, артистлар белән бергә төрле җирләргә, бигрәк тә казармаларга барып, шундагы концертларга да катнаша икән, әмма шулай да калмавының чын сәбәбе, минемчә, ул гына булмаска тиеш. Миңа калса, Салих әфәнде үзен килеп-китеп йөрүче бер укытучы итеп кенә санаганга күрә, бездә ашап-эчеп утыруны килештермидер, ә бәлки теләми дә торгандыр. Чын сәбәбе шул булса кирәк. Хәер, аның урынында булсам, мин дә бәлки шулай эшләр идем — кеше үз дәрәҗәсен саклый белергә тиеш ич!

Шулай да без әкренләп бер-беребезгә шактый гына ияләштек дияргә ярый. Дәрес вакытында без үзебезне табигыйрәк һәм гадирәк тота башладык. Мин инде артык каушамыйм, юктан да кызарырга тормыйм, ә ул үзен иркенрәк тә, тәкәллефсезрәк тә хис итә шикелле... Аңардагы бу үзгәреш галәмәтен миңа һич көтмәгәндә генә ачык сизәргә туры

килде. Соңгы дәресләрнең берсендә мин «Салих әфәнде» дип нидер әйтә башлаган идем, шул чакта ул кисәк кенә мине бүлдерде:

— Туташ, алла хакы өчен сез миңа «әфәнде» дип дәшмәгез әле.

Шактый катгый рәвештә әйтелгәнлектән, ахрысы, мин моңа гаҗәпләнә калдым:

— Нигә, әллә ярамыймы, әллә тыелган сүзме?

— Юк, — диде ул көлемсерәп кенә, — тыю турында декрет чыкканы юк әле... Тик мин үзем аны теләмим.

— Ни өчен?

— Сез күрмисезмени? — диде ул һаман шулай көлемсерәп. — Мин бит «әфәнде» булырга өлгерә алмыйча калган кеше. Соңрак туганмын лабаса!

Чынлап та, ул дөрес әйтә түгелме соң? Әфәнделәр гадәттә дәү, могтәбәр кешеләр була торганнар иде, ә моңа бит юньләп мыек та чыкмаган әле... Һәм мин үзем дә аңа — яшь кенә егеткә «әфәнде» дип дәшүнең әллә ничек сәер, ят булуын тоя идем ич!.. Әмма шул ук вакытта башкача дәшү мөмкин дә түгел иде.

Аз гына аптырап торганнан соң мин кыюсыз гына сорадым:

— Ә ничек дип дәшәргә соң?

— Хәзер, үзегез дә беләсез, бөтен кешегә дә «иптәш» дип дәшәләр, — диде Салих... Салих әфәнде. — Ләкин мин сезгә миңа да шулай дәшегез дип әйтергә җөрьәт итә алмыйм. Әллә ничек килешеп бетмәс кебек, бигрәк тә туташ кешегә. Сез миңа, һич булмаса, «абый» дип дәшә аласыз. Ә «Салих» кына дисәгез, бигрәк тә яхшы.

Дөрестән дә, нигә «абый» дип кенә дәшмәскә? Миннән берничә яшькә олырак ич ул!.. Казан кызлары үзләреннән яшьрәк берәр егетне ошатсалар, аңа да «абыем-җаным» диләр әле. Тик минә әтием яратмас дип куркам. Әллә ни уйлавы бар. «Әфәнде» сүзе кешеләрне бер-берсеннән ераграк тота, ә «абый», киресенчә, якынайта төшә... Юк, мин болай итәрмен: әтием алдында бик эре генә «Салих әфәнде» дип дәшәрмен, икәү генә булганда чын ихластан «Салих абый» диярмен, ә үзем өчен генә ул бары тик «Салих» кына булыр. Бу исем миңа бик ошый, аның үзенә дә бик килешә, шулай булгач, әйдә, «Салих» кына булып калсын ул миңа!

Мактанудан булмасын, безнең укулар хәзергә, шөкер, шактый уңышлы бара. «Туган тел»дән соң мин инде нотага карап «Хәмдия»не, «Асылъяр»ны, «Ямьле Агыйдел буйлары»н һәм «Галиябану»ны чибәр генә уйнарга өйрәндем. «Галиябану»ны Салих (әфәнде түгел, ә Салих!) аеруча ярата икән. Унсигезенче елның язында «Галиябану» драмасы беренче тапкыр Казанда уйналгач, аның көе халык арасына бик тиз таралды. «Галиябану-сылуым, иркәм» дип җырлап йөрмәгән кеше юктыр хәзер... Салих әйтә, әсәрнең уңышын тәэмин иткән, аны яшәткән нәрсә шушы көй, ди. Халык кына тудыра алган шушы көйдә татар кызы белән татар егетенең иң саф, иң пакь, оялчан-инсафлы, әмма бәхетсез мәхәббәтләре искиткеч тирән, күркәм, моңлы булып ачыла, ди. Бер уңайдан ул Галиябану ролендә уйнаган Әшрәф ханым Синаеваны да мактап бетерә алмый. Буе-сыны, тавышы-моңы, нәфислеге-нечкәлеге белән тере Галиябануның нәкъ үзе ул, ди.

Аннары Салих җыр-музыканың, ниһаять, сәхнә әсәрләренә керүен бик өметле, бик зур яңалык дип карый икән. Хәзергә әле халык көйләрен файдаланган, ә тора-бара музыкантлар тарафыннан махсус көйләр язылган сәхнә әсәрләре һичшиксез туачак, ди. Бик ышанып, бик рухланып әйтә ул моны!

Безнең дәресләр теге беренче көндәге тәртип белән бара диярлек. Башта Салих миннән элек өйрәнгән көйне уйнатып карый, аннары үзе берәр яңа көйне уйнап күрсәтә һәм шуны миңа нота буенча кат-кат уйнарга куша. Һәр дәрескә көйнең үз кулы белән язган нотасын китерә.

Әлеге вәгъдә иткән Черни этюдларын да алып килде ул миңа. Бармакларыгыз тик тормасын өчен мин аны сезгә бүләк итәм, диде. Бик файдалы булып чыкты алар минем өчен...

Ике дәрес арасында инде мин ул күрсәтеп киткән көйне бик әйбәтләп өйрәнергә тырышам, шуның өстенә даими күнегүләр рәвешендә әлеге этюдларны һәм бүтән җиңелрәк пьесаларны әледән-әле кабатлый торам. Кыскасы, безнең Сабира әйтмешли, пианиноны иртән дә дыңгырдатам, кич тә дыңгырдатам. Тик шуңа түзеп, тыңлап утыручы гына юк.

Салих (Салих абыем!) мине дәрес саен диярлек мактый. Юри түгел, юатыр өчен генә түгел, ә чынлап мактый бит, әхри! (бу да Сабира сүзе). «Сезнең слух бик әйбәт икән, ди, сез бик тиз отасыз һәм дөрес уйныйсыз, ди, сез, туташ, музыка өчен генә яратылгансыз», ди бит хәтта! Мин үзем башта моңа бик ук ышанып та бетмәдем. «Туташ» булганга күрә генә мактый торгандыр әле дип уйладым. Ләкин тора-бара үзем дә сизә башладым: минем уйнавым чынлап та көннән-көн яхшыра, шомара бара иде. Бәлки бу минем «кабилиятемнән» киләдер, ә бәлки Салих кебек оста музыкант, чибәр егет өйрәткәнгә күрәдер... Мин бит инде аңа булдыксыз яки ялкау бер кызый-шәкерт кенә булып күренергә һич тә теләмим. (Тәүбә! — әйттем исә кайттым.)

...Әмма Салихның үзе кебек уйнау... юк, бу кадәресе юк әле, юк... Үткән дәрестә ул, дәртләнеп китепме, тоташтан берничә халык көйләрен уйнап күрсәтте: «Хәмдия», «Казан сөлгесе», «Тәфтиләү» — йа хода, ничек итеп уйнады ул аларны!.. Мин хәтта сихерләнүдән курыккандай аңа туры карарга да кыймыйча, тик эчемнән генә: «Уйнасын... уйнасын, туктый гына күрмәсен», дип, бала шикелле теләп кенә утырдым. Бәя бирү минем эшем түгел, кулымнан да килми ул, әмма шуны гына әйтә алам ки, Салих халык көйләрен шундый табигый, шундый йомшак-нәфис итеп уйный менә, әйтерсең ул аларны отып кына алмаган, ә үзе, үз йөрәгендә тудырган... Чын әгәр!.. Һәрхәлдә, бу осталык кына түгел, бу аның халык моңына әверелүе дисәм бер дә хата булмас. Ләкин, һичшиксез, осталык та бар. Мин инде аның кулларын акчарлак канатына охшаткан идем. Ә менә «Эрбет»не уйнаганда шул ук куллар карлыгач очуын хәтерләтеп җибәрде. Нәкъ карлыгач очкандай, аның куллары тигез-җиңел генә йөзеп китә, кыйгачлап кына бер югары күтәрелә, бер түбән төшә. Әйе, кодрәтле куллар!

Иң ахырдан ул «Тәфтиләү»не уйнады... Әллә көй үзе, әллә аның уйнавы шул кадәр бәгырьгә төшә, шул кадәр җанны ләззәтле газапка дучар итә ки,— моны телдән аңлату һич мөмкин түгел, ишетергә, бары тик ишетергә генә кирәк! Бу көйгә хәзер Тукай сүзләрен җырлыйлар. Тукайның зарын, ачы язмышын...

> Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы,
> Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы

Салих уйнап бетергәч, читтә генә тыңлап утырган әтием дә, ир кеше, нык кеше булуына карамастан, тиз генә телгә килә алмыйча торды. Тик бераздан гына карлыга төшкән тавыш белән:

— Рәхмәт, Салих әфәнде! — дип куйды.— Тәмам эреттегез карт күңелне, рәхмәт сезгә!

Салих артына борылмыйча гына башын игәндәй итте, ләкин кайтарып бер сүз дә әйтмәде. Мактаганны яратып та бетерми, ахрысы... һәрхәлдә, аның бу игътибарсызлыгына минем әз генә эчем дә пошып куйды.

Шушы көннән соң Салих минем күңелемне һәм уемны үзенә тагы да ныграк бәйләде. Мин аның турында күп уйланам, ничектер менә бик кирәген, бик чынын гына беләсем килә: кем ул, нинди кеше асылда? Болай бит ул гади бер музыкант кына, мине укытып йөрүче чибәр бер егет кенә, әмма сизәм — акылдан бигрәк йөрәгем белән сизәм: зур талант, зур бер кодрәт булырга тиеш аңарда. Уйнавыннан гына түгел,

ә бөтен кыяфәтеннән — йөзеннән, күзләреннән, хәтта сүзләреннән сизәм кебек. Мондый камил килеш-килбәтле кеше буш булмаска тиеш, минемчә... Әллә ялгышам микән, ходаем?..

Әнә шулай уйландыра, борчый, тарта мине Салих «әфәнде»!.. Шул ул вакытта мин аңа шактый гына иянләшеп тә өлгердем инде. Җилгәнен гел көтеп кенә торам. Оятрак булса да яшерә алмыйм — аның янымда утыруын тою, тавышын ишетү, ак-матур кулларын күрү минем өчен тансык, тансык кына түгел, күңелле-рәхәт!.. Әлбәттә, мин моны үзем генә беләм, Салихның үзенә берәр төрле сиздерү юк, аллам сакласын!.. Киресенчә, еш кына аның алдында оялам-кызарам да әле мин...

Ә менә Салих үзе миңа ничек карый икән, ни уйлый икән минем турыда?.. Гомумән, нәрсә хис итә икән ул мине күргәндә, минем... янымда утырганда?.. Менә шуны беләсе иде ничек тә!.. Болай бик игътибарлы ул миңа, әдәпле, нәзакәтле, гел «туташ, туташ» дип кенә тора. Ә нинди рәк туташ? — хикмәт менә шунда ич! Бары әдәп йөзеннән (бигрәктә әтием алдында), телдән генә әйтелә торган «туташ»мы, әллә булмаса аның өчен... интересный туташмы? Гаеп итмәгез, бик тә шуны беләсем килә минем!..

Бүген дәрес көне — ул киләсе көн. Иртән күземне ачып җибәргәч тә шул исемә төште. Мин куанычымнан елмайдым һәм... уйландым. Гаҗәп, ул искә төшү белән күңелдә ниндидер бер җыр-моң туган кебек була. Нидән бу, аның музыкант булуыннан киләме, әллә ул үзе музыканы хәтерләтәме?.. Буламы икән соң күңелдә музыка тудырырлык кешеләр?! Аннары бүлмә эче дә бүген, бәйрәм иртәседәй, гадәттәгедән яктырак кебек. Бусы да миңа нигәдер сәер тоелды. Күтәрелебрәк тәрәзәдән карасам, тышта кар яуган икән ләбаса! Беренче кар, тансык кар!.. Менә ни өчен дөнья бердән яктырып та, чистарып та киткән икән! Быел, әйтергә кирәк, караңгы көз нишләптер бик озакка сузылган иде. Ноябрь узды, ә кар һаман төшми дә төшми. Урамнар пычрак, чокыр-чакырларда су, өйләр, коймалар гел юеш... Бик туйдыра, бик күңелсез була икән ул кыш үз вакытында килми торса.

Юк, учлап карамыйча ярамый иде бу беренче карны! Тиз генә түбән төштем дә иңемә шәл генә салып, аягыма сай галошлар гына эләктереп, ишегалдына чыктым. Сабира болдырдан капкага бара торган юлны көрәп тә куйган икән инде, әмма калган җир ак киез җәйгәндәй чип-чиста тора. Бер эз төшмәгән кар өстеннән атлап, мин бакча буена таба киттем. Азрак баргач та иелеп, мамыктай карны ике куллап учыма алдым, кая, нәрсәгә атыйм икән дип, кысып-кысып йомарлый башладым, ә ул, карны әйтәм, укмашмый гына бит! Коры, таралып бара. Димәк, эреми торган кар, китмәскә килгән кар!.. Көне дә шактый салкын икән — мин моны бигрәк тә галошларым аша сизеп алдым. Ә һавасы нинди тагын, һавасы!.. Сулаганда күкрәк үзеннән-үзе киңәеп бара... Әйбәт! Я, ак кыш, пакь кыш, төкле аякларың белән кил инде булмаса!

Шул чакта өй ишегеннән әнием кычкырды:

— Гөләндәм, кер тизрәк!

Мин тәпиләрен өшеткән песи шикелле сак-сак кына басып өйгә ашыктым. Әнием мине тиргәп каршы алды:

— Шыр тиле, бер кат күлмәктән генә чыгалармыни, салкын тидерсәң соң?!.

Ул кадәресен уйлап тормаганмын шул. Хәер, әллә ни өшемәдем дә, берни булмас әле, алла бирсә!.. Аннары кәефем бик әйбәт ич минем, ә кәефе әйбәт кешегә салкын тимәскә тиеш, әнием-бәгырем!

Чәйдән соң озак кына пианинода музыцировать итеп утырдым. (Маргарита Яковлевна шулай дип әйтергә ярата торган иде.) Башта, билгеле, Салих өйрәткән көйләрне уйнап чыктым. Ахырдан бармаклар өчен генә, бер дә иренмичә, төрле күнегүләр ясадым. Шактый ялыктыргыч эш, ләкин шунсыз оста уйнаучы булам димә.

Төшке аштан соң мин үз бүлмәмдә китап укыган булып, асылда исә Салих килер вакыт җиткәнне көтеп утырдым. Декабрь көне бик кыска, сәгать өчтән үк инде тәрәзәләргә эңгер-меңгер иңә башлый, ә ул биштә генә килергә тиеш әле. Ничек кенә үткәреп җибәрергә бу вакытны?.. Минутларны санап дигәндәй көтәм, ә үзем килер сәгате якынлаша барган саен тынычсызлана, хәтта дулкынлана да башлыйм. Гаҗәп, һаман әле мин аның белән очрашуга күнегеп житә алмыйм. Нидән бу?.. Әйткәнемчә, мин бит инде аңа шактый гына ияләштем дә, ул үзе дә минем белән бик гади, бик тыйнак тота үзен, шулай булгач, аның килепкитүләренә гадәти бер нәрсә итеп кенә карарга кирәк иде. Ләкин юк, карый алмыйм, киресенчә, аны күбрәк күргән саен минем әлеге хәлем (дулкынланып көтүем) көчәя генә бара. Бу мине гаҗәпләндерә дә һәм борчый да. Моның серен аңламыйм һәм аңларга куркам да шикелле.

Сәгать биш тулгач та мин залга төштем, ләкин Салих килмәгән иде әле. Беренче мәртәбә кичегүе... Әтием, унлы лампаның яктысы гына житмәгәч, тәрәзә төбенә шәм яндырып куеп, үзенең креслосында гәзитә укып утыра иде. Сары кәгазьгә начар гына басылган әллә «Эш», әллә «Эшче» гәзитәсе шунда. Хәзерге гәзитәләрне белеп тә бетерә алмассың — үзләре дә, исемнәре дә гел үзгәреп кенә тора. Соңгы ел-ел ярым эчендә аларның ниндиләре генә чыкмады. Күбесе онытылды да инде... Ләкин әтием өчен гәзитә — сулый торган һавасы диярсең, кулына төшкән берсен карап-укып бара. Хәер, аның хәзер бүтән эше дә юк. Сәүдәләр бетте, магазиннар ябылды. Доверенный чагында көн-төн чапкан кеше хәзер өендә тик кенә утырырга мәҗбүр... Нишләсен ул?.. Иртәнге якта базар тирәсеннән бер әйләнеп керә инде (базар бар, базарның беткәне юк), көн саен диярлек өйлә яки ястү намазына кереп чыга (мәчет күршедә генә), ә калган вакытын менә шулай гәзитәләр карап, Салих килгән көнне безне тыңлап үткәрә. Шуны әйтергә кирәк, әтием минем сабыр табигатьле аз сүзле кеше. Бөтен уе-фикере үз эчендә генә — зарланырга яки уфтанырга бер дә яратмый. Гүя ул сабыр гына нидер көтә, нәрсәгәдер ышанып тора. Шулай ук үзе кебек эшсез калып, базар таптаучылар белән дә артык аралашмый булса кирәк. (Һәм бик дөрес итә, минемчә.) Бердәнбер сөйләшкән кешесе — әнием, әнием белән икәүдәникәү генә үз бүлмәләрендә кичләрен шыпырт кына сөйләшәләр. Шуңа күрә мин дә бернәрсә дә белмим. Начармы безнең хәлебез, әллә түзәрлекме — һич тә хәбәрем юк. Тормышыбыз искечәрәк бара, элекке кебек мул тормасак та, әллә ни аптырамыйбыз да шикелле... Һәрхәлдә, тамагыбыз тук, өстебез бөтен. Шулай да вакыт-вакыт минем эчем бик поша, бик беләсем килә: ни көтә безне, ни булыр безгә?! Әниемнән бу хакта сорап та караганым бар, ләкин ул да мине балага санагандай кырт кисеп кенә әйтә:

— Син әнә укуыңны бел, башкасын тикшермә! Берни дә булмас, алла бирсә!

Әнием шулай дигәч, мин тынычланган кебек тә булам, ләкин күпмегә?.. Заман искиткеч тиз үзгәрә, иртәгә ни буласын мин түгел, чегән марҗасы да әйтеп бирә алмас!

...Менә парадный ишектә кыңгырау тавышы ишетелде. Мин хәтта урынымнан кузгала яздым, ләкин нәкъ вакытында тыелып калдым — әтием алдында аны каршыларга чыгу ярыймы соң?!. Сабира, ишетеп, тиз генә ишеккә китте. Ә бераздан кулларын угалап залга ул... Салих килеп керде. Суыктан яңаклары да кызара төшкән, күзләре дә гадәттәгедән ныграк елтырый... Өстендә бик ыспай утырган кара тужурка, тужурка астыннан кигән ак күлмәгенең яка чите күренеп тора. Ул әүвәл әтием янына барып, аның белән исәнләште. Әтием, урыныннан торып, аны ачык йөз белән каршы алды. Гадәттәге соравын бирде:

— Я, Салих әфәнде, кәефләрегез ничек, саулык-сәламәтлек?

— Рәхмәт, Әхмәтҗан абзый, хәзергә зарланырлык түгел.

— Бик хуп. Бирсен алла!.. Соң, дөньяда ниләр бар?
— Дөньядамы?.. Дөньяда хөррият бар, — диде Салих елмаеп кына.
— Шөкер, анысын күрдек. Тагын ниләр бар?
— Ә сезгә ни кирәк соң?..
— Миңамы?... Миңа, мәсәлән, тоз кирәк,— диде әтием дә көлеп.
— Тоз?!. Менә анысын миннән сорамагыз инде, Әхмәтҗан абзый. Тоз эзләп йөрергә туры килгәне юк. Хәер,ападан бер ишетеп калган идем: базарда, имеш, чи тиреләрдән селкеп җыйган нафталинлы тоз саталар дип... Дөрестерме-юкмы, ул кадәресен әйтә алмыйм.
— Дөрес, Салих әфәнде... тире складында эшләүчеләр андый тозны да саттылар. Тоз хәзер иң кадерле нигъмәт!
— Ашка ярамыйдыр ич ул?
— Ык кына юып киптерсәң, ярый диләр. Ләкин аны сатучыларны да тотып япканнар булса кирәк.
— Менә, Әхмәтҗан абзый, дөньяда ниләр барын сез миңа караганда күбрәк беләсез икән.
— Чүп-чарын, Салих әфәнде, вак-төяген генә...
— Зуррагы нәрсә соң?
— Зуррагын сездән ишетәсе килгән иде. Мәсәлән, кайчан бу дөнья үзенең эзенә төшәр икән?
— Ә ул бит нәкъ үз эзеннән бара, Әхмәтҗан абзый, — диде Салих, гүя ваемсыз гына итеп. — Нигә, әллә дөрес түгелме?
Әтием кычкырып көлгән булды:
— Шук кеше сез, Салих әфәнде, яшәве җиңелдер сезгә!
Салихның йөзе шунда ук җитдиләнде, күзләре дә кинәт уйчанланды, ләкин ул артык бер сүз дә әйтмәде. Менә ничә сынаганым бар: әтием белән Салихның сөйләшүе гел шулай, ни аллага, ни муллага дигәндәй, бер нәтиҗәсез бетә дә куя. Башта бу миңа бик сәер тоела иде, борчып та куйгалый иде, ләкин тора-бара аңлагандай булдым: Салих асылда җитди мәсьәләләр турында акыл сатарга, күп сөйләргә яратмый торган кеше булса кирәк. Инде сүз чыга калса да, әнә шулай ярым шаяртып, көлкегә әйләндереп бетерергә тырыша. Нидән бу, табигате шундыйга күрәме, әллә яшьлегеннән киләме? Ә бәлки әтием белән зур нәрсәләр турында җәелеп сөйләшүне кирәксез санайдыр. Ләкин бит әтием дә тел бистәсе түгел, бик чамалап кына сөйләшә торган кеше.
Салих минем яныма килде. Баш иеп кенә:
— Кичерегез, туташ, бүген соңгарак калдым, — диде.
— Зарар юк, — дидем мин.
Ул кулы белән генә утырырга ишарә ясады. Пианино каршына икебез дә утыргач, башта:
— Кәефегез ничек? — дип сорады.
— Рәхмәт, начар түгел, — дидем мин.
— Яхшы, алайса... Беләсезме, музыка бит ул бик бәйләнчек нәрсә, кайчан йоклаганда да колактан китмичә йөдәтә.
— Шулай укмыни?
— Ихлас. Минем үзем белән еш кына шулай булгалый. Дөрес, миңа күп уйнарга да туры килә... Хуш, инде башласак та ярый торгандыр.
— Мөмкин... Нәрсәдән? — дидем мин, уйнарга әзерләнеп.
— Элек өйрәнгәннәрне кабатлагыз.
— Кайсын?
— Кайсы да ярый... Кайсысын күңелегез тели.
Әйе, күңел дигәнең төрле чагында музыканың төрлесен тели. Мин «Хәмдия»не уйный башладым. Ләкин Салих мине шунда ук туктатты:
— Сез, туташ, минем өчен уйнамагыз. Үзегез, үз ләззәтегез өчен уйнагыз. Җаныгыз кушканча — иркен, хөр, табигый итеп... Ә мин — юк, мин читтән генә тыңлаучы!

Ул хәтта бер читкәрәк тартылып та утырды. Мин яңадан башладым. Үзем теләгәнчә һәм үзем тойганча итеп. Бер дә тарсынмыйча, иркен, табигый итеп... Әмма ләкин барыбер аның тыңлавын сизеп торам — сизмичә мөмкин дә түгел. Тыңлавын гына түгел, миңа төбәлеп карап утыруын да сизеп торам. Хәтта уйнавымны тыңлый-тыңлый минем хакта нидер уйлавын да тоям шикелле... Ул һәр вакытта миңа нидер уйлап карый, нидер уйлап... Баштарак мин аның күксел-зәңгәр күзләренең бу карашыннан бик уңайсызлана идем, ә хәзер юк, хәзер уңайсызланмыйм, киресенчә, шулай каравын телим, шулай караса миңа рәхәтрәк кебек, йөрәгемә ниндидер якты моң тула кебек...

Мин уйнап бетердем. Яхшы уйнадым мин бу юлы. Салих та аз гына дәшми торганнан соң шулай диде, «әйбәт уйнадыгыз, туташ!» — диде.

Уйнау да илһам эше. Бер дәртләнгәч, бер, ничек дим, иң кирәк кылын тотып алгач, музыка үзеннән-үзе бик табигый, бик җиңел уйнала. Минем белән дә шулайрак булды — моңарчы өйрәнгән көйләрнең барысын да җиңел-дәртле уйнап чыктым.

Шуннан соң Салих:

— Болай булгач, туташ, без сезнең белән берәр катлаулырак көйне дә өйрәнә алабыз,— диде. Аз гына уйланып торды да: Рөхсәт итегез әле, — дип, минем урынга күчеп утырды.

— Мин сезгә хәзер «Агыйдел каты ага» көен уйнап күрсәтәм. Ишеткәнегез бардыр, менә ул!..

Уйный башлады һәм әкрен генә сүзләрен дә әйтеп барды:

Агыйделдә йөрсәң иде
Камыштан кимә үреп,
Былбыл булып, гөлгә кунып
Сөйләшсәң иде күреп.

Агыйдел буенда
Җәяү йөрисем килә.
Сөя микән, сөйми микән,
Шуны беләсем килә.

Икенче тапкыр сүзләрен әйтмичә генә уйнап чыкты.

— Рәхим итегез! — диде ул, яңадан миңа урынымны биреп.

Мин утыргач, һәр вакыттагыча алдан язып китергән нотасын алдыма ачып куйды. Шуңа карап, кыюсыз гына, әкрен генә уйный башладым. Билгеле, беренче тапкырда рәтле-башлы чыкмый инде ул. Нотага күз иярләшеп җитмәгән, еш кына төртелеп тә каласың, шунлыктан кирәксез пауза да ясала, урынсыз кабатлану да була. Ләкин Салих мондый вакытта бик сабыр тыңлый, ризасызлык-фәлән һич күрсәтми, тик тагын һәм тагын кабатларга гына куша. Уйнаганда миңа бу җирендә анданте (салмаграк), бу төшендә аллегро (кызурак) дип әйтеп тә тора. Инде эзенә төшә башлагач, менә шулай дөрес, яхшы, дип рухландырып та куя.

Иң ахырдан ул миңа көлемсерәп кенә:

— Сез бу каты аккан Агыйделне дә җиңел кичәрсез, — диде. — Ләкин...

Һәм менә шуннан соң һич тә көтелмәгән искиткеч бер хәл булды: сүзен әйтеп бетермичә, ул нотаны үзенә тарта төште дә кулындагы карандашы белән ике юл арасына тиз-тиз генә нидер сызгалады. Аннары миңа шуны этәреп:

— Ләкин нотаның менә бу җирләренә аеруча игътибар итегез, — диде. — Күрәсезме?

Башта ук мин ул күрсәткән сызыкларның нота билгеләре булмыйча, язу икәнен ачык күрсәм дә, берничә секунд күзләремә ышанмыйчарак тордым: язу... нинди язу бу?.. Тик шуннан соң гына укый алдым. Юллар арасына: «Миңа сезнең белән сөйләшергә кирәк, кайчан, кайда мин

сезне күрә алам?» дип язылган иде... Моны укыгач, мин шул кадәр аптырап, каушап, югалып калдым ки, кинәт зиһенем таралып, күз алларым томанланып киткәндәй булды. Бер мәлгә хәтта сулыш алудан да туктадым. Ходаем, бу ни бу?!. Ничек җөрьәт иткән ул?.. Әтием карап утыра ич!.. Әгәр сизә калса?! Ләкин болай өнсез калу ярамый иде, болай берни әйтә алмыйча утыру үзе бик хәтәр иде. Әтиемнең мотлака нидер сизүе мөмкин. Шуңа күрә мин нота дәфтәренә иелдем, күз йөрткән булдым, Салихтан хәтта: «Шушы җиреме?» — дип сораган да булдым. «Әйе, әйе, нәкъ шул җире»,— диде ул, кулындагы карандашын миңа биреп... Бу — җавап көтәм дигән сүз иде. Йа ходаІ.. Мин тагы да иелә төшеп, «ярый, яхшы, онытмам» дигән булып, тиз генә сызгаладым: «Миңа болай язмагыз, әтием сизәр!»

Ул минем сүзләрне шунда ук укып та барды, ләкин бик тыныч калды. Тик бер иңбашын сәер генә сикертеп куйды. Һәм шунда ук:

— Алайса, туташ, бүгенге дәрес шушының белән тәмам, — диде дә урыныннан торды. Әтием янына барып, берни булмагандай, аның белән сөйләшә башлады.

— Әхмәтҗан абзый, безне тыңлап утыру сезнең өчен күңелсездер инде. Һаман бер үк нәрсәләрне кабатлыйбыз да кабатлыйбыз.

Әтием дә урыныннан торды:

— Алай димәгез, Салих әфәнде! Сезнең дәресләрегез минем өчен дә кызыклы, бик мәмнүн булып тыңлап утырам. Ләкин әйтегезче, шәкертегездән сез канәгатьме?

— Әлбәттә!

Ә мин шул арада бөтен ноталарымны җыеп алдым да мыштым гына залдан чыгып та киттем. Үз бүлмәмә менеп, бераз тын алгач, Салихның язган сүзләрен яңадан укып чыктым. Берничә кат... Аның кулын мин беренче мәртәбә күрәм әле... Саклаганда да ярар иде, ләкин юк, бетерергә, тизрәк бетерергә кирәк! Һәм резинка белән аларның барысын да (үзем язганнарны да) тиз генә чистартып бетердем.

*
* *

Әйтәсе дә юк, Салихның язганнары минем бөтен җан тынычлыгымны алды. Үземә урын тапмыйм, ни уйларга да белмим һәм торып-торып хәйран калам: моңарчы үзен шул кадәр тыйнак тоткан, һични сиздермәгән укытучым дәрес вакытында миңа әнә ни язды бит! Курыкмыйча, әтиемнең карап утыруына да игътибар итмичә! Нәрсә бу — кыюлыкмы, әллә... юләрлекме?.. Моның минем өчен дә, үзе өчен дә никадәр хәтәр икәнен ул белергә тиеш иде ләбаса!.. Ләкин, күпме генә гаҗәпләнсәм дә, мин аңа үпкәли алмыйм, юк, һич тә үпкәли алмыйм... Мин сизәм, мондый тәвәккәллек өчен житди сәбәп булырга тиеш, әлбәттә, шулай, уен эш түгел ич бу!.. Дөрес, ул алдан записка язып, шуны безнең Сабира аша тапшыра алган булыр иде. (Сабира бит аңа гел генә ишек ача.) Ләкин Сабирага да ышанып бетмәгән, күрәсең... Димәк, нотага язудан башка чарасы да калмаган инде.

Әмма иң аптыратканы бу түгел әле. Иң аптыратканы — ул минем белән кайдадыр читтә, аулакта гына сөйләшергә тели! Нигә, ни өчен? Ни әйтмәкче була ул миңа? Бик кирәкле сүзе бар микәнни, ходаем?!. Нәрсә икән соң ул? Шуны уйлап, шуны беләсем килеп күпме баш ватмадым, күпме борчылмадым мин... Хәтта йокыдан калдым, ашау-эчүдән, әнием сизә күрмәсен дип курка да башладым. (Шөкер, эш аңа хәтле барып житмәде.) Аннары вакыт узып, бераз тынычлана төшкәч, үз-үземә: туктале, җаный, ник син бу хәтле өзгәләнәсең, дидем. Исең киткән икән! Салих укытучым гына түгел, егет кеше дә бит әле. Ә егет

кешенең кыз кешегә нәрсә әйтәсе булмас! Мәсәлән, менә минем кебек туташка? Чынлабрак уйлаганда моны күтәргә дә була иде ич! Ихлас! Аның һәр вакытта миңа үтә игътибарлы булуы, йомшак мөгамәләсе, дәшүләре, ә вакыт-вакыт уйчан-серле генә карап та куюлары — болар барысы да нидер аңлата түгелме соң?!. Ә бәлки әле аның күңелендә миңа карата үзенә бертөрле хис тә яшидер яки уяна башлагандыр. Мин моны, һәрбер кыз шикелле, үз теләгемнән, үз өметләремнән чыгып кына әйтмим — мин егет кешенең йөрәк тибешен күңелем белән сизенеп әйтәм. Бик ихтимал, Салих та минем йөрәк тибешен сизгәндер... Ике якта да туган шушы сизенүләр... мәхәббәтнең беренче яралгысы, беренче чаткысы түгелме соң? Шулай башлана шикелле, ходаем, шулай башлана шикелле...

Ләкин... җитәр бу турыда, җитәр! Мин, тиле, һәр вакыт шулай бик тирән керә башлыйм. Ярамый болай. Әниләр әйтмешли, киләчәккә тапшырыйк. Безнең очрашачак көннәребез күп ич әле!

Тик күңелемдә бер генә төер калды: мин үземнең җавабым белән аның кәефен бозмадым микән? Ни уйлады икән ул?.. Хәер, монысын да киләчәккә калдырыйк, иң якын киләчәккә!

## IV

Бу килүендә дә ул һәр вакыттагыча җыйнак һәм пөхтә иде. Әмма бөтен ягы да килгән кешенең дә аеруча күзгә ташлана торган берәр нәрсәсе була икән. Салихта исә бу — аның күзләре һәм бик чиста ак маңгае... Ишектән килеп керүенә иң элек менә шул ак маңгае белән урман күледәй зәңгәр күзләре минем игътибарымны биләп ала иде. Шуннан соң гына мин аның башка якларын да күрә башлыйм.

Бу юлы мин аны шактый хәвефләнеп, эчке бер борчылу белән каршы алдым, билгеле. Ни дияр ул миңа, ничегрәк итеп карар, үпкәсен сиздерерме-юкмы? Ләкин аның кәефен чамалау бик читен иде. Гадәттәгечә ул үзен бик тигез, бик тыныч тота. Эчендәгесен һич сиздерми. Күрәсең, табигате шундыйдыр инде, көләр, көлдерер, әмма бервакытта да караңгы чырай күрсәтмәс.

Дәресне башлар алдыннан ул миңа беренче мәртәбә, туташ димичә, исемем белән дәште:

— Гөләндәм, утырыгыз! — диде.

Бик гади генә, шәкертенә дәшкән төсле генә итеп әйтте ул моны, ә шулай да минем өчен бу бәлзәм йоттырган шикелле булды. Димәк, миңа үпкәсе юк! Үпкәсе булса, бик әдәп белән, әмма коры гына итеп «туташ» дияр иде. Һәрхәлдә, нәкъ менә бүген беренче мәртәбә исемемне атамас иде.

Әйтергә кирәк, безнең бүгенге дәрес тә гадәттәгедән башкачарак үтте. Салих миңа яңа көй өйрәтеп тормады, (ахрысы, язып китергән нотасы булмагандыр), ә искеләрне кабатлату белән генә чикләнде. Мин аларның барысын да уйнап чыктым. Ул бер сүз дәшмичә тыңлап утырды, соңыннан төзәтү-мазар да ясамады, тик иң ахырдан сәер генә бер сорау бирде:

— Әйтегез әле, уйнаган чакта сез ни күрәсез?

Мин аптырап калдым: ни ишетәсез түгел, ә ни күрәсез?!. Ул аңлатырга тырышты:

— Менә сез «Агыйдел»не уйнадыгыз. Шул чакта сезнең күз алдыгызга берәр төрле күренеш килмәдеме?

— Юк шикелле... Ә нәрсә килергә мөмкин?

— Мәсәлән, ярларына сыя алмагандай бөтерелеп, кызу гына аккан Идел үзе... Аргы якта, киң тугайда киез эшләпә кигән агайлар тезелешеп печән чабалар... Ә бирге якта, су читендә ап-ак казлар канат кагына.

Бу шул кадәр сәер-кызык булып тоелды — мин хәтта көлеп җибәрдем.

— Ни өчен казлар, ни өчен кер чайкаучы кызлар түгел?

— Бу да бик табигый, — диде ул җанланып. — Һәрхәлдә, шул көй тәэсирендә ни дә булса күз алдыгызга килергә тиеш иде.

— Алай икән!.. Ә сезгә киләме соң?

— Һәр вакытта! Нинди генә көйне уйнамыйм яки тыңламыйм, шунда ук минем хыялымда берәр күренеш тумыйча калмый. Мисал өчен «Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем» дигән гади генә авыл көен алыйк. Менә шул көйне ишеттем исә, минем күз алдыма гел генә гаҗәеп бер күренеш килә: авыл, кояш баеп барган вакыт, көтү кайткан, сөт исе аңкый, кызлар, яшь киленнәр ак чиләкләренә тыныч кына кушәп торган сыерларын савалар. Ә шул чакта ындыр артыннан бер егет йөгәнен иңенә салып, авыз эченнән генә әлеге «Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем»не көйләп, батып барган кояшка карап, кайдадыр утлап йөргән атын эзләп китеп бара... Менә нинди күренеш!

— Кызык! — дидем мин дә гаҗәпләнеп. — Бик җанлы күренеш, әллә үзегез уйлап чыгарасызмы?

— Юк, туташ, бу — музыканың бер кодрәте! — диде Салих, җитди генә.— Уй-хисләрне генә түгел, хыялларны да уята ул! — Аннары аз гына уйланып өстәде:— Миңа калса, композиторлар да музыка язган чакта аны ишетеп кенә калмыйча, әнә шулай күрә дә торганнардыр төсле.

Шунда ук минем күңелгә «ә сез кайдан беләсез?» дигән сорау килде, ләкин мин аны әйтеп тормадым, билгеле. Я хәтерен калдырырмын... Ул бит үзе дә чын музыкант, аның шулай уйлавы гаҗәпмени?!

Әтиемә дә кызык тоелды, ахрысы — ул да сүзгә кушылды:

— Салих әфәнде, сез тасвир иткән гүзәл манзара кайчандыр күргәнне искә төшерү генә түгелме соң?

— Дөрес, музыка беренче нәүбәттә нәрсәнедер искә төшерә, күз алдына китерә, сагындыра, әмма аның, ягъни музыканың, тәэсире моның белән генә чикләнми: ул һич күрмәгән-белмәгән җирләрне, илләрне, кешеләрне дә хыялда тудыра. Мәсәлән, сезнең казакъ даласында йөргәнегез бармы?

— Юк, Салих әфәнде, туры килгәне юк.

— Минем дә әле күргәнем юк. Ләкин Мөхәммәдия мәдрәсәсендә укучы казакъ шәкерте моңаеп, үзенең җырын суза башласа, минем күз алдыма шунда ук казакъның чиксез даласы, ак тирмәләре, сибелеп, көтү-көтү йөргән җылкылары килә дә баса! Мин хәтта шул җылкыларның җил каерган озын ялларын да күргәндәй булам. Ышанасызмы?

— Ышанам, Салих әфәнде! Була андый хәл, була!

— Мин моның бик күп мисалларын китерә алыр идем, ләкин җитеп торыр хәзергә,— диде Салих һәм, тынып, нидер уйланып калды.

Аның үз кәефе дә бүген сәер генә иде. Нәрсәдер җитмиме аңа, нидер борчыймы аны, һәрхәлдә, күңеле-хыялы белән каядыр читтә, еракта йөри иде кебек.

Шулай тынып, уйланып торганнан соң, ул миңа Шопенны уйнарга кушты.

— Нәрсәсен? — дип сорадым мин.

— Берәр җиңелрәген. Мәсәлән, прелюдияләреннән берәрсен! — диде ул.

Ноталар арасыннан Шопенны табып, шуннан бер прелюдияне ашыкмыйча гына уйный башладым. Ул башын игән килеш кенә тыңлап утырды. Үземә калса, әйбәт кенә уйнап чыктым. Ә ул, музыка тәмам тынгач кына исенә килгәндәй, тирән сулап әйтеп куйды:

— Әнә нинди бит ул!.. Гүзәл, нәфис, әйтерсең йөрәкне ефәккә урый!.. Юк, сезгә болардан һич тә аерылырга ярамый. Уйнагыз сез аларны, күбрәк уйнагыз! Шунсыз чын музыкант булу мөмкин дә түгел, туташ!

Этием тагын үз сүзен кыстырды:

— Ә шулай да үзебезнеке җанга якынрак бит, Салих әфәнде!

— Әлбәттә. Яхшымы-начармы, үзебезнеке безгә ана сөте белән кергән, Әхмәтҗан абзый! Безнең бөтен моңыбыз, дәртебез, юанычыбыз халык көйләрендә. Әмма ләкин дөньяда музыка дигән бер бик борынгы, бик бай сәнгать тә бар бит әле. Менә шул сәнгатьтән без дә азыкланырга тиешбездер инде. Югыйсә, «Әчтүч-Бибкәй кыз» дан ерак китә алмабыз. Шулай бит, Гөләндәм?

Ул әз генә көлемсерәп, миңа сынаган да, якын да иткән төсле итеп карады. Мин ирексездән кызардым, шулай да дәшми калмадым:

— Әйе, Салих әфәнде, мин сезнең белән килешәм, — дидем.

Болай чынлап уйлаганда, аның шулай соравы, минем шулай дип җавап бирүем бик табигый иде һәм бик урынлы да. Ләкин, шуңа карамастан, мин үземнән бер дә канәгать түгел идем. Әдәп кагыйдәсен саклыйм дигән булып, һаман үземне ясалма рәвештә тотарга мәҗбүрмен. (Һич теләмәстән аңа «әфәнде» дим ләбаса!) Шуның өчен үземә ачуым да килә, ләкин этием алдында бүтәнчә булдыра да алмыйм. Ә Салих, билгеле, моны сизә, сизү генә түгел, эченнән бәлки көлә дә торгандыр әле. Үзе ул, әдәп кагыйдәсеннән һич чыкмаса да, безнең араны ничек тә гадиләштерергә тырыша кебек. Бүген исә шул нәрсә аның кыланышында аеруча нык сизелә иде. Менә хәзер дә ул миңа, тик торганнан нидер исенә төшкәндәй:

— Сез, Гөләндәм, җырлый да белә торгансыздыр әле? — диде.

Я, мин ни дип җавап бирергә тиеш инде? Әгәр аның бу сүзендә аз гына көлү яки үртәү кебек нәрсә сизсәм, минем җавабым да бик кыска булыр иде. Ләкин ул моны бер дә шик кузгатмаслык итеп әйтте. Шуңа күрә мин дә сорау белән генә чикләндем:

— Ни өчен алай дип уйлыйсыз?

— Музыкант кеше үзе өчен генә булса да җырларга тиеш, — диде ул.

Ләкин минем җырлый беләм дияргә һич тә исәбем юк иде. Нигә кирәк әле бу? Безнең дәрескә аның ни мөнәсәбәте бар?.. Ләкин этиемнең минем белән мактанасы килде, ахрысы.

— Дөрес әйтәсез, Салих әфәнде, — диде ул, вәкарьлеген саклап кына. — Безнең Гөләндәмне ходай тавыштан да мәхрүм итмәгән. Чибәр генә җырлый ул!

Моны ишеткәч, Салих бөтенләй дәртләнеп китте.

— Ышанам, ышанам! Ягез әле, туташ, без әфәндегезгә дә бер җырлап күрсәтегез булмаса!

Билгеле, минем этиемә ачуым килде, шулай ук Салихның соңгы сүзләре дә күңелемә бер дә ошамады.

— Мин җырчы түгел, — дидем шактый киреләнеп. — Минем чит кеше алдында бервакытта да җырлаганым юк!

— Ә мин чит кеше түгел ич! Хәлфәгез! — диде Салих, ничектер ваемсыз-хәйләкәр генә итеп.

— Ләкин бит сез мине җырчылыкка өйрәтмисез!

— Ә бәлки өйрәтермен дә... Мин бит сизәм — сез җырлый алырга тиешсез! Ягез әле, ягез!

— Зинһар кыстамагыз! — дидем мин ялварып. — Булмый, җырлый алмыйм.

— Менә мин сезгә аккомпонировать итим әле, — диде ул, минем ялваруыма һич тә игътибар итмичә һәм пианино каршысына күчебрәк утырды. — Сез ашыкмагыз, уйлагыз... Иң элек теләгән көегезне искә төшерик.

Лəкин минем һаман əле карышасым килə. Җырлый алуыма ышансам да, карышасым килə. Шул ук вакытта артык тискəреләнүдəн дə куркам — аның гайрəтен үземнəн бөтенлəйгə чигермим дип куркам. Шулай да икеләнə төшебрəк мин:

— Башка вакытка калдырыйк,— дидем.— Бүген əллə ничек, кəефем юграк.

Салих башын борып, бик туры итеп минем күзлəремə карады. «Мин сораганга күрə генə җырлыйсыгыз килми, шулаймы?» дия иде аның кинəт җитдилəнеп киткəн күзлəре. Тəмам какшатты мине аның бу карашы... Җитмəсə, əтием дə əйтеп куйды:

— Кызым, я, я, кыстатма!

Ахырда мин əкрен генə урынымнан торып бастым. Салих исə яңадан уйнарга җыенды һəм берни дə булмагандай йомшак кына сорады:

— Нəрсəне телисез?.. Бəлки «Сибелə чəчəк»не җырларсыз?

— Авыр булмас микəн?

— Карагыз!.. Əмма хатын-кыз тавышына бик туры килə ул. Исеме ук җыр бит! Сибелə чəчəк!.. Чəчəклəрнең җилдəн сибелгəнен күргəнегез бармы?

— Бар, əлбəттə... Безнең бакчадагы чиялəрнең чəчəклəре җиргə апак кар шикелле ява торган иде.

— Минем дə күргəнем бар, тəңкə-тəңкə булып яталар, иеме? Лəкин бу җырда гөлчəчəклəрнең җилдəн сибелүе турында əйтелə. Бичара чəчəклəр!.. Ярый, башлап карыйк булмаса!

...Бармакларын җиңел генə клавишларга тидерде һəм беренче аккордтан соң ук инде «Сибелə чəчəк» минем колагымда гына түгел, күңелемдə дə яңгырый башлады. Хəтта көчле шəраб шикелле кан тамырларым буйлап йөгерде. Җырлыйм, əлбəттə, җырлыйм! Сүзлəре дə тел очымда гына тора, тик аның бер тапкыр уйнап чыкканын гына көтəм.

Уйнап бетергəч, ул миннəн: «Шулай ярыймы»? — дип сорады. Мин баш кына кактым. Ул яңадан башлады, мин тирəн генə бер тын алып, аңа иярдем... Минем җырым бу, җанымны сызландырган моңлы, лəззəтле җырым!

Гөлбакчага керəмсең,
Гөлбакчага керəмсең лə,
Гөл чəчəген өзəмсең?
Өзелгəн гөл чəчəге күк
Аерылуны сизəмсең?
Сибелə чəчəк җиллəр лə искəндə,
Өзелə үзəк ислəремə төшкəндə.

Бу хəтле дə оста аккомпанировать итəр икəн Салих абый! Əйтерсең канатлар өстендə генə күтəреп илтə. Шул ук вакытта ник бер генə тапкыр минем тавышымны басып китсен! Җырның бик сузылган җирендə тынып торган кебек тə була, лəкин нəкъ кирəк чакта гына тагын күтəреп ала.

Мин, үземə калса, тигез-җиңел генə җырлап чыктым. Əмма матурмоңлымы? — бу кадəресен инде миннəн сорамагыз. Хөкемне ул чыгарырга тиеш. Кыстап-кыстап җырлатты ич, тик ни əйтсə дə, турысын гына əйтсен иде! Лəкин ул ни өчендер ашыкмый иде əлс. Җыр тынгач, күпмедер вакыт алдына гына карап, нидер уйланып торды, аннары ашыкмыйча гына миңа таба борылды, яңа күргəндəй, сəер генə бер карап куйды, бары шуннан соң гына елмаеп, бик гади генə итеп:

— Курыккан идегез, менə җырладыгыз ич! — диде.

«Шул гынамы?» дип уйладым мин пошынып, лəкин ашыга төшкəнмен икəн. Аз гына көттереп, ул, ниһаять, əйтте:

— Тавышыгыз, безнеңчə əйтсəк, сопрано, дөресрəге — лирик сопрано икəн. Матур тавыш. Тембры да йомшак, чиста... Лəкин иң əһəмиятлесе,

туташ, сез көйне нечкә хис итеп, тәмен белеп дигәндәй җырлыйсыз. Мактау йөзеннән түгел, ә чын дөресен әйтәм.

— Рәхмәт! — дидем мин, дулкынлануымны сиздермәскә тырышып.

— Тагын берәрне җырламыйсызмы?

— Юк, — дидем мин ашыгып.

Күрәсең, аңардан шундый мактауны ишеткәч, яңадан җырлап күрсәтергә курыкканмындыр инде. Була икән мондый хәл дә! Ләкин ничектер акланырга кирәк иде. Әзрәк хәйләгә керешеп:

— Сез кичерегез инде, — дидем, — бүген минем барасы җирем бар, ашыгам, башка вакытка калдырыйк (Хәер, дөрестән дә, туган апаларга барып кайтырга кирәк иде миңа).

— Яхшы, алайса! — диде Салих. — Ләкин беләсезме, туташ, Сезне иркенрәк урында, мәсәлән, сәхнәдән җырлатып караганда да зарар итмәс иде. Ничек уйлыйсыз?

Мин куркуымнан бары:

— Ни сөйлисез?! — дип кенә әйтә алдым.

Әтием дә бик гаҗәпләнгән булып:

— Сез безнең кызыбызны әллә җырчы да итмәкче буласыз инде, Салих әфәнде? — диде.

— Нигә, Әхмәтҗан абзый,— диде Салих бик тыныч кына,— җырчы булу гаеп эшмени?.. Ходай биргән талант ич ул! Сез үзегез дә туташның чибәр генә җырлавын әйтеп тордыгыз бит әле.

— Анысы болай гына, сезнең өчен генә... Иллә мәгәр Гөләндәмнең кайдадыр, кемнәрдер алдына чыгып җырлавы асла килешә торган эш түгел. Безнең мөселман ни... әдәбенә һич сыймый ул!

— Ник сыймасын! — диде Салих ваемсыз гына. — Мөслимәләр дәртләнеп җырлый, мөселманнар рәхәтләнеп тыңлый — бик табигый нәрсәгә әйләнде бит инде бу хәзер!

— Нинди мөслимәләр? Кайда?.. Ә сез әртискәләрне әйтәсез! Шулай диегез, мөслимәләр димәгез. Бу — икенче мәсьәлә. Аларның кәсепләре шул... Кәсеп ул тамак туйдырыр өчен, ә Гөләндәмгә андый кәсепнең кирәге булмаячак, алла боерган булса! Гаиләдә уйнарлык кына музыка белсә, аңа шул җиткән. Сез инде, Салих әфәнде, аны шуңа гына өйрәтегез! — дип бетерде ул сүзен, ничектер ялварган шикелләрәк итеп.

Салих ни өчендер җавап биреп тормады, ә яңадан пианинога борылды да, канатларын җәйгәндәй, кинәт кенә дәртләнеп уйнап та җибәрде. Попурри тезгәндәй бер көйдән икенчесенә, өченчесенә күчеп, төрле вариацияләр ясап, бик кызу уйнады ул... Бездә аның болай уйнавы беренче тапкыр иде әле. Бу мине шактый гаҗәпләндерде дә һәм әзрәк кенә борчылырга да мәҗбүр итте. Гүя әтиемнең сүзләренә каршы ниндидер бер яшерен ният белән уйнаган төслерәк тоелды миңа... Чыннан да, ул кинәт кенә уйнап бетерде дә әтиемнән кычкыра биреп сорады:

— Әйтегез әле, Әхмәтҗан абзый, Гөләндәм туташ миңа шулайрак уйнаса, сез канәгать булачаксызмы?

— Бу хәтле үк булмаса да, без канәгать, — диде әтием көлеп.

— Ә уздырып җибәрсә?

— Һем, һем, анысына да каршы түгелбез.

— Менә мин дә Гөләндәм туташка шуны телим! — диде Салих, бу сүзләренә ниндидер бүтән бер мәгънә дә салгандай итеп.

Аннары ул урыныннан торды, пианино капкачын сак кына ябып куйды. Һәм миңа аеруча түбәнчелек белән башын иеп:

— Туташ, сезнең барасы җирегез дә булгач, мин вакытыгызны артык алырга җөрьәт итә алмыйм,— диде.

Әтием дә аны озатыр өчен креслосыннан торды. Хәер, мин аның бездән кайчан чыгып киткәнен күрмәдем. Гадәттәгечә, залдан иң элек үзем чыгып киттем. Башта бу шулай кирәк кебек иде (бигрәк тә әтием өчен), ә хәзер моның килешмәгәнен, ясалма бер әдәп кагыйдәсе икәнлеген

сизә башладым. Ни өчен мин аны озатып калмаска тиеш? Кыргыйлык ич бу, валлаһи!

Бер ярты сәгатьтән соң киенеп, урамга чыксам, Салих безнең тыкрык башында әрле-бирле йөренеп тора! Өстендә озын чабулы кара пальто, башында каракул бүрек. Күрү белән таныдым, ләкин ни өчендер «Улмы соң?» дип уйлап та алдым, гаҗәпләндем, хәтта каушадым, әмма ихтыярсыздан куандым да.

Мине күрүгә ашыгып каршыма килде, елмая төшеп:

— Көтмәгән идегезме? — диде.

Мин зиһенемне җыеп җавап биргәнче, ул, янәшәмнән атлый-атлый, сүзен кызу гына дәвам иттерде:

— Сез минем белән очрашырга теләмәсәгез дә, мин менә әрсезләнеп сезне көтеп алдым. Кәефегез кырылмасын, туташ!..

— Салих абый, зинһар, мине дөрес аңлагыз! — дидем мин ашыгып. — Һич тә теләмәүдән түгел, тик әтием сизә күрмәсен дип курыктым мин...

— Әтиегез өчен мин бары сөекле кызына музыкадан дәрес бирүче генә шул, — диде ул көрсенеп. — Югыйсә, өенә аяк та бастырмас иде.

— Алай әйтә күрмәгез! — дидем мин ялварып. — Әтием дә сезне хөрмәт итә, ышаныгыз!

— Хуш, ышаныйк та ди... Ул чагында мин сезнең аңардан бу хәтле... куркуыгызны аңлап җитә алмыйм, Гөләндәм!..

— Ләкин сез беләсез ич, әтием минем иске фикердәге кеше, ә мин кыз бала, үзегез дә аңларга тиешсез.

Салих кинәт кенә көлеп куйды:

— Шулай шул... Мин — бүре, ә сез — куян, менә ашый күрмәсен дип саклап утыра да инде ул!

— Юкка көләсез, Салих абый, юкка! — дидем мин, елардай булып.

Салих шунда ук җитдиләнеп:

— Кичерегез! — диде. — Сездән көләргә һич тә уйлаганым юк, аллам сакласын!.. Тик сез үзегез бит әтиемнән куркам дисез — шуңа гаҗәпләнәм мин.

— Әйе, куркам, әмма үзем өчен түгел, сезнең өчен! — дидем мин, яшь тулы күзләрем белән аңа карап. — Сезне югалтырмын дип куркам, аңлыйсызмы?!.

Салих бер мәлгә тып-тын булып калды, хәтта адымнарын әкренәйтә төште. Ә мин эчемнән генә: «Ходаем, ничек әйттем мин моны? Ничек әйттем?!» — дия-дия, һаман кызу гына атлый бирдем... Бераздан аның йомшак кына дәшкәнен ишеттем:

— Гөләндәм, ашыкмагыз!

Мин әкренрәк атладым. Ул килеп җитте дә беләгемнән кысып тотты, ләкин шунда ук кире җибәрде.

— Рәхмәт! — диде ул, дулкынлануыннан, ахрысы, пышылдап кына. — Рәхмәт, Гөләндәм!.. Әллә ничек менә күзләрем кинәт ачылып киткәндәй булды. Беләсезме, миндә дә бары шул теләк бит: сезне бер дә югалтасым килми. Сез бик сәләтле кыз, Гөләндәм, сез музыка өчен яратылгансыз. Сезне очратуыма мин бик шатмын...

Ул аз гына тынып торды, тирән итеп бер сулыш алды, аннары яңадан башлады:

— Шулай да минем сезгә әйтәсе сүзем бар, Гөләндәм! Музыка дәресе белән бәйләнмәгән сүзем бар, шуның өчен генә мин нота кәгазенә «очрашыйк» дип язарга да мәҗбүр булдым. Ләкин сез бырчылмагыз, хәтәр сүз түгел ул.

— Мин тыңлыйм!

— Ә сүзем шул, — диде Салих ашыккандай кызу гына, — сезгә дөньяга чыгарга кирәк, Гөләндәм, аңлыйсызмы, дөньяга чыгарга! Бу бик мөһим... Югыйсә, сезгә килгән саен мин бер нәрсәгә гаҗәпләнәм:

сез беркая да чыкмыйсыз, читлектәге кенәри шикелле, гел бүлмәгездә бикләнеп утырасыз... Нәрсә бу, ни өчен?.. Тыялармы, рөхсәт итмиләрме?

— Әтием әйтә, хәзер куркыныч вакыт, ди...

— Һич тә дөрес түгел!.. Киресенчә, бик кызыклы вакыт! Дөнья шаугөр килеп тора — ишетмисезмени? Ә төрле коточыргыч сүзләргә килгәндә, ышанмагыз, бик күбесен арттырып сөйлиләр. Совет власте шәһәрдә тәртип урнаштырды инде, менә йөрибез — берни дә булганы юк. Кичләрен мин үзем сезне каршы алырмын, үзем озатып куярмын, тыныч булыгыз! Ә чыгарга кирәк, театрларга, концертларга йөрергә кирәк. Сез — булачак музыкант, барысын да күрергә, ишетергә тиешсез. Мин сезне әдипләр, артистлар, музыкантлар белән таныштырырмын... Менә күрерсез, үзегезне канатлар үскәндәй хис итә башларсыз. Сәнгать ул хөрлек ярата, хөр кеше генә аның бусагасыннан атлап керә ала. Югыйсә, нәрсә бу, хорафатлар җимерелгән бер заманда бикләнеп яту? Юк, ярамый, акыллым, бигрәк тә сезгә ярамый!

Салихның бу әйткәннәре миңа, билгеле, нык тәэсир итте. Әмма шушы зур, мөһим сүзләр арасыннан берсе минем колагыма аеруча ныграк кереп калды: «акыллым» диде бит ул миңа!.. Һәм шушы бер сүзе белән ул мине үзенә ничектер тагы да якынайта төшкәндәй итте.

— Сез хаклы, — дидем мин, тиз генә килешеп, — сез бик хаклы, Салих абый!.. Үзем дә сизәм — дөньяга, кешеләр арасына чыгарга кирәк, барысын да күрергә, белергә кирәк. Сез хөррият заманы дисез — моны кем генә тоймый икән? Җиде кат стена аша да үтеп керә бит ул!.. Ләкин мин бикләнеп ятучы түгел, мине бикләп куйган кеше дә юк. Без элек чыга идек, әнием белән «Сәйяр» спектакльләренә бара торган идек. Тик хәзер генә тыелдык. Дөнья бик буталып китте бит. Шәһәрдә атышлар, үтерешләр дә булды. Әле аклар, әле чехлар, әле кызыллар — кем баш икәнен дә белмәссең. Менә безнекеләр мондый чакта чыгып, күренеп йөрүдән бик сакланалар. Бигрәк тә әтием минем өчен курка, урамда эт-кош күбәйде, ди... Минем тыңламыйча хәлем юк, шуңа күрә менә «бикләнеп» утырам да инде.

Без Кабан буе урамының башына житеп туктаган идек. Аңа «Шәрык» клубына, ә миңа Мещанскийга таба китәргә кирәк иде.

— Әлбәттә, әти-әнине тыңламыйча ярамый, — диде Салих уйчан гына. — Ләкин аларның котын алган бик буталчык, куркыныч вакытлар үтте бит инде. Казан тирәсендә хәзер аклар да юк, чехлар да юк, кызыллар гына баш. Ә алар тәртипне саклый беләләр, җыен эт-кошка селкенергә дә ирек бирмиләр. Аннары әти-әниләрнең үз исәпләре, үз кайгылары, ә безнең үз теләгебез, үз максатларыбыз — электән үк ул шулай килгән инде. Кыскасы, Гөләндәм, мин сезне башлап бер спектакльгә чакырмакчы идем.

— Нинди спектакльгә?

— «Соңгы сәлам»гә. Кәрим абыйның бу әсәре былтыр бер куелган иде инде, быел менә яңадан уйнала. Килерсез бит?

— Рәхмәт, Салих абый!.. Ләкин белмим шул.

— «Белмим» түгел, киләсез! Әгәр теләсәгез, мин үзем Әхмәтҗан абзыйдан рөхсәтне сорармын.

— Юк, юк, — дидем мин ашыгып. — Ярамый. Мин әнием белән генә сөйләшермен.

— Бигрәк тә яхшы!.. Көнен мин сезгә алдан хәбәр итәрмен. Исәнлегемне әниегезгә кайтарып тапшыруны да үз өстемә алам, ләкин килмичә калмыйсыз, ишетәсезме?

— Мөмкин булса, — дидем мин икеләнебрәк.

— Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, туташ! — диде ул көлеп. — Шулай да безнең бүгенге сөйләшү әйбәт булды әле, һәрхәлдә, минем өчен.

— Минем өчен дә, — дидем мин кыюланып.

— Шулаймы? — диде ул ничектер яктырып. — Мин бик шат!.. Тик ешрак, ешрак булсын иде безнең хәр сөйләшүләр...

Мин дәшмәдем. Ул миңа кулын сузды.

— Ә хәзергә сау булып торыгыз!

Мин перчаткамны салмыйча гына кулымны бирдем. Бу безнең беренче тапкыр кул бирешүебез иде. Җыйнак, нәфис кулының шактый нык-көчле булуын сиздем.

— Ә беләсезме, — диде ул, минем кулымны җибәрмичәрәк торып, — сезнең исемегезне үзгәртеп була икән ләбаса!

— Ничек итеп?

— Гөлгенәм! Гөләндәм урынына — Гөлгенәм!

— Зинһар, алай әйтә күрмәгез! — дидем мин, ут капкандай кызарып.

— Сезнең үзегездән башка моны берәү дә ишетмәс,— диде ул, серле генә итеп.

Минем ни дә булса әйтерлек хәлем калмаган иде — башымны идем дә тиз-тиз генә китеп бардым.

* * *

Юк, килешмәде әле бу, качкан шикеллерәк килеп чыкты. Әмма башкача мөмкин идемени соң? Берәү күзләремә карап миңа «Гөлгенәм!» дисен дә, мин шуңа авыз ерып, тагын нидер көтеп торыйм, имеш! Әлбәттә, мин китәргә, шунда ук китәргә тиеш идем. Үпкәләп, ачуланып түгел, һич юк, ә артык көтелмәгән, артык серле-сихри сүз ишетүдән... Мондый сүзне тыныч кына кабул итеп буламы соң?! Салих үзе дә аңлагандыр, аңларга тиеш!

Аңардан шулай аерылып киткәч, мин әле туган апаларыма да туры гына барып кермәдем. Урамнан-урамга күчеп, озак кына йөрдем әле мин... Тынычланырга, йөрәкне урынына куярга, уйларны әзрәк кенә булса да тәртипкә китерергә кирәк иде миңа... Салих белән беренче мәртәбә сөйләшүебез ич бу — ике ай пианино янында янәшә утырганнан соң беренче мәртәбә икәүдән-икәү генә туры килеп сөйләшүебез!.. Ә сөйләшү үзе, миңа калса, шактый кызыклы, мәгънәле булды шикелле. Бигрәк тә Салихның әйткәннәре... Инде менә уйлыйм: ул әйткәннәрнең кайсы дөрес, кайсысы чын күңелдән, кайсысы минем өчен әһәмиятлерәк? Боларны әле хәзер генә аерып, белеп бетерүе дә бик читен. Һәрхәлдә, иң мөһиме — аның миңа әйткән назлы сүзләрендә түгелдер инде, назлау сүзен туташ кешегә комплимент итеп тә әйтергә була. (Гәрчә комплимент та юктан гына әйтелми, ул да нидер аңлатырга тиеш)... Иң мөһиме — Салихның минем өчен борчылуында, кайгыртуында, мине зуррак, иркенрәк дөньяга чакыруында булса кирәк. Ә бу инде кечкенә мәсьәлә түгел.

Әмма минем өчен тагы да мөһимрәге — ул да булса шушы көтелмәгән сөйләшү безне бер-беребезгә ничектер бәйли төште, безнең арада нindидер бер уртак нәрсә тудырган кебек булды. Моннан соң инде без бары укытучы һәм укучы гына булып калмабыз шикелле... Һәм бу хәл миңа тынычлык бирми, юк, бирми, нәрсәдер менә сагаеп көтәргә мәҗбүр итә... Теләп һәм куркып көтәргә!

## V

Мин ничек кенә булса да «Сонгы сәлам»гә барырга дип үземә сүз биреп куйдым. Бер килүендә Салих миңа спектакльнең көнен дә әйтте. Хәзер инде әнием белән сөйләшергә кирәк иде. Сөйләшү, әлбәттә, җиңел булмаячак. Әниемнең башта ук каршы төшүе мөмкин иде. Үзе дә

куркыр, мине дә куркытып маташыр: театрга йөри торган вакытмыны дияр. Яки исә ул миннән, һичшиксез: «Кем белән бармакчы буласың?» — дип сораячак. Менә шуңа минем, күпме генә уйлансам да, җавабым юк. Бары: «Үзем генә», дип әйтергә туры киләчәк. Ләкин әнием минем үземне генә җибәрәме соң?!. ...Кыскасы, тәгаен генә бер хәйләсен таба алмасам да, мин әнием белән сөйләшергә булдым. Тик каушамыйча, гади бер нәрсә хакында сүз баргандай итеп кенә сорарга, кирәксә, нык кына тартышырга да. Ахыр чиктә мин бала түгел бит инде, теләгән җиремә барырга да, йөрергә дә хакым бардыр, шәт! Бер башлагач сүзен табармын әле. Халык бара ич, халык белән бергә кайтырмын диярмен.

Спектакльгә бер көн калгач (ул 18 декабрьда булырга тиеш иде), мин кичке чәйдән соң әниемә җайлап кына әйттем;

— Әни, — дидем, — театрда яңа спектакль куела икән, минем шуны бик күрәсем килә, син инде миңа рөхсәт итәрсең?..

— Нинди спектакль ул? — диде әнием.

— «Соңгы сәлам». Быелтыр бер уйналган икән инде ул, халык бик мактый үзен...

Әнием аз гына дәшми торды да аннары туп-туры сорады:

— Нәрсә, Салих әфәнде чакырамы?

Мин моны һич тә көтмәгән идем. Бу хәтле дә белеп, туры китереп сорар икән! Бик гаҗәпләндем мин моңа һәм, билгеле, шактый аптырап, каушап та калдым. Әмма мин ялганлый алмый идем, ялган сөйләргә өйрәнмәгәнмен дә... Ирексездән ялганлый башласам да, әнием барыбер сизәчәк һәм гафу да итмәячәк. Ләкин дөресен әйтү дә бик хәтәр: әниемнең рөхсәт итмәве генә түгел, минем өчен, бигрәк тә Салих өчен бик күңелсез нәтиҗә ясап куюы да ихтимал. Шулай да мин дөресен әйтергә булдым:

— Әйе, әни,— дидем оялыбрак кына.— Салих әфәнде миңа ул спектакльне карарга киңәш иткән иде.

Әнием һичнәрсә сиздермәде, хәтта йөзеннән бер күләгә дә узмады, бары тыныч кына сорады:

— Ул үзе дә бара торгандыр бит?

— Ул шунда, оркестрда уйный ич! — дидем мин.

— Ә, әйе шул, оныта язганмын, — диде әнием, аннары аз гына уйланып торды да карар чыгаргандай әйтте: — Ярый, барырсың, ләкин үзең генә түгел.

— Кем белән соң? — дидем мин сак кына.

— Берәр дус кызың белән... Әнә Сания апаның Суфиясен чакырырсың!

— Барыр микән?

— Ник бармасын — куанып барыр. Әнисенә үзем әйтермен.

Мин дәшмәдем. Минем «ахирәтләр» ияртеп йөрисем килми иде, билгеле... Әнием шуны сизгәндәй:

— Сиңа ялгыз йөрергә иртә әле, үзең дә белергә тиешсең,— диде.

Шуның белән сүз бетте. Гомумән, безнең гаиләдә сүз күп булмый иде. Минем колакка да гел генә: «Тегe ярамый да бу ярамый!» дип тукып кына тормыйлар. Күбрәк әнә шулай «үзең белергә» яки «үзең аңларга тиешсең» дип кенә әйтәләр. Һәм мин аңларга, ягъни әти-әниенең нәрсә теләүләрен, нәрсәне рөхсәт итә алуларын үзем белергә, үзем чамаларга тиеш идем. Әмма шулай да мин бик канәгать, мин спектакльгә барачакмын, алла бирсә!.. Әнием Салихның чакыруын кире какмады — бу, һичшиксез, Салих «әфәнде» белән хисаплашу иде. Хисаплашмыйча мөмкин дә түгел, чөнки Салих минем укытучым, чөнки заманасы шуны куша. Ләкин шуның белән бергә бу әле мине Салих «әфәнде» кулына тапшыру дигән сүз дә түгел. Япь-яшь кенә туташны яшь егет белән икесен генә халык арасына чыгару — бу ярый торган эшме соң?! Аллам

сакласын! Әнием үзенчә акыллы да, сизгер дә иде. Ул, әлбәттә, этиемне дә күндерәчәк.

Тик менә тагылып барачак «ахирәт» кенә гел эчемне пошырып тора. Дөресен генә әйткәндә, безнең арада чын дуслык та юк. Әниләр үзләре ахирәт булгач, безне дә «ахирәт кушарга» тырышалар. Ләкин Суфия ул миннән ике-өч яшькә олырак, миңа чебешкә караган төслерәк итеп карый. Үзе генә күп белә, гел өйрәтеп торырга ярата, бигрәк тә егетләрдән бик сак булырга куша (әйтерсең үзенең авызы пешкәне бар!). Шуның өстенә ул әнисе кебек зур гәүдәле, таза кыз — мин аның янында чынлап та чебеш төсле генә булып калам. Әйтәсе дә юк, ул миңа бик шәп «күз-колак» булачак.

Әмма бәхет бар икән әле. «Ахирәтем» авыру булып чыкты, ангина икән үзендә, врач салкынга чыгып йөрергә кушмаган. Шул ук вакытта мин, эш сүтелмәсә генә ярар иде, дип курка да калдым. Әнием ялгыз җибәрмәячәк бит, икенче «ахирәт» табарга кирәк булачак. Кемгә әйтеп карарга: Кәримәгәме, Зәкиягәме, Зәйнәпкәме?.. Ләкин баш ватып эзләп торырга туры килмәде — асравыбыз Сабира (рәхмәт төшсен үзенә!) мине бу кыенлыктан коткарды: борчылма, туташ, бергә барырбыз, диде. Мин моңа бик тә риза идем, тик менә әнием риза булырмы? Асрау белән җибәрүне килештерерме? Ә Сабира безнең бик сылу кыз, килмәгән җире юк, шуның өстенә үткен-чая да. Ул үзе үк, бер дә каушап тормыйча, әниемә:

— Апа, миңа да туташ белән бергә театрга барырга рөхсәт итегезче! — диде.

Белмим, әнием эченнән ни уйлагандыр, ләкин шулай да әзрәк икеләнгәннән соң, ризалыгын бирде. Ни әйтсәң дә хөррият заманы, тиюкысуларның ярамаганлыгын беләләр... Аннары иң мөһиме — без бергә барып, бергә кайтачакбыз, әнием иң элек менә шуны уйлаган булырга тиеш.

...Безнең куанычыбыз эчебезгә сыймый иде. Икәү генә калгач, кочаклашып, сикерешеп тә алдык. Бигрәк тә Сабираның шатлыгы ташып бара, чөнки аның өчен театрга барудан да зуррак бәйрәмнең булуы мөмкин дә түгел иде. Шуның өстенә ул минем өчен дә бик сөенде, чөнки Салих чакыруы буенча баруымны белеп тора. Ә Салихны ул да ярата, минем өчен, гүя мин булып ярата. «Менә шундый шәп егеткә гашыйк булсаң да ярый, ичмасам!» — ди ул җай чыккан саен. Сизәм инде, үзенчә миңа теләктәшлек белдерәсе килә. Баштарак мин бик уңайсызлансам да, соңыннан аның бу эчкерсез сүзләрен ничектер ихтыярсыздан көтә торган булып киттем.

Ярый, моны куеп торыйк. Безнең кайгыбыз хәзер бүтәндә — театрга әзерләнергә кирәк. Ә кызлар өчен бу ансат эштән түгел: нәрсә кияргә, ничек киенергә, чәчләрне ничек төзәтергә, бизәнергәме-юкмы? — менә күпме аның кайгысы... Мине һаман бер нәрсә борчый: Сабира белән безнең өс-башыбыз бер төсле үк булмаса да, бик үк аерылып та тормаска тиештер инде. Ничек тә бертигезрәк киенергә кирәк. Шуның өчен мин башта Сабираның «туалетын» тикшереп карадым. Былтыр гына тектергән, әле юньләп кимәгән дә шактый модный — тар билле, тар җиңле, иңбашлары күпертмәле зәңгәр йон күлмәге бар икән. Минем дә зәңгәр күлмәгем бар (тик фасоны гына башкачарак), димәк, без бер төсләдән кия алабыз. Тик менә аякларда гына төрлечә — Сабирада шнурлы гади ботинка, ә миндә зур перламутр каптырмалы модный туфлиләр. Ләкин моны бер ничек тә тигезләп булмый инде. Күлмәкләребез озын, аякларыбыз бик күренеп тормас әле дип тынычланган булдык... Инде башны нишләтергә — калфак кияргәме-юкмы?.. Әнием ялан баш баруыбызга һич тә риза түгел. Сабира да шуны әйтә — ялан баш йөрергә оялам, ди. Ә минем нигәдер киясем килми, калфакны хәзер ташладылар инде, дим. (Хәер, моның дөрес түгеллеген үзем дә беләм: чәчләрен кыр-

кып, ялан баш йөрүчеләр күренгәләсә дә, калфакны бик кияләр әле). Ахырда риза булырга туры килде. Икебез дә вак энҗеле сай калфаклар кидек. Сабирага әнием үзенекен биреп торды.

Бу әле безнең алдан киенеп каравыбыз гына иде. Сабира белән икәү генә калгач, без трюмо көзге алдына янәшә бастык. Каршыбызда бертигез диярлек ике бик матур туташ басып тора! Тик берсе бик яшь әле, ә икенчесе — олырак. Бик яшенең йөзе сөттәй ак, чәчләре чем-кара, ә күзләре зәп-зәңгәр. Кара чәч, зәңгәр күз! — бу бит әллә ничек, бер дә табигый түгел сыман. Нигә ходай мине яратканда төсләрне шулай саташтырды икән?! Ә олыракның чәче дә, күзләре дә кара, хәтта йөзе дә кара тутлы, әмма бик чиста. Ходай бу юлы саташмаган, игътибарлырак булган. (Тәүбә, тәүбә!). Сабира миңа әйтә: «Гөләндәм, син нинди матурсың!» — ди. Ә мин әйтәм: «Юк, Сабира, син тагы да матурраксың»,— дим. Ә ул: «Кит тиле, көлмә!» — ди миңа үпкәләп. Ә мин көләргә уйламыйм да. Ул бит миңа караганда, ничек дим, гәүдәгә житүрәк, биегрәк, күкрәкләре дә тулырак, тик мин моны аның үзенә әйтергә генә оялам.

Ә театрга без, насыйп булса, иртәгә барачакбыз. Салихка хәбәр итә алмадык инде, ләкин ул мине барыбер көтәчәк. Әйе, көтәчәк!.. Иа хода! Бу бит минем егет чакыруы буенча беренче мәртәбә театрга баруым... Салих абыем, Салих бәгырем, мин шулай ук сезнең игътибарны җәлеп итәрлек, театрга дәшәрлек чын туташ булдыммыни инде?! Ни бәхет бу, ни бәхет!

Икенче көнне без Сабира белән җыенып, киенеп-ясанып, гәзиткә төргән туфлиләрне култык астына кыстырып, сәгать ике тулар-тулмас өйдән чыгып киттек. Болай көпә-көндез кузгалуыбыз гаҗәп тоелмасын. Чөнки татар спектакльләре Проломныйдагы рус театрында («Большой театр»да) көндезге сәгать өчтә башлана иде. (Кичләрен руслар үзләре уйный). Салих әйтә: бу озакка бармаячак, тиздән татар театрының үз бинасы булачак, ди. Милли сәнгатькә хәзер киң юл ачылачак, ди. Әлбәттә, шулай булырга тиеш, азатлык, тигезлек, диләр ич!

Без килеп җиткәндә театр алдында халык күп түгел иде әле. Иртәрәк, ахрысы, дип уйладык, шулай да эчкәре уздык. Ә Салих ишек төбендәге билет тикшерүчедән аз гына арттарак басып тора иде инде. Менә кайчан ук көтә башлаган! Безне күреп ул елмайды, без аңа елмайдык. Шунда ук ашыгып янибызга да килде. Мин, Сабира белән икәү булгач, кәефе бозылмасмы икән дип борчылган идем. Ләкин, киресенчә, ул аңа чын ихластан сөенде генә.

— Менә рәхмәт, Сабира туташны да калдырмагансыз! — диде, аның да кулын кысып, һәм билет тикшерүчегә:— Болар минем кунакларым,— дип, безне эчкә алып кереп тә китте. Гардероб янына баргач, өстебездән салырга да булышты. Шул арада хәл-әхвәлебезне дә сорашып алды. Аннары көлеп кенә: — Инде туташлар, сезгә көзге дә кирәктер, — диде һәм безне идәннән түшәмгә кадәр сузылган зур көзге янына да китерде. Мин, бераз әйләнгәләп, өс-башымны карадым, чәчемне төзәткәләдем, ә Сабира үзенең көзгедәге кыяфәтенә чит бер кешегә карагандай күз төшереп кенә алды.

...Фойега уздык. Бер читтәрәк туктап, уртада әйләнгән халыкны күзәтәбез. Салих әйтә, минем өчен тамаша шушыннан башлана, ди. Театрга килгән халыкка читтән генә карап торырга ярата икән: кешене читтән күзәтеп белү кызыклы, ди... Бәлки шулайдыр да... Минем исә театрга килмәгәнемә бер ел бардыр инде, ә бу вакыт эчендә безнең шәһәрдә ниләр генә булып узмады. Театр эчендә дә зур үзгәрешләр булгандыр, бигрәк тә тамашачы нык үзгәргәндер дип уйлаган идем. Алай ук түгел икән. Хатын-кызлар шул ук дияргә ярый — күбесе европача киенгән, әмма барысы да калфаклы ханымнар һәм туташлар. Иске моданы саклыйлар икән әле. Тик, бая әйткәнемчә, чәчләрен кистергән ялан башлы

хатыннар да сирәк кенә күренгәли. Өсләрендә аларның билен каеш белән буган гади солдат гимнастеркасы һәм кыскарак кара юбка. Ә аякларында солдат итекләре! Кемнәр алар — хәрби идарәләрдә эшләүчеләрме, әллә хәрбиләр тирәсендә йөрүчеләр генәме? Бәлки бу хәзер үзенә күрә бер модадыр яки хөрлек билгеседер?!

Ирләр исә шактый чуар. Элеккечә тройкадан бик фырт киенгәннәр дә күренеп кала, зур бант тагып, озын блузадан йөрүчеләр дә күренгәли, җиз төймәле яшькелт тужурка кигән студентлар да күзгә чагыла. Шулай да хәрби киемлеләр күбрәк. Болары инде кызыл гаскәриләр, өсләрендә гади гимнастерка яки дүрт кесәле френч, зәңгәр яки кызыл галифе, озын конычлы итекләр, әмма бернинди погон-мазар яки башка дәрәҗә билгеләре юк. Дөрес, кайберләренең күкрәгендә кызыл бантиклары бар, ләкин бит аны хәзер теләсә кем кадый ала шикелле. Кыскасы, солдатмы, офицермы (хәер, офицер дию һич тә ярамый хәзер) — аерып булырлык түгел, бары тик кыяфәтенә, тотышына, өс-башының шәплегенә карап кына чамаларга була... Арада бик көязләре дә күренгәли. Эре, һавалы йөриләр. Хатын-кызга артык игътибар да итмиләр кебек, әмма бер карасалар — көйдереп алырлык итеп карыйлар.

Алар арасыннан Салих белән исәнләшеп узучылар да булды. Шул чакта миңа да күзләре белән сөзеп карарга өлгерделәр. Мин инде уңайсызлана да башладым. Салих шуны сизгәндәй:

— Әйдәгез, без дә агымга иярик, — диде.

Без кузгалдык. Мин Сабираны култыклап алдым, Салих минем якка чыкты, ләкин аз гына ара калдырып янәшәмнән атлады. Култыклау түгел, миңа орынып китүдән дә саклана кебек... Бүген ул кара костюм, ак күлмәк, кара бантиктан иде — бик килешә икән үзенә.

Салих Сабирага җитди генә әйткән була:

— Сабира туташ, мин сезне берәр комиссар белән таныштырыйммы?

— Юк, юк, кирәкми! — ди Сабира, чынлап курыккандай.

— Нигә? Комиссарлар арасында бик шәп кешеләр бар. Әнә сул ягыгызга карагыз әле. Күрәсезме, матрос тужуркасы кигән егетне? Фамилиясе — Җиһаншин. Питердан җибәрелгән бик гайрәтле матрос-комиссар диләр аны!..

— Булса ни, — ди Сабира исе китмәгәндәй, ә шулай да үзе каршы яктан узып баручы киң җилкәле, куе кара кашлы пәһлевандай таза егеткә күз төшермичә үтә алмый.

— Сез юкка куркасыз,— ди Салих отыры шаяртып.— Карап торырга бик гайрәтле күренсә дә, хатын-кыз янында ул бик юаш икән... Кулга ияләшкән арыслан кебек диләр, чын булса!..

— Ә сез аның шундый икәнен кайдан беләсез?

— Минме?.. Егет театрны бик ярата, бер генә спектакльне дә калдырмый... Безнең артисткалар аның белән танышырга да өлгерделәр инде — мин шулардан ишеттем. Ә артисткалар ирләрне таный беләләр, Сабира туташ!

Сабира кискен генә башын селки:

— Юк, миңа әртисткәләрдән калган кәмисәр кирәкми, үзләренә булсын!..

Салих рәхәтләнеп көлә. Шаркылдамыйча, ничектер әкрен тавыш белән, әмма бик тәмле итеп көлә. Аңа ияреп мин дә көләм — көлмичә мөмкин дә түгел: менә бит ул безнең беркатлы Сабирабыз үзенең көнчелеген дә күрсәтеп өлгерде.

Салих, көлеп туйгач, шулай да аңа йомшак кына әйтте:

— Сез мине зинһар кичерегез! Мин бит болай гына, кызык өчен генә... Үпкәләмәгәнсездер ич?

— Үпкәлим тагын! — диде Сабира эре генә.

Шул арада беренче звонок та булды. Без, яңадан бер-ике тапкыр әйләнгәч, зал ишегенә таба борылдык. Салих безгә урыннарның бик

әйбәтен алып куйган икән — партерның өченче рәтендә, уртадан уза торган юл кырында гына... Мин аның үзенә урын булмас дип пошынган идем, ләкин урын өчебезгә дә булып чыкты.

— Ничек белдегез безнең икәү киләсебезне? — дип сорадым мин аңардан, ә ул серле генә итеп:

— Күңелем сизде,— диде һәм, кавалерларча иелә биреп, Сабирага кереп утырырга тәкъдим итте:— Сабира туташ, рәхим итегез!

Аның янына мин утырдым, ә иң кырыйга Салих үзе утырды.

Тамашачылар — калфаклы хатын-кызлар да, элеккеге әфәнделәр дә һәм хәзерге кызыл комиссарлар да кереп, урындыклары белән азрак дөбердәшкәннән соң, ниһаять, утырышып беттеләр. Сәхнә артыннан җиз кыңгырау соңгы мәртәбә шалтырады, кемнәрнеңдер ашыгып йөргүләре, кабаланып чыш-пыш сөйләшүләре ишетелеп калды. Ниһаять, барысы да тынды һәм пәрдә әкрен генә икегә аерылды.

...Без «Соңгы сәлам»не карыйбыз. Якты сәхнәдә яхшы гына үк бай җиһазлы татар сәүдәгәренең өе. Күпмедер вакыт сәхнә буш тора, тик берадан гына европача бик зәвык белән киенгән, утызлар тирәсендәге, урта буйлы чибәр генә ир кеше килеп керә. Ул әле бер сүз дә әйтми, сәхнә буйлап әрле-бирле йөренә, аннары туктап, күкрәк кесәсеннән бер фотокарточка чыгара да шуңа уйланып карап тора.

Салих иелә төшеп миннән сорый:

— Танадыгызмы?

Мин «Сәйяр» артистларының барысын да диярлек таный идем, ләкин сәхнәдәге ирнең тавышын ишетмәгәч, икеләнебрәк калдым.

— Тинчурин бу,— ди Салих шыпырт кына.— Үз әсәрендә баш рольне уйный!

Шул арада сәхнәгә юка гына зифа буйлы, мөлаем-матур гына яшь бер хатын газеталар күтәреп килеп керә. Ир кешегә йомшак кына, Вахит, дип дәшә. Хатыны икән.

— Ә бусын? — ди Салих миңа.

— Бусын таныдым. Өммегөлсем ханым Болгарская, шулаймы?

— Дөрес!

Без, артык сүз алышмыйча, бик игътибар белән сәхнәдә барган вакыйганы карыйбыз. Беренче күренештән үк инде ир кешенең үз хатынын яратмавы, каядыр читтәге икенче берәүне яратуы ачыклана башлый. Җитмәсә, ул «берәү» рус кызы булса кирәк — шулай аңлашыла. Татар сәүдәгәренең рус кызына мәхәббәте — бу, әлбәттә, бик кызыклы иде. Хәзер үк инде гадәттән тыш нидер көтәргә мәҗбүр итә. Вахитның исә сөйкемле хатыны гына түгел, шактый диндар карт әнисе дә, кечкенә баласы да бар икән әле... Кая илтеп чыгарыр, ни белән бетәр бу... мәхәббәт?!.

Артистлар, минемчә, бик табигый уйныйлар. Тинчурин кайгылы-уйчан, хыялый кешедәй үзенең эчке дөньясына бикләнгән, шуңа күрә якыннарына үтә игътибарсыз, ә сәүдә эшләренә әйтерсең бөтенләй кулын селтәгән... Хатыны исә (Болгарская) иренең шушы хәлен күрә, сизә, газаплана, еш кына җылап та ала, әмма ләкин аңа каты бәрелүдән курка, ничек тә кәефен бозмаска тырыша. Ярата ул, бичара, чынлап ярата ирен!

Бу урында мин үз хәлем турында да әйтмичә уза алмыйм. Сәхнәдә барган вакыйга минем дикъкатемне беткәнче биләп алса да, мин янымда утырган Салихны бер генә секундка да онытып тормадым. Әз генә кыенсыну катыш эчке бер сөенү белән аны тоеп утырам. Ходаем, нәрсәдер инде бу, — үзем дә аңламыйм!

...Беренче пәрдә бетте. Урыннарыбыздан торгач та Салих безгә әйтте:

— Сез, туташлар, мине кичерегез инде, үзегезне генә калдырырга туры килә. Миңа оркестрым янына барырга кирәк.

— Барыгыз, бар, безнең өчен борчылмагыз, — дидек без аңа.

Ул алданрак чыгып китте. Халыкка ияреп, ашыкмыйча гына без дә фойега чыктык. Мин бер читтә генә басып тормакчы идем дә, Сабира беләгемнән тотып кыстый башлады...

— Әйдә, әйдә, йөрибез! Абыстайлар шикелле стена буенда авыз каплап тормыйк әле.

Аның кешедән бер дә калышасы килми иде — башкалар уртада йөриләрме, димәк, ул да иркенләп йөрергә тиеш. Кай җире ким аның бүтәннәрдән?! Тыңларга туры килде үзен... Ә бераздан фойеның алгы башындагы сәндерәгә урнашкан кечкенә оркестр дәртле генә уйнап та җибәрде. Ике скрипка, ике мандолина һәм пианинода «Баламишкин»ны сыздыралар. Халыкның бердән йөзләре ачылып, хәрәкәтләре җиңеләебрәк киткәндәй булды — кәефле елмаешып, башларын күтәрә төшеп атлый башладылар. Хәрби киемдәгеләр исә аеруча тураеп дөньяның хуҗаларыдай горур карап, һавалы атлыйлар, тик ара-тирә бөгелә төшеп, яннарындагы кызларның колакларына нидер әйтәләр, ә кызларга әйтерсең шул гына кирәк тә — күңелләре кытыклангандай шаркылдап көлеп җибәрәләр. «Баламишкин»нан соң оркестр «Ком бураны»н уйнады, аннары, озын көйгә күчеп, «Уел»ны салмак кына суза башладылар. Һәм музыканың сихри кодрәтенә буйсынып кешеләрнең дә кәефләре шунда ук үзгәрде. Гүя «Уел» дулкыннарына уралып, каядыр еракка-еракка агып киттеләр. Кычкырып көлүләр бетте, үзара сөйләшүләр дә тынды, тик идәнне чыш-чош ышкыган аяк тавышлары гына ишетелеп торды. Ә уйнаучылар үзләрәләр генә, бигрәк тә беренче скрипка үзере — уйнаучысы кечкенә кара кеше — Мөхәммәт абый Яушев. Ләкин мин күбрәк пианинога колак салам, Салихның ничегрәк уйнавын ишетәсем килә. Дүрт-биш кешелек оркестрда да, билгеле, беренче нәүбәттә скрипка-мандолина тавышлары яңгырый, шулай да мин Салих уйнавын аермачык ишетәм. Шул скрипка-мандолиналарга тәмам көйләнеп, алар белән бергә үрелеп дигәндәй, гадәтенчә, җиңел-йомшак кына итеп уйный ул... Хәер, аның уйнавын мин иң зур оркестрны тыңлаганда да менә шулай ап-ачык ишетер идем кебек.

Күрәсең, антракт беткәндер, музыка тынды, халык залга керә башлады. Без дә борылдык. Шул чакта мин ложа ишеге төбендәрәк бер төркем яшьләрнең кемнедер уратып алуларына игътибар иттем. Туктала бирөп (ә Сабира моны сизмичә алдан кереп китте), әйе, туктала биреп карасам, түгәрәк эчендә, тәгәрмәчле креслода бер кеше утырып тора. Моңарчы күргәнем булмаса да, мин аны шунда ук таныдым. Рәсемнәре буенча, ишеткәннәрем буенча, хәтта әсәрләре буенча да мин аны таныдым: бу — Фатих Әмирхан иде. Иа хода, әдип Фатих Әмирхан! Минем иң яраткан әдибем!.. Билгеле инде, мин үтеп китә алмадым, әдәп кагыйдәсен бозып булса да, бер читтәрәк тукталдым — мондый форсаттан файдаланмыйча калу мөмкинмени?!. Дөрес, әйләнәсендәге кешеләр иркенләп карарга комачаулыйлар, ләкин шул ук вакытта алар ашасыннан күзәтү минем өчен уңай да иде. Ничек кенә булмасын, мин әдипнең йөзен-кыяфәтен дә, өс-башын да шактый тулыачык күрдем. Ул ялан баш иде, чәче кыска итеп китәрелгән, борын өстендә калын пыялалы пенсне, шуңадыр, ахры, коңгырт күзләре аеруча зур булып күренә. Иреннәре дә калын, һәм бу аның чыраена ниндидер бер ныклык, тәвәккәллек биреп тора кебек... Кигәне кара тройка, катыргы ак яка, шуңа ак төрткеле зур гына кара галстук бәйләгән. Ә әйләнәсендәге яшьләр — нәкъ аның үз геройларына охшаган берничә калфаклы туташ та яшел тужуркалы бер-ике студент — ул шулар белән, яңагына таянган килеш, ашыкмыйча гына нидер сөйләшә. Дөресрәге, яшьләр бер-берсен бүлә-бүлә аңа нидер сөйлиләр, ә ул башын

каккалап, күбрәк тыңлап кына утыра... Миңа калса, әдип бу «чорналыш» уртасында калудан бик үк канәгать тә түгел шикелле, һәрхәлдә, ул нигәдер уйчан, житди-уйчан, күзләре дә салкын (әллә пыяладанмы?), гүя мөнә ирексездән генә яшьләрнең комплиментын тыңларга да шуларга саран гына елмаеп җавап бирергә мәҗбүр — шулай күренде ул миңа. Әмма бу мин күрергә теләгән әдип иде, хыялымда мин аны нәкъ менә шушындый ирләрчә җитди-горур, чын интеллигент кыяфәтле бер кеше итеп саклый идем. Тагын шул — мин аның гарип булуын күптән ишетеп белә идем, ләкин менә хәзер үз күзем белән күргәч, — ни гаҗәптер — ул миндә кызгану хисе уятмады. Мескенлектән бик өстен иде ул!

Кузгалырга да вакыт иде инде. Әдип тирәсенә җыелган яшьләр дә таралдылар, ә мин һаман китә алмыйча торам. Ярый әле, шул арада Салих килеп җитте. Ул шунда ук Фатих Әмирханны күрде һәм аңа таба атлады. Әдипнең салкын-уйчан йөзе ничектер бердән йомшарып-җылынып киткәндәй булды. Үзе үк башлап:

— Ә, Салих туган! — дип дәште.— Уеныгыздан бик мәмнүн булдык, рәхмәт сезгә!..

Алар кул бирешеп күрештеләр.

— Сездән мактау сүзе ишетү безнең өчен зур шәрәф ул! — диде Салих дулкынлана төшеп. — Мин моны, әлбәттә, иптәшләремә дә җиткерермен.

Әдип башка сүз әйтмәде. Салих исә, тиз генә миңа таба борылып:

— Гөләндәм туташ, килегез әле! — диде.

Мин тәмам аптырап, каушап калдым: бу ни эш, ни өчен чакыра ул мине? Ә Салих һаман дәшә:

— Килегез инде, килегез!

Кыстатып торуның һич килешмәсен аңлап, мин урынымнан кузгалырга мәҗбүр булдым.

— Фатих абый, — диде Салих түбәнчелек белән генә. — Рөхсәт итсәгез, мин Гөләндәм туташны сезнең белән таныштырырга теләгән идем.

— Рәхим итә күрегез, — диде әдип елмаеп кына. — Туташлар белән танышудан ваз кичә алмыйм!

Бу минутта мин нишләргә, ни әйтергә кирәклеген һич белә алмыйча тора идем. Әдип шуны сизде, ахрысы, үзе башлап миңа кулын сузды. Бик таркау хәлдә булсам да, мин аның озынча-ябык, кайнаррак кулын тойдым.

Ә Салих ашыгып мине мактарга кереште:

— Гөләндәм туташ пианинода шактый чибәр уйный. Кабилияте бар. Киләчәктә, һичшиксез, музыкант булырга тиеш.

— Бирсен алла! — дип куйды әдип.

— Мин инде аның сезне никадәр яратып укуын әйтеп тә тормыйм.

— Дөрес эшлисез! — диде әдип ваемсыз гына, аннары миңа туры гына карап әйтте: — Салих әфәнде сезнең хакта мотлака белеп әйтәдер дип уйлыйм. Сезгә, туташ, аның өметләрен акларга гына кала.

— Рәхмәт! — дидем мин чак ишетелерлек итеп.

Фойеда беркем дә калмаган иде инде. Залда ут та сүнде. Сүз беткәнгә ишарә ясап: «Хәзергә, туганнар!» — диде әдип. Артында басып торган түгәрәк кенә ак сакаллы, сөйкемле генә бер бабай әдипнең креслосын тәгәрәтеп якындагы ложага алып кереп китте. Без әдипкә баш иеп калдык. Ашыгып залга кердек. Пәрдә ачылмаган иде әле. Мин шунда ук Салихка үпкәмне белдерергә ашыктым:

— Ник сез мине Фатих абыйга күрсәттегез? Шундый уңайсыз булды миңа, оятымнан нишләргә дә белмәдем. Ходаем, ярыймы соң шулай кинәт кенә...

— Ник ярамасын?! — диде Салих, әкрен генә көлеп. — Бик уңай

килеп чыкты ич!.. Фатих абый үзе дә бит, «туташлар белән танышудан ваз кичә алмыйм», диде.

— Ваз кичә алмый шул, бичара!.. Әмма туеп беткәндер инде ул алардан.

— Сез — башка! — дип куйды Салих җитди генә.

— Ничек «башка»?

— Шулай. Мин бит сезне аның белән чибәр туташ итеп кенә түгел, ә бигрәк тә булачак музыкант итеп таныштырдым. Сәнгатьнең әһлесенә күрсәттем мин сезне, Гөләндәм!

— Йа хода! Булачак музыкант!.. Сез дә көләсез...

— Аллам сакласын! — диде Салих ашыгып һәм кулыма җиңелчә генә орынып алды.— Тынычланыгыз! Бу таныштыру өчен соңыннан үзегез дә миңа рәхмәт әйтерсез әле. Фатих Әмирхан ич ул!.. Ә хәзер спектакльне карыйк.

Пәрдә ачылган иде инде. Кайда бу, нәрсә бу? Сәхнәдә чит шәһәрдәге номерларның бер бүлмәсе икән. Әлеге яшь, чибәр татар сәүдәгәре сәгатенә карый-карый кемнедер көтә. Номер хадимәсе кереп-чыгып йөри. Бүлмә уртасындагы түгәрәк өстәлгә төрле ашамлык-эчемлекләр кертеп куя. Ә бераздан, хадимә чыгып китүкәч, ишек кагалар. Вахит ашыгып ишеккә бара. Ишек ачыла һәм бусагада битенә кара вуаль каплаган бик зифа буйлы яшь кенә бер туташ пәйда була. Күпмедер вакыт алар бер-берсенә өнсез карашып торалар. Аннары Вахит: «Ольга, бу синме?» — дип, кызга ташлана. Кыз вуален күтәреп җибәрә дә егет кочагына сыена. Минә кемне Вахит зарыгып, сабырсызланып, үзенә урын таба алмыйча көткән икән!

Әйе, әйтәсе дә юк, кыз искиткеч сылу-чибәр. Вахит шашынып аның кулларын, йөзен, күзләрен үбә башлый. Менә кайда икән ул... мәхәббәт! — тилерүгә якын ниндидер иңрәүле, ялварулы, газаплы хәтәр мәхәббәт!..

Ольга исемле рус кызын моңарчы мин күрмәгән яңа артистка уйный иде. Салих колагыма иелеп кенә әйтте: Әшрәф Синаева, диде. Петербургтан махсус театр курслары бетереп кайткан яшь артистка икән. Кара син аны — татар кызлары нишли хәзер?!.

Яшь артистканың буе-сыны бик нәфис-килешле, йөзе дә бик гүзәлсөйкемле, тавышы да чиста-ягымлы иде. Кыскасы, үзенең роленә бөтен ягы белән дә туры килгән чын, табигый рус кызы!

Әмма яратамы соң бу чәчәктәй чибәр, яшь марҗа кызы татар сәүдәгәрен? Ярата, бик ярата сыман... һәрбер әйткән сүзе, һәр кыланышы шуны раслап тора кебек... Нәрсә ди ул?.. «Мин бит сине сагынып гакылдан яза яздым... Юк, чынлап та, Володя, бу синме?.. Бу синме, Володя?.. Бу төш түгелме?» — ди ул, Вахитның күзләренә керердәй булып... Менә ул иреннәрен «Володяның» авызына суза, калтыранган тавыш белән: «Сөеклем, князем минем... өзелеп сөям бит мин сине!.. Аңлыйсыңмы, бөтен барлыгым белән бит мин сине сөям!» — ди, һәм алар һушларыннан язганчы үбешәләр. Ходаем, шул дәрәҗәгә җитәргә кирәк бит! Оятымнан мин хәтта башымны иярга мәҗбүр булдым. Әмма ләкин шулай шашынып яратышуларына карамастан, кызның мәхәббәтенә ышануы читен иде. Чын мәхәббәт түгелдер бу, берәр төрле хәйлә генәдер дигән шик күңелне минә берөзлексез тырный да тора. Һәм бу шик, бу сизенү әсәрдәге вакыйга куера барган саен отыры арта гына бара.

Чынлап та, Ольга бу татар сәүдәгәрен ни өчен яратырга тиеш әле? Байлыгы өчен дияр идең, ул үзе дә миллионер кызы. (Әсәрдә миллионнарны кушу турында сүз дә булып ала, ләкин мин моны аңламадым: мәхәббәт бар җирдә нинди миллионнар турында сүз булырга мөмкин икән?) Матур, таза ир булганы өчен диярр идем, Ольга шикелле шундый чибәр кызга үз шәһәреннән, үз милләтеннән сайлап алырлык шәп егет табылмас идемени?.. Җитмәсә әле, Вахитның яшерүенә кара-

мастан, кыз аның хатынлы-балалы кеше булуын да белә шикелле... Юк, ничек кенә юрама, Ольганың мәхәббәтен аңлавы да, аңа ышануы да читен иде. Бәлки кызга Вахитны гаиләсеннән, диненнән, милләтеннән аеру кирәктер? Ольга бит аңа, этиләр белә, этиләр сине көтә, дип әйтә. Ул аны үзләренә кат-кат чакыра, аңа зур бәхетләр вәгъдә итә. Ниһаять, соңыннан Вахитны алып китәр өчен ул торган шәһәргә дә килә. Димәк, Ольга боларның барысын да этиләре белән уйлашып, киңәшеп эшли! Нинди мәхәббәт була соң бу?!.

Ә менә Вахитның Ольганы өзелеп яратуы бер төрле дә шик уятмый. Киресенчә, ул инде мәхәббәтеннән тәмам исергән, акылын җуйган кеше, Ольганың колына әверелеп, ак-караны күрмичә, үзенең һәлакәтенә бара торган кеше... Аның газапларына карап булмый иде, әледән-әле яшь төере бугазга килеп тыгыла иде. Залда әкрен генә елап утыручылар да булды шикелле. Бигрәк тә соңгы пәрдәдә... Соңгы пәрдәдә алар Идел яры буенда очрашалар. Вахит, Ольга белән качар өчен, өен, гаиләсен, карт әнисен ташлап бирергә килә. Әмма Вахитны соңгы минутта нидер тота, гүя ул үзенең алдында төпсез упкын күрә. Китәргә дә, чигенергә дә мөмкин түгел. Һәм ул, гел ашыктырып торган Ольганы, хәзер артыңнан барып җитәрмен дип, көймә белән пристаньга озата да үзе яр буенда... атылып үлә... Әйе, менә револьверын чыгарып, чикәсенә терн дә... ходаем, үзең күрсәтмә моның кебек бәхетсез үлемне!.. Атылыр алдыннан ул: «Мин алдандым, алар мине алдадылар!» — ди. Димәк, белгән нинди җәтмәгә эләккәнен... Иң ахырдан, Идел өстендәге акчарлакларга мөрәҗәгать итеп, алар аша әнисенә, хатынына соңгы сәламен тапшыра.

Әнә шулай җан тетрәтеп һәм нигәдер шомландырып бетә бу «Соңгы сәлам» дигән спектакль. Алкышлар көчле булды. Пәрдә берничә мәртәбә ачылды. Тамашачылар әсәрне язган һәм баш рольне уйнаган Кәрим абый Тинчуринны аеруча озак алкышладылар. Ул арыган кыяфәт белән, әмма бәхетле елмаеп, башта үзе генә, аннары Болгарская белән Синаеваның кулларыннан тотып, аларны да алгарак чыгарып, халыкка кат-кат башын иде.

Спектакль сәгать җиделәр тирәсендә генә бетсә дә, тышта күптән караңгы төшкән иде инде. Һава шактый салкын, зәһәр генә җиле дә бар, бик сирәк урыннарда гына, җилдән селкенгәләп, зәгыйфь кенә фонарьлар яна. Тротуар чокырлы-чакырлы, тайгак — Сабира белән икәү нык кына култыклашып атлыйбыз. Ә Салих минем яннан гына гүя мине саклап бара, ләкин беләгемнән алырга кыймый. Мин эчемнән генә борчылып, әллә үзем алыйм микән дип тә уйлап куям, әмма моңа минем батырлыгым җитми, билгеле... Урам уртасыннан ара-тирә извозчиклар чаптырып узып китәләр — аларда хәзер байлар түгел, ә кызыл комиссарлар утырып кайта.

Билгеле инде, кайтып җиткәнче безнең арада сүз яңа гына күргән спектакль турында булды. Һәркемнең үз хөкеме. Мәсәлән, безнең Сабирага марҗа кызына гашыйк булган яшь сәүдәгәр бер дә ошамаган икән.

— Бай маена чыдый алмый, шуңа сикерә ул! — ди ачуланып. — Әнә, сикерә торгач, үзенең башына да җитте. Шул кирәк аңа!

— Ни сөйлисез, Сабира туташ! — ди Салих бик гаҗәпләнеп. — Сез мәхәббәткә ышанмыйсызмыни?

— Ник ышанмыйм — ышанам! Мәхәббәт бит ул бер-берсен яхшы белгән, тиң килгән кешеләр арасында гына була. Ә болар нәрсә? Икесе ике шәһәрдән, берсе марҗа, икенчесе татар да ишшу хатынлы, балалы... Ә хатыны нинди сөйкемле, сабыр, ярата да бит әле шул азгынны!.. Юк инде, юк, сөйләмәгез, чын гыйшык түгел бу... Татар байларының марҗалар артыннан сөберелгәнен ишеткәнебез бар инде.

Салих башта, гадәтенчә, рәхәтләнеп бер көлә, аннары, тынычлангач, миннән әкрен генә сорый:

— Ә сезнеңчә ничек, Гөләндәм?

Ә мин ни әйтергә дә белмим. Күңелемнән әллә ниләр уйласам да, нигәдер менә тотып кына әйтер сүзем юк. Салихка да шулайрак аңлаттым, ә ул тагын сорый:

— Ә сез алар арасындагы мәхәббәткә ышандыгызмы?

— Ничек дим?.. Вахитның яратуына ышанмыйча мөмкин түгел, ә менә Ольганың... юк, мин ышана алмадым аның чынлап яратуына.

— Ни өчен?

— Кызны бит гүя туганнары котыртып тора, шулар кушуы буенча ул Вахитны гаиләсеннән аермакчы да була — шулай аңладым мин пьесадан... Ә нигә, ни өчен кирәк соң аларга татар сәүдәгәре?

— Чукындырыр өчен! — ди Сабира кискен генә.

Салих тагын бер рәхәтләнеп көлә:

— Ну, Сабира! Ярып кына сала!..

— Ату ни өчен?.. Нинди урыс үз кызын чукынмаган татарга бирсен ди?!.

— Ә бәлки кызның туганнарына татар сәүдәгәрен чукындырып тормыйча гына йоту кирәк булгандыр? Икенче яктан, Вахит та рус капиталын эләктерү турында хыялланагандыр?... Сәүдә эшләре хәйләи-шәргыйгә корылган нәрсә бит ул!

— Әллә тагын, анысын мин ишетмәдем.

— Ләкин пьесада шул нәрсә дә сизелә бит!.. Кыскасы, туташлар, минем фикеремчә, монда күп нәрсә зур бер төенгә бәйләнгән: дин, гаилә, байлык мәсьәләләре... Вахит менә шул төенне чишә алмыйча һәлак була да инде. Бигрәк тә дин һәм милләт аермасы күп кенә очракта гашыйкларны әнә шундый фаҗигага китерә дә... Ләкин бу инде үтеп бара торган фаҗига, киләчәктә андый фаҗигалар булмас, булмаска тиеш.

— Сез шулай уйлыйсыз?

— Әйе, Гөләндәм! Иске хорафатлар әкренләп җимерелә бит, үзегез дә күрәсездер... Мәсәлән, байлык белән ярлылык та гашыйклар арасында шундый ук киртә иде, ә хәзер аның ни әһәмияте бар?..

Дөрес сүзгә җавап юк диләр — мин дәшмәдем. Без инде кайтып та җиткән идек. Семинария каршысында тукталдык. (Ә безнең йорт шуның кырыендагы тар тыкрыкта гына). Монда, күл буенда, һава тагы салкынрак, җиле дә көчлерәк иде. Салих та:

— Туташлар, сезне бу суыкта өшетеп тотасым килми, булмаса барыгыз инде, — диде. Ә аның үз аягында шиблетлар гына иде. Сабира шуларга күрсәтеп:

— Үзегезгә карагызчы, аяксыз каласыз ич, йөгерегез тизрәк! — диде.

— Ә мин өйрәнгән инде, — диде Салих ваемсыз гына һәм саубуллашыр өчен безгә кулын сузды. — Тәмле йокы, матур төшләр сезгә, туташлар!

— Сезгә дә шулай ук, — дидем мин, кулымны биреп. — Рәхмәт спектакль өчен.

Ул миңа елмаеп кына карады:

— Рәхмәтне мин әйтергә тиеш, Гөләндәм!.. Тыңладыгыз. Тик соңгысы булмасын!

Мин килешкәндәй башымны гына кактым. Ул житез генә борылып китеп барды, без дә ашыгып өебезгә таба йөгердек.

...Әнием безне чәй әзерләп көткән. Өебез май кебек җылы, тик бераз караңгырак. Керосинга хәзер кытлык булгач, түшәмдәге зур фарфор лампаны яндырмыйча, күчереп йөртә торган җиделе лампаны гына кабызалар. Әтием ясту намазына киткән икән (Касыйм хәзрәт мәчете күршебездә генә)... Без өчәү генә чәй эчәргә утырдык. Әнием спектакль турында сораша башлады. Әйткәнмендер дә инде, безнең әни «замана имин» чакта үзе дә театрга йөрергә ярата иде. Хәтта русныкына да бар-

галый иде. Тик хәзер генә, бигрәк тә этиемне тынлап, чыгып йөрмәс булды. Әтием минем, әйткәнемчә, үтә сак кеше. Кайчагында аның әйтеп ташлаган сүзләре дә кызык кына: «Тизрәк влас булсын, ди, акмы-кызылмы — минем өчен барыбер, югалтырлык капиталым юк, ә влас кирәк, төпле властсыз тәртип-низам булмаячак», ди. Ул шуны көтеп утыра.

Әнием: «Я, ни күрдегез, ошадымы сон?»— дип сорауга Сабира, «И-и Бибимәликә апа...» — дип, гаҗәп-хәйранга калгандай бик тәфсилләп спектакль турында сөйли дә башлады. Ишеткәнен яки күргәнен әнә шулай түкми-чәчми, бизәп-матурлап, үзеннән дә өстәп энигә сөйләү аның иң яраткан эше иде... Мин сүзгә катнашмадым. Минем үзем өчен генә бик әһәмиятле, бик кадерле кичерешләрем бар — аларны бирәү белән дә бүлешәсем килми. Ике генә чынаяк чәй эчтем дә тизрәк үз бүлмәмә менеп киттем.

*

* *

Әйе, бүгенге кичә минем хәтеремнән тиз генә чыкмас, юк, чыкмас! Шунда күргән-кичергәннәр белән бөтен күңелем-хыялым тулган минем... Күпме дулкынландырган, күпме уйлар кузгаткан гаҗәеп бер спектакль. Тинчурин, Болгарская, Синаеваларның сокландыргыч уеннары... Әле дә менә шулардан айнып җиткәнем юк... Ә Фатих Әмирхан белән танышу! Моның һич көтелмәгән тәэсирен ничек кенә әйтеп бирим икән? Хәтта спектакль үзе бер мәлгә югалып, онытылып торган кебек булды. Ишеткәндә исеме генә дә мине сихерләгән мәшһүр әдип көннәрдән бер көнне миңа җылы карашын ташлар, минем кечкенә кулымны үзенең үлемсез кулына алыр дип уйлаганым бар идемени?!. Юк, болар барысы да бер кич өчен күп иде, бик күп иде... һәм боларның барысына да Салих, рәхмәт төшкере, «гаепле» ич!

Салих!.. Бөтенесеннән дә тирәндәрәк ята ул минем йөрәгемдә. Нәкъ менә бүген, бүгенге кичәдән ул миңа тагы да якынрак булып китте түгелме соң?.. Залга кереп, янәшәсенә утыргач та мин бу якынаюны тоя башладым бит! Һәм менә хәзер дә, чишенеп җылы урыныма яткач та, мин шул егет кешегә карата туган гаҗәеп бер яңа, тансык якынлык хисен йөрәгем-тәнем белән тоюдан һич арына алмыйм... Нәрсә соң бу, ходаем, нәрсә соң?!. Шулай ук бу минем буй җиткән кыз булып өлгерүем микәнни инде?!. Рәхәт тә миңа, куркыныч та... Эчке күлмәк кенә каплаган түшләремне ике кулым белән кочаклап, кемнәндер оялып качкандай, йөземне тизрәк мендәргә яшерәм.

## VI

Иртән уянып, күземне ачып җибәрүгә, караңгылы-яктылы бүлмә эчендә, колагыма әллә нинди сәер тавышлар ишетелде. Нәрсәдер ачуланып мыгырдана, ухылдый, кинәт кенә үкереп тә куя; өй үзе дә нәрсәдәндер ыңгыраша, шыгырдый, әкрен генә селкенә дә кебек. Шик юк, бу сәер тавышлар тыштан килә иде. Тиз генә үрелеп, тәрәзә пәрдәсенең бер читен күтәреп карасам, тышта галәмәт буран икән ләбаса! Шул дөньяга сыя алмыйча котырына, имеш!

Кичә Салих безне озата килгәндә, Кабан өстеннән кар себертеп искән әче җил тора-бара әнә нинди дәһшәтле буранга әйләнгән. Дәһшәтле буран, мине уяткан шикелле, аны да сискәндереп уяткандыр әле. Ул да күксел-зәңгәр күзләрен зур ачып, буран тавышын тыңлый-тыңлый уйланып ята торгандыр... Безнең аралар бик ерак та түгел бит — аның торган йорты Мещанскийда гына — ул да шушы араның якынлыгын

тоямы икән? Әллә аңа бу ара бик ерак булып тоеламы икән? Еракмы, якынмы безнең ара?.. Еракмы, якынмы?..

Я, тиле түгел диген инде мине, ни уйлап ятам бит, әй генәм!.. Буран гаепле моңа, буран шулай саташтыра, буран бөтен нәрсәне я бик якынайта, я бик еракка алып китә. Менә буран басылгач, барысы да яңадан үз урынына кайтыр, һәм мин дә, алла бирсә, чын дөресен генә белермен. Чын дөресен?!. Әмма кирәкме соң ул «чын дөресен генә» белү, кирәкме? Нәрсә китерер ул миңа — сөенечме, әллә көенечме? Ходаем, тагын әллә ниләр уйлый башладым. Юк, торырга кирәк, торырга! Бу җен-париләр оркестрына охшаган кыргый-шомлы буранны тыңлап ята торгач, бөтенләй хыялыйга әйләнерсең, билләһи!

Ә вакыт соңдыр инде, өйдәгеләр күптән торганнардыр. Безнең әти калган чәйгә торып чыгуны бер дә яратмый, тизрәк җыештырып алырга куша. Бигрәк тә уянганнан соң урын өстендә киерелеп-сузылып ятуны җене сөйми — начар бер гадәт итеп саный ул аны. Уяндыңмы — тор, шайтан коткысына бирелеп ятма, ди. Белеп әйтә әти кеше!..

Менә шул шайтан коткысына бирелмәс өчен юрганымны ачып ташладым да җәһәт кенә торып утырдым. Идәнгә аякларымны салындырып, җылы чүәкләремне эләктердем, өстемә бумази халатымны киеп алдым. Чәчләремне җыештырып, батист яулык белән бәйләгәч, песидәй тавышсыз гына басып кухняга төштем. Әлбәттә, чәйне эчкәннәр, самовар-чынаяклар да залдан кухняга күчкән иде... Әнием әз генә шелтә белдереп:

— Озак йокладың, кызым! — диде.

Иркә кызлар кебек, башым-фәлән авырта дип, ялганларга да мөмкин иде, ләкин мин инде ялганлап торырга ирендем. Бары:

— Тышта буран ич! — дип кенә куйдым.

Җавабым балаларча булып чыкты, күрәсең, әнием ирексездән көлемсерәп кенә:

— Алайса, ник тордың, буран басылганны көтәр идең, — диде.

— Ачыктым әле, — дигән булдым да, өстәл башына гына утырып, өлешемә калган йомырка тәбәсен ашый башладым, аннары сөтләп, баллап чәй эчтем. Буш чынаякларны юып, сөртеп торган Сабира миннән хәйләкәр генә:

— Я, туташ, төшеңдә ниләр күрдең? — дип сорады.

Аның ни уйлап сораганын сизәм инде, шуңа күрә юри ваемсыз гына:

— Әллә тагын, хәтерләмим,— дидем,— каты йоклаганмын.

— Ай-һай, чын микән? — диде Сабира ышанмыйча. Аннары мич янында булашкан әниемә ялт кына карап алды да пышылдап кына әйтте:

— Мөгаен, теге... зәңгәр күзле егетне күргәнсеңдер әле, керми калмас ул синең төшеңә!

— Чү! — дидем мин аңа шелтә белән. Ә ул, хәерсез, чынаякларын шалтыраткалап, миңа күз генә кысты: янәсе, курыкма, ишетмәс, ишетсә дә берни булмас!

Бу тел бистәсеннән тагын шундый берәр нәрсә ишетмим дип, мин юри тәрәзәгә карап тора башладым. Ә буран тәрәзә турында гына, әйтерсең, котырынып йон тетә — һич ни күреп булырлык түгел. Тик аның бер ярсып китеп, бер тына төшеп улавы гына ишетелә. Нигәдер эчем поша, сулкып поша, ни эшлим икән дип аптырап уйланам, ә үземнең кыл да кыймылдатасым килми. Сабира белән минем бүлмәдә карта ачарга яки дураклы уйнарга да булыр иде, ләкин аның тиктормас теленнән, җанны җәрәхәтләп үрти башлавыннан куркам. Мин бит Салих турында уйларга гына яратам, әмма аның хакында сөйләргә, бигрәк тә кеше сөйләгәнне тыңларга һич яратмыйм... Нишләргә соң?.. Буранга да ачуым килеп куя, гүя миндәге эч пошуга, гаҗизлеккә, эшсезлеккә бары ул гына гаепле!

Ә мена Сабира өчен таш яуса да барыбер. Әнә ул ап-ак оекбашларын киеп алган да жил шикелле бөтерелеп кенә йөри. Бер эшен бетерүгә, икенчесенә тотына, шул арада үзе такылдарга да, көләргә дә, хәтта җырлап алырга да җаен таба. Ул инде бишмәтен башыннан гына бөркәнеп, киез каталарын әләктереп, бер-ике тапкыр ишегалдына да чыгып керергә өлгерде. Кергәч, кагына-кагына шаркылдап көлә генә: «Чистый пәри туе! — ди.— Куеныңа кияү генә кертәсе көн икән бу, әхри!» ди. Әшәке, ничек теле әйләнә!

Юк, миңа да нидер эшләргә кирәк. Дөрес, һәр вакытта мине үзенә дәшеп-чакырып торган эшем-юанычым бар: ул — музыка, ул — залдагы пианино. Тик бүген ни сәбәптер ул да тартмый иде. Ләкин беләм — барып янына утырдым исә, минем кәефем үзгәрәчәк. Чәй яныннан торып, бүлмәмә мендем дә, халат урынына күлмәк киеп, залга төштем. Әтием гадәтенчә анда, креслосын тәрәзә яктысына тартыбрак, сары кәгазьгә тонык кына басылган газеталарны карап утыра иде.

Пианино янына килгәч, мин аңардан сорадым:

— Әти, мин сиңа комачауламыйммы?

Ул газетасыннан башын күтәрә төшеп:

— Зарар юк, уйна! — диде һәм миңа сынап кына бер карап алды.

Аның шушы кыска гына карашы мине әчтән генә булса да куырылып куярга мәҗбүр итте, гүя ул барысын да күрә, белә, аңлый иде. Ләкин бер вакытта да ни уйлаганын, шиген яки шелтәсен минем үземә туптуры әйтмәс. Бары әнием белән генә сөйләшә. Әйтергә теләгәнен әнием аша гына миңа җиткерә. Билгеле инде, кичә минем театрга баруым турында да алар арасында сүз булган, булырга тиеш — әтиемнең сынаулы карашы моны бик ачык сиздерде. Хәер, үткән эшкә салават дигәндәй, мин үзем өчен хәзер һич тә борчылмыйм, тик мена Салихка гына берәр зәхмәте тия күрмәсен дип борчылам. Әтиемнең бит бик хәтәр ягы да бар: шулай дәшми генә йөреп, берәр төрле карарга килсә, аны инде үләм дисәң дә үзгәртеп булмаячак. Ә бәлки әле әнием аңа барысын да әйтеп тә бетермәгәндер — ана кеше гадәттә җитеп килгән кызын канаты астына ала инде ул!

Мин кулларымны клавишлар өстенә сак кына салдым. Ни уйныйм икән? Бармаклар үзләреннән-үзләре клавишларның әле берсенә, әле икенчесенә баса — нечкә һәм калын авазлар чыга. Авазлар әкренләп тереләләр, җанлана, авазлар бер-берсен ишеткән кошлар шикелле кушыла башлый. Тукта, нәрсә бу?.. «Сакмар» ич! Бик тә яраткан көем, шуңадыр инде, менә үзеннән-үзе килде дә чыкты. Бик артык сузмыйча, әмма борылышларын ничек тә өзмичә генә табигый итеп, нәфис-моңлы итеп уйнарга тырышам. Сүзләрен дә эчемнән генә кабатлап барам: «Үсәдер лә таллар Сакмар су буенда, үсәдер лә кызлар әнкәләре куенында». Әтием дә бик ярата бу көйне... Ул инде укуын да оныткандыр, газетасына караган булып кына тыңлап утырадыр. Әтиемнең күңеле таш түгел, ул мине, һичшиксез, ярата, хәтта минем белән горурлана да торгандыр әле... Әмма, әмма, әти, бәгърем, ни өчен син миңа карата бу кадәр саклык күрсәтәсең?.. Нидән шикләнәсең, ни ошамый сиңа?.. Зифа талдай үсеп җиткән кызыңның үз бәхетен үзе сайларга хакы юкмыни, әти, җаным-бәгърем?!.

Уйнап бетергәч, башымны иеп, тынып калдым. Кинәт күңелем тулды, шунда ук торып, чыгып китәсем килде. Ләкин тагын әтиемнән яхшысынмадым. Әллә аңа, әллә үземә ачуым килеп, яңадан клавишларга каты гына суга башладым: до, ре, ми, фа, соль... Менә шулай! Ә авазлардан гамма хасил була, ди Салих... минем Салих абыем... Бармакларым йөрүдән туктады. Син, Салих, кулымны бәйлисең, син, Салих, күз алдымнан китеп тор әле!.. Яки кил, яныма утыр, сиңа ияреп уйнавы миңа шундый җиңел, шундый рәхәт!.. Ә болай булмый, булмый лабаса!.. Җитәр!..

...Кинәт кенә урынымнан кубып, як-ягыма да карамыйча, ашыгып чыгып киттем. Бүлмәмә менгәч тә тизрәк урын өстенә капландым. Шушы кирәк булган икән миңа, җыелып торган яшьләрнең бәреп чыгуы кирәк булган икән... Әйдә, чыксын, чыгып кына бетсен!..

Ә төштән соң буран басылды. Бераздан Сабира да җилләнеп менеп җитте.

— Әйдә, ятма мыжып... Кар көрәргә чыгабыз! — диде ул, аягымны ук тарта башлап.

— Тукта, нишлисең? Авырттырасың ич, тиле!

— Бигрәк черки тимәс чер итәр!.. Тор-тор, әйдә!

Ул җенледән котылып буламы соң — тордым тизрәк... Кухняга төштек тә, иске бишмәт, киез итекләрне киеп, бияләйләрне алып, ишегалдына чыктык. Әтием дә чыккан, сарай-каретник алларын көрәп йөри иде. Мин үземә агач көрәкнең җиңелрәген сайлап алдым. Башта капкага илтә торган юлны көрәдек, аннары, урамга чыгып, капка төбен көрәргә тотындык. Монда буран карны шактый калын салган икән, көри торгач бөтенләй кызарып, пешеп чыктык. Ә шулай да кар көрәү бик күңелле эш. Саф һава, өзлексез хәрәкәт бөтен сүлпәнлекне юа да төшерә. Бердән җиңеләеп китәсең. Аннары бит әле буран артының үзенә генә хас яме, хозурлыгы да бар. Табигать котырып-дулап алганнан соң ничектер хәлсезләнеп, юашланып кала. Тын, тымызык, бер чыбык та селкенми, шылт иткән тавыш та юк. Күк йөзе сыекланып, агарып, биекләнеп китә. Кар шикәрдәй ап-ак, чип-чиста, ә һава... чишмә суы кебек, эчеп тә туярлык түгел!.. Еш кына туктап, көрәкләребезгә таянып, ял итәбез.

— Менә кып-кызыл әнис кебек булдың,— ди Сабира миңа.

— Ә үзең соң... пешкән чия кебек, чиртсәң каның чыгарга тора!

— Минем каным чыкканчы, синең җаның чыгар! — ди дә Сабира мине төртеп җибәрә.

Мин чак-чак егылмыйча калам, ә ул чәрелдәп көлә! Аннары үзем аны ике куллап кинәт кенә төртеп җибәрәм. Сабира лып итеп карга утыра, ә мин аның өстенә ташланам.

— Кемнеке чыгар бит әле, кемнеке чыгар! — дия-дия, аны карга ничек тә тирәнрәк батырырга тырышам. Ләкин Сабира көчлерәк шул. Аяк-куллары белән мине читкә этәреп ташлый да күз ачып-йомганчы өстемә менеп тә атлана. Малайларча итеп... Мин, котым алынып, ялвара башлыйм:

— Сабира, бу нишләвең, оятсыз! Тор, җибәр! Җибәр дим! Әтием күрсә ни әйтер?!

— Әтиең күрмәс! — ди Сабира, отыры үчекләп.— Ә менә Салихның күрсә, ни әйтер иде икән, ә, Гөләндәм туташ?!. Син шуңардан куркасыңмы?

Салихның! Бу ни дигән сүз?.. Миңа шундый уңайсыз, оят булып китте ки, гарьләнүемнән күзләремә хәтта яшьләрем килеп тыгылды.

— Җибәр! — дидем мин, чак еламыйча. — Әшәке!

Сабира үзе дә минем хәлемне сизеп алды булса кирәк, шунда ук аягына басып, мине дә тартып торгызды. Өстемне кага-кага, үзенчә юатырга да тырышты:

— Я, я, ачуланма, мин бит болай гына, уйнап кына инде, әхри!..

Мин дәшмәдем, дәшәрлек хәлдә түгел идем. Уйнапмы, чынлапмы, әмма бик җан җиремә кагылды ул минем. Соңыннан тынычлансам да, әкренләп аңа үпкәм басылса да, «Салихның» дигән сүзе, мине үртәгәндәй, бик озак колагымнан китмичә торды. Бик кадерле, бик яшерен серемне бер сүз белән гүя фаш итте дә куйды. Әнә шулай үтеп китте минем... буранлы көнем!

## VII

Ахыр чиктә этиемне дә урыныннан кузгаттылар. Бүген иртән — без әле чәйдән дә тормаган идек — урам комитетының әгъзасы Хәйретдин абзый, бер хәрби кешене ияртеп, безгә килеп керде. Сабира ишек ачарга чыккан иде, алданрак ашыгып керде дә шомлы гына итеп: «Килделәр!» — диде. Без тынып калдык, тик ишектә Хәйретдин абзый күренгәч кенә азрак тынычландык.

Күп кенә еллар Сәгъдиевләрдә кучер булып торган Хәйретдин абзый, иске гадәте буенча, әүвәл кычкырып сәлам бирде:

— Әссәләмәгаләйкем, Әхмәтҗан абзый!

— Вәгаләйкүмәссаләм! — диде этием, урыныннан торып. — Әйдүк, Хәйретдин!

Шунда ук аның артыннан итекләрен кага-кага кергән хәрби кеше дә күренде.

— Без йомыш белән генә, Әхмәтҗан абзый! — диде кучер.

— Алай икән, рәхим итегез, ни йомыш?

— Менә бу кәминдәнттән килгән иптәш үзе әйтер.

Ләкин сырма бушлат киеп, билен буган, наган таккан хәрби кеше сүзен әйтергә ашыкмады. Ул иң әүвәл ни өчендер безнең зал эчен дикъкать белән күздән кичерде, бары шуннан соң гына:

— Исәнмесез, хуҗа! — диде.

— Ә үзебезнең мөселман кешесе икән әле,— диде этием, куангандай.— Аллага шөкер, туган! Әйдәгез, түрдән узыгыз! Әзрәк яманлап йөрисез! Әнисе, кая самоварыңны яңарт әле.

— Юк! — диде хәрби кеше, кулын күтәрә төшеп.— Чәйләп утырырга килмәдек, гафу!

Аннары итекләренә карап алды да бер читтәрәк торган урындыкка үрелде. Этием аңа шунда ук урындыкны алып бирде. Шуңа утыргач, хәрби кеше башындагы кызыл йолдызлы соры солдат бүркен арткарак этәрә төште дә куеныннан урталайга бөкләгән бер дәфтәр тартып чыгарды. Этием башта аның алдында нишләргә белмичәрәк торды, аннары үзе дә чигенебрәк бер урындыкка утырды.

Хәрби кеше өшегән бармаклары белән дәфтәренең битләрен көчкә генә ачкалап карарга тотынды.

— Исем-фамилиягез?

— Безнеңме?.. Әхмәтҗан булабыз, Әхмәтҗан Солтанов.

— Дөрес, Әхмәтҗан Солтанов! Ничә яшьтә?

— Тиздән илле биш тулачак, алла боерган булса!

— Кайчан ул «тиздән!» Берничә көннән, берничә атнадан што ли?

— Юк, алай ук тиз түгел, кем, иптәш, туган!.. Язга, апрель аенда, алла бирсә!

— Ә-ә, ерак икән әле! — диде хәрби кеше, ияген чөеп. — Менә шулай, Әхмәтҗан абзый, бүген сез тимер юл комендатурасына барырга тиешсез.

Этием сизелерлек агара төште.

— Ни өчен? Рәхим итеп, шуны әйтмәссез микән?

— Рәхим итмичә дә әйтәбез аны!.. Эшкә мобилизовать итәбез сезне!

— Алай. Ниндирәк эшкә инде, белергә мөмкин булса?

— Кар көрәргә!.. Тимер юлны кардан чистартырга. Составлар утә алмый тора, абзый кеше, шәһәргә утын керми, утсыз-сусыз калуыбыз бар. Положение шундый, халыкны мобилизовать итәбез!..

— Аңлашыла! — диде этием. Ул инде шактый тынычланган иде, ләкин шулай да тамагын кыргалап янадан сорады бит:

— Эһем-эһем... Мәҗбүри индеме бу?

Хәрби кеше этиемә сәер генә карап алды:

— Ә сез ничек уйлыйсыз?
— Гафу итегез, туган, белмәгәнгә күрә генә соравым.
— Әллә эштән куркасызмы? — диде хәрби кеше, аны тыңламыйча.
— Юк, эштән курыкмыйбыз. Без эшләп өйрәнгән кеше.
— Байларда доверенный булып, шулаймы?
— Анысы соңыннан. Ә башта ат карап та йөк ташып дигәндәй...
— Менә, бик әйбәт!.. Яңадан рабочий булып карагыз... Шулай, абзый кеше, сәгать уннан да калмагыз! Көрәгегезне дә онытмагыз, аннары үзегезгә бер өч көнлек азык та алыгыз!
— Нигә? — диде әтием аптырабрак. — Өйгә кайтырга мөмкин булмасмыни?
— Ераграк җибәрсәләр — булмас!
Хәрби кеше урыныннан торды, тагын ни өчендер зал эченә күз йөртеп чыкты. Яңа гына күргәндәй миңа бик төбәлеп карады. Әйтәсе килмәгән шикелле, авыз эченнән генә «борчыдык!» дип куйды, аннары кычкыра биреп:
— Хушыгыз! — диде.
— Хушыгыз, хуш! — диде әтием, аларны озата чыгып.
Ул борылып кергәч, без барыбыз да берничә минут сүзсез генә утырдык. Бу хәлгә ничек карарга да белми идек. Бер яктан, хәвефләнергә урын да юк кебек, эшкә генә куалар, икенче яктан, әллә ничек хәвефле дә кебек — өеңә кире кайтармасалар нишләрсең?!.
Ахырда әтием башлап телгә килде:
— Ярар, баш салындырып утыра торган чак түгел, аллага тапшырдык! Әнисе, әзерләнергә кирәк.
Әнием авыр гына сулап урыныннан торды.
— Ярый ла өч кенә көнгә булса!
— Юл чистарту белән генә эш бетсә, өч көнгә дә бармас. Вакыт күпме әле?
— Тугызынчы ярты, — дидем мин.
— Ике генә рәкәгать намаз укып алырга өлгерәм икән әле... Ашыгыйк. Чакырганнан иртәрәк бару хәерле.
— Нәрсәләр әзерлим соң? — диде әнием.
— Җылкы ите куярга онытма, ә калганын үзең кара!
Әтиемне калдырып, без өчебез дә кухняга чыктык.
Ә бераздан мин яңадан әйләнеп кердем. Әтием келәм өстенә намазлык җәеп тора иде.
— Ни кирәк, кызым?
— Саквояж кирәк иде.
— Нинди саквояж? — диде әтием гаҗәпләнеп.
— Теге үзең белән йөртә торган саквояж... азыкларыңны салырга!
— Әй башсызлар, башсызлар! — диде әтием ачынып. — Мәскәү байларына товарга бармыйм ласа мин!.. Бөрмәле капчыкка салыгыз барысын да, ишетәсеңме, бөрмәле капчыкка!
Анысы да табылды тагын... Ит-май, чәй-шикәр, ике бөтен икмәк, сөлге-сабын, яңа оекбаш — шуларның барысын да киндер капчыкка тутырып, бавын да тартып бәйләп куйдык. Ә бер ярты сәгатьтән әтием иске бишмәтен, иске бүреген, олтан салган киез итекләрен киеп, билен яшел билбау белән буып, ике кат бияләйләрен дә кулына алып, әзерләнеп бетте. Чыгып китәр алдыннан утырып дога кылдылар, аннары әнием ашыгып киенә башлады.
— Син кая? — диде әтием.
— Озата барам.
— Кирәкмәс, әнисе, Себер җибәрмиләр ич.
— Әзрәк кенә булса да барыйм инде, — диде әнием, ялваргандай.
— Әзрәк кенә дисеңме?.. Әзрәк кенә ярый, алайса! — диде әтием гүя аны кызганып.

Алар чыгып киткәч, без Сабира белән икәү генә калдык. Кызык хәл!.. Әтиемнең элек юлга чыгып китүләрен ихтыярсыздан исемә төшерәм (заманында Мәскәү, Петербург, хәтта Варшавага еш кына барып йөрде ул). Әмма ничек чыгып китә иде?!. Бер көн алдан мунча кереп, сакал-мыегын төзәтеп куяр иде. Өстенә Петербург мастерларыннан махсус тектергән иң яхшы тройкасын кияр иде; жилет кесәсендә алтын чылбырлы сәгать, бармакларында — алтын балдаклар... Җәен — бостоннан теккән җиңел генә пальто, кышын — мех эчле тун... Ә вокзалга шәп ат җигелгән резин ходлы пролеткада гына илтеп куялар иде үзен! Әнә шулай аның китүе дә, кайтуы да безнең өчен бәйрәм генә иде, чөнки әтием барган бер җиреннән безгә кыйммәтле бүләкләр алып кайтмыйча калмый иде... Кайчан гына иде бит әле бу?! Заманның шундый кинәт, тиз үзгәрүенә исең-акылың китәр! Нишлисең, язмыштан узмыш юк, диләр. Тик шулай да авыр, эч поша, хәтта өебез дә бушап, күңелсезләнеп калгандай булды. Мин түгел, әнә Сабира да көенә.

— Абзый кызганыч! Юкка үзем генә барыйм дип әйтмәдем.

— Кит, җүләр, шундый куркыныч җиргә! — дим мин аңа гаҗәпләнеп.

— Кемнән, нәрсәдән?

— Анда торганы ирләр генә ич!

— Ирләр үзләре миннән курыксыннар! — ди Сабира гайрәтләнгән булып. — У-у, мин ул ирләрне!

Мин ирексездән көләм:

— Куырып ашар идең бугай!.. Ләкин әтием җибәрер иде дисеңме?

— Менә анысы дөрес! Җибәрәме соң?!

Мондый көнне һәм мондый чакта нәрсәгә тотынырга да белмисең. Ә кирәк, ниндидер эш-хәрәкәт кирәк — шунсыз эч пошуын басып булмаячак. Сабира да шуны чамалап, ахрысы, әрле-бирле йөренде дә, миңа килеп:

— Әйдә, әхри, кер юабыз! — диде.

Әлбәттә, бу эш инде, ләкин мин кулларыма карыйм: эссе, сабынлы суда бер дә бозасым килми шул үзләрен... Сабира, очлы күз, шуны сизеп алды бит:

— Ә-ә, Салих әфәнде киләсе көнмени әле бүген? — дигән булды.

— Булса соң!

— Музыкәл бармакларыгыз кызарыр бит, туташ!

— Җен, пәри, албасты! — дидем мин кинәт кызып. — Телеңне тартып кына өзәр идем мин синең!.. Әйдә, чыгар керләреңне, юабыз!

— Я, я, нәнәм, чәпчемичә генә! — диде Сабира, шунда ук мине юмалап. — Мин аңлыйм ич, барысын да аңлыйм... Син миңа булышырсың гына, яме?

Шулай итеп, без эшкә дә тотындык. Сабира керләрне чыгара башлады, ә мин утын керттем, су керттем. Плитәне ягып җибәрдек. Ул арада әнием дә кайтып керде. Кәефе начар түгел иде кебек. Без аңардан, кая кадәр озаттың, ни күрдең, дип сорадык.

— Печән базары чатына хәтле генә, — диде әнием. — Халыкны шактый күп җыйганнар икән, араларында бик могтәбәр кешеләр дә бар. Гаеткә барган шикелле төркем-төркем булып стансага таба киттеләр.

— Тәкбир әйтмәделәрме соң? — диде Сабира.

Әнием Сабираның көлеп сораганына каршы ачуланыбрак:

— Юкка тотынгансыз бу эшкә! — диде. — Кеше озатканнан соң идән себермиләр, кер юмыйлар, — белергә кирәк иде.

Бу юлы инде Сабира дәшмәде. Көч белән баса-баса керен юа гына бирде. Мин инде кечкенә ялгашта үземнең вак-төяк керләремне генә юыштырдым. Кулларымны сакладым.

Ә кичкырын, билгеләнгән вакытта, Салих та килде. Әмма һич булмаган бер хәл — ул ишектән үк көлә-көлә килеп керде. Моңа мин бик

гажәпләндем. Шулай да ул яныма килеп кулымны кыскач, көлүеннән туктап, әдәп белән генә миннән сорады:
— Каефегез ничек, Гөләндәм?
— Рәхмәт! Ә сезнеке?
Ул яңадан әкрен генә көләргә тотынды. Мин тагын аптырап калдым:
— Ни булды, ник көләсез?
Ләкин ул гадәтенчә көлеп туктагач кына ни булганын сөйли башлады:
— Беләсезме, әле сезгә килешли генә шундый бер кызыкка очрадым. Барабызчы агай... (ул тагын әзрәк кенә көлеп алды), әйе, менә чикмән якасын күтәреп, үрәчәле чанасына аягүрә баскан барабызчы агай, дилбегәсен болгый-болгый, Мәскәүски буйлап чаптырып килә. Артында моның бер мөселман абзый бөрешеп кенә утырып бара. Кызу чапкан ат чатка җиткәч кинәтрәк борылды, ахрысы — бу абзый чанадан очып төште дә калды. Ә барабызчы шуны сизмичә атын куа да куа. Урамдагы кешеләр аңа төрле яктан: «Әй, Гыйбад, юлчыңны төшереп калдырдың бит!» — дип кычкыралар, сызгыралар, ә агайның гамендә дә юк, борылып та карамыйча китте дә барды... Инде күз алдыгызга китерегез (ул тагын көлә башлады), агай... агай теге абзый әйткән җиргә барып җиткәч, атын туктатып, борылып караса, пассажиры юк, пассажирдан җилләр искән! Я, кызык түгел диегез?!.
Кызык икән шул, ләкин мин нигәдер көлә алмадым. Бары:
— Теге очып төшкән абзый үзе торып, артыннан йөгермәдемени? — дип кенә сорадым.
— Кая йөгерсен! — диде Салих, батист яулык белән күзен, маңгаен сөрткәләп. — Ул, бичара, түгәрәк, юан гына бер кеше — онга баткан таракан шикелле көрткә чумды. Кемдер тартып чыгарды үзен! — Салих шунда ук җитдиләнеп, тирә-ягына каранып алды.— Гафу итегез, ә этиегез кайда соң?
Мин икеләнебрәк калдым: әйтергәме-юкмы? Юл чистартырга җибәрделәр дип әйтүе ничектер кыен да, оят та кебек иде. Шуңа күрә:
— Этием өйдә юк шул әле, — дию белән генә чикләндем.
— Алайса, безнең дәрескә кайтып өлгерер, — диде Салих, елмаеп кына.
— Белмим тагын... бәлки бүген кайтмас та. Аны бит эшкә җибәрделәр.
— Әх, шулаймыни?!. Кая, нинди эшкә инде?
Ләкин минем кыенсынып торуымны күргәч, ул бераз гажәпләнеп өстәде:
— Хәер, әйтмәсәгез дә була!
— Юк, ни өчен? — дидем мин, уңайсызланудан ашыгып.— Этиемне начар эшкә җибәрделәр.
Салих миңа туры гына карап, иңбашын җыерып куйды:
— Эшнең авыры була, хәтта пычрагы була, әмма начары була микән? Бер дә ишеткәнем юк, Гөләндәм!
— Соң... тимер юл чистарту, сезнеңчә, яхшы эшмени инде ул?
— Авыр эш. Бигрәк тә Әхмәтҗан абзый кебек өйрәнмәгән кешегә.
— Менә шул шул! Олы кеше дип тә тормадылар!
— Алай икән!.. Күрәсең, шулай кирәк булгандыр инде, башкача мөмкин булмагандыр... Ләкин сез артык борчылмагыз, Гөләндәм. Әхмәтҗан абзыйга кумәк халык арасында әллә ни авыр булмас, яшенә карамастан, таза кеше ич ул!
Мин дәшмәдем, минем бу хакта сүзне тизрәк бетерәсем килә иде. Ләкин Салихның әйтер сүзе бетмәгән икән әле.
— Беләсезме, Гөләндәм, — диде ул, аз гына тынып торганнан соң, — шәһәрнең хәле бик авыр бит! Азык юк, ягулык юк, юллар җимерек. Без менә йөргәч күрәбез: мәктәпләр ягылмый, лазаретлар ягылмый, ә анда

бит мәжрүх солдатлар ята. Билгеле инде, яңа власть ничек кенә булса да шушы авыр хәлне җиңеләйтергә тырыша. Ләкин аңа халыкның ярдәме кирәк, Гөләндәм, аңлыйсыңмы?

Әлбәттә, бик аңлашыла, бигрәк тә Салих шулай гади генә төшендереп тә биргәч, тик миңа бу хакта сүз алып баруы читен иде. Шуңар күрә мин бары: «Аңлыйм, Салих абый!» дию белән генә чикләндем.

— Менә бик әйбәт! — дип куйды ул, ләкин шулай да сорады: — Я соң, чибәрем, бүген нишлибез, сабак укыйбызмы, әллә калдырып торабызмы?

— Юк, нигә калдырырга? — дидем мин гаҗәпләнеп.— Мин бит сезне көн озын көтеп тордым!

— Шулай укмыни?!. Утырыштык, алайса!

Бу юлы пианино янына ул үзе башлап утырды. Ләкин уйнарга ашыкмады. Миңа таба борылып, сер әйткәндәй әкрен генә:

— Гөләндәм, мин сезгә бүген ике гаҗәеп нәрсә китердем бит әле,— диде.

— Нәрсә икән ул? — дидем мин, шунда ук кызыксынып.

— Ашыкмагыз, хәзер белерсез... Ләкин башта шуны әйтәсем килә: без моңарчы гел халык көйләрен, ягъни кем тарафыннан чыгарылуы билгесез булган көйләрне уйнадык. Ә бүген мин сезгә чыгаручысы мәгълүм булган ике көй уйнап күрсәтмәкче булам.

— Андыйлар да бармыни?

— Бар шул! Берсен аның сез дә белергә тиешсез. Бу — Заһидулла абзый Яруллин тарафыннан язылган «Тукай маршы». Ма-рш! — аңлыйсызмы?

— Беләм, ишеткәнем дә бар.

— Ул халык арасына бик тиз таралды. Без дә аны еш кына уйныйбыз.

— Заһидулла абзый үзе дә сезнең оркестрда уйнаган түгелме соң?

— Әйе, баштарак уйнады. Аны «Сәйяр»ның беренче музыканты диярга була. Тукай, Галиәсгар абзый, Кариевлар белән якыннан аралашкан кеше. Аннары мине дә бит рояль телләренә басарга башлап ул өйрәтте. Минем беренче хәлфәм!

— Шулаймыни? Күптәнме?

— Шактый вакыт узды инде аңа.

— Сез үзегез аны эзләп таптыгызмы?

— Дөресрәге, ул мине «тапты!»

— Кызык бу, сөйләгез әле!

— Сөйләсәм, озакка китмәс микән?! — диде Салих, ак маңгаен ышкып. — Кыскасы, болай булды. Малай чактан ук минем бармакларым тик тормый иде инде. Апам миңа кечкенә гармун алып бирде — мин шуны ничектер ансат кына тарткаларга да өйрәндем. Ә безнең җизнигә — безнең җизнине беләсезме икән, Шиһап Әхмеров, китапханә тотучы — менә аңа гел генә әдипләр, шагыйрьләр килеп йөриләр иде. Шул җөмләдән, Заһидулла абзый да бездә еш кына була торган иде. Мин, билгеле, алар алдында кечкенә тальянымны кычкыртмый идем. Әйтергә кирәк, ни өчендер кешеләрдән яшеренеп, ялгыз гына уйнарга ярата идем. Шулай да Заһидулла абзыйның сизгер колагы минем караңгылар артына посып гармун тартуымны ишетеп алган бит! Бер ишетә бу, ике ишетә, аннары мине чакыртып алып, үзе алдында уйнарга куша. Ә мин, тиле, аяк терәп киреләнәм, оятка калудан куркам, янәсе... Тик җизни кыстагач кына уйнап күрсәттем. Шуннан соң Заһидулла абзый җизнигә әйтә: «Синең бу кайнешеңә ходай бик сизгер бармаклар биргән икән, Шиһабетдин әфәнде, чынлабрак шөгыльләнергә кирәк үзе белән, югалып калмасын», ди. «Малайда нидер барын без үзебез дә чамалый идек», ди җизни дә. Менә шул сөйләшүдән соң озак та үтми, безнең мәгърифәтле җизнәбез ничектер туры китереп, бер тотылганрак рояль дә сатып

ала. «Бу синең өчен, Салих!» ди ул миңа. Беләсезме, Гөләндәм, моның кебек зур бүләкне минем күргәнем дә юк һәм яңадан күрүемә ышанмыйм да. Көннәр буе мин шул көзгедәй ялт иткән, эченә әйтерсең дөньяның бөтен сихри авазларын җыйган мәһабәт, кара, өч аяклы «өстәл» тирәсендә генә әйләнә торган булдым. Менә шул чакта инде Заһидулла абзый мине рояль алдына утыртып, бер изге эшкә керешкәндәй бисмилласын әйтеп, рояльнең ак-кара телләренә басарга да өйрәтә башлады. Һәркөн диярлек үзе теләп, бары мине өйрәтү өчен генә (әлбәттә, бер нинди мөкяфәтсез!) махсус килә торган иде бу җаны-тәне белән музыкага бирелгән гаҗәеп кеше! Ихтимал, шул чакта мин музыканың аңа бөтен гомерен дә, йөрәген дә багышлаган кешеләр эше генә булуын аңлап та калганмындыр!

Салих тынды, минем аңа туп-туры карап утыруыма уңайсызлангандай, башын бераз гына читкә дә борды. Ә мин карамыйча булдыра алмыйм, чөнки аның сүзләрендә һичбер төрле фальшь юк, үзен-үзе күтәрергә, күрсәтергә тырышу юк — барысы да бик табигый һәм бик гади, чөнки аның өчен музыка бары чын мәхәббәт эше икән! Димәк, бернинди ясалу-кылануларга мохтаҗ түгел ул!

— Инде рәхим итеп, хөрмәтле Заһидулла абзыйның «Тукай маршы»н уйнап карыйк! — диде ул, мине уйларымнан айнытып. Ләкин мин, аңа башларга ирек бирмичә, тиз генә сорадым:

— Ә сез Тукайның үзен күрдегезме?

— Күрдем, бәгырь, күрдем!

— Кайчан, кайда?

— Безгә, җизни янына килгән чагында.

— Әйтегез әле, ниндирәк кеше иде ул?

— Бик зур кеше иде, бәгырь!

— Мин аның шагыйрьлеген әйтмим, ә кыяфәткә ничегрәк иде дим... Имеш, ул буйга кечкенә, арык кына бер кеше булган диләр, дөресме шул?

— Дөрес, әмма буйга бик озын кешеләр дә аның алдында түбәнчелек белән башларын иялар иде, — диде Салих, хәйләкәр генә елмаеп.

— Мин чынлап сорыйм, ә сез көләсез! — дидем мин, әзрәк үпкәлисем килеп.

— Юк, мин көлмим, — диде ул, шунда ук җитдиләнеп. — Хикмәт аның буендамыни, Гөләндәм?!.

— Әлбәттә, түгел! Ул кадәресен генә мин дә аңлыйм инде. Ә сезгә аның белән сөйләшергә туры килдеме?

— Тукай минем белән сөйләштеме дип сорамакчысыз — шулаймы? Ул миннән дәүрәк ич!

— Гел шаяртасыз, Салих абый!

Ләкин Салих нидер үзенекен уйлый башлаган иде, ахрысы — дәшми калды. Тик бераздан гына ул шундый ук уйчанлык белән:

— Мин бер нәрсәне бик ачык хәтерлим, Гөләндәм! — диде. — Көннәрдән бер көнне миңа, ниһаять, аның алдында да уйнарга туры килде. Билгеле, Заһидулла абзыйның бик нык кыставы аркасында гына, югыйсә, мин үзем һич тә җөрьәт итә алмаган булыр идем. Чөнки бу махсус Тукай өчен, ул ишетсен дип уйнату иде. Әле башка кунаклар да бар — алар да көтәләр. Үзенә күрә бер имтихан дисәм, һич тә артык булмас!.. Уйнаган чакта мин моны бөтен җаным-тәнем белән дигәндәй сизеп тордым, ә ул, Габдулла абый, йомшак диван башында бөрешеп кенә шылт та итмичә тыңлап утырды. Ул инде бик сырхау иде... Бер көйне уйнап бетергәч тә кунаклар шаулашып миңа: «Менә афәрин, менә рәхмәт, шәкерт!» диештеләр. Ләкин мин Габдулла абыйның тавышын ишетмәдем — ул үзенең почмагында һаман шулай тын гына, хәрәкәтсез генә утыра бирде. Әмма ул минем яңадан уйнавымны көтә иде, мин моны ничектер йөрәгем белән сиздем... Һәм аның өчен генә тагын ике көй уйнап чыктым. Шунын соңгысы — «Әллүки» иде.

Салих ни өчендер кинәт кенә пианино өстенә иелә төште һәм көттеребрәк әкрен генә: «Менә шул!» дип әйтеп куйды. Мин дә бер мәлгә сүзсез калып, тынып тордым. Аннары сак кына сорадым:

— Әмма соңыннан ул сезгә ни дә булса әйткәндер бит?

— Ишетмәдем, бәгырь, ишетмәдем! Уйнап бетергәч тә мин торып чыгып киттем — әйтерсең, бизгәгем кузгалды, качтым тизрәк! Балалык инде... Шулай да Габдулла абый нидер әйткән булырга тиеш, чөнки шактый вакыттан соң, ул үзе үлгәч инде, Заһидулла абзый миңа бер сүз чыкканда әйтә куйды: «Бел, Салих, син Тукайның фатихасын алган кеше!» — диде. Гаҗәп зур йөк бу минем өчен, әгәр чын булса?!.

— Чыгып китмәгән булсагыз, аның фатихасын үз авызыннан ишеткән булыр идегез, — дидем мин.

— Ә бәлки чыгып китүем кирәк тә булгандыр?!

— Ни өчен?

— Чын дөресен шәкертнең үзеннән бигрәк хәлфәсенә әйтәләр ич!..

— Шәкерт күңелен табу да кирәк бит!

— Зарар юк. Я, артык масаеп киткән булыр идем. Ә масаю ул вак, көнче кешеләр эше. Ярый, Гөләндәм туташ, сүз бозау имезер ди, эшкә күчик, булмаса!

— Мин тыңлыйм, Салих абый!

Салих пианинога тартылыбрак утырды, кулларын җәя төште, ләкин башлап киткәнче әүвәл шуны әйтте:

— Тукайның үлеменә карата җыр туарга тиеш иде — тумыйча калуы мөмкин түгел иде. Һәм ул җыр туа — шагыйрьнең бик яраткан музыканты Заһидулла абзый Яруллин күңелендә туа ул җыр!.. Башта Заһидулла абзый җырын «Тукай хатирәсе» дип атый, ләкин озак та үтми, әзрәк үзгәреп, «Тукай маршы»на әйләнеп китә.

Сүзләренә игътибар итегез:

Ташладың син безне, Тукай,
мәңгелеккә ташладың.
Син хәзер дөньяда түгел,
үзгә хаят башладың[1].

Үзгә хаят!.. Халык күңелендә мәңге яшь башлау!.. Инде тыңлагыз!..

Гадәттә нәфис-йомшак кына уйнаган Салих бу юлы кулларын киң җәеп, батыр-көчле итеп башлады. Хәтта үзе дә бераз арткарак каерыла төште. Һәм музыка да, үзенең остасын тапкандай, ничектер бик куәтле булып яңгырады.

— Ишетәсезме, бәгырь? — диде Салих дәртләнеп уйный-уйный. — Күпме уй-хис бу музыкада! Олы хәсрәттән тирән әрнү бар, хәтта тәкатьсез үксү дә ишетелеп кала, әмма шул ук вакытта ул кешенең рухын төшерми, өметсезләндерми, киресенчә, ул аны үстерә, дәртләндерә, гүя зур-зур эшләргә канатландыра!.. Ихлас! Ә менә бу җирендә — тыңлагыз әле, тыңлагыз! — ниндидер бер тантаналы горурлык яңгырый түгелме соң?!. Тукай өчен, Тукайны тудырган халык өчен горурлык — ишетәсезме сез шуны?!.

Әйе, ишетәм мин, ишетәм! Ишетү генә түгел, әллә нинди бер сызланулы ләззәттән, билгесез бер сөенечтән хәтта елыйсым да килеп китте. Музыка һәм халык икесе бергә үрелсә, бик тирән яткан тойгыларны да кузгата икән ул! Аннары минем Салихтан: «Сез дә шушының кебек музыка яза алыр идегезме?» дип сорыйсым килә, ләкин куркам, бик яшерен теләгенә (әгәр шундый теләге булса) саксыз орынудан куркам!

Ике тапкыр уйнап чыккач, Салих туктады һәм, хәлсезләнгәндәй иңбашларын салындыра төшеп, бераз тынып торды. Аннары миңа урын биреп:

---

[1] Бу юлларны миңа шагыйрь Нури Арсланов, исенә төшереп, язып бирде.— Ә. Е.

— Инде сез уйнап карагыз! — диде. — Нотасыз гына — нотасын язып килергә өлгерә алмадым.

— Юк, — дидем мин, — сездән соң уйнарга кулым бармый, кыстамагыз!

— Ник?

— Шулай инде, җөрьәт итә алмыйм... Ә сез миңа икенчесен дә уйнап күрсәтегез әле, булмаса!

— Ярый, алайса, — диде Салих һәм бер иңбашын сәер генә сикертеп куйды да яңадан пианино каршысына тартылыбрак утырды.— Икенчесе... икенчесе, Гөләндәм, романс булачак!

— Романс?! Чынлап әйтәсезме?

— Әлбәттә! Башта марш иде, ә хәзер — романс! «Мәхәббәтем» дип атала.

— Кызык! Кем язган соң аны?

— Фәттах Латыйпов дигән җырчы. Ә сүзләре шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләйнеке. Ничек әле үзе? — Ул сүзләрен исенә төшереп, әкрен генә җырлап карады:— «Тормыш синсез — җилле диңгез, күз карам!» — һәм шуңа ялгап уйнап та китте.

Әйтәсе дә түгел, бу моңарчы без белгән, без уйнаган көйләрнең берсенә дә охшамаган иде. Моның яңгырашы, агышы бөтенләй яңа — колак ишетмәгәнчә!.. һәм сүзләре дә бик сәер — ничек кенә дип әйтергә? — әллә нинди шашыну, өзгәләнү бар сүзләрендә:

Миннән ник качтың?
Күккә ник аштың?
Ник сөйдең дә ник
Тәмугка аттың?..

Көе дә сүзләренә бик туры килә икән — шундый ук тирән сагыш, әрнү, йолкыну ишетелеп тора үзеннән. Кыскасы, ошады миңа бу романс!

Уйнап бетергәч, Салих миннән сорады:

— Я, ничек соң, бәгырь?

— Ә сезнеңчә ничек? — дип сорадым мин үз нәүбәтемдә.

— Мин — гашыйк! — диде Салих бер генә сүз белән.

— Шул кадәр үк әйбәтмени?

— Көнләштерерлек дәрәҗәдә!.. Әмма шунысы зур куаныч — бездә, ниһаять, чын музыка туа башлады бит!.. Менә сиңа марш, менә сина романс!.. Ләкин болар әле беренче карлыгачлар гына... Болар артыннан бер заман симфонияләр, хәтта опералар туа башлар!.. Фатих абзаңның «Фәтхулла хәзрәт»тә язганнары коры хыял гына булып калыр дисеңме әллә?!. Татар операсын ул үзе күрәчәк әле, насыйп булса!

— Кайдан сездә бу кадәр ышаныч?

— Вакыты җитте, Гөләндәм, вакыты!

— Әмма ләкин кешесе дә кирәк ич әле... Композиторларың кайда?

— Алары да булыр!.. Милли азатлык нәрсә өчен соң ул?! Безнеңише изелгән халыкка юл ачу дигән сүз түгелмени? Ә талантлар табылачак, бар алар!

Минем тагын аңардан: «Бәлки сез дә музыка яза башларсыз әле?» дип сорыйсым килде, ләкин бу юлы да ни өчендер тыелып калдым. Дөресен генә әйткәндә, мин инде әчке бер сизенү белән аның оста уйнаучы гына булып калмаячагын, иртәме-соңмы үзе дә музыка яза башлаячагын сизә идем. Тик менә үзенең бу хакта һичбер сүз әйткәне юк. Хәтта ялгыш кына да...

— Я, «Мәхәббәтем» бик ошагач, үзегез дә уйнап карагыз инде, — диде ул миңа.

Бу юлы мин баш тартмадым. «Мәхәббәтем»не күңелемдә чакта уйнап карыйсым килде. Салих торып бер читкә китте, мин әкрен генә башладым. Юк, болай түгел шикелле... Ничегрәк соң әле? Тукта, менә

болай... Әйе, әйе, нәкъ шулай!.. Көйне әйбәт кенә «тотып», ишетептоеп, шуңа тәмам бирелеп-дәртләнеп, уйнап чыктым ахырда үзен!.. Хәтта Салихның артыма килеп басканын да сизмәдем. Бары колагыма бик якын иелеп, назлы-йомшак кына пышылдап:

— Гөлгенәм, мин хәйран! — диюен ишеткәч кенә сискәнеп киттем. Аның җылы сулышы ачык муеныма тиде — мин, үбә ахрысы дип, бер мизгелгә бөрешеп, өнсез булып калдым. Ләкин ул... үпмәде, яныма утырып, сул кулымны ике учына алды да, күзләремә карап, яңадан кабатлады:

— Мин хәйран!.. Сез, акыллым, мелодияне шул кадәр тиз тотып аласыз... мин ни әйтергә дә белмим. Талант, чын музыкаль талант — бары шул гына!

— Арттырасыз, Салих абый! — дидем мин, сөенечемнән балкып.

— Һич юк! — диде ул җитди генә.— Арттырырга яратмыйм, аннары мондый нечкә эштә арттырырга ярамый да. Беләсезме, мин сезне бер бик әйбәт музыка әһле белән таныштырам әле.

— Кем ул?

— Әхмәтсолтан Габәши...

— Ә ни өчен мине аның белән таныштырмакчы буласыз?

— Күрсен, уеныгызны ишетеп карасын. Ул бик укымышлы кеше, музыканы бик яхшы белә... Үзе... бик сөйкемле дә,— диде Салих елмаебрак.

— Юк, кирәкми, таныштырмагыз... Я гашыйк булып куярмын! — дидем мин дә, сүзне уенга борасым килеп.

— Эһем, эһем! — дип тамак кыргалады Салих.— Мин каршы түгел, лаек кеше!

— Шулай да мин теләмәсәм?

— Барыбер таныштырам!

— Ни өчен соң? Нигә кирәк ул?

— Кирәк, бәгырь, кирәк! Сезнең үзегез өчен кирәк!

— Ә минем менә бер кем белән, хәтта бик әйбәт, бик сөйкемле кеше белән дә танышасым килми.

— Бу нинди кирелек? — диде Салих кинәт ачуланган булып. — Ахыр чиктә сез, туташ, мине тыңларга тиешсез. Онытмагыз — мин сезнең хәлфәгез!

Ә минем юри киреләнәсем килә, чынлап үпкәләр микән дип сынар өчен генә киреләнәсем килә:

— Әгәр тыңламасам?

— Ул чагында мин сезгә җәза бирәчәкмен!

— Нинди җәза?

Салих инде көлеп җибәрүдән чак тыела иде, шулай да кашларын җыера төшеп, әйткән булды:

— Мин сезне, туташ, сандык күтәртеп, әнә, почмакка бастырып куярмын!

Инде мин ирексездән көлеп җибәрдем:

— Ү-ү, сандык бик авыр ич ул! Безнең сандыкларны дүртәр кеше генә күтәрә ала!

— Ә мин, — диде Салих көлә-көлә, — күрше Касыйм хәзрәт мәдрәсәсеннән берәр шәкертнең таракан оялап беткән кечкенә сандыгын алып чыгармын да шуны эчендәге бөтен чүп-чарлары белән сезгә күтәртермен!

— Әбәү, кирәкми, юк-юк, тараканнардан бик куркам! — дидем мин, кулларымны бала шикелле селтәп.

Икебез дә күзгә яшьләр килгәнче рәхәтләнеп бер көлештек. Ниһаять, көлешеп беткәч, Салих миңа, үзеннән-үзе хәл ителгән мәсьәлә турында искә төшергәндәй:

— Ярый, Гөләндәм, Солтан абый белән кайчанрак очрашуыбызны мин сезгә хәбәр итәрмен, — диде. — Ә хәзер рөхсәт итегез, миңа китәргә вакыт!

— Нигә бик тиз?

— Егетләрем көтә! — Аннары иелә биреп әкрен генә әйтте: — «Мәхәббәтем»не онытмагыз!..

...Әтием өйдә булмагач, бу юлы мин аны үзем озата чыктым. Тышкы ишек төбендә безнең ара күкрәк күкрәккә тияр дәрәҗәдә бик якын калган иде, мин стенага елыша төшеп, нидер көткәндәй ирексездән, хәтта сулышымны бүлеп, тынып тордым. Ләкин Салих миңа орынмады, бары сул кулымны каты гына кысты да колагыма шыпырт кына «Хуш, Гөлгенәм!» диде һәм шунда ук ашыгып чыгып та китте. Мин дә, әллә үкенечтән, әллә сөенечтән, тирән генә бер көрсенеп, тизрәк өйгә ашыктым.

Салихны озаткач, бераздан өчәү генә кичке чәйгә утырдык. Әтием юк, әтием кайдадыр юл чистарта. Ни хәлдә йөридер инде ул, бичара?!, Әнием күңелсез, ләкин тыштан сабыр — ул бер дә уфтанырга яратмый. Минем дә, кинәт вөҗданым уянгандай, җаным сыкранып куйды: әтием шундый хәлдә чакта мин монда берни булмагандай романс өйрәнеп ятам. Ярыймы, килешәме бу?.. Хәер, әллә ни хәсрәткә тарырлык хәвеф юк та кебек, ә шулай да күңел борчыла, эш поша.

Чәйдән соң үз урыннарыбызга таралыштык. Өй эче тып-тын, йоклап кына үткәрә алмаслык кышкы төн — нишләргә?.. Иренеп кенә чишендем дә, җылы-йомшак урыныма ятып, Купринның «Аң»да татарча басылган «Сүләмиф»ен укый башладым. Бик матур, бик шигъри язылган әсәр, ләкин ни сәбәптер йотылып кына укый алмыйм — уйларым мине һаман каядыр читкә алып китәләр. Уйларым да әллә нинди — ни башы, ни ахыры юк, бик биектән аккан күчмә болытлар шикелле килә торалар, китә торалар... Аптырагач, журналны ташлап, урынымнан торам, лампаның филтәсен басып, тәрәзәгә килəм. Җаным тыныч түгел, җаныма нидер кирәк минем... Ә тышта гаҗәеп тын, сыек-зәңгәр төн, кеше эзе төшмәгән ап-ак чиста кар... Ә биек салкын күктә яңа гына туган нечкә ай!.. Тын гына, серле генә сызылып тора ул!.. Бу минем яңа, унтугызынчы елга кергәч, беренче тапкыр күргән яшь аем! Нәрсә вәгъдә итә ул миңа, ни көтә мине киләчәктә? Ел озын, ел хәвефле, туасы һәм туласы айлар күп, — ни буласын алдан белүләре бик читен шул миңа, бик читен!.. Ә син дәшмисең, серле, салкын аем, дәшмисең?!.

*Ахыры киләсе санда*

## Нажар Нәҗми

### Кайда булдым?..

Акыл өләшкәндә өй артында калган.
Әнием сүзләре.

Кайда булдым, кайда йөрдем
Мәңгелек-тын серләшкәндә?
Туганмын — өйдә булганмын
Җирдә гомер өләшкәндә.

Гомер — ул бер сайраган кош —
Очып килә, очып китә,
Өлешкә тигән елларның
Көмеш кылын чиртә-чиртә.

Көмеш кыллар — кыска еллар
Алтыннарга тиңләшкәндә,
Кайда булдым мин матурлык
Һәм олпатлык өләшкәндә?

Кайда булдым яшьлек сөю
Телләрендә сөйләшкәндә?
Булдым сафта — афәт килгәч —
Илдә мылтык өләшкәндә.

Булдым өйдә яхшылыклар
Яман белән алышканда.
Чыктым өйдән булдыксызлар
Дан артыннан чабышканда.

Үзем булдым булганынча,
Ә булганы артмады һич.
Булмаганны бар димәдем,
Дан-шөһрәткә китмәде ис.

Акылым да, ялкыным да
Булган тиклем... Үзем белән.
Яхшылыкка, матурлыкка
Табындым мин шигырь белән.

Мин сер бирмәм мәңгелектән
Билгесезлек җилгәндә дә.
Беләмен, өйдә булырмын
Миңа әҗәл килгәндә дә.

## Уфа юкәләре

Яшьлек урамнары...
Тулы хыяллары...
Без шатлыкка туймас исәрләр.
Уфа юкәләре
Безнең хакта да әле
Яфрак яра-яра сөйләрләр.

Безнең менгән атлар,
Еллар-аргамаклар,
Көмеш тезген, алтын йөгәннәр.
Уфа юкәләре
Безнең хакта да әле
Чәчәк ата-ата сөйләрләр.

Гомер ике килми,
Утлар ике сүнми,
Без мең янып, тик бер сүнгәннәр.
Уфа юкәләре
Онытмас әле —
Яфрак коя-коя сөйләрләр.

## Кичә үлсәм...

I

Таңге кар бу! Дөнья ап-ак! Бер әкият
Һәр минутың, һәр сәгатең, һәрбер көнең.
Әй, кар ява! Кар түгел бу — ак нур ява —
Кичә үлсәм, бүген аны күрмәс идем.

II

Әй, кара күз! Шушы ап-ак җир йөзендә
Карап минем күзләремә: «Сөям!» дидең.
Кара күзләр! Кара урман, ап-ак хыял, —
Кичә үлсәм, бүген аны күрмәс идем.

III

Фани дөнья, нигә соң син мәрхәмәтсез —
Явызларың һаман туып тора синең?!.
Ак бәгырьгә кара агу сипте бераү —
Кичә үлсәм, бүген аны күрмәс идем.

IV

Шатлык керде, бәйрәм керде дус өенә —
Яхшылыклар гел тантана итсен! — димен.
Дус өеннән керде бәйрәм минем өйгә, —
Кичә үлсәм, бүген аны күрмәс идем.

## Иҗат

Җир астыннан ташлар ярып
Һәм ургылып чыга чишмә.
Аккан юлы — гомер юлы
Күренеп тора күрер күзгә.
Ишетелеп тора җыры —
Тавышы бар, бар үз моңы.
Ләкин бар бит шул чишмәнең
Зур дөньяга туар юлы —
Серле юлы, чыгар юлы.
Нинди юл ул? Тамырларын
Кемнәр юллап тапкан аның?!.
О, син иҗат! Кайдан синең
Һәрбер нурың, төсең, моңың?
Әллә сер дә, тылсымнар да
Гадәтиме бу дөньяда?
Җиргә ятып сулар эчәм —
Чишмә чыга... Чишмә ага.

## Имән

Кайсыбыз соң җырламаган
Агачларның кайсыларын:
Усакларның яфрак шавын,
Зифалыгын каеннарның.

Кайсыбыз соң сокланмаган
Имәннәрнең ныклыгына.
Ышанганбыз имән өчен
Җил-давылның юклыгына.
... Ә менә кыш, кыш уртасы
Җил-давылсыз булды — тып-тын.
Күз алдымда куе, тыгыз
Томаннары салкын кышның,
Ә салкыннар тып-тын, тып-тын...
Үтте тынлык, буран аша
Шашып килде яз көннәре.
Өрде җан, нур җир йөзенә
Яз бизәге, яз өннәре.
Яфрак ярды усак, каен...
Имәннәр соң?.. (Мин ни күрәм!..)
Кайсыбере, ах, шәп-шәрә...
Бер яфраксыз тора имән —
Үлә имән.

Җилләрдә һәм давылларда
Ир-егет нык, иманнар нык.
Ах, шул тынлык... салкын тынлык...
Салкынлык...

## Күчсә иде...

Иртә иде. Урамнарда
Халык әле сирәк иде.
Күңелемә нидер җитми,
Миңа нидер кирәк иде.
Кышның җепшек иртәсеме,
Әллә елак томанымы,
Күңелемнең шат нурларын
Моңсулыкка урадымы —
Мин белмәдем... Күрәм менә
Бер яшь хатын үтеп бара.
Үз-үзеннән ул елмаеп,
Нурлар чәчеп китеп бара.
Бәхеттәнме, кызыктанмы
Елмайган ул? Ә кем белә...
Ирексездән шул хатынның
Елмаюы күчте миңа.
Аны уйлап үз-үземә
Китеп барам мин дә көлеп,
Минем шатлык, елмаю да
Башкаларга күчәр кебек...
Күчсә иде...

## Җәйге шигырь

Җир ямь-яшел... Яшел яфракларга
Яшел җилләр сөйли яшел сер.
Юллар яшел. Яшел сукмаклардан
Үтәм... Гүя мин бер яшүсмер.

Яшел дөнья! Яшел моңнарыңа
Минем мәңге гашыйк икәнне
Белгән килеш, белгән килеш бер чак
Син дә саргаерсың микәнни?!
Уф!..

## Бөтнек

Яланнарда, чагылларда
Күзләргә дә чагылмыйча,
Гади үлән — бөтнек үсә
Бер нәрсәгә ялынмыйча.

Җил кагылса, мал кагылса,
Әгәр таптап үтсә кеше,
Аның саен хуш ис бөркеп,
Аңкып китә бөтнек исе.

...Кагылсын! Үтсен кагылып
Җырларыма заман җиле.
Кагылган саен алар да
Бөтнек кебек булса иде.

●

Их, ичмасам, еламасаң икән,
Күрмәс идем шундый чагыңны.
Кайгыларың авыр... күтәрә алсам,
Алыр идем бөтен кайгыңны.

Их, ичмасам, еламасаң икән,
Күз яшь сиңа һич хас түгел дә.
Нур идең бит!.. Барысы да сүнгән
Бүгенгәме, әллә гомергә...

Их, ичмасам, еламасаң икән —
Тора җаным җаныңа куш булып.
Синдә елый минем мәхәббәтем
Яшьлек хыялыма кушылып.

## Дустыма

Хәтта фәрештә булсаң да,
Һәркемгә ярап булмый.
Дуслык тудырган гомер дә
Дуслыктан гына тормый.
Беркайчан да, беркемнән мин
Тел тидертмичә сиңа,
Үзем генә мактап, үзем генә
Сине әрлисем килә.

●

Чәчәкләрдә мин кунакта булдым —
Сихри иде июнь кичләре.
Рәхмәт сезгә шул минутлар өчен,
Ал карашлар һәм хуш исләре!

Онытылдым — мәңгелек дип бугай
Гомернең шул татлы мизгелен.
Югалттым мин вакыт исәпләрен,
Оныттым мин көзләр килерен.

Ә хәзер кыш... Тик өемдә шул ук
Ал карашлар һәм хуш исләре!
Бүген гөлләр миндә кунакталар —
Йөрәгемдә июнь кичләре.

•

Төн уртасы... Саф, аяз төн...
Саф тынлыгы кергән өйгә.
Шул тынлыкта һичтуктаусыз, —
Ләң-ләң, ләң-ләң бер эт өрә.
Тирә-якта юк тавыш-тын,
Ә ул сизә, күрә бугай.
Нигә өрә, кемгә өрә —
Үзе генә белә бугай.
Илаһи төн, илһамлы төн,
Ай-йолдызлар бии гүя.
Йолдызларга өрәме ул,
Әллә микән Айга өрә?
Әллә, димен, чыгып үзен...
Ә юк! Нигә күренергә?..
Өрсен әйдә! Эт өргәнгә
Вакыттыр бит күнегергә.

## Дүртьюллыклар

•

Туган илем, туган җирем,
Синең нинди улыңмын мин?
Шуны беләм: яралансаң,
Кан тамчыңда булырмын мин.

•

Хакыйкать ул — яп-ялангач,
Яңа туган бала төсле.
Үзе көчле. Көче тиңсез,
Ләкин көчсез синсез, минсез.

•

Дөреслеккә гомер табындылар...
Мин дә аннан, башым иеп, сабак алдым.
Бары тик бер явыз хакында мин
Гел дөресне сөйләп хаталандым.

•

Бу дөньяга мин пакь килеп кердем,
Саф чишмәсе булып өметнең.
Хәзер инде бер зур шәһәр аша
Агып үткән елга кебекмен.

●

Дошманым бар. Аның булуыннан
Һич курыкмыйм — хәтта мин тыныч.
Ләкин аның белән бер кашыктан
Ашаган дус үтә куркыныч.

●

«Миңа җитте!» дип ул һич тә
Әйтмәс адәм... Адәм комсыз.
Ә үзенә кайсы чакта
Җитә бер сүз, бары бер сүз.

●

Бөтен нәрсә утта эрнеп кыза,
Эрнеп янып, ката соңыннан.
Минем йөрәк сиңа бер таш икән,
Ул да эрнеп, янып суынган.

●

Алдыңда килде буласым акыллырак,
Акыл белән башкалардан матурырак.
Тик гел булдым мәхрүм акыл алтыныннан,
Чөнки сине сөйдем язып акылымнан.

------------

## Фаил Шафигуллин

### Диңгез төне

Килгән идем төнлә торып
Диңгез каршына.
Күзем төште ярда ялгыз
Кабер ташына.
Диңгезчеме йоклый монда,
Бер мөсафирмы? —
Мамык кебек җиңел томан
Каплады җирне.
Сөю утларында янган
Берәр гашыйкмы? —
Чал дулкыннар, нидер сөйләп,
Ярга ашыкты.
Юлбасар, я хыянәтче
Ятамы монда? —
Ай кызарып кереп посты
Таулар артына.
Изге яуда һәлак булган
Яшь бер батырмы? —
Сискәндереп диңгез төнен
Йолдыз атылды.

### Кыргый атау

Булган бу хәл әүвәл заманда,
(Күрәсеңдер инде, язмышы) —
Океандагы кыргый атауда
Калган икән кеше ялгызы...

Сүнгән саен күктә йолдызлар,
Чыккан саен кояш диңгездән,
Кыргый кошлар күргән кешене
Үксеп яткан килеш йөзтүбән...

Моңайма, дип океан шаулаган,
Тор инде, дип җылы җил искән,
Атла, диеп чыклы үләнгә
Ай сукмаклар салган көмештән.

Шифалы су биргән чишмәләр,
Карурманнар татлы аш биргән,
Киңәш биргән эшчән дулкыннар,
Куышка дип, таулар таш биргән...

Сабыр иткән кеше, илкәен
Сагынса да өзелеп-өзелеп.
Узган айлар кыргый атауда
Киек казлар кебек тезелеп.

Ә бер көнне зәңгәр офыктан
Балкып чыккан кинәт ак җилкән.
Ярга килеп баскан кешенең
Еллар инде чәчен ак иткән.

Гаҗәпләнеп, каушап торганда
«Өнемме бу, — диеп, — төшемме?!» —
Утырткан да туган иленә
Алып киткән кораб кешене.

Кошлар озак очкан озатып,
Боегып калган атау еракта...
Караган да кеше караган
Нидер җуйган сыман шул якка...

Елаган ул өнсез-тавышсыз,
Һәм аттырган палубада таң...
Авыр булган аңа аерылу
Хәзер инде кыргый атаудан.

●

Арба тартып тауга менгән кебек
Озак, авыр яхшы исем алулары.
Тауга түбән җибәрелгән арбадан да
Тизрәк йөри кешеләрнең начар даны.

## Ел фасыллары

1

Ямь-яшел болыннар,
Ямь-яшел урманнар,
Зәп-зәңгәр күк өстә.

2

Сап-сары урманнар,
Сап-сары болыннар,
Һавалар күк төстә.

3

Урманда — ап-ак кар,
Болында — ап-ак кар,
Күк һаман зәңгәрсу.

Урманда — зәңгәр су,
Болында — зәңгәр су.
Һавалар зәңгәрсу.
Нигәдер бик рәхәт,
Нигәдер ямансу.

4

## Әти

Болай юксынмаган идем сине
Сабый чакта, әти.
Болай уйланмаган идем
Малай чакта
Синең хакта, әти.
Олайгач белдем: син бик кирәк икән,
Кирәк икән, әти.
Өскә кайгы ишелгәндә син нык
Терәк икән, әти...
Дус-ишләр бар, кардәш-туганнар бар,
Иптәшләр бар, әти.
Тик син генә бирә ала торган
Киңәшләр бар, әти.
Сиңа әйтер сүзне беркемгә дә
Әйтмим бит мин, әти.
Син аңламый мине кем аңласын —
ӘТИ бит син, әти.

●

Бер улыйсы килә айга карап,
Сахрадагы ялгыз бүредәй.
Улап булмый. Оят. Яхшы түгел,
Яхшы түгел, кешеләр күрерләр.

Бер елыйсы килә, бушаганчы
Сагыш белән тулы күңелләр.
Елап булмый. Оят. Яхшы түгел,
Яхшы түгел, кешеләр күрерләр.

Бер янасы килә кочагыңда
Әверелгәнче утлы күмергә.
Янып булмый. Оят, яхшы түгел,
Яхшы түгел, кешеләр күрерләр.

Улыйк, елыйк, янып —
Дөнья фани,

Кемдә кемнең нинди эше бар!..
Юк, кирәкми,
Түзик, түзик әле,
Түзик әле —
Без бит кешеләр.

●

Суга кара —
Гайбәт елгасында
Сулар кара.
Ярга кара —
Гайбәт елгасында
Яр да кара.
Үзе теләп керми
Беркем бу елгага.
Таңга илткән салым
Кара судан ага.
Ак салыма ярсып
Бәрә кара дулкын.
Ярда шикле күзләр —
Кара судай салкын...
Салга кара —
Я, йоктымы кара?!
Җанга кара —
Я, йоктымы кара?!.
Таңга кара...

●

Хан тамаша кыла...
Киң мәйданда
Кылыч айкый ике кол-егет,
Вәзирләрнең йөзе кояш кебек,
Җарияләрнең йөзе көл кебек.

Берсен-берсе кисә ике кылыч,
Кем кала да бүген кем китә...
Хан бәйрәмен тынып карап тора
Мәхәббәт, Дан, Үлем бер читтә.

Үлем илтифатсыз тамашага,
Кем үлсә дә барыбер Үлемгә.
Мәхәббәтнең зәңгәр күзләрендә
Курку катыш газап күренә.

Ә Дан инде нәкъ җәллады ханның —
Көлеп карый үлем уенына.
Ә Дан инде нәкъ уйнашчы хатын —
Кайсы җиңсә,
Сарылыр ул шуның муенына.

**Аяз Гыйләҗев**

# КҮПНЕ КӨТӘБЕЗ!

Гариф Ахуновка илле яшь тулуын уйлый башлауга, ни өчендер, халык арасында бик тиз таралган бер җырның сүзләре хәтергә төшә:

Менә без дә үсеп җиттек, әни!

Әйе, без бергә диярлек башлаган идек. Юлга бергә чыктык. Күмәкләшеп, иңнәрне-иңгә терәп, бер булып... Шул иптәшләребезгә дә илле тула башлады! Башка бик күп өлкәләрдә юлдашларына караганда күбрәк эшләгән, күбрәк хезмәт куеп өлгергән кебек, монда да безнең арада иң өлгере ул булып чыкты: Гариф иллене тутырды.

«Без» дигәндә мин монда күп санлы университет шәкертләрен күз алдында тотам.

Эш һәм иҗат бәйрәме көннәре хатирәләр көне дә ич ул!..

Әйе, сугыштан соңгы сөенечле, бәхетле, эчкерсез бирелгәнлек белән сугарылган өметле еллар иде. Хөкүмәтебез сугышның иң хәтәр чагында, кырык дүртнең көзендә, Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачты. Шушы бүлек шигырь-хикәя белән җенләнгән яшьләрне бик тиз арада үзенә тартты.

Ул елларда студентларның мохиты бик чуар иде. Алтышар-җидешәр ел иңнәреннән солдат шинеле төшмәгән мыеклы агайлар янына әле генә мәктәп партасы арасыннан чыккан сары чебешләр кереп утырды. Завод-фабрикаларда, колхоз ызаннарында биш-алтышар ел хезмәт итеп дөньяның ачысын-төчесен үз җилкәләрендә татыган апалар яшь кызыкайлар белән укый башладылар. Аерма бик зур — берәүләр дәреслекләрдә язылганны яттан белсә, икенче берәүләр тормыш фәнен бик яхшы үзләштергәннәр иде. Шул еллардагы безнең остазларыбыз — кафедра җитәкчесе, гаять таләпчән Рабига Афзаловна Хәкимова, иңендә тау чаклы хәзинә, тел байлыгын күтәреп йөргән зирәк профессорыбыз Латыйф ага Җәләй, укытучыларыбыз М. Гайнуллин, Х. Госман, Г. Кашшаф, Ш. Рамазанов, Б. Яфаров, Д. Сафин, М. А. Тарасов шул чуар яшьләрне ныклы бер коллективка берләштерә алдылар, өлкәннәр өчен дә, яшьләр өчен дә уртак интереслар таптылар.

Университет аудиторияләре гөрләп торган гаҗәеп чор иде ул!

Әдәбият түгәрәге атна саен диярлек үзенең ялкынлы утырышларын уздыра, ул диспутлар, тамак карлыкканчы бәхәсләшүләр дисеңме — бар да бар иде! Университет шәкертләренең күз өстендә кашы булган атаклы «Әдәби сүз» газетасы болын хәтле булып чыга...

Гариф иң әүвәл, дусты Яхъя Халитов белән бергә, иптәшләре, чордашлары арасында әнә шул газетаның җаны—художнигы булarak танылды. Студент халкы, гадәттә, күп яктан бер-берсенә охшаш була. Тик Гарифның шул чакта ук аерылып торган сыйфатлары бар иде: ул беркайчан да башкаларга салынмады, үз көнен үзе күрде.

Искиткеч тырыш, эшкә һәм укуга чиксез бирелгән, пөхтә, вөгъдәчел, кием-салымы заманча, җыйнак, чибәр егет иде. Төпле, уйчан, җитди кеше иде... Акрын гына, уйсу җирдән тын гына бәреп чыккан чишмә кебек, студент ишләре арасыннан сызылып кына килеп чыкты. Килеп тә чыкты, күзгә дә ташланды.

Башта хикәяләр, очерклар туды. «Яшьлек яме» повесте белән Гариф үзенең йөрәк серен ачты: яңа язучы пәйда булды.

Шуннан бирле күпме сулар аккан, татар әдәбияты мәйданында Гариф Ахунов күпме юллар узган.

Ниһаять: «Менә без дә үсеп җиттек, әни!»



Н. Кочнев фотосы.

Әни сүзе нинди мәгънәдә алынган биредә? Нинди киңлектә?

Гарифны тудырган газиз әнкәсе — дүрт ятим баланы тол килеш карап үстергән Бибинур апа гына күздә тотыламы?

Әллә язучыны тудырган, аңа тел ачкычы биргән Казан артымы?

Аңа канатлар куйган университетмы әллә?

Аны тәрбияләгән язучылар оешмасы, аның остазларымы? Гарифның дөньяга карашын киңәйткән, аны язучы буларак халык арасына алып чыккан Татарстан нефтьчеләреме?

Әллә *шушы мәгънәләрнең* барын берләштергән туган илебез, туган халкыбызмы?!

Илле яшь тулганда аңа, каршына килеп хезмәттән ныгыган куллырыбызны илле ел буе заман белән бергә бәхетле һәм бәхетсез секундларны санаган йөрәгебезгә куеп әйтер сүзләр бар. Бар, бик бар!

Дөрес, Гарифның иҗаты турында «соңгы зур хөкемне чыгарырга бәлки бик иртәдер дә әле. Гадәттә, язучы үзенең «иң-иң мөһим, иң-иң газиз китабы» язылмаган дип йөри. Без — язучылар да, аның күп санлы укучылары да — Гариф Ахуновның андый китабы алда дип исәплибез, хөрмәтле каләмдәшебез, үзенең ярты гасырын бәйгеләрдә узышкан егет кебек, ак тулпарын иярләгән килеш, «Идел кызы» романының беренче китабын язып бетереп каршылый. Үзенә таләпчән, гомер уртасында инде кыек атарга ярамаганлыгын бөтен күңеле белән сизгән автор буларак, үтә зур җаваплылыкны тоеп кына бу романны бастырып чыгарудан тыелып калды. Байтактан күреп киләбез инде без бу әсәрне. Әлмәттә чакта ук, моннан җиде-сигез ел элек, күзгә чәчрәп торган эре, тәэсирле хәрефләр белән язылган роман юлларын калын-калын амбар кенәгәләрендә күргәли идек. Күңеле ачылып китеп, дуслар белән аралашырга, язылачак әсәрләре турында очынып сөйләргә яратучан Гариф романның аерым эпизодларын укып та күрсәткәли иде. Ул байтактан шушы әсәр геройлары белән яши, халык арасында йөргәндә, әңгәмәләрдә җор сүз, кызык фикер ишеткән чакта тиз генә куен дәфтәренә теркәп куя — хәтер сандыгында туктаусыз үсә, ачыклана барган роман юлларына урнаштыра.

Гадәттә, юбилей тантанасы вакытларында язучының үткән эшенә күбрәк игътибар юнәлтеп, авторның язылган, таралган әсәрләре хакында сүзне күбрәк алып баралар. Нигә соң без бүген әүвәл башлап аның яңа язылып килгән әсәренә мөрәҗәгать иттек?

«Кырык яшь — яшьлекнең картлыгы, илле яшь — картлыкның яшьлеге» дигән Виктор Гюго. Илле яшь, шул яктан караганда, барлык кеше өчен, бигрәк тә иҗат әһелләре өчен, аерата мөһим сызык икән. Игътибар итегез — монда Гюго ун ел араны бәясез калдырган. Кырык яшендә кеше яшьлеге белән саубуллашса, кырык белән илле арасында кеше чынлап торып сыналу, яңарыш чоры кичерә. Аның дөньяга карашы, теге яки бу мәсьәләләргә мөнәсәбәте тәмам ачыклана... Эшлекле кеше яшьләрчә җиң сызганып хезмәт итә башлый!.. Хезмәт аны яшьлегенә алып кайта! Кайта алмаса, бу — кешенең һәлакәте... Илле яшьтә кеше акыл утырткан, сабырлык, зирәклек туплаган иң егәрле, иң көчле эшче була!

Егерме биш ел эчендә байтак романнар, повестьлар, пьесалар, хикәя-очерклар иҗат иткән, үзен ялкынлы публицист, менә дигән тәрҗемәче, редактор, җәмәгать эшлеклесе итеп танытып өлгергән Гариф Ахуновның кырык еллыгы белән эшлекле хушлашып, илле еллыгын, нәкъ менә Гюго әйткәнчә, яшьләрчә башлап җибәрүе безнең барыбыз өчен дә куанычлы күренеш. Без егет чагыннан ук белгән тыйнаклык, эшкә бирелгәнлек сыйфатларын ул югалтмады, «изге эшкә бал авыз, яманлык күрсә бик явыз» булып ныгыды.

Моны раслау өчен, әлбәттә, язучының иҗатына мөрәҗәгать итәргә кирәк! Әйдәгез, иң киң таралган, Гарифка язучылык исемен китергән «Хәзинә» романына күз салыйк. Менә романның үзәк персонажларыннан берсе Лотфулла Дияров, нефть чыгару остасы, Куйбышевтан Татарстанга кайтырга җыена. Мин монда бу вакыйганың тарихи дөреслеккә ифрат та хас килүен, башка якларын да әйтмим. Кайчандыр эш эзләп, бәхет эзләп чыгып киткән кешеләрнең нефть осталары булып туган туфракларына кайтулары үзе дә игътибарга лаеклы факт. Шушы беренче карашка гади генә эпизодны Гариф зур бер тантанага, һәр мизгеле эчке мәгънәгә ия булган зур вакыйгага әйләндерә. Лотфулла Дияровны озату өчен Куйбышев нефтьчеләре зур бер кәрван оештыралар, останың үзен, хәләл җефетен һәм сигез баласын утыртып Кәлимәткә кадәр автобус җибәрәләр. Озатырга бөтен бригада, дуслары, ахирәтләре җыела.

Куйбышевтан Кәлимәткә нефть чыгару остасы, моңарчы гел күченеп, ягымлы якларда, әйбәт кешеләр арасында яшәсә дә, ничектер, үзенең оясын әле ныклап корып бетермәгән кеше кайта. Туган ягына кайта. Кәлимәттә аның иске булса да өе бар, нигезе бар, көне, теле бар. Гариф озату моментын тантаналы, югары стильдә хәл итсә, Кәлимәттә каршылауны тагын да уңышлырак, калку итеп, күзгә бәрелеп торган ачык буяулар белән тасвирлый. Иң элек — туып-үскән җиренең газизлеге, үзе ил кайгысын кайгыртып йөргән чакта буш һәм нәүмиз булып торган йорты Лотфулла останың җанын айкап ала. Ләкин монда да аңа сагышланып утырырга юл калдырмыйлар. «Дияровларның җил капкасы буена тагын ике машина — бу юлы Кәлимәт машиналары — килеп туктады. Аларның берсенә йортны ремонтлау өчен кирәкле материаллар, икенчесенә кузов төбәсеннән кешеләр төялгән», иде ди автор.

Бер көн дигәндә Лотфулланың йортын төзәтеп, мичен чыгарып куялар. Аларның төнлә кайтып китмичә эшләүләре аерата ошый. Автомашиналарның фара яктысында туктаусыз хәрәкәт иткән бу төнге эшчеләргә карата Лотфулла оста күңелендә генә түгел, укучы күңелендә дә рәхмәт хисләре уяна, үзеңне сафрак, байрак, яхшырак хис итә башлыйсың.

Озатучыларда да, каршы алучыларда да Гариф өчен бик кадерле уртак сыйфат бар — бу аларның яхшы күңеллелеге. Кешеләрдә яхшылыкны эзләү, аны нәкъ менә гомернең кискен минутларында таба белү, шул яхшылыкны җырлау, яхшылыкка соклану — Га-

риф Ахуновның төп иҗат принцибы. Дөрес, бу изге юлдан кереп киткәндә дә белеп эш итәргә кирәк, чама хисен һич тә онытырга ярамый. Яхшылыкны җырлауны — гади төчеләнү белән алыштыруың, чыннан да бал авыздан балавызга әйләнеп эреп-җебеп төшүең дә ихтимал! Юк, Гариф андый юлны сайламый. Чөнки тормыш аллыгөлле сукмаклардан гына тормый, җәмгыятьтә төрле-төрле кешеләр яши. Әйтик, «Хәзинә» романында ике машина актырткан тантаналы өмәдә әкияттәге баһадирлар кебек эш torкан риясыз ир-егетләрне лапас караңгылыгыннан кулларын кушырып Шәвәли карт күзәтеп тора. Кәлиматтә ул да яши! Андыйлар бер ул гына да түгел. Алар да кеше. Лотфулла Дияровлар тормышына әнә шул бәрәкәтле хәзинә — нефть тудырган үзгәрешләр генә түгел, караңгы чырайлы Шәвәлиләрне яшәтүче шартлар да йогынты ясый. Чөнки җир бер, тормыш бер, ә икесенең дә гомере шул бер чорга туры килгән.

Әле алай гынамы сиңа, җирдә Лотфулла белән Шәвәлинең нәсел-токымын дәвам иттерүче мут егет Булат белән чая Фәйрүзә дә бар, картлар берни сизми калганда, алар уртак малай Тансыкны алып кайтып та өлгергәннәр!.. Катлаулы ул тормыш дигәнең, беркатлы мәдхия укып кына, кешеләрне гел-гел бер мәйданда йөртеп кенә аның чын диалектикасын ачып бетерә алмассың!

Шиксез, яхшы белән яман көрәшендә гаделлек өстенлек ала бара һәм аның шулай икәнлеген Гариф җай килгән саен шәрехләп, ассызыклап узарга ярата. Кәлимәт кешеләренең канына шактый еллар тоз салган Җилкуар Тимбик белән булган бер вакыйганы искә алмый китү мөмкин түгел. Гомерендә берәүгә дә бер тиенлек яхшылык күрсәтмәгән, очраклы рәвештә кулына власть алган бу кеше ниләр генә кыланмый! Шамаилләргә ата, ураза тотучыларны колхоздан кудыра, эчеп-исереп колхозның нәсел айгырын яндырып үтерә. Көннәрдән бер көнне шушы әкәмәт кешенең өе кара тузан туздырып җимерелеп төшә. Тантана итәме авыл халкы? Юк. Чалгыларын күтәргән, тырмаларын тоткан агай-эне, хатын-кызлар печән өстендә, уттай эш вакытында болын уртасына җыйналалар да киңәшәләр: «Я, нишлибез? Тимбикне йортсыз яшәтәбезме?» Авылның атаклы балта осталары Тимбиккә йорт бурыйлар, миччеләре мич чыгара. Бөтен авыл өй котлау мәҗлесенә килә!

Һәм шуны карап торган Тимбик, кичерешләренә чыдый алмыйча, халык аягына егылып җан бирә.

Менә бу Гариф! Үзе! Бу эпизодларда аның бөтен барлыгы, бөтен күңеле ачылып-ярылып ята. Ләкин бу эпизод та болай гына, халык бөеклеген раслаучы эпизод кына булып кала алмый. Әле Тимбикнең улы Кәрим бар, әтисенең кара күләгәсеннән котылыр өчен аңа байтак тырышырга, байтак тырмашырга туры киләчәк.

«Менә без дә үсеп җиттек, әни!»

Шәүкәт Галиевнең үткенлеге белән мине таң калдырган мондый юллары бар:

«Халкым!», «Халкым!» дигән сүзләреңне
Уңга-сулга сибеп талпынма.
Синең әйтү генә җитми әле —
«Улым!» дисен сиңа халкың да!

Гарифның халыкка булган мөнәсәбәте ачык булган кебек, халкыбыз да аңа булган мөнәсәбәтен көн кебек ачык белдерде:

Халык улы булуның никадәрле мактаулы һәм җаваплы икәнен беләбез. Гариф та моны белә. Димәк, без аңардан бик күпне көтә алабыз, күпкә өметләнәбез.

Ул Г. Тукай бүләге лауреаты, РСФСРның атказанган культура хезмәткәре, СССР Верховный Советы депутаты.

## Гариф Ахунов

# УТЛАР ЯНА УЧАКТА

ДРАМА

**ӨЧ ПӘРДӘ, АЛТЫ КҮРЕНЕШТӘ**

УЙНАУЧЫЛАР:

Х ә й р у л л а  Х ә к и м о в (Хыялый Хәйруш) — нефть чыгару мастеры. 30 яшьләрдә.

Җ ә ү д ә т  Г а л и ә х м ә т о в — институт тәмамлап кайткан яшь инженер. 25 яшьләрендә.

Т а л и п — пенсиядәге бораулау остасы. 80 нәр тирәсендә.

Г ы й м р а н  Н у р и ш а н о в — дипломсыз инженер. Промыселда хәвефсезлек кагыйдәләре буенча инженер вазифасын үтәүче. 60 ларда.

Г ү з ә л и я — оператор. 20 яшьләрендә. Соңыннан Җәүдәтнең хатыны.

М ә р ь я м — укытучы. Хәйрүшнең хатыны. 27 яшьләрендә.

Х ә д и ч ә — Җәүдәтнең әнисе. 60 лардан узган.

С ә л ә х и, А з а м а т, Н и к о л а й — өлкән операторлар.

З ө б ә р җ ә т — җәйге практикага кайткан художник кыз. 18 ләрдә.

Ш ә й х а т т а р — оператор.

С а д р и — уйлап табучы.

Тана хуҗасы.

Оператор кызлар, егетләр.

Вакыйга безнең көннәрдә, нефть шәһәрендә бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### СӘХНӘ АЛДЫ

Заманча салынган шәһәр капкасы: вышка, аңа тоташкан космос эмблемасы. Капкада язу: «Күңелең саф булса, рәхим ит!» Машина гудогы. Кулына чемодан тоткан Җ ә ү д ә т керә.

Җ ә ү д ә т (*капка каршында туктап*). Шушында очрашырга сүз куештык. (*Кесәсеннән хат чыгарып карый.*) «Шәһәрнең яңа капкасы булыр. Анда безнең теләкләр язылган булыр. Син шуларны укый торганчы, мин ялт итеп килеп җитәрмен. Гүзәлия». «Карап карыйк, нинди теләкләр бар монда. (*Язуны укый.*) «Күңелең саф булса, рәхим ит!» (*Сәгатенә карый.*) Актыккы студент акчамны түләп, аэропорттан машина кудым. Киләме, юкмы? (*Чемоданына утырып уйга кала.*)

Г ү з ә л и я керә. Җәүдәтнең башын иеп утырганын күреп, сиздерми генә, аяк очларына гына басып, атлый башлый.

Җәүдәт инстинктив рәвештә сизенеп, сикереп тора, һәм алар бер-берсенә ташланалар.

Гүзәлия. Җәүдәт...

Җәүдәт. Гүзәлия...

Гүзәлия. Кайтыр көнең дә бар икән!

Җәүдәт. Көттеңмени?

Гүзәлия. Биш ел буе көтү ул чаклы озак тоелмаган иде. Соңгы биш көне... Ой, ник сөйлим соң әле мин боларны?

Җәүдәт. Сөйлә син, сөйлә.

Гүзәлия. Сөйләр сүз күп иде... Үзеңне күргәч, онытып бетердем...

Җәүдәт. Гүзәлкәй!

Гүзәлия. Әү?

Җәүдәт. Йом күзеңне.

Гүзәлия. Ник?

Җәүдәт. Йом инде.

Гүзәлия *(аның ниятен сизеп, каушап).* Йоммыйм, йоммыйм, йоммыйм!

Җәүдәт *(аяк тибеп).* Йом дим!!

Гүзәлия *(рәхәтләнеп көлә).* Йоммыйм, йоммыйм. Сиңа карап торасым килә.

Җәүдәт. Сагындыңмы?

Гүзәлия. Син бит әле миңа дипломыңны да күрсәтмәдең!

Җәүдәт *(кесәсеннән дипломын алып бирә).* Мә, кара, Гүзәлкәй, сөен!

Гүзәлия *(карый).* Ай, нинди чибәр син монда! *(Укый.)* «Галиәхмәтов Җәүдәт Галиәхмәт улы. Туган елы — 1940. Тау инженеры!» Әйдә, киттек!

Җәүдәт. Кая?

Гүзәлия. Иптәшләр янына! Алар бит сине ашкынып көтәләр. Шундый зур эшләр куптарырга торабыз!

Җәүдәт. Нинди эшләр?!

Гүзәлия. Болай гына аңлатып булмый аны. Баргач белерсең, баргач...

Җәүдәт. Бүген бармыйбыз...

Гүзәлия. Бармыйбыз?

Җәүдәт. Мин аларга өч көннән кайтам дип телеграмма суктым.

Гүзәлия. Өч көннән?! Бу бит... алдау. Нишләдең син, Җәүдәт?

Җәүдәт. Алдау түгел бу, сюрприз! Аңламыйсыңмыни? Алар мине инженер булып кына кайта дип көтәләр иде. Ә мин кияү булып та кайтам!

Көлешәләр. Җитәкләшеп, сөенеп чыгып китәләр.
Чаң. Әчке пәрдә ачыла.

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман аланы. Таң ата. Алгы планда — бөтен иңенә җәелеп үскән имән. Арткы планда — күгелҗем урман. Урман өстеннән промысел вышкалары башларын сузганнар. Горизонтта ап-ак резервуарлар һәм нефть чистарту корылмасының биек морҗасы ярты күккә чаклы менеп җиткән.

Пәрдә ачылганда сәхнә бик тын. Таң нурлары белән кушылып, әкрен генә музыка уйный, бу бәлки музыка да түгелдер, таң атуы безгә шулай тоеладыр.

Талип керә. Ап-ак сакаллы, башында җәйге ак эшләпә. Кулында артыш таяк.

Талип *(имән каршысына килеп).* Хәерле иртә, имән! Торам дисең, ә? *(Тирәли әйләнеп чыга).* Җил-давылларга бирешмим дисең, ә?

Oh-ho-ho-ho... Әгәр тамырларыңа азык килмәсә, усал җилләр ботакларыңны сындырып бетерсә... Тора алырсыңмы? Дәшмисең шул син...

Вахтага баручы яшьләрнең җырлап узганы ишетелә. Дөньяга тагын яңа бер көн туды. Яшьләр эшкә килә... Хәйрүш керә.

Хәйрүш. Хәерле иртә, бабай! Бик иртә кузгалгансың түгелме?

Талип. Йомыш бар синдә, кияү.

Хәйрүш. Нинди йомыш ул, бабай?

Талип. Йомыш зур, Хәйрулла. Син мине бүлдерми генә тыңла, ярыймы? *(Күзләрен йома төшеп, көйләп сөйли.)*

Табигатьтән качмыйм, чыгам көнгә,
Ялгыз чыкмыйм, үзем белән таяк алам,
Шушы артыш таягыма таянам да
Җилгә каршы гайрәтләнеп алга барам.
Гадәтемчә, атлап китәм, тауга җитәм,
Тау буенда җил дә юаш исә икән.
Теләк кыстый биек тауга үрмәләргә,
Сулыш кыскач, туктап тагын мин ял итәм.
Менәм тауга, басам таныш кыяларга,
Никтер картлык ак сакалны сыйпап көлә:
Тауга меңдең, Талип, ничек төшәрсең, ди.
Хыялыңа, йөрәгеңә нефть сеңгән,
Шунда күмел, вышка булып үсәрсең, ди [1].

Кем әйтә моны?

Хәйрүш. Талип бабайның тынгы белмәс йөрәге әйтә.

Талип. Нәрсә дип әйтә?

Хәйрүш. Беркайчан да үлмәм, ди.

Талип. Белмәдең. Бабаң монда соңгы мәртәбә килде.

Хәйрүш. Соңгы мәртәбә?!

Талип. Имән белән саубуллашам да...

Хәйрүш. Ни сөйлисең син, бабай?!

Талип. Бүлдермә. Мине үз кулың белән күмәрсең!

Хәйрүш. Туктале, бабай...

Талип. Бүлдермә дип әйттем бит! Минем мәңгелек пропискам менә шушы имән төбендә булыр. Моннан мин сезнең эшегезне тикшереп ятармын. Кызларым минем баш очымнан вахтага йөрерләр.

Хәйрүш *(шаяртып)*. Бабай! Үлем турында син шундый матур итеп сөйлисең, хәтта үземнең дә үләсем килеп китте!

Талип. Сиңа үләргә иртә әле!

Хәйрүш. Ник?

Талип. Бабаң дөньяда сиксән ел яшәде. Җир йөзендә Талип бораулаган йөз егерме скважина фонтан атып утыра. Ә синең нәрсәң бар? Я, нәрсәң бар синең?

Хәйрүш. Мастер дигән исемем бар!

Талип. Юк. *(Таягын каты тукылдатып.)* Юк! Мастер Хәйрулла дип авыз тутырып әйтү өчен сиңа әле җитмеш җиде кат тир түгәргә, туксан тугыз пот тоз ашарга кирәк. Хәзергә син бары Хыялый Хәйрүш кенә!

Хәйрүш. Шаяртма, бабай! Хәйрулла Хәкимов бригадасы быел беренче урында булачак!

Талип. Әйтимме, кияү, бер сүз?

Хәйрүш. Әйт, бабай!

Талип. Хәтереңкалмасмы?

Хәйрүш. Калмас.

Талип. Күптән түгел мин бер китап укыдым. Профессор әйтә, әгәр дә мәгәр, ди, тавык күкәен кытакламый гына салса, бер елга җитмеш биш күкәй артык салган булыр иде, ди.

---

[1] Пенсиядәге бораулау остасы Талипов мөнәҗәте.

Хәйрүш. Алайса, мин кытаклап йөрүче тавык булып чыктым? *(Көлә.)*

Яшьләр җыры якынарa.

Җырлап чыгабыз иртән юлларга,
Кырлар, урманнар уяна, уяна.
Көч бар беләктә, кодрәт — йөрәктә,
Кеше бәхеткә юл яра, юл яра...[1]

Талип *(җыр ерагайгач)*. Нәрсә ди? Кеше бәхеткә юл яра диме?

Хәйрүш. Нәрсә әйтмәкче буласың, бабай?

Талип. Син, кияү, яшьләрнең командиры, ягъни, җыруда әйткәнчә, юл ярып баручы корыч борау син, беләсең килсә. Ә борауның ныклыгы кайда сынала? Борауның ныклыгы сынала гранит токымда. Аңладыңмы?

Хәйрүш. Аңлап җитмәдем әле, бабай, Нәрсә әйтмәкче буласың?

Талип. Мин әйтмәкче булам, ягъни мәсәлән, кияү, шуны: булсаң бул чын командир, ярсаң яр турыга, яшьләрне кыек-мыек юлга алып керә күрмә. Алар сине гафу итмәсләр. Менә минем сиңа соңгы васыятем... *(Китә.)*

Хәйрүш. Бабай, бабай! Әти... *(Талип китә, Хәйрүш ялгызы.)* «Гранит токымда сынала... Яшьләрне кыек юлга алып кермә». Ә туры юл кайдан уза? Бик зур таш бастырып китте бит әле бу җилкәгә. *(Уйга калып чыгып китә.)*

Аланга, шау-гөр килеп, оператор егетләр керә. Аланның икенче ягыннан тигез сафлар белән оператор кызлар төркеме агыла. Алар алдыннан бик эре генә, гармун уйнап, Азамат атлый.

Азамат *(кояшта янган чуен кебек чибәр егет. Өстендә кыек якалы кара сатин күлмәк, җилкәсенә брезент курткасын салган. Искиткеч шат табигатьле.)* Карахмәт улы Сарәхмәт, Сарәхмәт улы Салават, Салават улы Азамат, ягъни буладыр ул зат... мин! Һә-ә-әй! Мин җитәкли торган кызлар вахтасы! Тыңла минем команданы! Сми-иир-но! Башларны югары, кулларны түбән. Имәнгә карап тигезләнергә! Бригада егетләренә салют бирергә!

Кызлар. Исәнмесез-саумысыз, Хыялый Хәйрүшнең кара чутырлары!

Егетләр. Нечкә билле, киң күңелле, кара кашлы, пумала башлы алсу гөлләргә, дегеткә буялып йөрүче былбылларга салют! *(Гармунда көчле аккорд.)*

Азамат. Во-оль-но! Вахтага басарга ярты сәгать вакыт бар. Шуңарчы егетләр белән күрешергә, кулларны бирешергә, серләрне бүлешергә! Имән төбенә, бегом марш!

Кызлар чыр-чу килеп, сөенешеп, имән төбенә сибеләләр. Бераздан дөнья тып-тын булып кала.

Азамат. Әйдә, Шәйхаттар, булмаса, берәр нәрсә ялганла!

Шәйхаттар. Юк, бүгенгесе ялган түгел. Беләсезме, иртән иртүк үзебезнең участокка килеп, вышкаларны урлап китмәгәннәрме дип санап йөри идем, килеп чыга бер Хөзер Галиәссәләм!

Азамат *(бик гаҗәпләнгән булып)*. Хөзер Галиәссәләм?

Шәйхаттар. Өстенә брезент куртка кигән, кулына парафин кыра торган скребок тоткан. Ә сакалы, сакалы, мин сиңа әйтим, җилкә аркылы әйләндереп салган да пута итеп биленә урап куйган!

Азамат *(рәхәтләнеп көлә)*. Хөзер Галиәссәләм картаймыш көнендә оператор булып киткәнмени? *(Көлешәләр.)*

---

[1] Җыр текстларын Саҗидә Сөләйманова, музыкасын Мәсгут Имашев язды.

Ш ә й х а т т а р. Чынлабрак карасам — Хәзер дигәнем Талип карт булып чыкты.

Н и к о л а й. Нишләп йөри ул монда?

Ш ә й х а т т а р. Нишләп йөрсен? Сигез дистәне тутырган кеше нишләп йөри ала? Үләргә җыенып, үзенә кабер эзләп йөри.

А з а м а т. Аңламагансың, Шәйхаттар. Талип карт кабер эзләми. Безнең эштән кимчелек эзләп йөри. Узган ел бригаданың нефть чыгару планы тулмый башлагач, аяктан егылды. Больницага илтеп салдылар.

Н и к о л а й. Палундра! Кем дә кем хәвефсезлек кагыйдәләрен тапшырмаган, ычкыныгыз! Инженер Нуришанов килә!

Г ы й м р а н Н у р и ш а н о в керә. 60 лар тирәсендә. Кожаннан, таза күн итекләрдән. Күз өстен бөркеп торган йөнтәс кашлы, салмак хәрәкәтле. Сүзнең төмен белеп сөйли

Г ы й м р а н. Сәлам бирдек хезмәт иясе сыйныфына!

А з а м а т. Сәламне алдык, кесәгә салдык. Әйдәгез, түрдән узыгыз, ташның йомшагын, нефтьнең чистасын сайлап, утырыгыз, иптәш хәвефсезлек инженеры!

Г ы й м р а н. Мастерыгыз кайда?

А з а м а т. Мастер килер, бер көйрәтеп җибәрик, иптәш хәвефсезлек инженеры!

Г ы й м р а н. Кайсыгызда бар тәмәкенең усалы?

Аңа төрле яктан папирос каплары сузалар. Нуришанов бер папиросны авызына каба, берне колак артына кыстыра. Имәнне баштанаяк күздән кичергәч, ашыкмый гына егетләр янына килеп утыра.

А з а м а т. Гыймран агай, сез Әлмәтнең үз кешесеме?

Г ы й м р а н. Ә нигә?

А з а м а т. Беләсе килә, менә бу имәнне дөньядан ваз кичкән бер дәрвиш утырткан, диләр. Имеш, аның йорты да, хатыны да, туган-тумачасы да булмаган. Бик зур кайгысы гына булган, ди. Дөресме шул сүз?

Г ы й м р а н *(кеткелдәп көлә).* Әкәмәт тә сәер интересный кешеләр сез, хәзерге яшьләр, һе-һе-һе... Романтика эзлисез! Һәр нәрсәдән мөгез чыгарырга тырышасыз. Талип карт имәне бит бу!

Т а в ы ш л а р. Чынмы? Кит аннан! Булмас!

Г ы й м р а н. Чудак бит ул Талип! Тик торганнан сөйләнә башлый. Такмак әйтә. Инде алай да күңеле булмаса, начальство белән тиргәшә!

Ш ә й х а т т а р. Анысын беләбез. Безнең канга да тозны аз салмады.

Н и к о л а й. Талип карт кебек кешеләр күбрәк булсын иде әле.

А з а м а т. Тавыш, тавыш! Сөйләгез, Гыймран агай.

Г ы й м р а н. Талип бабагызны мин революциягә чаклы ук беләм. Шуннан бирле килә торган атаклы чудак ул. Кешеләр тырышып-тырмашып йорт салды, ә ул өй борынча самовар төзәтеп, казан төбе ямап, ач карынга мәзәк сөйләп йөрде. Ул гынамы? Тапкан акчасына бала-чагага конфет-прәннек өләште. Карыйсың — урамда җыр тавышы. Бөтен авылны бер итеп Талип килә. Артында бер көтү бала-чага. Исерек тә түгел үзе, аракы белән шаярганын хәтерләмим мин аның.

А з а м а т. Юмарт кеше булган икән.

Г ы й м р а н. Юмартлык түгел бу, ыштансызлык!

Н и к о л а й. Юкка алай дисез, Гыймран Шәймәрдәнович, ул бит ике ятим кыз тәрбияләп үстергән.

Гыймран. Кем әйтә аны үстермәде дип? Картлык көнендә, нефть бирмәүче скважина кебек, япа-ялгыз каласың килмәсә, үстерерсең!

Кызлар. Дөрес түгел. Гүзәлия белән Мәрьямнән аның бер тиен дә акча алганы юк.

Гыймран. Әкәмәт тә сәер интересный кешеләр сез хәзерге яшьләр. Әйтерсең карап-багып үстергән балаларыңның игелеген күрү гаеп. Кайсы законга язган моны? Нинди моральный кодекста бар бу? Ул бит әнә шул кызларны эвакуация пунктыннан алып, буровойда үстерде. Сугыш. Кыр. Буровойда мунча кертә торган иде. Гәүрәтен киндер алъяпкыч белән ябып. Ә сез әйтәсез, акча алганы юк та, фәлән дә фәсмәтән. Алганы юк икән, үзе гаепле. Үстергәч алсын, и алырга полный хакы бар.

Азамат. Гыймран ага, бәхәсләшмибез. Ала гына күрсен. Имән турында сөйләгез сез, имән турында.

Гыймран. Башымны катырмагыз, егетләр. Аның нәрсәсен сөйләп торасың инде! Тиленең законы үзе белән дигән. Азмыни бу дөньяның чудагы. *(Урыныннан кузгала.)*

Азамат. Бер генә минут! Талип бабай сезне Бакуга алып барган, диләр. Дөресме?

Гыймран. Барганыйк шул... *(Күрсенә. Аның нәрсәнедер әйтеп бетермәгәнен аңлап, егетләр бер-берсенә карашып алалар. Гыймран моны сизә, котылу юлын тапкандай кычкырып җибәрә.)* Әһә, мастер да килә! Әй, мастер, мастер! *(Кул болгый.)*

Хәйрүш, Сәләхи, Зөбәрҗәт керәләр. Хәйрүш утыз яшьләрендә, күн курткадан, брезент итектән, хәрәкәтләре җитез, сүзен тиз һәм ярып сөйли. Зөбәрҗәт унсигезләрдә, зифа буйлы, шәһәрчә матур киенгән, кулында бәләкәй чемодан. Сәләхи операторлар киеп йөри торган эш киеменнән.

Хәйрүш. Исәнмесез, егетләр! Җыелдыгызмы? Оһо, хәвефсезлек инженеры да монда! Исәнмесез, Гыймран агай! Нинди җилләр белән?

Гыймран. Алты егетең хәвефсезлек кагыйдәләреннән имтихан тапшырмаган. Кисәтү ясарга килдем, мастер. Менә исемлек.

Хәйрүш. Кәтәргә вакытыгыз бармы?

Гыймран. Кәтәрбез.

Хәйрүш *(бригада өстенә күз ташлап)*. Гүзәлия Талипованы күрмим.

Кызларның берсе. Аның урынына мин чыктым.

Хәйрүш. Авырыймы әллә?

Кызларның берсе. Юк... белмим... Сәбәбен әйтмәде.

Хәйрүш. Сәләхи! Талипованың сәбәпсез эшкә чыкмый калуы беренче мәртәбәме?

Сәләхи. Беренче мәртәбә.

Хәйрүш. Сәбәбен ачыкла. Иртәгә миңа хәбәр итәрсең!

Сәләхи. Була, иптәш мастер!

Хәйрүш. Ә хәзер, иптәшләр, таныш булыгыз: мин сезгә кунак алып килдем. Зөбәрҗәт туташ, художник. *(Зөбәрҗәт нефтьчеләргә баш ия.)* Нефтьчеләр тормышыннан картина язарга тели. Герой итеп кайсыгызны сайлар, анысы үзегездән тора.

Зөбәрҗәт. Ой, сез мине оялтасыз, иптәш мастер. Картина түгел, эскизлар гына.

Хәйрүш. Тыйнаклык кызларны бизи торган сыйфат. Азамат, Зөбәрҗәтне синең карамакка тапшырам. Нефть чыгару планы белән бергә сәнгатьнең язмышын да синнән сорармын.

Азамат. Фьюююу!

Хәйрүш. Нәрсә сызгырасың?

А з а м а т. Булмый, мастер! Сәгать — гөлләр, ә без дегет мичкәләре.

Х ә й р у ш. Ишеттеңме, Зөбәрҗәт, дегет мичкәләре! Әгәр бу мичкәләрнең бер кат мазутын кырып төшерсәң, һий җүләр! Боларның һәркайсыннан чаптар ат кебек ярсып торган кайнар йөрәк килеп чыга. Их, белмибез, егетләр, дәрәҗәбезне. Соң менә, Азамат, сине генә ал. Әйтик, Зөбәрҗәт синең портретыңны язды ди...

А з а м а т. Кемгә кирәк минем портрет?

Х ә й р у ш. Җүләр син. Хыяллана белмисең. Бөтен дөньяда коммунизм булгач, барлык буржуйлар кабергә күмелгәч, коммунизм кешеләре Зөбәрҗәт туташның портретына карарлар да әйтерләр: егерменче гасыр уртасында Әлмәт каласында почык борынлы бер оператор яшәгән: мәхәббәт дигән нәрсәне белмәгән, кызларга якты чырай күрсәтмәгән, җир мае сеңгән куртка киеп йөргән. Төн йокыларын калдырып, кичке техникумда укыган, ә менә шул чыгарган җир мае нинди корабларны космоска күтәргән, диерләр...

П а у з а.

Ш ә й х а т т а р. Син безне, мастер, экият тыңларга дип җыйдыңмы? Әллә эш турында сөйләшергәме?

Х ә й р у ш. Нефть маңгай тире белән генә чыкмый, Шәйхаттар. Акыл белән, хыял белән дә чыга. Әйе, әйе, хыял белән! *(Шәйхаттарның корсагына төртеп ала.)* Син моны чыкмаган мыегыңа урап куй. *(Кызлар ягына борыла.)* Ә сезгә, чибәркәйләр, ун кило сабын белән өр-яңа спецовкалар яздырдым. Менә кәгазь — иртәгә складтан барып алырсыз.

К ы з л а р н ы ң б е р с е. Бәйрәмгә ерак бит әле, мастер.

Х ә й р у ш. Их сез, шуны да белмисезмени? Өч көннән бригаданың бәйрәме!

К ы з л а р. Нинди бәйрәм?!

Х ә й р у ш. Телеграмма алдык. *(Баш өстендә селки.)* Җәүдәт кайта! *(Телеграмма кулдан-кулга китә.)*

Т а в ы ш л а р. Җәүдәт кайта!

— Каршы алабыз!

— Бәйрәм ясыйбыз!

Х ә й р у ш. Азамат, бер кочак чәчәк хәзерлисең.

А з а м а т. Есть, чәчәк әзерләргә!

Х ә й р у ш. Ә син, Шәйхаттар, азык-төлек коменданты!

Ш ә й х а т т а р *(кукрәк киереп).* Рад стараться!

Н и к о л а й *(ирония белән).* Бәлки оркестр чакырырга, почетлы каравыл куяргадыр?!

Х ә й р у ш. Кирәк икән, оркестр да чакырырбыз, каравылын да куярбыз, иптәш Николай. Бригада өчен Җәүдәт кечкенә кеше түгел.

Г ы й м р а н. Мин, кәнишне, монда чит кеше. Әмма дә ләкин, тыңлап-тыңлап торам да, бәк тә сәер, әкәмәт интересный фикер йөртәсез бит сез, әй... Кем ул сезгә Җәүдәт Галиәхмәтов? Чит илдән килгән туристмы, әллә булмаса, корыны бушка аударып, сафсата сатып йөрүче дипломатмы? Юк, ул турист та и шулай ук дипломат та түгел. Җәүдәт Галиәхмәтов — сезнең гап-гади бер иптәшегез. Сез аны үз арагыздан иң булдыклы егет иттереп институтка укырга җибәрдегез. Сез аңа дүрт ел буена зарплата түләп бардыгыз. Соң бит ул сезгә кунак булып кайтмый, җиң сызганып эшләргә кайта, бригаданы күтәрергә дип. И шулай булгачыннан, акылыгыз белән исәпләп, башыгыз белән фикер йөртеп карагыз: нигә кирәк аңа музыка? Нигә кирәк аңа чәчәкләр? Музыка — бер тыңладың — онытыла. Чәчәк — бер сәгать кояшта тордымы — шиңә. Инде әгәренки аны олыларга телисез икән, бу егет безнең йөзебезгә кызыл-

лык китермәде дип әйтәсез икән, бирегез үзенә гомер буе истә калырлык бер бүләк.

Хәйрүш *(уйга калып)*. Ә нәрсә бирергә соң?

Азамат. Баян бирергә.

Шәйхаттар. Баянны кулына да тотканы юк бит аның.

Кызлар. Мотоцикл! Мотоцикл!

Николай. Каян табасың? Магазинда мотоцикл юк.

Хәйрүш. Нәрсә бирергә соң?

Гыймран. Миндә бер нәрсә бар барын... белмим, сез аны килештерерсезме икән?

Хәйрүш. Нәрсә ул, Гыймран агай?

Гыймран. Ау мылтыгы!

Шәйхаттар. Ау мылтыгы? Үзеңнекеме? Иске түгелме? Тутыкмаганмы?

Гыймран. Әнә Николайның күргәне бар, әйтсен. Искеме?

Николай. Мылтык яңа.

Гыймран. Ижау заводыныкы. Иң зур мастерлар кулыннан узган штучный эш. Ерак баҗай танышлык белән генә алып биргән иде.

Шәйхаттар. Яралап кына калдырмыймы?

Гыймран. Ничек яралап?

Шәйхаттар. Була шундый мылтыклар, атуын да шәп ата, тидерүен дә тидерә, ләкин куянны җиргә сыламый, кошны да имгәтеп кенә калдыра....

Гыймран. Нуришанов мылтыгы имгәтеп кенә калдырмас. Бер чүкүдә җиргә сылар.

Хәйрүш. Туктагыз әле, Гыймран агай. Мылтыкка бит сез хуҗа...

Гыймран. Ай алла, исең киткән, бригада исеменнән бирергә телисез икән, миңа акча җыеп бирерсез.

Хәйрүш. Менә монысы акыл. Алабызмы, егетләр?

Егетләр. Алабыз!

— Шәп бүләк!

— Каршылыйбыз Җәүдәтне!

Хәйрүш. Рәхмәт, Гыймран агай, коткардыгыз. Бирегез бишне. *(Каты итеп кул кысышалар, гомуми җанлану.)* Бригада, по местам!!! *(Шау-гөр килеп чыгып китәләр.)*

Сәләхи *(үз алдына)*. Беренче мәртәбә мин аны имән янында каршы алмадым... Кайда йөри бу кызый?

Мәрьям керә. Сулуы капкан.

Мәрьям. Әтисе. *(Кул болгый.)* Әти-ии-сее!

Хәйрүш *(керә)*. Нәрсә бар, әнисе? *(Хатынының шаяртып битеннән үбеп ала.)*

Мәрьям *(шыпырт)*. Бер генә сәгатькә өйгә кайтып килә аласыңмы?

Хәйрүш *(куркып)*. Талип бабай авырдымы әллә?

Мәрьям. Юк.

Хәйрүш. Мәктәбеңдә берәр күңелсезлекме?

Мәрьям. Юк.

Хәйрүш. Нәрсә соң? Әйт инде, әйт.

Мәрьям. Җәүдәт кайтты.

Хәйрүш. Кит аннан! Чынмы? Кайтып та җиттемени?!

Мәрьям. Шаулама!

Хәйрүш. Нигә шауламаска! Шаулыйбыз, әнисе, шаулыйбыз! *(Кул болгый-болгый кычкыра.)* Иптәшләр, дуслар, килегез әле монда! *(Барысы да аның янына җыела.)* Җәүдәт кайтып җиткән!

Т а в ы ш л а р. Кайчан? Кайда?

Х ә й р ү ш *(Мәрьямгә).* Кайчан кайтты, бетергәнме институтын?

М ә р ь я м. Бетергән.

Х ә й р ү ш *(егетләргә).* Бетергән, ди. *(Мәрьямгә.)* Дипломын күрдеңме?

М ә р ь я м. Күрдем. Дипломын да күрдем, үзен дә күрдем.

Х ә й р ү ш *(егетләргә).* Дипломын күрдем, ди. *(Мәрьямгә.)* Кайчан кайтты?

М ә р ь я м. Өч көн инде аның кайтканына.

Х ә й р ү ш. Өч көн?! Ничек?! Өч көн буена бригадага килми йөриме?

Т а в ы ш л а р. — Безобразие!

— Дөрес.

— Дөрес түгел.

— Яклашма.

— Яп авызыңны, өшегән!

Х ә й р ү ш. Иптәшләр, иптәшләр!.. *(Мәрьямгә.)* Әйт, сузма, ник килмәде?

М ә р ь я м. Ул сезгә сюрприз ясарга тели. Мин шуны әйтергә дип йөгердем. *(Бүтәннәргә сиздерми генә Хәйрүшкә йодрык күрсәтә.)*

Х ә й р ү ш. Нинди сюрприз тагын? Монысы да җитеп узган!

М ә р ь я м. Җәүдәт өйләнә.

С ә л ә х и. Өйләнә?! Кемгә?!

М ә р ь я м. Минем сеңелгә.

С ә л ә х и. Гүзәлиягәме?

М ә р ь я м. Әйе.

Сәләхи чайкалып китә, беркемгә карамый чыгу юлына бара.

Х ә й р ү ш. Сәләхи, син кая? *(Сәләхи борылып та карамый.)* Ни булды? Ник дәшмисез?

Н и к о л а й. Әйбәт килеп чыкмады бу, мастер...

Х ә й р ү ш. Аңламыйм, ни булды?

А з а м а т. Сәләхи бит аны ярата иде.

Н и к о л а й. Операторлык эшенә өйрәтте.

Х ә й р ү ш. Ничек соң мин белми калдым?

Уңайсыз тынлык.

Г ы й м р а н. Мин, кәнишне, монда чит кеше. Ләкин тыңлап-тыңлап торам да... Куертасыз да инде, егетләр! Кайсыбызның сөйгән ярлары калмаган?! Табар Сәләхи үзенә тиңне. Давай, мастер, бир командаңны, иртәгә ял көне, дөнья шаулатып бәйрәм итегез. Хуҗалык ягын рәтләргә үзем булышам. Авылдан бик шәп бер тана алып кайтып бирәм.

Х ә й р ү ш. Рәхмәт, Гыйммран абзый. Сезнең ярдәм безгә бик кирәк. Азамат, быргың мондамы?

А з а м а т. Монда, иптәш мастер.

Х ә й р ү ш. Сигнал бир. Бригаданы үзәк культбудкага җыябыз!

А з а м а т. Есть, сигнал бирергә!

Шаулашып чыгып китәләр. Сәхнә тып-тын кала. Бераздан кемнеңдер моңаеп җырлаганы ишетелә.

Тиңләр өчен серле күзләреңне
Күк йөзеннән йолдыз эзләдем.
Гөлләр сибеп йөрдем эзләреңә,
Ятка калырсың дип белмәдем.

С ә л ә х и керә.

Сәләхи *(күңеле белән сөйләшә).* Сөя белмәгәнмен, имеш, сөймәгәнмен, имеш, беркемне... Их, белмисез, белмисез, йөрәксез бу егет дип уйлыйсыз инде, ә?.. Хисләремне әйтмәдем шул мин аңа, уйларымны яшереп йөрдем. Аңлар әле дигән идем, аңламады... *(Җырлый.)*

Янсын әйдә йөрәк, янсын дөрләп! —
Ялкыннары берәр сүрелер,
Сүнмәс мәхәббәтем очкыннары
Йолдыз булып күккә сибелер.
Караңгыда юллар эзләрсең дә
Йолдызларга карап табарсың.
Сызылып кына йолдыз атылганда
Өзелеп сөюемне аңларсың.

Талгын музыка кинәт көчәя. Ерактан, урман әчләрен айкап, быргы тавышы ишетелә.

## СӘХНӘ АЛДЫ

Гыйммран белән тана хуҗасы ашыгып килеп керәләр.

Тана хуҗасы. Син тананы карадым дисең, алайса?

Гыймран. Каравын карадым да, безгә ярарлык түгел әле ул.

Тана хуҗасы. Нәрсәсе ярарлык түгел?

Гыймран. Гәүдәгә дә кечкенә, симерүе дә җитмәгән.

Тана хуҗасы. Син андый сүзләрне бүтән кешегә сөйлә, акыллы абзый. Суйсаң аның пот ярым мае гына чыга. Әлмәт базарына илтеп йөрергә вакытым гына юк: комбайным ремонтлап бетмәгән. Югыйсә, мин синең белән сөйләшеп тә тормас идем.

Гыймран. Әкәмәт тә сәер интересный кеше икәнсең син: кала кешесе дигәченнән дә әллә син мине гомер буе мал күрмәгән әдәм дисеңме? Бик беләсең килсә, Гыймран абзаң ун ел буе заготскотта эшләгән һәм шулай ук синеке ише йолкыш таналарны гына күрмәгән! Холмогор үгезләрен егып суйган абзаң булыр бу! Алай бәхәскә китсә, бир кулыңны, танаңны күз алдында егып суябыз: күп булса биш пот ите, егерме кадак мае чыга!

Тана хуҗасы. Китче! Бозау булып бозаудан дүрт пот ит чыга бит.

Гыймран. Беләсеңме, чибәр егет, дөньяда Хуҗа Насретдин дигән акыллы бер җүләр булган, әнә шул акыллы җүләр әйткән: әдәм ышанмастайны чын булса да сөйләмә, дигән. Бозаудан беркайчан да дүрт пот ит чыкмый. Так што син минем башымны катырма, әйдә, кайтабыз өеңә, танаңны егып суябыз, мин дигәнчә булмаса — битемә төкерерсең!

Тана хуҗасы. Ярый, синеңчә булсын, күпме бирәсең?

Гыймран. Тана синеке, син сора.

Тана хуҗасы. Артыгын сорамыйм: өч йөз тәңкә.

Гыймран. Өч йөз?!

Тана хуҗасы. Нигә бик шаккаттың?

Гыймран. Бар, энем, битеңне юып кил!

Тана хуҗасы. Безнең бит юган, акыллы абый.

Гыймран. Юган булса, тиярен генә сора.

Тана хуҗасы. Ә нигә, миңа ике ярымны бирделәр инде.

Гыймран. Биргәч, сатасың калган.

Тана хуҗасы. Сатармын да!

Гыймран. Сата гына күр. *(Ашыгып китә башлый.)*

Тана хуҗасы. Тукта, син бит әле үз бәяңне әйтмәдең?

Гыймран. Йөз илле тәңкә көмеш сиңа, артыгы бер тиен дә юк.

Тана хуҗасы. Китче булмаганны! Әллә син аны урлаган мал дип белдеңме?

Гыймран. Ә син күпме дисең?

Т а н а  х у җ а с ы. Минә синң соңгы бәя — ике дә сиксән.

Г ы й м р а н. Нәрсә?!

Т а н а  х у җ а с ы. Ике дә сиксән дим.

Г ы й м р а н. Кеше көлдермә. Базарда булганы юк андый бәянең.

Т а н а  х у җ а с ы. Мотоцикл алырга дип кенә асраган танам иде. Әйдә, кадалып кит: ике дә илле.

Г ы й м р а н. Минә монысы кешечә. Ләкин таяк тоткан җиреннән генә сынмый. Давай без болай итик: син тагын җитмеш сумны киметәсең, мин җитмеш сумны күтәрәм: йөз сиксәнгә килешәбез дә мәгәричен эчәбез.

Т а н а  х у җ а с ы *(җан ачуы белән)*. Син минемканымны эчмә, әнә, аласың килә икән, ике дә егерме, инде шуңа да риза булмасаң, сөйләшеп тә тормыйм!

Г ы й м р а н *(эшләрнең чуалуын аңлап)*. Ярый, миннән булсын яхшылык, ике багана!

Т а н а  х у җ а с ы. Син бит мине кычкыртып талыйсың.

Г ы й м р а н. Ай, алла бәндәсе, әйтеп торам лабаса! Акчалата ике йөз тәңкә, ул гына әз дисәң, башы-аягы, эче-бавыры синеке. Өстәвенә тиресен калдырам: үзе ун тәңкә. Бир кулыңны!

Т а н а  х у җ а с ы. Ә мәгәрич?

Г ы й м р а н. Миннән булсын яхшылык — бер ярты!

Т а н а  х у җ а с ы. Аз.

Г ы й м р а н. Мин эчмим. Үзеңә генә. Бир бишне! *(Шартлатып кул сугалар.)* Мин хәзер киләм, юлда машина тота тор. *(Тана хуҗасы китә. Гыймран итек кунычыннан сугым пычагы чыгарып, кайракта яный башлый.)* Гыймранны алдардай кеше дөньяда тумаган әле! Тугыз поттан да ким түгел ул тананың ите. Безнең кесәгә саф сиксән тәңкә акча керә дигән сүз, һе-һе-һе. Ә без ул акчага инженерның яшь бикәченә бик шәп бер бүләк әзерләрбез. Сюрприз, һе-һе-һе! *(Китә)*.

Т а л и п. *(таягына таянып керә)*. Оһ-һо-һо-һо... И гомерләр, гомерләр! Кайчан гына әле мин аны юындырудан туктадым. Хәреф танырга өйрәтеп йөрдем. Дөньяны танырга өйрәтә алдыммы? Бүген ул ата йортыннан очып китә. Ныкмы аның канатлары? Туй күлмәге алдым. Аппак туй күлмәге... Нинди йортка алып барасың син минем кызым Гүзәлияне? Мин көткән йорткамы? Оһ-һо-һо-һо...

Чаң тавышы. Эчке пәрдә ачыла.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман аланы. Имән әйләнәсендә туй өстәлләре. Чәчәкләр. Вазаларда — кып-кызыл каен җиләге, җир җиләге. Рюмкалар, бокаллар, портвейн һәм шампан шешәләре кояш нурыннан кабынып-кабынып китәләр. Ак эскәтер өстендә, җанлы бизәкләр булып, имән яфракларының күләгәләре төшкән.

Пәрдә ачылганда сәхнә буш, каяндыр урман ягыннан сөенеп көлгән, шаулаган тавышлар, күңелле җырлар ишетелеп кала. Кемдер икенче тарафта өздереп баянда уйный, аңа тыпырдатып бииләр. Сәхнәгә әкрен генә С ә л ә х и керә.

С ә л ә х и. Бу аланнардан ул мазутлы кием белән уза торган иде. Бүген туй күлмәгеннән киләчәк. Бүтән көнне мин аны каршы ала идем. Бүген инде аның шатлыгын башка кеше уртаклашыр. Дүрт ел бүе операторлыкка өйрәттем, авыр сүз әйттермәдем. Күбәләк тасмалы үсмер кыз! Син миңа, сәер итеп, Сәләхи абый дип дәшә торган идең... Бүген менә кияүгә чыгасың. *(Көрсенә)*. Китәргә кирәк моннан. Олагырга! Кая китә алам соң мин? Ул бит менә монда, күңел түрендә. Үз күңелеңнән качып буламыни? *(Пауза)*. Егет бул, Сәләхи, бирешмә! Син аның туенда булырга, син аны күрергә тиеш. *(Хыялланып)*. Туй күлмәгеннән нинди була икән ул? Юк, китәргә ярамый. Мин Җәүдәтне дә күрергә тиеш. Мин яраткан чаклы ярата мы ул аны? Аңлыймы? *(Әкрен генә чыгып китә)*.

Сәхнәнең икенче ягыннан кулына пиво шешәсе белән стакан тоткан Ш ә й х а т т а р керә. Чирәм өстенә утырып, ашыкмый гына пиво сала, шешә белән чәкәшә.

Ш ә й х а т т а р. Бәйрәм матур булырга охшый. Шәп егеткә чыкты Гүзәлия. Ә без, Шәйхаттар Габсаттарович, үзебезнең саулыкка бер күтәреп алыйк. *(Эчәм дигәндә генә Азамат килеп керә).*

А з а м а т. Туйга килдеңме син, Шәйхаттар, качып-посып сыра эчәргәме?

Ш ә й х а т т а р. Эчәсең килгәч, ерактан уратып маташма син, Азамат, «эсәһем килә» диген дә туп-туры әйт. *(Кесәсеннән запас стакан чыгара, ике стаканга да тутырып сала).* Синең саулыкка, башкорт токымы! Кияү белән кыз килгәнче берне әйләндерик! *(Эчәләр).* Син ничек уйлыйсың, Гүзәлия белән Җәүдәт тиң килгәннәрме?

А з а м а т. Гүзәлия Сәләхигә чыкса, бәхетлерәк булыр иде.

Ш ә й х а т т а р. Менә бу — минем өчен яңалык. Ә ни өчен?

А з а м а т. Җәүдәтнең бер кимчелеге бар: акчага бик хирыс кеше. Ә халык нәрсә ди?

Ш ә й х а т т а р. Алтын күргәч, фәрештә дә азган, ди.

А з а м а т. Дөрес әйтәсең, мин бәләкәй чакта...

Ш ә й х а т т а р. Я, ярый, алдан юрамыйк, дустым. Әгәр Гүзәлия апасы Мәрьямгә охшаса, Җәүдәтнең ике аягын бер кунычка тыгып куяр. *(Көләләр. Шаулашкан тавышлар якыная).* Киләләр! *(Стаканны яшерә).* Ал гармуныңны!

Аланга бәйрәмчә киенгән Хәйрүш белән Мәрьям керәләр. Хәйрүш уңга-сулга кул болгый. Азамат аларны гармун уйнап каршылый. Шәйхаттар кунакларны каршы алып, җиңеләеп, ду килеп йөри. Н и к о л а й йөгереп керә.

Н и к о л а й. Киләләр!

Х ә й р ү ш. Кияү белән кызга юл ачыгыз!

Халык ике якка аерылып, яшьләргә юл ача. Салмак кына атлап, аланга ап-ак туй күлмәгеннән Г ү з ә л и я, кара костюмнан Җ ә ү д ә т килеп керәләр. Кулларында чәчәк бәйләме. Алар белән янәшә Гыймран Нуриханов һәм озын чуклы ефәк шәл бәйләгән Хәдичәттәй атлый.

Х ә й р ү ш. Иптәшләр! Җәүдәт белән Гүзәлияне яңа тормыш башлаулары белән бригада исеменнән тәбрик итәм!

Т а в ы ш л а р. Ура! Ура! Ура!

Азамат баянда туш уйный.

Х ә й р ү ш. Бригада исеменнән тәкъдим кертәм: кияү белән кыз, җитәкләшеп, аланны бер мәртәбә әйләнеп чыксыннар!

Музыка астында Җәүдәт белән Гүзәлия түгәрәкне әкрен генә әйләнеп, башта өлкәннәр утырган өстәл янында, аннары яшьләр өстәленә, соңыннан гармунчыга баш иеләр. Өстәл янындагылар кияү белән кызга җыр белән теләкләрен әйтә баралар.

Теләк җырлары:

Аерылмагыз, каерылмагыз,
Пар булсын канатыгыз.
Айга түгел, елга түгел,
Гомергә яратыгыз.

Алтын фонтан атып торсын
Йөргән юлларыгызда.
Тагын бер биесәк иде.
Алтын туйларыгызда.

Бергә яшик, әй, туганнар,
Тыныч торсын дөньялар.
Энием дип бер әйтергә
Тилмермәсен оланнар.

Гармунчыга баш игән чакта С ә л ә х и кереп, кияү белән кыз каршысына туктый. Җыр беткәнче Гүзәлиядән күзен дә алмый карап тора.

Х ә й р ү ш. Дусларым, без бу көнне озак көттек. Бригадабыз символы имән дә көтте. Сез хәзер менә шушы имәнле аланда бербрегезгә туры булырга, кабергә чаклы яратышырга, бригаданы беркайчан да онытмаска сүз бирегез!

Пауза.

Җ ә ү д ә т *(дулкынланып)*. Рәхмәт сезгә, дусларым... Яхшылыгыгызны беркайчан да онытмам... *(Бригадага баш ия)*.

Х ә й р ү ш. Тутырыгыз бокалларны! *(Җанлану)*. Игътибар! Бокалларны кулга тотуыгызны сорыйм!

А з а м а т *(Хәйруш янына йөгереп килә)*. Хур булдык, кияү белән кызга бокал куймаганнар.

Х ә й р ү ш. Иптәшләр, кияү белән кызның бокаллары юк, ди. Дөресме шул хәл?

Т а в ы ш л а р. Дөрес!

Х ә й р ү ш *(тантана белән)*. Кадерле дусларыбыз Гүзәлия һәм Җәүдәт, без бөтен бригадабыз белән уйлаштык та: яшьләр бәхетләрен тустаганнан башламасыннар, көрәктән башласыннар, дигән фикергә килдек. Шуңа күрә, дуслар, сез бүгенге туегыз хөрмәтенә, Җәүдәтнең институтны тәмамлап кайту истәлеге итеп, безнең аланга нәни алмагач утыртыгыз. *(Борылып кычкыра)*. Гыймран абзый!

Г ы й м р а н киндергә төргән алмагач үсентесе белән көрәк алып керә. Хәйруш көрәкне Җәүдәткә, үсентене Гүзәлиягә тоттыра. Җәүдәт пиджагын салып, ярсынып, җир казырга тотына, Гүзәлия, нәни алмагачны бик сак кына, ватмагаем дигән төсле, иплән кенә тотып тора: әйтерсең лә аның кулында алмагач үсентесе түгел, аның үзенең киләчәк язмышы саклана.

Х ә й р ү ш. Табын янына рәхим итегез! *(Шаулашып утыралар)*. Бүген без яшьлек бәйрәменә җыелдык. Тантанага. Имән янында безнең дусларыбыз безгә сүз бирделәр. Акыл өйрәтә дип үпкәләмәгез: сүз бирү яхшы, ләкин дөньяда бер хакыйкать бар: арба, йөк салгач, шыгырдый, ә бораунң ныклыгы гранит токымнарда сынала. Җәүдәт белән Гүзәлия сынатмаслар дип ышанабыз. Бүгенге кичәнең гаепле кешеләре Җәүдәт белән Гүзәлия саулыгына! *(Бокалларны күтәрәләр. Кул чабалар)*.

Кызлар җиңел газовой яулыклар белән яшьлек вальсын башкаралар. Вальсның азагында зур бер яулыкны бик нәфис итеп, кияү белән кыз өстенә китереп каплыйлар. Гомуми җанлану, кул чабулар.

Н и к о л а й *(табын тынычлангач)*. Иптәшләр, мин менә бу бокалны эчеп караган идем, бик ачы булып чыкты. Кияү белән кызга бер үтенечем бар: кунакларны хөрмәтләп, безнең бокалларны баллы итеп бирмәсләрме. Ачы бу! Ачы!

Х ә й р ү ш. Ачы!!

Кияү белән кыз аяк өсте басалар. Гүзәлия, оялып, каушап башын читкә бора, үптермәскә тели, бригада аның саен ярсына, кул чаба, рәхәтләнеп көлә. Гармун дәртле бию көенә күчә. Уртага ярсынып Шәйхаттар чыга.

Ш ә й х а т т а р *(такмак әйтеп бии)*. Бие, бие, Шәйхаттар, Габсаттар, Гайфулла! Ай җаный, Мәйсәрә, Рәхилә, Гүзәлем! Биегән кеше бай була, ай җаный, Шәйхаттар, Азамат, вай җаный, Гүзәлия! Биегән кеше бай булганчы, Шәйхаттар, ай җаный, Мәйсәрә, Кәүсәрия, Гөлгенә, карт алаша, ай җаный, ай! Киңрәк мәйданны, киңрәк! Менә шулай, менә шулай, һоп! Атның аласы була, Камәрия, Гүзәлия! Җем-җем карасы була, Мәйсәрә! Ай җаный, кенәри, сандугач, сөйсәң сөй ярның чибәрен, Сәләхи, сөйсәң сөй ярның матурын, Шәй-

хаттар, сөйсәң аласы була, дусларым! Һай-ли-һай-ли, кара күзләр алдалый, кара күзләргә алданып, зәңгәр күзләр калгалый! Дөресме, дусларым!

Тавышлар. Браво!

— Молодец, Шәйхаттар!

Гыйльмран белән бер кодагый картларча мәзәк бию башкаралар.

Сәләхи. Мин җырлыйм. *(Сагаюлы тынлык урнаша. Сәләхи кияү белән кыз янына басып җырлый).*

Аккошлар китәр көзгә,
Каурыен күлдән эзлә.
Аккошлар юлы шикелле
Ак бәхет телим сезгә.

Сәләхи җырлап бетерүгә кинәт борылып, ашыгып, йөгереп чыгып китә. Уңайсыз тынлык.

Гыймран. Гомернең узуына исләрең китәрлек. Әле күптәнме-ни Җәүдәтнең әтисе Галиәхмәт белән гапләшеп утырган идек. «Әй, кордаш, дигән иде миңа, шушы улымның үсеп җитеп, кеше булуын күрер көнем булыр микән?» дигән иде. Бик киң күңелле, бәк компанийский душа кеше иде Җәүдәтнең әтисе, авыр туфрагы җиңел булсын. Сугышына барып сугышып та кайтты, ярасын алып, ранный булып та кайтты. Ишулай ук ярасыннан гүр иясе булып та китте... *(Пауза).* Җәүдәткә ничә яшь иде әле ул чакта, Хәдичә?

Хәдичә. Җиде.

Гыймран. Әйе, дөрес әйтәсең, Хәдичә. Җәүдәт беренче сыйныфка укырга кергән сабак баласы гына иде ул чакта. Үләр алдыннан кордаш миңа әйтте: ышаныч синдә инде, Гыймран, улымны күздән ычкындырма, үз улың кебек итеп кара, и шулай ук кеше ит, диде. Инде менә үзегез күреп торасыз, Җәүдәт укып кеше булды, аның өстәвенә, өйләнеп башлы-күзле дә булды. Мин моның белән нәрсә әйтергә телим? Бүгенгесе көнне бу табында мөхтәрәм кеше Хәдичәттәй утыра. Авырлыкларга бирешмичә, шундый да акыллы, шундый да башлы егет тәрбияләп үстергәне өчен без бүген Хәдичәттәйгә рәхмәт әйтергә тиешбез. *(Алкышлар. Хәдичәттәй яулык чите белән күзләрен сөрткәли).* Безнең бүгенге мәҗлеснең түр башында икенче зур хөрмәтле кеше, өлкән дустыбыз, нефтьчеләр ветераны Талип агай утырырга тиеш иде. Аның монда булмавы үкенечле, әлбәттә. Ни хәл итмәк кирәк, ул авырып киткән. Балаларының сөенечен уртаклаша алмый. Ә бит сиксән яшәр бу карт үз гомерендә ниләр генә күрмәде, күпме скважина бораулады, шуның өстәвенә, берсеннән-берсе чибәр, берсеннән-берсе булдыклы и шулай ук тәүфыйклы Мәрьям белән Гүзәлияне тәрбияләп үстерде. Шуның өчен без аңар кайнар рәхмәтебезне белдерергә и шулай ук тизрәк терелүен теләргә тиешбез...

Пауза.

Аттан ала да туа, кола да туа, ди халык. Әлбәттә, Җәүдәт белән Гүзәлия үзләре тырышмасалар, берни дә барып чыкмас иде. Рөхсәт итегез миңа, Гүзәлиягә бәхет теләп, үз исемемнән шушы кечкенә генә бүләкне тапшырырга. *(Зәңгәр бәрхет тартма бирә. Алкышлар).*

Кызлар. Бүләкне күрсәтсен.

Гүзәлия тартманы ачып, сәгать ала.

Кызлар. Ай, нинди матур!

— Алтын сәгать!

Кызлар җыелып бүләкне карыйлар.

Гыймран. Җәүдәт институтта сезнең ышанычны аклады. Дипломлы инженер булды. Зур корабка зур диңгез дигәннәр. Эшнең бик зурысы көтә аны. Рөхсәт итегез миңа, Җәүдәтнең әтисе урынына калган кешегә, бригада рөхсәте белән шушы бүләкне тапшырырга. *(Чехолдан ике көпшәле ау мылтыгы чыгара. Алкышлар).* Мә, энем, хәвеф-хәтәрдән юлдашың булсын бу мылтык.

Шәйхаттар. Атып карасын.

Николай. Кирәкми.

Азамат. Ата белми бит ул.

Гыймран. Яле, инженер, күрсәт әле дусларыңа һөнәреңне, мә нә синә патрон!

Җәүдәт мылтыкны кора, иңенә тери һәм имән ягына төзәп, гөрселдәтеп атып җибәрә. Имәннең бер ботагы сынып җиргә килеп төшә. Тирән тынлык.

Гүзәлия *(ботакны барып ала).* Ай... имәнне яраладык...

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Җәүдәтләр ишегалды. Тәрәзләр тәрәзкән иске койма. Койманың теге ягында алма бакчасы күренә. Сул якта йортның чолан башы чыгып тора. Ул да нык искергән. Вакыт әле иртә. Өйдән Хәдичә чыга.

Хәдичә. Йа, раббем, йортыбызга кергән бәрәкәтне сакла, улым белән киленемне тәүфыйклы ит. Ярабвый ходаем...

Бакча ягыннан кулына кәрәк тоткан Җәүдәт кайта.

Җәүдәт. Әни, син теләкләрне күбрәк тели башладың түгелме?

Хәдичә. Көфер сүз сөйләмә, улым: синең бәхетең өчен тырышам. Җәүдәтем укымышлы булсын, кара эштә чиләнмәсен дип, намаз укып, теләк теләдем. Ходай теләгемне кабул итте: менә дигән итеп укыдың, бөтен калага дан итеп туй ясадың. Иптәшләрең дә бик зурладылар! Машинасы белән төяп өй җиһазы китерделәр.

Җәүдәт *(көлә).* Алары да син теләгәнгә булдымы?

Хәдичә. Мин теләгәнгә, улым, мин теләгәнгә!

Җәүдәт *(көлә).* Әни, бик зур итеп бер теләк телә әле, мин уйлап табасы диспетчерлык системасы үзеннән-үзе тезелсен дә куйсын!

Хәдичә. Авызыңны ерма, Җәүдәт. Әтиеңнең дә гомере мине үртәп үтте. Синең кебек бик үзсүзле кеше иде, мәрхүм. Авыр туфрагы җиңел булсын: бүген менә үлгәненә унбиш ел тулды.

Җәүдәт. Әтинең үлгән көнемени бүген?

Хәдичә. Үлгән көне. Син укуда чакта ул утырткан җимеш бакчасын корытмый сакладым...

Җәүдәт. Әни, миңа әйтер сүзең бар мәллә?

Хәдичә. Бар, улым, бар. *(Пауза.)* Көтмәдем түгел, көттем. *(Пауза.)* Кичә әтиеңнең каберенә барып кайттым. Чардуганнары җимерелгән, баш очындагы имән тактасы черегән...

Җәүдәт. Беләм, әни...

Хәдичә. Түбән очның Фәтхерахман малае, нефтедә эшләүче Сәүбәнне әйтәм, Бөгелмәдән кара таш апкайтып, әтисенең каберенә куйган. Гранит диме, мәрмәрме... Бөтен кеше исе китеп сөйли. Бер мең тәңкәгә төште дип әйтә, ди.

Җәүдәт. Анысын да күрдем, әни... Институттан кайтышлый зиратка кереп чыктым...

Хәдичә. Менә йорт та тузып килә. Капка баганалары әллә-хәлле... Җил чыкса, авып төшмәгәе дип котларым алына.

Җәүдәт. Алары да күз алдымда, әни...

Хәдичә. Күз алдында булу гына җитми. Чарасына керешергә кирәк. Син дә кайгыртмасаң, мин дә кайгыртмасам, кем кайгыртыр аларны? Бөтенләй череп беткәч, кайда торырбыз?

Җәүдәт. И әни, хәсрәтең шул гынамы? Чересен, аусын! Улың — инженер. Эшли башлау белән промыселга гариза бирәм. Квартирның өр-яңасын алырбыз. *(Хәдичә ашыгып читкә борыла. Күзләрен яулыгы белән каплый.)* Чү, әни, ни булды сиңа?

Хәдичә. И, улым, улым... *(Авыр сулый.)* Килен белән икегез йортның әллә нindiләренә күчегез, минем моннан беркая да китәсем юк.

Җәүдәт. Нишләп, әни? Чиләк белән су ташып туймадыңмыни? Кыш көннәрендә мич ягып йөрүләре бик асатмыни? Әмин тагын... сине газлы, ванналы йортларда яшәтәм дип ашкынып кайткан булам.

Хәдичә. Кирәкми! Газыгыз да, ваннагыз да — үзегезгә булсын. Бабаңны шушы йортта аклар атып үтерде, әтиең шушы йортта гүр иясе булды, шушы йортта минем яшьлегем узды. *(Тагын күңеле тула.)*

Озак пауза. Гыйм ран Нуришанов керә.

Гыйм ран. Рөхсәтме?

Җәүдәт. Әйдәгез, Гыйм ран абзый!

Гыйм ран. Исәнлекме, Хәдичә?

Хәдичә. Ярыйсы, бер көе... *(Өйгә кереп китә.)*

Гыйм ран. Ни булды әниеңә? Рәнҗеттеңме әллә?

Җәүдәт. Ю-уук...

Гыйм ран. Алайса, ник әвене янган кеше төсле утырасың? Талип карт берәр күңелсезлек ясадымы әллә?

Җәүдәт. Юк ла...

Гыйм ран. Миннән яшермә, энем, күреп торам.

Җәүдәт. Мин, Гыйм ран абзый, инженер дипломы кесәдә булгач, дөнья түгәрәкләнде, дип уйлаган идем. Борчудан баш чыгасы юк икән әле.

Гыйм ран. Никтән борчу ул тагын?

Җәүдәт. Өй тузган. Капка аварга тора. Әтинең каберенә таш куярга кирәк.

Гыйм ран. Молодец, Җәүдәт! Болай булса — мин синең дустың! *(Җилкәсенә кулын сала.)* Бөтен курыкканым шул иде: мәйтәм, бу егетнең башына институтта кибәк тутырып җибәргәннәрме? Молодец! Әниеңне ташлама, әтиеңне беркайчан да онытма! Менә булырсың кеше!

Җәүдәт. Аларны беләм, Гыйм ран абзый...

Гыйм ран. Әйтеп бетер, әйтеп бетер... Нишләргә уйлыйсың?

Җәүдәт. Бөтен бәла дә шунда шул: нишләргә? Кесәдә биш сум акча бар...

Гыйм ран. Әйе. Хәлең авыр. Эшкә кая урнашасың?

Җәүдәт. Төне буе Хәйрүш белән утырдык. Мастер ярдәмчесе итеп чакыра.

Гыйм ран. Ә син?

Җәүдәт. Белмим, Гыйм ран абзый, куркып торам әле. Хыялый дип юкка гына әйтмәгәннәр икән аны! Шул чаклы күп планнар сөйләп ташлады. Өстемә шул чаклы күп эш өйде. Өр-яңа диспетчерлык системасы! Бер скважинадан берьюлы өч горизонт нефть суырту проекты! Болар бит, Гыйм ран абзый, беләсеңме, минем бөтен белемемне, ял сәгатьләремне суырып алачак! Шуның өстенә хуҗалык!

Г ы й м р а н. Яшерен-батырын түгел, энем: Хәйрүшкә сүз бирдеңме?
Җ ә ү д ә т. Бурычым бар бит...
Г ы й м р а н. Нинди бурыч?
Җ ә ү д ә т. Бригада бит мине укытты, биш ел буена хезмәт хакы түләп торды. Миннән эш көтәләр.
Г ы й м р а н. Эш көтәләр дисең. Эш көтәләр. Ә бажаң сиңа үз урынын бирәме? Аның белеме бит техникум белеме генә! Ә син инженер!
Җ ә ү д ә т. Ни сөйлисең, Гыйммран абзый?! Аның урынына борын сузу... бу бит — әдәпсезлек!
Г ы й м р а н. Ярый, шулай да булсын. Сине борчыганы бурыч түләүме? Ул чакта инде зур итеп түлә син аны. Мин сиңа яучы булып килдем.
Җ ә ү д ә т. Яучы?! Нинди яучы?
Г ы й м р а н. Промыселга өлкән инженер кирәк.
Җ ә ү д ә т. Нигә, анда инженер юкмыни?
Г ы й м р а н. Инженер барын бар, ләкин ул безгә кулай кеше түгел.
Җ ә ү д ә т. Ничек аңларга моны?
Г ы й м р а н. Чамадан тыш интеллигент. Хәзер бит игәү белән тырнак чистартып утырган өчен генә инженер итеп тотмыйлар. Хәзер, иптәшкәем, бюрократлар белән бугазга-бугаз килә торган замана. Моның өчен нәрсә кирәк? Деловой булырга! Инә күзеннән дә үтә бел, Мәскәүнең Кремль сараенда да югалып калма! Менә булырсың җитәкче! Ә синдә, Җәүдәт, ул сыйфатлар — җитәрлек.
Җ ә ү д ә т. Ул эшнең тәртибе ничек соң?
Г ы й м р а н. Тәртибе дип... Промысел мөдире үзе чакырып тора бит. Ялынып-ялварып йөрисе түгел. Хезмәт хакы да приличный, машинасы да үз кулыңда...
Җ ә ү д ә т. Мөдир мин килер дип ышанамы?
Г ы й м р а н. Әйттем мин аңа: ай-һай, дидем, бригададан җибәрерләр микән, дидем.
Җ ә ү д ә т. Ә ул?
Г ы й м р а н. Ул өстәл артыннан сикереп торды да бер генә кычкырды. Зур корабка — зур диңгез! — ди. Я, ничек дип әйтим мөдиргә?

Сулуы капкан А з а м а т керә.

А з а м а т. Уф, үләм, су бирегез. *(Ишегалдында торган чиләкне күтәреп, түгә-түгә, су эчә.)*
Җ ә ү д ә т. Ни булды?
А з а м а т. Әкәмәт анда! Юлдагы машинаны туктатып чаптым.
Г ы й м р а н. Нәрсә бар? Җүнләп сөйлә: куркынычсызлык кагыйдәсен бозганнармы әллә?
А з а м а т. Мастер әйтте, Җәүдәтне тап, хәзер үк килеп җитсен, диде. Менә шул! Мин киттем, килә дип әйтимме?
Җ ә ү д ә т. Хәзер килеп җитәм.

Азамат китә.

Г ы й м р а н. Сер булмаса әйт, энем, нәрсәгә чакырган?
Җ ә ү д ә т. Сер дип... сер түгел. Яңа системаның датчигын сынап карарга булган идек. *(Ашыгып җыена башлый.)* Әни, әни! *(Өйдән Хәдичә чыга.)* Әни, минем эш киемнәрен чыгар әле!
Х ә д и ч ә. Хәзер, улым. *(Өйгә кереп китә.)*

Г ы й м р а н. Син, энем, минем сорауга җавап бирмәдең бит әле. Промысел мөдиренә нәрсә дип әйтим?

Җ ә ү д ә т. Баш инженер булырга теләмим, дип әйтте диген.

Г ы й м р а н. Ялгыш иштмәдемме мин?

Җ ә ү д ә т *(өздереп)*. Бригада миңа изгелек эшләде. Әгәр мин дусларымның ышанычын акламасам, адәм актыгы булыр идем.

Г ы й м р а н. Мин сине, энем, акыллырак кешегә чутлап йөри идем, ялгышканмын икән... Ярый, хәерлегә булсын. Борчыдым — гаеп итмә! *(Китә.)*

Җ ә ү д ә т. Гыймран абзый, туктале... *(Гыймран туктый.)* Әйтә башлагач, әйтеп бетерергә кирәк: акылсыз булып мин нишләгән?

Г ы й м р а н. Ярар, калсын инде...

Җ ә ү д ә т *(аның юлын бүлеп)*. Юк, алай гадел түгел, әйт! *(Гыймран дәшми.)* Гадел булырга кирәк дип үзең әйттең бит...

Г ы й м р а н. Яхшы. Әйтим, алайса. Бәк сәер кешеләр сез хәзерге яшьләр: дөньяны китап белән каплап куясыз да, китап битеннән башка бернәрсә дә күрмисез. Әз генә ерактанрак та уйлап карарга кирәк ләбаса! Ярар, син әйттең, бурыч дидең! Ә нәрсә соң ул бурыч? Әйдә, бергәләп фикер йөртик. Бабаң синең Хикмәтулла карт, ирек өчен сугышып, ак бандитлар кулыннан һәлак булды. Әтиең Галиәхмәт бу сугыштан иләк кебек тишкәләнеп кайтты да биш-алты елдан гүр иясе булды. Инде килеп, мисалга әниеңне ал: сине үстерәм, сине кеше итәм дип, тол катын килеш яшәп, күпме җир тырмашты, күпме җәфалар чикте! Я, аның бер генә мәртәбә булса да, һич югы, азаккы көнендә матур итеп яшисе килмимени? Башың булса, үзең уйлап кара: бабаң, әтиең, әниең... ил өчен җәфа чиккәннән соң да, инде тагын синең ачлы-туклы яшәвең кемгә кирәк? Совет власте синең, бригада хакы дип, талантыңны, белемеңне корбан итүеңә мохтаҗмы? Революция синең бригадада эшләмәвеңнән страдать итәме? Башы булса, Хәйрүш боларны сиңа үзе аңлатып бирергә, сине зуррак урынга күтәрергә, үстерергә тиеш иде. *(Пауза.)* Баҗа шул, баҗа! Җиде баҗаны бер бүре ашаган дип юкка әйтмәгәннәр аны! *(Пауза.)* Ялгышасың, энем, үкенерсең, шушы кара мужик Гыймран әйткәние дип әйтерсең: ул чакта инде соң булыр! Революция җиңгәнгә тиздән илле ел тула, сезнең нәселдән берегезнең генә булса да кешечә матур итеп яшәгәне бармы әле?

Җ ә ү д ә т *(уйга калып)*. Белмим...

Г ы й м р а н. Ә партия нәрсә ди? Хезмәт иясе сыйныфы рәхәт яшәсен, ди. Ашамый да, эчми дә, уйнамый да, көлми дә «Ура!» кычкырып кына яши торган интузиас заманнар бетсен, ди. Давай инде, дустым, әзрәк кенә үз кайгыбызны да кайгыртып, кешечә яшәргә дә өйрәник. *(Пауза.)* Я, промысел мөдиренә нәрсә дип әйтим?

Җ ә ү д ә т. Уйларга кирәк аны, Гыймран абзый...

Г ы й м р а н. Уйла син, энем, бәк ныгытып уйла. Әмма ләкин озакка сузма. Менә мин сиңа беренче эш тә алып килдем инде. *(Төргәкне сүтеп кәгазьләр чыгара.)*

Җ ә ү д ә т. Нәрсә бу?

Г ы й м р а н. Калҗа бу, энем, калҗа!

Җ ә ү д ә т. Нинди калҗа?

Г ы й м р а н. Син иң әүвәл кара.

Җ ә ү д ә т *(кәгазьләрне карый)*. Чертежын сызаргамыни?

Г ы й м р а н. Кайчанга өлгертәсең?

Җ ә ү д ә т. Моның эше әллә ни күп түгел. Бер атна утырсам...

Г ы й м р а н. Шулаймы? Бер атна дисеңме? Молодец! Монысын бер атнада өлгертсәң, тагын икене китерәм!

Җ ә ү д ә т. Туктагыз әле, мин бит эшлим дип әйтмәдем. Минем бит Хәйрүш белән башлаган зур эшем...

Гыймран *(бүлдереп).* Алай кырт кисмә син, Җәүдәт! Кесәңә үзе кирәргә торган акча бар чагында... Йортыңны нәрсә белән сипләмәкче буласың? Әтиең каберен?

Җәүдәт. Йортны сиплисе бар... *(Күккә карап.)* Болыт килә, давыл булмагае... киттем мин...

Гыймран. Җәүдәт...

Җәүдәт. Әни! Әни! *(Өйгә таба бара.)*

Өйдән кулына сумка, киемнәр күтәреп Хәдичә чыга.

Хәдичә. Һай, улым, давыл чыгарга тора, кая ашыгасың?

Гыймран. Җәүдәт...

Җәүдәт. Соңыннан, Гыймран абзый, соңыннан... *(Әйберләрен алып чыгып йөгерә.)*

Гыймран (паузадан соң). Яшьлегенә бара-а-а...

Хәдичә. Ярамаган сүз әйттеме әллә?

Гыймран. Сүз нәрсә ул! Авызына салган сары майны йотарга теләми. Бәк дәү инженер итәргә йөрим бит улыңны, Хәдичә!

Хәдичә. Чынмы, шулаймы? Бәрәкалла, бирсен ходай!

Кинәт көчле җил ишегалдына кәгазь чүпләре, яфраклар өереп алып керә, шапылдап тәрәзә капкачлары ябылган, пыяла ватылган тавышлар ишетелә.

Хәдичә. Харап булды, бетә капка! *(Капкага таба бара башлый.)*

Гыймран. Якын барма! Тилердеңме әллә?! *(Җилкәсеннән тотып туктата.)*

Бик көчле дөбердәгән тавыш. Яшен ялтырап уза.

Хәдичә. Харап булды, капка ауды!! *(Дөбердәү тавышы тынгач.)* Нишләргә инде?

Гыймран *(бик сабыр тавыш белән).* Кайгырма, Хәдичә, яңасын ясарбыз. Кырык ел карап үстергән имәнем бар. Капкаңа яңа багана алып кайтырмын!

Хәдичә. Булыр микән?

Гыймран. Була! Мә, моны Җәүдәткә бирерсең.

Хәдичә. Нәрсә соң бу?

Гыймран. Капкага бу, капкага. *(Кәгазьләр эченә акча салып бирә.)*

Хәдичә *(акчаны күреп, беравык аптырап тора. Аптыравы сөенечкә әйләнә).* Рәхмәт, Гыймран!

Гыймран. Рәхмәте соңыннан, Хәдичә, соңыннан. Сау бул. *(Чыга башлагач, кире борыла.)* Карале, Җәүдәткә ныгытып әйт, моны*(Хәдичә кулындагы төргәккә күрсәтә.)* бүген үк эшләп куйсың, ярыймы?

Хәдичә. Ярый, ярый, әйтермен.

Гыймран. Ә капкаңны рәтләрбез. Мин барында борчылма. Капкасыз йорт — басымчак йорт ул. Сау бул.

Хәдичә. Хуш, Гыймран.

Хәдичә өйгә, Гыйран урам ягына китә.
Гүзәлия кайта.

Гүзәлия. Ай! Нәрсә булган монда? *(Бакча ягына күз сала,* кире чыга.) Әни, Әни!

Өйдән төргәген тоткан Хәдичә чыга.

Нәрсә булган монда, әни? Капка ауган бит...

Хәдичә. Бер дә кайгырма, килен. Капкасы да булыр, йорты да. Башлар исән-сау булсын да, дөньяда әйбәт кешеләр бетмәсен.

Ут сүнә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Җәүдәтләр ишегалды. Пәрдә ачылганда Җәүдәт папкалар күтәреп өйдән чыга. Хәдичә бер кәрзин алма күтәреп, бакча ягыннан килеп керә.

Хәдичә. Улым, сине бер егет сорап килгән иде.

Җәүдәт. Кем ул?

Хәдичә. Хәйрулла бригадасыннан бугай. Баҗаң җибәрде, ди. Йоклый әле, дидем.

Җәүдәт. Дөрес әйткәнсең. Мин бакчага кереп утырам. Килсәләр, өйдә юк диген.

Хәдичә. Ничек була инде ул?!

Җәүдәт. Әни, син әйткәнне үтә.

Хәдичә. Бер дә килешкән эшең түгел, улым. Кичә булды кичә алдашып калдың!

Җәүдәт *(нервыланып)*. Әйткәнне үтә дим бит...

Хәдичә. Ярар, ярар, түлке шуны әйтәм: килешкән эшең түгел.

Җәүдәт. Ишеттем бит инде, әни.

Хәдичә. Ишетмәдең дип әйтмим. Кичә баҗаң кергән иде. Ике мәртәбә сине сорады. Бүген өйдә торсын, әбәттән соң килеп чыгам, диде.

Җәүдәт. Килсә, өйдә юк диярсең.

Хәдичә. Олы башым белән алдашым торыйммыни?

Җәүдәт. Эшем бар дигәнне аңлыйсыңмы, әни?

Хәдичә. Кем килсә дә өйдә юк дип әйтимме?

Җәүдәт. Гыйммран абзый килсә, чакырырсың. *(Китә.)*

Хәдичә *(ялгызы)*. Хәзерге яшьләрне аңламассың. Баҗасы җанын бирергә әзер, монысы, корчаңгы тай кебек, баш бирми йөргән була.

Капкада Талип башы күренә.

Талип *(капкага таягы белән бәреп)*. Байлар өйдәме?

Хәдичә. Кем ул бүрәнә аркылы бүре күреп йөри?

Талип. Мин бу, кодагый. Җәүдәт өйдәме?

Хәдичә. Исәнме, кода? Ни йомыш?

Талип. Йомыш зур, Хәдичә.

Хәдичә. Зур булса, кереп сөйләш.

Талип. Вакыт юк, Хәдичә.

Хәдичә. Алайса, сау бул! *(Ашыгып китә башлый.)*

Талип *(таягы белән капкага кага)*. Туктале...

Хәдичә *(кире әйләнеп килә)*. Кереп сөйләш дидем бит.

Талип. Керми дә булмас шул! *(Керә.)* Җәүдәт кайда?

Хәдичә. Җәүдәт өйдә юк, йомышың булса, миңа әйт!

Талип. Синең баш җитә торган нәрсә түгел ул.

Хәдичә. Һай, шушы кыланууларың! Эшем иясе булып йөрисең ләбаса! Нәрсә җитми соң сиңа? Пенсия дисәң,— пенсияң бар, кызлар дисәң — кызларыңны арыслан кебек егетләргә бирдең. Курортларга барып, сырхау сөякләреңне ял иттереп кенә ятар чагында...

Талип. Һы, пенсия, курорт... Әйт әле син миңа, Җәүдәт нитәме? Кичләрен язгалый-сызгалыймы?

Хәдичә. Язгалый да, сызгалый да, аллага шөкер, бер дә генә тик торганы юк!

Талип. Яза торган кәгазе ниме... зурмы?

Хәдичә. Нигә кирәк булды әле ул сиңа?

Талип. Син сораганга җавап бир. Зурмы дип сорыйм мин синнән?

Хәдичә. Әй, башларымны катырмасана! Зур инде, зур.

Талип. Ничаклы бар?

Хәдичә. Палас чаклы!

Т а л и п *(сөенеп).* Йорт рәвешенә, вышка сурәтенә охшаганнары юкмы?

Х ә д и ч ә. Бар инде, бар, йортлары да, капкалары да, мунчалары да бар, аллага шөкер!

Т а л и п. Мунчалары, капкалары кирәкми, вышкалары бармы?

Х ә д и ч ә. Йа-а, тынгысыз да адәм булырсың икән, бар дидем бит инде.

Т а л и п. Җәүдәт янына кемнәр килеп йөри?

Х ә д и ч ә. Килмәгән кеше юк, барысы да килә.

Т а л и п. Хәйрүш киләме?

Х ә д и ч ә. Баштарак килә торганые.

Т а л и п. Ә хәзер?

Х ә д и ч ә. Аралары бозылып тора әле...

Т а л и п. Һы! Нишләп бозыла аларның аралары?

Х ә д и ч ә. Башларымны катырмасана! Мин каян белим?

Т а л и п. Тагын кемнәр килә?

Х ә д и ч ә. Тагын... Гыймран килә...

Т а л и п. Гыймран?! Ә ул нәрсәгә килә?

Х ә д и ч ә. Улмы? Ул — кирәккә килә. Бакчама менә дигән итеп кое казытып бирде!

Т а л и п. Кое? Күпмегә казытты?

Х ә д и ч ә. Ничек күпмегә?

Т а л и п. Акчаны күпме каерды, дим?

Х ә д и ч ә. Ни сөйлисең син? Бер тиен дә алмады, бушлай казытып бирде. Тол карчыкка бер ярдәмем булсын, диде.

Т а л и п. Кара син аны, ә! Ярдәмем булсын, ди. Һы!

Х ә д и ч ә. Нәрсә башларыңны боргалаган буласың? Үзеңнең гомер буе нефтедә эшләп, орден алган почтуный мачтыр булып та эшләтә аласың юк, инде кеше казыткан коены да күпсенеп торма.

Т а л и п. Я, я, тагын нәрсәләр эшләде Гыймран?

Х ә д и ч ә. Аллага шөкер: барысын да эшләде. Коема промыслодан насос алып кайтып куйды...

Т а л и п. Нинди насос?

Х ә д и ч ә. Суны үзе качать итә торган. Карлыганнарыма су сибә алмый аптырап йөри торган идем, җаннарым рәхәтләнде.

Т а л и п. Һы! Серләр килешкән, алайса, сезнең?

Х ә д и ч ә. Ярдәмчел кеше Гыймран, рәхмәтләр яусын үзенә, кулаяклары сызлаусыз булсын, дөнья рәхәтләре күрсен. Әле менә тагын йортыма капка ясатып бирәм, ди. Капкасыз йорт ди, басымчак йорт ул, Хәдичә, ди.

Т а л и п. Һы, һы!.. Кара син аны, ә, кара син... *(Ашыгып чыга башлый.)*

Х ә д и ч ә. Туктале, кода... Бүләкләрне карамадың бит!

Т а л и п. Башка вакытта, башка... *(Капкага таба бара.)*

Х ә д и ч ә. Тукта инде, чәй эчәрбез. Кайнаган самаварым бар.

Т а л и п. Синең самаварың гына басарлык түгел мондагы ялкынны, Хәдичә! Утлар яна монда!.. *(Ашыгып чыгып китә.)*

Х ә д и ч ә *(аның артыннан баш селкеп).* Нинди бәндә бу? Мин белә башлаганнан бирле шул булды. Өйләнмәде, йорт кормады, беркайчан кеше белән рәтләп сөйләшмәде. Бу чаклы да шыр тиле булса булыр икән!

М ә р ь я м (к е р ә). Исәнме, кодагый, кемне тиргисең?

Х ә д и ч ә. Әй, әйтмә инде, кодача, Талип килгән иде.

М ә р ь я м. Әти?! Ул нишләп торып чыккан әле? Авырый иде бит?

Х ә д и ч ә. Аныкын белмәссең кодача, әллә нәрсәләр бутады-бутады да, җен суккан кебек, чыгып чапты. Йөри шунда иләс-миләс.

Мәрьям *(рәнҗеп).* Ничек иләс-миләс?

Хәдичә. Ничек булсын инде, ничек булсын, гомер буе акылга туймады. Яшь чагында акча сугам дип Бакуга чыгып киткән. Суга алмагач, монда кайтып, мазутка буялып йөрде. Үзенә дә тынгы юк, кешеләрнең дә җанын тындырмый. Әйтмә инде, кодача, утыз тугызлы инде, кода.

Мәрьям *(тирән рәнҗү белән).* Ничек телең әйләнә, кодагый? Оят түгелме?!

Хәдичә. Ай алла, нинди начар сүз әйттем әле мин сиңа?

Мәрьям. Гүзәлия — Ватан сугышында үлеп калган капитан кызы. Мин — фашистлар асып үтергән Донбасс шахтерының баласы. Кем белә безнең бертуганнар түгел икәнне? Үз балаларыннан артык итеп үстерде. Белем бирде. Шушы кешегә карата бит... *(Күңеле тула.)*

Хәдичә. Ай алла, белмәдем ләбаса...

Мәрьям. Әти дип әйтү генә аз аңа. Үз баласын ташлап киткән аталар бар. Аның яхшылыгына исем юк. Рәнҗеттең, кодагый, хуш! *(Китә.)*

Хәдичә. Ай алла... ялгыштым лабаса... Берәүнең дә бурасы буш түгел, ходаем...

Гыймран *(керә).* Җәүдәт өйдәме, Хәдичә?

Хәдичә. Өйдә.

Гыймран. Нишли?

Хәдичә. Кем белгән хәзер кемнең нишләгәнен?

Гыймран. Кое әйбәт эшлиме, Хәдичә?

Хәдичә. Әйбәт.

Гыймран. Менә кыяр орлыгы китердем сиңа. Иртә өлгерә торганы. Ничек утыртырга икәнен үзем күрсәтеп бирермен. Җәүдәтне генә чакырчы.

Хәдичә. Чакырам. *(Чыга.)*

Гыймран. Нәрсә булган монда? Бу кортканың миңа алай төксе дәшкәне юк иде. Ярый, әллә кая сикерә алмассың. Гыймран синең кебекләрне генә күрмәгән!

Бакчадан Хәдичә белән Җәүдәт чыгалар.

Җәүдәт. Исәнме, Гыймран абзый. Булдырдыңмы?

Гыймран. Булдырдым, энем. Кара тиргә төшсәм төштем, әмма булдырдым.

Җәүдәт. Әни, безгә берәр чынаяк чәй әзерләп чыгар әле.

Хәдичә. Комачаулыйсың, китеп тор дип, туп-туры әйт инде аны.

Җәүдәт. Әни!

Хәдичә. Китәм, китәм... *(Өйгә кереп китә.)*

Гыймран. Менә, энем, биш йөз тәңкә акча, үз кулың белән санап ал. *(Кесәсеннән акча түргәге чыгара.)*

Җәүдәт. Ничек? Жиде йөз дип сөйләшкән идек бит?

Гыймран. Синдә тамак булып, башкаларда күз түгел бит, эш табып бирүчеләргә дә өлеш чыгарырга туры килде.

Җәүдәт. Ярар, кадалып китсен. Икенче эшләмим. *(Акчаны эскәмиягә ташлый.).* Мин монда көне-төне, йокыны-ялны белми утырам, минем исәпкә кемдер ансат кына ике йөзне алсын да куйсын. Бригада егетләре дә бик кырын карый башладылар.

Гыймран. Нәрсә, тартәгә тибәләрме әллә?

Җәүдәт. Укуны бетереп кайткач, бер ай ял биргәннәр иде бит. Бер ай да узып китте, аннан соң тагын ун көн узды, минем әле бригадага барып та караганым юк. Көн саен эзләп киләләр, көн саен алдашып калам. Хатыным булып хатыным үпкәли башлады инде. Моның бер чиге булырга тиештер бит?

Гыймран. Купкә түзгәнне азга түзәрсең. Күзләренә күренмим дисәң, аулга чыгып йөрербез. Мылтыкны тик яткырмаска кирәк. Бер атнадан өлкән инженер урыны бушый.

Җәүдәт. Ә нигә бер атнадан?

Гыймран *(шыпырт).* Промыселда бүген кичкә бер атналык эш әзерләп куярбыз, диделәр. Монысы инде ярты меңлек кенә түгел, мең ярымлык. *(Акча төргәгенә кесәсендә яшереп калган ике йөзне кушып бирә.)*

Җәүдәт. Бәҗәй алдында уңайсыз бит.

Гыймран. Шаулама инде, капкан саен калҗа керми. Баш инженер камытын кигәч, андый эшкә вакытың калмас. Ләкин кара аны, мин эш табып биргәнне Хәйрүшкә әйтә күрмә. Бәҗәсын бәҗә да бит, ләкин дөньядан бәк ерак кеше. Башы тулган хыял! Ник эшкә килмисең дип бәйләнсә, хуҗалыгымны рәтләп бетерәсем бар диярсең. Тагын бер атнага ял сора — законный булсын. Баш инженер булып алсаң, үзләре тирәңдә биеп йөри башларлар. Ярый, мин китим, хәвефсезлек кагыйдәләрен тикшереп кайтасым бар. Эшне кичкә таба кертеп чыгармын. Сау бул!

Җәүдәт. Ярый, хушыгыз. Мин өйдә торырмын.

*Җәүдәт бакчага, Гыймран урман якка чыгып китә. Сөйләшә-сөйләшә Мәрьям белән Гүзәлия кайтып керәләр.*

Мәрьям. Ялгышасың, сеңелем. Ярату әле ул — ирең эшләгән теләсә нинди эш белән килешеп яшәү дигән сүз түгел.

Гүзәлия. Нинди гаебе бар аның?

Мәрьям. Гаепкә киткәч, соң була. Җәүдәтнең яшь һәм көчле чагы. Эшләсә ул, менә хәзер эшләп кала. Аның... институттан кайтуга... шушында, коймалар эчендә бикләнеп ятуы... сине бер дә борчымыймыни?

Гүзәлия. Юк, апа. Белмисең син аны. Җәүдәт бит ул сабый. Хәйрүш җизни килде, үзенең яңа системасын шундый матур итеп сөйләде, Җәүдәт үлгәнен-калганын белми, шул эш белән утыра башлады. Юк, юк, чиста кеше ул Җәүдәт. *(Пауза.)* Аннары минем дә аз гына булса да кеше төсле матур итеп, кайгы-хәсрәтсез яшисем килә. Азмы йөртте безне эти буровой юлларында. Менә бит үз йортыбыз, үз бакчабыз, кайтып керүләре үк рәхәт.

Мәрьям. Рәхәт сүзен бик ярата башлагансың әле син, кызый. Эти моңа риза булмас.

Гүзәлия. Кычкырма инде, әни ишетер.

Мәрьям. Кычкырам. Бөтен дөньяга ишетелерлек итеп кычкырам. Талип эти кызы икәнеңне онытма! Сөйләшергә йөрәгең җитмәсә, Җәүдәт белән үзем сөйләшәм.

Гүзәлия. Апа җаным, кирәкми. Ул бит мин бәхетле булсын дип тырыша.

Мәрьям. Бәхет бик аз кирәк икән, алайса, сиңа. Болай булса, безнең туганлык җепләре өзелә.

Гүзәлия. Бетте, апа җаным, бетте. Бүген үк Җәүдәт белән сөйләшәм.

Мәрьям. Вәгъдәме?

Гүзәлия. Әгәр сөйләшмәсәм, Талип эти кызы булмыйм.

Мәрьям. Менә хәзер минем күңелем тыныч. *(Гүзәлияне кочаклый.)* Сау бул, үскәнем.

Гүзәлия. Өйгә керик, апа. Чәй эчеп китәрсең. Өйләрне шундый матур итеп җыештырдым. Күреп тә китәрсең.

Мәрьям. Бүген вакытым юк әле, сеңелем. Беренче класска керәсе балаларның ата-аналарын күрергә кирәк. Лагерьга китәсе пио-

нерларны озатып җибәрәсем бар. Килермен әле, килермен. Сау бул! *(Китә.)*

Гүзәлия *(аның артыннан кычкырып).* Апа-а! Җизни белән парлап килегез! *(Кул болгый.)*

Өйдән Хәдичә чыга.

Хәдичә. Кайттыңмы, килен? Әйдә, әсләреңне алыштыр, юын, ашым да өлгерде, самаварым да кайнап тора. Чүкердәшеп кенә бер чәй эчеп алыйк әле. Бик болганчык көн булды бүген.

Гүзәлия. Әллә берәр күңелсезлек бармы, әни?

Хәдичә. Әйтмә инде, килен... килмәгән кеше калмады. Карлыганымны җыярга өлгермәдем.

Койма буена Шәйхаттар килеп туктый.

Шәйхаттар. Җәүдәт өйдәме?

Хәдичә *(каушап).* Ни бит... өйдә югые бит...

Шәйхаттар. Кайткач та әйтегез. Мастер чакырды. Сәгатеминуты белән промысел конторына килеп җитсен, диде. Ишеттегезме?

Хәдичә. Ай аллам, ишеттек инде, ишеттек.

Шәйхаттар. Менә шул! Әйтмәде дип әйтмәгез! *(Китә.)*

Гүзәлия. Әни...

Хәдичә. Әү, балам?

Гүзәлия. Нишләп Җәүдәтне өйдә юк дидең?

Хәдичә. Әй, буталып беттем инде, килен... Үзең белерсең әле, әйтер. *(Өйгә кереп китә.)*

Гүзәлия *(ялгызы).* Нигә кирәк булды икән инде алдашу? Аңламыйм, һич башыма сыймый.

Бакча ягыннан Җәүдәт чыга.

Җәүдәт. Минем сандугачым кайткан икән! Кил әле монда. *(Гүзәлия назландырмакчы булып, килми тора. Җәүдәт аяк тибеп).* Кил, дим! *(Кисәк кенә борыла да Гүзәлияне күтәреп алып, зырылдатып әйләндерә башлый.)*

Гүзәлия *(рәхәтлектән чинап).* Ай, ай, ай! Үләм, беттем, башым әйләнә! *(Җәүдәт аны төшерә.)* Тот, егылам! *(Җәүдәт тота. Гүзәлия аның кочагына сыена.)* Җәүдәт... бер кызык күрсәтимме?

Җәүдәт. Яле, күрсәтеп карале, нинди кызык икән...

Гүзәлия. Йом күзеңне!

Җәүдәт. Йомдым күземне.

Гүзәлия. Юк, әйбәтләп йом. Я инде, хәрәмләшмә инде, Җәүдәт! *(Җәүдәт күзен йома, Гүзәлия вахтага йөртә торган сумкасыннан кесә радиоалгычы транзистор чыгарып, тиз генә көйли дә косынкасы белән каплап, эскәмиягә куя.)* Ач күзеңне.

Җәүдәт. Ачтым күземне.

Транзистордан матур бер көй яңгырый. Сүзләре Сәләхи җырлаган җырның сүзләренә охшаган. Эскәмиягә утырып көйне тыңлыйлар. Гүзәлия әкрен генә яулыкны ачарга үрелгәндә, Җәүдәт кинәт «һам!» дип кычкыра. Гүзәлия куркып, кулын кире тартып ала. Көлешәләр.

Гүзәлия *(паузадан соң).* Матурмы?

Җәүдәт. Искиткеч. Каян алдың?

Гүзәлия. Бүләк. Сәләхи абый бирде.

Җәүдәт. Сәләхи?!

Гүзәлия. Туеңа бернәрсә дә алып килә алмаган идем, миннән бер бүләк булсын. Скважиналарыңны караган чакта, музыка тыңлап йөрерсең, ил хәбәрләрен ишетеп яшәрсең, ди. Белсәң иде, Җәүдәт, мин аны моңарчы...

Җ ә ү д ә т. Нәрсә моңарчы?

Г ү з ә л и я. Белми йөргәнмен. Ул бит мине ничә ел операторлыкка өйрәтте, күзләрен күтәреп караганы юк иде. Мин аны дөнья белән алыш-биреше юк кеше дип торам. Бүген ул миңа шундый итеп карады...

Җ ә ү д ә т. Ничек итеп карады?

Г ү з ә л и я. Шундый итеп карады... *(Сүз таба алмый, кызарына.)*

Җ ә ү д ә т. Ярый, аңладым.

Г ү з ә л и я. Нәрсә аңладың?

Җ ә ү д ә т. Икенче тапкыр... бүләк алма.

Г ү з ә л и я. Нишләп? Ул бит мине...

Җ ә ү д ә т. Сине мин үзем бәхетле итәрмен.

Г ү з ә л и я. Нигә, мин хәзер бәхетле түгелмени?

Җ ә ү д ә т. Хәзер дә бәхетле... Ул чагында тагын да бәхетлерәк булырсың.

Г ү з ә л и я. Ай, күңелемә ут салдың? Нинди бәхет ул, Җәүдәт?

Җ ә ү д ә т. Хәзергә әйтми торам әле.

Г ү з ә л и я. Җәүдәт! Алай әйбәт түгел бит инде... Әйтмәслек булгач, ник соң күңелемне җилкендердең?

Җ ә ү д ә т. Алай түзәрлегең булмаса, әйтәм: мине промыселга баш инженер итеп куялар.

Г ү з ә л и я. Баш инженер?!

Җ ә ү д ә т. Әйе. Бер елдан безнең үз «Волга»быз булачак.

Г ү з ә л и я. Үз «Волга»быз?!

Җ ә ү д ә т. Ә нигә? Нигә аптырадың?

Г ү з ә л и я. Бик сәер бу, Җәүдәт, бик сәер!

Җ ә ү д ә т. Җүләркәем, сөенергә кирәк. Мин сине үз машинабызда вахталарга илтеп куярмын. Ял көннәрендә сахрага чыгарбыз. Кырымга барырбыз. Кара диңгез буйларына!

Г ү з ә л и я *(боегып)*. Күңелем үк сизгән иде аны...

Җ ә ү д ә т. Нәрсә сизгән иде?

Г ү з ә л и я. Бригададан качып, ниндидер чертежлар белән буталып йөрүең юкка булмаган икән...

Җ ә ү д ә т. Синең белән миңа гына дөньяның хәсрәтен чүмерергә димәгән! Без дә бер кеше төсле яшәп карыйк әле!

Г ү з ә л и я *(үз алдына)*. Оят! Оят!

Җ ә ү д ә т. Син нәрсә сөйлисең?

Г ү з ә л и я. Бригада сине дүрт күз белән көтеп алды. Бригада сиңа ышанды... Шушымы синең рәхмәтең? *(Күңеле тула.)*

Җ ә ү д ә т. Чү, чү, нишләвең бу?

Г ү з ә л и я. Кирәкми бәхетең... Ай, нинди хурлык! *(Үкси.)*

Өйдән Хәдичә чыга.

Х ә д и ч ә. Балалар! Әйдәгез. Ашым суынып бетә бит инде. *(Пауза.)* Җәүдәт... Килен... Әйдәгез, керик.

Г ы й м р а н керә. Кулына зур бер төргәк тоткан.

Г ы й м р а н. Менә мин, энем, килеп тә җиттем. Ничек итсәм иттем, тәки булдырдым! Мә, Җәүдәт, җылы кулдан алып җибәр. *(Төргәкне суза.)*

Җ ә ү д ә т *(шикләнеп Гүзәлия ягына карап ала)*. Кичкә табан дип сөйләшкән идек бит...

Г ы й м р а н. Барасы җирем бар, ашыгыч эш килеп чыкты. Мә, ал, үз вакытың белән эшләрсең. *(Төргәкне бирә.)*

Г ү з ә л и я. Нәрсә ул, Җәүдәт?

Җ ә ү д ә т. Юк ла... ни... вак-төяк эш шунда...

Г ү з ә л и я. Миннән яшерәсеңмени?

Җ ә ү д ә т. Гүзәлия!

Х ә д и ч ә. Килен, дим, сиңа әйтәм, булмаса, керик без. Ир-атның сөйләшәсе сүзе булыр. *(Гүзәлияне алып кереп китә дә кире әйләнеп чыга.)*

Җ әү д ә т. Башың бармы синең, юкмы?

Г ы й м р а н *(аптырап).* Нәрсә булды тагын?

Җ ә ү д ә т. Сорау юк, белү юк, Гүзәлия алдында төргәк сузып маташасың! Янган утка керосин сибү белән бер булды инде бу. Күрмәдеңмени кыяфәтен?

Г ы й м р а н. Ничава. Катын-кыз кая бара ала? Бер чәпчер дә бетәр.

Х ә д и ч ә. Ялгышасың, Гыймран! Белмисеңмени? Талип кызы диләр аны!

П ә р д ә.

## *ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ*

### БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман аланы. Пәрдә ачылганда берәү дә юк. Шомлы музыка. Г ы й м р а н керә. Адымнары сагаюлы, чүпрәккә төреп, авыр бер нәрсә тоткан.

Г ы й м р а н *(имән каршысына туктый).* Син миннән көлдең, Талип. Ничә еллар буе мине әзәрлекләп килдең! Әйдәле, без көч сынашып карыйк, мин синең гомер буе эшләгән эшеңне юкка чыгарыйм! *(Чүпрәкне сүтеп, балта ала.)* Аллага тапшырдык! Бер! Ике! Өч! Менә шул җитәр сиңа! Ай буена син күз яше коярсың, аннары бәгырең таш булып катар! Гыймран сабыр кеше. Көтә ул Гыймран. Без сине аударырбыз. Син капка баганасы булырсың. Акыл тешләре чыгып җитмәгән Хәйрүшләр пускай зур ут турында лыгырдап йөрсеннәр! Безгә утның кечкенәсе, үзебезне генә җылыта торганы да җитә. *(Балтасын чүпрәккә төреп югала.)*

С ә л ә х и керә. Ул Гыймранның имән каршысында сөйләнеп торганын күреп калды. Ерактан моңлы итеп җырлаган җыр тавышы ишетелә. Сәләхи җырны имәнгә сөялеп тыңлый.

**Гүзәлия җыры**

Таң атканда уйланам,  
Су акканда моңланам.  
Таң нурында син йөзәсең,  
Утларыңда мин янам.

Биек тауга менимме,  
Агым суга керимме,  
Дусларыма сөйлим микән,  
Үзем генә белимме?

**Сәләхи җыры**

Таулар текә, су тирән,  
Тирән булса да керәм.  
Тәкәбберлегең дә беләм,  
Нигә шулай үз күрәм.

Г ү з ә л и я *(керә).* Сәләхи абый!

С ә л ә х и. Син каян килеп чыктың?

Г ү з ә л и я. Мин сезне эзләдем, эзләдем... Сез йөри торган урыннарның барысын карап бетердем... Иптәшләр әйтә, әле генә шушында иде, диләр...

Сәләхи. Мин дә... кирәк булдыммыни?

Гүзәлия. Эшләремнең көе китте бит, Сәләхи абый.

Сәләхи. Минем кулдан килә торган эш дип уйлыйсыңмы син аны?

Гүзәлия. Сез бит минем укытучым. Мине операторлыкка өйрәткән кеше.

Сәлихи. Шундый авыр, тынгысыз эшкә өйрәткәнгә, үпкәләмә инде, Гүзәлия...

Гүзәлия. Сез ни сөйлисез, Сәләхи абый?!.

Сәләхи. Үпкәләмисеңме? Чынмы? Киттек, алайса?

Гүзәлия. Кая?

Сәләхи. Авария дисең түгелме соң?

Гүзәлия. Юк, мин ул турыда түгел...

Сәләхи. Әллә тормышыңда күңелсезлек бармы? Әйт, сеңелем, яшермә. Әллә берәрсе рәнҗетәме? *(Кулларын йомарлый.)*

Җәүдәт *(керә)*. Гүзәлия... син нишләп үз объектыңда түгел?

Гүзәлия. Мин... киңәшергә килдем.

Җәүдәт. Соңыннан киңәшерсез, минем сиңа сүзем бар.

Гүзәлия. Бара тор, хәзер киләм.

Җәүдәт *(кискен)*. Көтәргә вакытым юк. *(Җилтерәтеп алып китә.)*

Хәйрүш узып бара.

Сәләхи. Мастер! *(Аның артыннан ташлана.)*

Хәйрүш. Нәрсә бар?

Сәләхи. Кул куегыз! *(Кәгазь бирә.)*

Хәйрүш. Нәрсә бу?

Сәләхи. Гариза.

Хәйрүш. Ниткән гариза?

Сәләхи. Китәм.

Хәйрүш. Китәсең?!

Сәләхи. Туйдым дегеткә буялып йөрүдән. Чистарак эш эзлим.

Хәйрүш. Шаяртма, Сәләхи!

Сәләхи. Хәл шаярудан узган, мастер. Кул куй да китәм.

Хәйрүш. Беркая да китмисең. Юк белән башны катырып йөрмә.

Сәләхи. Ә мин әйтәм, китәм!

Хәйрүш. Туктале... аңлатып бир син: ник китәсең?

Сәләхи. Аның бәхетсезлегенә шаһит булып яшисем килми.

Хәйрүш. Кемнең?

Сәләхи. Комедия уйнама, Хәйрүш. Син аны бик яхшы беләсең!

Хәйрүш. Беләм. Барыгыз да акыллы башлар: эшләр әйбәт чагында Хәйрүш кирәк, эшләр кирегә киттеме — качасыз!

Сәләхи. Качам, качам, качам!

Хәйрүш. Сиңа кияүгә чыкса, ул бәхетлерәк булыр идеме?

Сәләхи. Шуңа күрә мин аңа яратуымны әйтмәдем дә. Таламагыз җаңымны, кул куегыз да җибәрегез мине!

Хәйрүш. Куймыйм!

Сәләхи. Куймыйсыңмыни?! Куймасаң... *(Гаризасын теткәләп ташлый.)* Рөхсәтсез китәм. *(Ярсынып чыгып китә.)*

Хәйрүш, ул киткәч, кулын бик хәтәр селки, иреннәре кыймылдаганы күренә: сүгенә булса кирәк. Кулын тагын бер мәртәбә бик хәтәр селки дә, дөньясын җимерергә теләгәндәй, атылып бәрелеп чыгып китә.

Арты белән чигенә-чигенә, кемнәндер күзләрен ала алмыйча, Азамат керә. Еракка төбәлеп, күңел түреннән килгән бер ярату тойгысы белән «Азамат» көенә җырлый.

Николай керә. Борылып, иптәшләренә кул болгый. Оператор егетләр аяк очларына гына басып киләләр дә, кулларын яңакларына куеп, моңаеп басып торалар. Җырның азагында, Азаматны үчекләп, барысы бергә сүзсез генә көйләп җибәрәләр.

Азамат. Но-оо инде, егетләр!

Николай *(иптәшләренә борылып)*. Но-оо инде, егетләр! *(Шушы ук сүзләрне егетләр бер-берсенә тапшыралар.)*

Азамат. Николай! Дустым бул, зинһар өчен дип әйтәм, моннан китеп торчы. Беренче мәртәбә, аңлыйсыңмы, беренче мәртәбә свидание...

Егетләр. О-оо! Уңыш телибез! *(Борылалар, бер-бер артлы тезелеп чыгып китәләр.)*

Зөбәрҗәт керә. Кулында кыр чәчәкләре.

Зөбәрҗәт. Исәнме, Азамат!

Азамат. Исәнмесез... *(Кулын суза, ләкин кулы мазутлы икәнен күреп, күрешергәме, юкмы дип бер генә мизгел икеләнеп ала да, куртка итәгенә сөртеп, кулын Зөбәрҗәткә суза. Ул арада шыпырт кына кергән егетләр, кулларын, Азамат кебек, курткаларына сөртеп, берәм-берәм Зөбәрҗәткә кул сузалар.)*

Азамат. Но-оо инде, егетләр! Алай ярамый бит инде...

Николай. Но-оо инде, Шәйхаттар, алай ярамый бит инде...

Шәйхаттар. Алай ярамый бит инде... *(Шушы ук сүзләрне бер-берсенә әйтә-әйтә, тезелешеп чыгалар, чыгып киткәндә рәхәтләнешеп бер көлеп җибәрәләр дә йөгереп үк чыгып китәләр.)*

Азамат *(тирә-ягында берәү дә юк икәненә ышангач)*. Менә... язмыш безне тагын очраштырды...

Зөбәрҗәт. Язмыш... Ә мин чәчәкләр җыйдым. Кыңгырау чәчәкләре.

Азамат. Миңа берсен бирерсезме?

Зөбәрҗәт. Бирәм. Сез «Азамат» көен шундый матур җырладыгыз, сәнгать өчен мин бөтен букетымны бирергә риза.

Азамат. Фьюююуу!

Зөбәрҗәт. Зинһар сызгырмагыз. *(Колагын каплый)*.

Азамат *(көлә)*. Ә нәмә? Мин бәләкәй чакта авылда егетләр шулай сызгыра торган иде.

Зөбәрҗәт. Сезгә кыргыйлык килешми.

Азамат. Рәнҗеткән булсам, гафу итегез. Мин бәләкәй чакта...

Зөбәрҗәт. Бәләкәй чактагысын сөйләдегез инде, анысын гафу итәм. *(Көлә.)*

Азамат. Сез озакка кайттыгызмы?

Зөбәрҗәт. Ике айга. Диплом эшем өчен картинага материал туплыйм. Нефтьчеләр тормышыннан.

Азамат. Ә нигә нефтьчеләр?

Зөбәрҗәт. Индустрия! Республиканың йөзе! *(Азамат көрсенә.)* Нигә бик авыр суладыгыз?

Азамат. Ике аегыз тулгач та китәсезме?

Зөбәрҗәт. Китәм. Монда бит мастерской юк.

Азамат. Мастерской! Верещагин мастерскойда ятканмы? Муса Җәлил дөньяны тетрәткән җырларын аккош күлендә язганмы?

Зөбәрҗәт. Ә сез Верещагинны каян беләсез?

Азамат. Тагын бер мәртәбә сызгырыр идем, кыргый диярсез. Оператор дигәч тә, берни белми, дегеткә генә буялып йөри дисезме? Их, сез... нефтьчеләр турында картина язам дигән буласыз!

Зөбәрҗәт. Сөйләгез, сөйлә, туктамагыз!

Азамат. Мәхәббәт турында картина языгыз сез.

Зөбәрҗәт. Мәхәббәт?! Нинди мәхәббәт?

Азамат. Кешене күтәрә торган мәхәббәт! Кеше күңелен омтылышлы итә торган!

Зөбәрҗәт. Андый мәхәббәт бармы?

Азамат. Бар.

З ө б ә р җ ә т. Кайда?
А з а м а т *(күкрәгенә суга).* Менә!
З ө б ә р җ ә т. Ай... җырчы егет, күңелемне кузгаттың. Озатып куйчы мине.
А з а м а т. Рөхсәтмени?
З ө б ә р җ ә т. Ә син рөхсәтсез генә озат... *(Чыгалар.)*

Аларның каршысына Талип очрый.

Т а л и п. Болан балалары уянды. *(Авыр итеп көрсенә.)* Дөнья тулы матурлык. Ил яшәрә. Синең генә күңелең тыныч түгел, Талип. *(Имән янына килә.)* Эшләр хөрти безнең, кордаш! Гомер буе тырышканнарым бушка китәр микәнни? Нинди кызлар үстердем, арыслан йөрәкле кияүләргә бирергә хыялландым. Булмады. Гыймран-йомран җиңдемени? Миннән көчлерәкмени соң ул, имән? *(Имәнгә якын ук килеп сыена, чөйне күрә.)* Чү! Нәрсә бу?! Кайсы миһербансызының эше бу? Егетләр! Егетләр! Егетләр!

Төрле яктан операторлар йөгерешеп керәләр. Алар арасында Хәйрүш, Николай, Шәйхаттар, Азамат, Сәләхи, Гүзәлия һәм башкалар

Х ә й р ү ш. Кем кычкырды?
Н и к о л а й. Нәрсә бар?
Ш ә й х а т т а р. Пожармы? Авариямe?
Т а л и п. Бармы җаныгыз?! Бармы? Нәрсә бу?! Бу... бу...
Х ә й р ү ш. Бабай, дим, бабай, туктале.
Т а л и п. Туктама! Нинди туктау! Кая туктау?!
Х ә й р ү ш. Бабай дим... бабай! Зинһар, аңлатып кына сөйлә!
Т а л и п *(көч-хәл белән генә тын алып).* Бетәсез, үләсез! Хурлык! Позор!
Х ә й р ү ш. Нәрсә булган соң?
Т а л и п *(калтыранып торган таягын алга сузып, имәнгә күрсәтә).* Күрмисезмени?! Күзегез чыкканмыни?! Нәрсә бу? Нәрсә, ә?! *(Кинәт йөрәген тотып ава.)*

Операторлар Талипны күреп алалар.

Г ы й м р а н *(керә).* Ипләп, егетләр, иплэп... *(Озата бара. Сәхнә бөтенләй буш калгач.)* Кәкрәйдеңме, дәрвиш? Ниһаять, сүнде синең скважинаң, учагың бүтән кабынмас инде... *(Операторлар керә.)* Нәрсә булды, егетләр?
Х ә й р ү ш. Кемдер имәнне корытырга уйлаган.
Н и к о л а й. Тимер чөй сукканнар.
Г ы й м р а н *(үтә сабыр).* Бар хәсрәтегез шул гынамы? Ә мин тагын авария булган яки пожар чыкканмы дип торам! Кем күтәрде бригаданы?
Н и к о л а й. Талип бабай...
Г ы й м р а н *(бүлдереп).* Уйлаган идем аны. Дөнья бутап, кешеләрне ызгыштырып йөрмәсә, җаны тынмый инде аның.
Х ә й р ү ш. Әкрен. Бабайга тел тидермәскә. Нәрсә әйтмәкче буласыз?
Г ы й м р а н. Минме? Мин менә нәрсә әйтмәкче булам: шушы бер пүчтәк имән өчен шул чаклы тавыш күптарып йөрергә кирәк микән?
Г ү з ә л и я. Юк, пустяк имән түгел бу! Әти бу имәнне 1915 елда, Бакуга бәхет эзләп чыгып киткәндә утырткан. Борынгыдан килә торган йола бар икән: кеше туган-үскән җирләреннән киткән чакта истәлек итеп агач утыртып калдыра. Агач корымаса, киткән кеше кире әйләнеп кайта, корыса — кайтмый. Талип әтине беләләр, ул бит: «Өем урам, бөтен кеше миңа туган», дип яшәүче чиста күңелле кеше. Мондый кешенең агачын халык корыта аламы? *(Пауза.)* Ко-

рытмый халык имәнне, үз имәне итеп үстерә. Кырык ел читтә йөргәннән соң Талип эти Татарстанга кайта. Кайтса — имән исән, имән шаулап утыра. Имән янынннан олы юл уза. Димәк, бәхетне ерактан эзләп йөрисе дә булмаган, бәхет аяк баскан җирдә, туган-туфракта ята икән. Сиздегезме инде? Бу имәнгә кул яккан кеше — безнең бәхетебезгә кул ягучы.

Гыймран. Әй, яратасыз да соң күпертергә: бәхет, олы юл! Күпме генә мөгез чыгармагыз, агач инде ул: баганадан башкага ярамый!

Гүзәлия. Нинди багана?

Гыймран *(уртәп).* Нинди багана... Капка баганасы.

Гүзәлия. Кем капкасына?

Җәүдәт. Гүзәлия!

Хәйруш. Бүлдермә. Сөйләп бетер, Гүзәлия.

Гүзәлия *(Гыймранга борыла).* Нишләп йөрдең син бездә, хәвефсезлек инженеры? Нинди папкалар күтәреп килдең? Коега насос каян алып кайттың?

Җәүдәт. Гүзәлия! Акылыңа кил!

Гүзәлия. Сабыр, Җәүдәт... бригададан яшермик. Бригада безнең семьябыз. Миңа боларны сөйләве авыр... Тик әйт, Җәүдәт, яшермә: биш ел буе сине күз карасы кебек көтеп алган иптәшләреңә, зур учак кабызабыз дип хыялланган дусларыңа төкереп карарга кем мәҗбүр итте сине? Качып-посып, вак эшләр белән йөрергә кем өйрәтте? Әйт, егет булсаң яшермә.

Җәүдәт. Әйтәм. Элекке заманда ирләр хатыннарына өч мәртәбә талак дип кычкырганнар. Мин бер генә мәртәбә әйтәм: минем бусагамда эзең булмасын! Вон!

### СӘХНӘ АЛДЫ

Садри белән Сәләхи. Садри кызмача.

Сәләхи. Нихәл, яшьти? Бәйрәм иткәнсең түгелме?

Садри. Абзаң премия эләктерде. Бер ел буе тозлап яткырганнар иде. Шалиш! Гаделлек өскә чыкты. Рабочий заманы хәзер. Пускай мин инженер булмыйм, рас минем баш эшли, дайош Садрига премия!

Сәләхи. Эшләр гөрли, алайса?

Садри. Гөрли абзаңның эшләр! Галиәхмәтов бер көн эчендә дөбердәтте генә! Башлы малай икән, имансыз. Ә нигә, артык акча кесәне тишәмени?!

Сәләхи. Икегез исеменнән бирдегезмени?

Садри. Аңламыйсың. Содействие диләр. Мин уйлап чыгарам, инженер схемасын сыза. Җитмеш проценты миңа, утызы аңа — законный! Башлы егет Галиәхмәтов! Киттек, яшьти, салабыз Җәүдәт саулыгына!

Сәләхи. Рәхмәт, вакытым юк...

Садри. Юкка борын чөясең, яшьти! Өлкән оператор булдым дигәченнән дә, ул әле трест управляющие булдым дигән сүз түгел! Галиәхмәтов синең ише генәме. Мәскәүнең Губкин институтын бетергән инженер! Контордан әйттеләр — и пожалысты — дөбердәтеп схемасын сызды да бирде — бер көн эчендә утыз сумны каерып кына алды.

Сәләхи. Ә кем табып бирде сиңа Галиәхмәтовны?

Садри. Ха! Хитрый. Тел яздырмакчы. Шалиш, сабакташ! Аш биргәнгә таш атмыйлар. Шалиш!

Сәләхи. Соң мин аны синнән алданрак белгән.

Садри. Я, әйт, әйт — белсәң!

Сәләхи. Гыймран Нуришанов.

Садри. Во! Сыер икәнсең — өстенә үк бастың! Акыллы кеше Нуришанов! Син, ди, Садри энекәш, ди, минем рационализаторский

предложениене карамыйлар дип тавыш куптарып йөрмә, андый эшләрне салкын акыл белән эшләргә кирәк, ди. И дөрес әйтә. Хитрый адәм Нуришанов, хи-хи-хи! Мин сиңа инженерның кәттәсен табып бирәм, ди. Киттек, сабакташ, салабыз Нуришанов саулыгына!

Сәләхи. Башка вакытта!

Садри. Юкка борын чөясең, Сәләхи! Син дә алланың кашка тәкәсе түгел! Душа кеше Галиәхмәтов и Нуришанов! *(Китә.)*

Сәләхи *(ялгызы).* Алай... Димәк, Җәүдәт үзенә эш тапкан... Акча көри. Ә соң кем аны гаепли ала? Эшчеләргә ярдәм итә бит. Күпме яңа тәкъдим гамәлгә аша. Ә зур эшебез? Бөтен бригаданың өмете? Ышанычы? Ашкындыргыч хыяллар? Димәк, Җәүдәт шуларның барысына да төкерде? Мин моны Хәйрүшкә әйтергә тиешмен. Бөтен бригаданы аякка бастырырга! «Нәрсә карыйбыз, бетә бит инженер, югала, баклана!» Юк, мин моны булдыра алмыйм! Гүзәлиянең үчен Җәүдәттән ала диячәкләр! Әгәр Гүзәлиягә әйтсәм. Ул аңлар. Ул бит аны ярата. Бетә бит Җәүдәт. Коткарсын. Юк, китмим. Гүзәлия! Гүзәлия!

Чаң тавышы. Эчке пәрдә ачыла.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Урман аланы. Иртәнге сәгатьләр.

Хәйрүш *(ялгыз).* Нәрсә булды соң бу? Нигә бөтен бәла минем өстемә ябырыла? Их, Хәйрүш, Хәйрүш, белмисең бугай син бригадаңны... Җиде төн уртасында уятып сорасыннар, бригадамда ничә скважина, аларның һәркайсы тәүлегенә ничә тонна нефть куа, күз йомып әйтеп бирә алам. Ә менә кул астымдагы кешеләрнең йөрәгендә нинди утлар яна — белми йөргәнмен!

Николай, Азамат керәләр.

Николай. Нихәл, мастер? Ни эш бетереп утырасың?

Хәйрүш. Эшләр шәп түгел, егетләр: Җәүдәт өч көн инде урманда йөри. Кулында мылтык.

Азамат. Ә мин атылып үлмәс идем. Бөтен дөнья чәчәккә күмелгән чакта, иң биек вышка түбәсеннән чәчәкләр арасына сикерер идем.

Хәйрүш. Син авызыңны ерма әле, Салават токымы. Хәзер үк Җәүдәтне эзләп табарга кирәк. Азамат, мин моны сиңа тапшырам. Җәүдәтне эзләп табып, мылтыгын аласың!

Азамат. Син нәрсә, мастер, минем әле якты дөньядан туйганым юк! Мин Зөбәрҗәт белән чәчәк плантациясе әзерлим.

Хәйрүш. Менә, менә, менә! Чәчәк плантациясе әзерлә син. Ләкин Җәүдәтне дә күздән ычкындырма. Алдан ук кисәтеп куям: шаяртмаска, кискен бәрелешкә кермәскә. Аңладыңмы?

Азамат. Аңладым.

Хәйрүш. Нәрсә аңладың?

Азамат. Маңгайны пуля астына куймаска!

Хәйрүш. Дөрес аңлагансың. Ә син, Николай Иванович, бригададагы тәртипне күзәтәсең. Нефть чыгару планын мин синнән сорармын. Булдымы?

Николай. Була, иптәш мастер. Николай Иванович дип зурлап әйткәч, үтибез аны!

Хәйрүш. Ә мин Талип бабайның хәлен белергә барам. *(Китәләр.)*

Сәхнә бераз буш. Җәүдәт керә, кулында мылтык. Туктап, тыңлап торгалый. Сызгырына. Авыр көрсенә. Үтеп китә. Аланга тоенчек тоткан Хәдичә керә. Кулын каш өстенә куеп карана.

Хәдичә. Бала-чага дип борынгылар белми әйтмәгәннәр. Кечкенә чакта гына бала, үсеп җиткәч, чага икән шул... *(Утыра.)*

Мәрьям *(керә)*. Исәнме, кодагый, нишләп йөрисең монда?

Хәдичә. Әй, әйтмә инде, Мәрьям, дөнья бетереп өйләнгән улыңны эзләп йөр инде! Башка сыя торган эшмени бу! Җәүдәтнең өч көн инде өйгә кайтканы юк.

Мәрьям. Дөньялар бозылган икән, кодагый. Сезгә барып чыгарга вакыт та тигәне юк. Эшләрем шундый күбәйде, шундый күбәйде...

Хәдичә. Күбәер, кодача, күбәер, туган-тумача ул синең әйбәт чагыңны гына ярата. Тормышыңның көе киттеме — кандала даруы сипкән кебек кача ул синнән.

Мәрьям. Шулай шул, кодагый, туганнарның кадерен белү юк шул бездә. Гүзәлия инде өч көн рәттән мендәргә капланып елый. Ичмаса, әнкәй дә килеп чыкмый дип өзгәләнә...

Хәдичә. Тәки кайтмыйм димени?

Мәрьям. Дуңгызлык эшләп, куып җибәргән улың янына нишләп кайтсын.

Хәдичә. Алай бик начарга чыгарма әле, кодача, минем улымны.

Мәрьям. Берәү дә начар дими Җәүдәтне. Кулында ут уйната ала торган егет! Ә менә хатынына карата дуңгызлык эшләгән.

Хәдичә. Торасың да шулай дисең син, кодача! Гомер буе авызны-авызга куеп кына яшәп булмый лабаса! Була әйбәт чагың, була начар чагың: бөтен бригат алдында иренең яман атын сатып тормаса...

Мәрьям. Юк инде, кодагый, гаделсезлеккә күз йома алмыйбыз инде. Талип әти балалары без. Гүзәлия соңга калган әле. Аның урынында мин булсаммы? Җәүдәтеңне Кремль сәгате кебек йөртер идем. Мин кияүгә чыкканда Хәйрүш кем иде? Кибет саен шешә эзләп йөрүче! Ә хәзер кем? Үзенең дәрәҗәсен белеп яшәүче! Кем тоттырды аның кулына китап? Кем укытты аны техникумда? Җәүдәтне кулыннан ычкындырган өчен дә арт сабагын укытам әле мин аның.

Хәдичә. Анысы дөрес инде, кодача. Ирне үстергән дә катын, үтергән дә катын дип белми әйтмәгәннәр аны. Һай, син минем киленем булсаң...

Мәрьям *(Николайны күрә)*. Николай, Николай! *(Китә.)*

Хәдичә. Кодача! Кодача! *(Китә.)*

Зөбәрҗәт белән Азамат, кулларына тасма тотып, җир үлчи-үлчи керәләр.

Зөбәрҗәт. Егерме метр булды, как менә шунда казык. Монда без дөньядагы иң-иң матур чәчәкләр, ак розалар утыртырбыз! Синеңчә, ничек, Азамат?

Азамат. Минемчә дә шулай!

Зөбәрҗәт. Культбудкалар әйләнәсенә нинди чәчәкләр утыртырбыз икән? Мәк чәчәге ярыймы? Синеңчә, ничек, Азамат?

Азамат. Минемчә дә шулай!

Зөбәрҗәт. Син, ичмаса, юри генә булса да каршы килгән бул инде, юкса, Казанга киткәнче, синең белән бер кычкырышып та булмый!

Азамат. Мин юри генә кычкырыша белмим. Бәләкәй чакта, кызлар өчен сугышканым да бар. Әйдә сугышабыз: истәлек булыр!

Зөбәрҗәт *(рәхәтләнеп көлә. Кинәт моңсу)*. Син мине сагына да белмәссең әле. *(Пауза.)* Ник дәшмисең? Сагынырсыңмы?

Азамат. Сагынып караган булмагач, каян белим: я сагынырмын, я юк...

З ө б ә р җ ә т. Их, син, кара чутыр! Юри генә булса да, сагыныр-мын диләр аны!

А з а м а т. Ә мин юри генә әйтә белмим. Сине бер генә көн күрми торсам да, барлык скважиналарым ватылып беткән кебек тоела...

З ө б ә р җ ә т *(каушап).* Нәрсә дидең? Тагын бер генә әйт әле, бер генә! Ай, Азамат...

А з а м а т. Тукта, Җәүдәт килә. Җәүдәт! Җәүдәт!

Җ ә ү д ә т *(керә).* Нәрсә бар?

А з а м а т. Җәүдәт, мылтыгыңны биреп тор әле, бер генә атып карыйм әле. *(Җәүдәт дәшми, усал итеп бер карый да китә. Азамат аның артыннан иярә.)*

Җ ә ү д ә т. Син нәрсә минем арттан йөрисең?

А з а м а т. Җәүдәт, биреп тор инде, пожалысты! Әнә Зөбәрҗәт әйтә, *(Зөбәрҗәткә күз кыса.)* син мылтыктан ата белмисең, ди. Атып күрсәтим инде, ә?

Җ ә ү д ә т. Нәрсә комедия уйнап маташасың монда? Ычкын яхшы чакта! *(Мылтыгын күтәрә.)*

А з а м а т. Мә, ат, оятың булса, ат! *(Күкрәк киереп аның каршысына бара.)*

З ө б ә р җ ә т. Тукта! Миңа батырлык эшләргә туры килмәде. Революция узгач туганмын. Сугышта да булмадым. Ичмасам, сөйгәнем өчен һәлак булыйм! Мә, ат! *(Өстенә килә. Җәүдәт әкрен-әкрен чигә.)*

Х ә д и ч ә *(керә).* Җәүдәт! *(Җәүдәт әнисен күреп каушый, Зөбәрҗәт белән Азамат хәлне аңлап чыгып китәләр.)* Бик рәхмәт инде, балакаем... *(Күңеле тула.)*

Җ ә ү д ә т. Әни, син дә телгәлә инде йөрәкне!

Х ә д и ч ә. Йөрәк? Каян килгән ул сиңа йөрәк?!

Җ ә ү д ә т. Ярар инде, әни, ярар инде...

Х ә д и ч ә. Ярамас! Син миңа актык сүземне әйттермә! Апкайтасыңмы киленне, юкмы?

Җ ә ү д ә т. Кирәк булса, алып кайт. Аның миңа кирәге юк!

Х ә д и ч ә. Шулаймыни? Башыңнан сыйпаганны көтәсеңме? Укытырмын мин синең арт сабагыңны. Гүзәлияне үзем апкайтам. Минем җибәрә торган киленем юк! *(Китә.)*

Җ ә ү д ә т *(ялгыз).* Бөтенесе миңа каршы. Нинди начарлык эшләдем соң мин? Әйбер урламадым. Авария ясамадым. Шундый авыр чакта Гыймран абзый да юк. *(Кузгала.)*

Г ы й м р а н *(керә).* Исәнме, энем.

Җ ә ү д ә т. Исәнмесез, Гыймран абзый?

Г ы й м р а н. Нишләп йөрисең көпә-көндез мылтык күтәреп?

Җ ә ү д ә т. Җанымны кая куярга белми йөрим, Гыймран абзый.

Г ы й м р а н. Андый катын белән асылынып та үләрсең. Бөтен бригат алдында нишләтте үзеңне! Тиле Талипның кәрәчинле тун ябынып үскәнен онытткан! Их, энем, энем, мин синең урыныңда булсам...

Җ ә ү д ә т. Нишләр идең?

Г ы й м р а н. Телен кыскарта белер идем мин аның.

Җ ә ү д ә т. Кыйнапмы?

Г ы й м р а н. Тәүбә диген! Хәзерге заманда катын-кызга кул ягарга ярыймы соң! Икенче көнне үк партоешмага барып җитәләр. Кешегә күрсәтми эшләргә кирәк, күрсәтми...

Җ ә ү д ә т. Ничек?

Г ы й м р а н. Анадан тума ялангач калдырып чишендерәсең дә...

Җ ә ү д ә т. Я, я?

Гыймран. Салкын кар базына ябып куясың. Ул сиңа, кар базы хәзерге холодильниклар гына түгел, промахсыз эшли. Менә шунда гомерлеген ала инде ул.

Җәүдәт. Син бигрәк инде, Гыймран абый.

Гыймран. Синең кәнтәеңә ул гына да аз әле.

Җәүдәт. Чамалап! Нинди кәнтәй?

Гыймран. Әнә кара!

Гүзәлия белән Сәләхи керәләр. Гыймран белән Җәүдәт имән артына яшеренәләр.

Гүзәлия. Сәләхи абый, кирәкми, ул турыда сөйләшмик.

Сәләхи. Юк, сөйләшик, Гүзәлия. Аңла, мин синең бәхетең...

Гүзәлия. Сәләхи абый... Кирәкми, тотмагыз мине...

Сәләхи. Тыңлап бетер инде.

Җәүдәт мылтыгын кора.

Сәләхи. Гүзәл... Яратасыңмы?

Гүзәл. Мин ярату белән генәмени?

Сәләхи. Юк, син турысын әйт: яратасыңмы?

Гүзәлия. Яратам.

Сәләхи. Яратсаң, коткар!

Җәүдәт *(имән артыннан чыга)*. Стой! Кузгалма.

Гүзәлия. Җәүдәт, акылыңа кил.

Җәүдәт. Басыгыз имән төбенә!

Сәләхи. Җәүдәт!

Азамат *(керә, Җәүдәткә ташлана)*. Хәйрүш, Николай, егетләр!!!

Тавышка бригада егетләре керә.

Хәйрүш. Нәрсә булды? Ни бар?

Җәүдәт. Гүзәлиянең минем өстән ни өчен сөйләгәнен аңладым. Аңа Сәләхи кирәк икән.

Сәләхи. Дөрес түгел!

Җәүдәт. Шаһитым бар. Гыймран абзый!

Талип керә.

Талип. Нәрсәгә шаһит? Кемгә шаһит?

Гыймран. Юк ла, Талип абзый... вак-төяк. Куркыныч бер нәрсә дә юк.

Талип. Син булган җирдә, Гыймран, куркыныч булмый калмый. Син... син... эттән туган... син...

Хәйрүш. Бабай, дим, бабай, туктале... тынычлан, утыр.

Талип. Юк, тынычландырма мине. Утыртма да. Арагызда менә мондый йомраннар бар чагында тынычланырга хакыгыз юк.

Гыймран. Мыскыл итәсез. Мин... мин... юл куймам.

Азамат. Спокойно! *(Мылтык белән юлын була.)*

Талип *(Хәйрүшкә)*. Яшьләрнең командиры булып җитмәгәнсең икән шул әле син, кияү. Скважиналарыңны җиде төн уртасында уятып сорасалар да әйтеп бирә аласың, ә менә кул астындагы кешеләрнең йөрәгендә нинди утлар янганны белмисең.

Хәйрүш. Нәрсә белмим, нәрсә?

Талип. Менә бу йомран асыл егетнең җанына җылан булып кергән. Шуның аркасында Җәүдәт нинди якты теләкләрегезне, хыялларыгызны аяк астына салып таптады.

Җәүдәт. Сүз монда хыяллар турында бармый. Сүз синең кызың турында бара.

Сәләхи. Дурак син, Җәүдәт! Гүзәлия, сөйләп бир үзенә.

Гүзәлия. Сәләхи абый миңа әйтте, әгәр Җәүдәтне яратсаң, коткар аны Нуришановның караңгы эшләреннән, диде.

Җәүдәт. Нинди караңгы эшләр?

Талип. Әле ул семья арасына да барып тыгылдымыни? Җылан, җылан... Алайса, сөйләп бирим инде мин сезгә. 1915 елны Бакуга бергә чыгып киттек. Менә бу имәнне мин утыртканны ул күрде, көрәк тотып торды, бу бәхет имәне дигәнемне дә ишетте.

Сәләхи. Болай булгач, мин дә аңладым.

Хәйрүш. Нәрсә аңладың?

Сәләхи. Имәнгә тимер чөйне Нуришанов юкка гына какмаган икән.

Гыймран. Күрдеңме?

Сәләхи. Күрдем.

Талип. Шулай булыр дип уйлаган идем аны.

Гыймран. Җәмәгать! Бу ни эш бу: намуслы кешегә яла ягалар. Мин моңа түзә алмыйм. *(Кузгала.)*

Азамат. Кузгалма! *(Мылтыгын төзи.)*

Талип. Юк инде, Гыймран, тыңлап бетер инде син. Бүтән чакта син мине тыңларга теләмәдең, ә бүген... тыңламый хәлең юк. Мин сине Бакуга алып бардым. Сине кеше итәргә теләдем. Халык бәхете өчен даулашканга, Нобель приказчигы мине нагайка белән ярды, ә син, йомран, караңгы ояңа кереп постың. Мин революция өчен мылтык күтәреп сугышып йөрдем, ә син, йомран, икмәк белән сату итеп, акча җыеп яттың. Гомер буе үз ояңа ташыдың син. Караңгы эшләреңне әйтә башлагач, хатыныңны кар базына ябып үтердең. Инде менә хәзер иң бай җиргә — нефтьчеләр каласы Әлмәткә килеп сырышкансың да яшьләрне комсызлыкка, акча җыярга өйрәтмәкче буласыңмы? Без кабызган утлар тирәсендә үзең генә җылынырга телисеңме? Юк инде, анысы барып чыкмас! Без учакны халык өчен кабыздык.

Җәүдәт *(Азаматтан мылтыкны тартып алып, Нуришановка ташлана).* Ах син, бүре!!

Гүзәлия. Җәүдәт, нишлисең?

Җәүдәт. Үтерәм. Үзе биргән мылтык белән!

Гүзәлия. Җәүдәт бәгырем, пычратма кулыңны!

Пәрдә.

Иршат Вергасов

# КЫРЫМ ПАРТИЗАННАРЫ

ХИКӘЯЛӘР

## Филипп Филиппович

Апрель дә җитте. Таулар аркылы үтеп яз килә. Көньяк яр буе бакчаларында шактый озак шаулаганнан соң ул тау итәгендәге урманнарга да яшеллек китерде һәм җилләр үзәгендә яткан салкын җәйләүне узып, Таврия далаларына таба ашыкты.

Җылы тамчыларын шыбырдатып ләйсән яңгырлары явып үтте. Елгалар тагын тулып-ташып, шаулап агарга кереште. Иң биек тауларның төньяк итәгендә карлар эри башлады. Киртләч-киртләч булып торган тау сыртларына таба тарлавыклардан кавырсындай җиңел томаннар күтәрелеп, зәңгәр күктә таралып юкка чыга иде.

Күбекләнеп аккан Донго елгасы буендагы партизан торaклары бушап калды. Теге «он операциясе»ннән соң инде кешеләрне землянка һәм шалашларда яткыру кыен иде — алар дошманны кыйнарга киттеләр.

Пөхтә штабчыбыз подполковник Алексей Петрович Щетинин бер көнне отрядтагы кешеләр исемлеген тикшерергә, кемнең кайда гаиләсе, ничә кешесе барлыгын белешергә кереште.

— Нигә кирәк ул? — дип сорадылар аннан партизаннар.

— Менә озакламый Севастополь белән элемтә башланачак. Хәрби комиссариатларга хат язып, аларга сезнең гаиләләрегез турында кайгыртырга кушабыз, — дип җавап бирде Алексей Петрович.

Һәркемнең телендә бары тик бер генә сүз: элемтә, элемтә! Партизаннар, самолет күренмиме дип, әледән-әле күккә, һавага карангалыйлар. Ләкин төннәрен күк йөзен тоташ соры болытлар каплап ала — безне бер самолет та эзләп таба алмый.

Әмма бер көнне иртән безнең урман өстендә бер самолет-истребитель күренде. Башта моңа игътибар итүче булмады диярлек — тирәягыңда шундый зур сугыш кайнап торганда нинди самолет очмас — ләкин бу самолет башкалар шикелле туры гына очып үтмәде: әле

Ахыры. Башы журналыбызның сигезенче санында.

өскә таба атылып, әле агач башларына тияр дәрәҗәдә аска томырылып, бер тирәдә әйләнеп йөри башлады. Без, моны күзәтә торгач, канатларындагы кызыл йолдызларын күреп алдык.

— Безнең самолет бу! Безнеке!!!

Тиз генә сигнал учаклары кабызып җибәрдек: «Без монда! Без сине көтәбез» — янәсе.

Самолет, моны аңлап, канатларын чайкады.

Менә Югары Аппалах аланы өстендә самолет әйләнеп йөри, шунда таба барлык отрядлардан кешеләр йөгерә. Самолет аланны бер әйләнгәч, канатларын тагын бер тапкыр чайкап алгач, Севастопольгә таба очып китте.

Без, бу хәлгә сөенешеп-дулкынланып, төрлечә гөман кылдык, безнең белән элемтә булдырырга, безгә ярдәм итәргә телиләрдер, дидек. Безне эзләргә керешүләре инде көн кебек ачык иде!

Урмандагылар, яңа хәлләр, яңа вакыйгалар буласын көтеп, тынгысыз тормыш белән яши башлады.

Дүртенче тәүлек дигәндә көндезге сәгать унберләр тирәсендә мотор тавышы ишетеп, землянкаларыбыздан тагын йөгерешеп чыктык. Штаб дежуры әче тавыш белән:

— Кукурузник, — дип кычкырып җибәрде.

Әлеге атаклы биплан, канатларында һәм фюзеляжларындагы йолдызларын ялтыратып, нарат башларына тия язып очып үтте. Безнең йөрәкләр кысылып куйды: очучысы бик тәвәккәл егеттер — көпә-көндез фанер «У-2» самолетында очып йөри бит. Немец истребителенә юлыкса, аны шундук самолеты-ние белән тишкәләп, тетеп бетерәчәкләр ич.

Күк йөзендә бер болыт әсәре күренми, без борчылып як-якка каранабыз: алай-болай дошман самолеты гына килеп чыга күрмәсен инде!

«У-2» әйләнә-әйләнә түбәнәя бара... Әллә җиргә үк төшәргә уйлый инде?! Кая төшмәкче була ул?

Чытырманлыкларны ерып, көч-хәл белән Югары Аппалахка килеп чыктык. Анда ачык урын бар, барын, ләкин самолет төшеп утырырлык микән ул?

Мин, аланга чыгып, тирә-якка күз йөрттем: алан, үр сыман биегәя-биегәя, куе урманга барып терәлә, аңа «У-2» да төшәрлек түгел.

Ә самолет инде төшеп килә.

Бәрелеп ватылмасын, көл булмасын гына иде!

Менә ул җиргә якыная башлады, якынайды... көпчәкләре җиргә тиде, тигезле-тигезсез алан өстеннән сикергәләп китте. Аннары шатырт-шотырт итте дә... тынып калды.

Ярым ватык-җимерек машина өстендә җете зәңгәр күзләре белән елмаеп торган, диңгез очучысы киемендәге яшь кенә бер егет күренде. Без, йөгереп барып, аны күтәреп алдык, җиргә төшердек. Һәркайсыбызның аны — Ватаныбызның Олы җиреннән килгән кешене — тотып карыйсы килә иде.

Егет:

— Иптәшләр! Иптәшләр! — ди-ди уңайсызланып, кешеләр кулыннан ычкынырга тырышты. Аннары: — Ягез әле, иптәшләр, бурычымны әйтергә рөхсәт итегез, — диде.

Каршына Северский килеп баскач, кунак егет хәрбиләрчә төз басты да яңгырап торган яшь тавыш белән рапорт бирде:

— Севастопольдән кече лейтенант Герасимов, Филипп Филиппович...

Северский аталарча ягымлы елмаеп:

— Исәнме, Филипп Филиппович. Сау-сәламәтме? — диде.

Барысы да көлешеп куйдылар.

— Филипп Филипповичны һавага чөяргә! — дип кычкырды күпләр.

Шушы шатлыклы минутларны кичергәндә без икенче кабинадан петлицасына өчпочмаклы билгеләр кадалган тагын бер кунак чыкканын абайламый да калганбыз. Аның гаепле кешенеке сыман борчулы кыяфәтениндидер бәхетсезлек булганлыкка ишарәли кебек иде. Ул кешеләр арасыннан Герасимов янына үтеп керде дә еламсыраган тавыш белән:

— Рация... Рация челпәрәмә килгән, иптәш кече лейтенант, — диде.

— Нәрсә-ә-ә? — диде Филипп Филиппович, зәңгәр күзләрен түгәрәкләндереп.

Самолет җиргә төшеп утырган вакытта, рация ватылмасын дип, радист аны кулына тоткан булган икән дә, рация самолет бортына бәрелеп челпәрәмә килгән.

Менә сиңа көтелмәгән бер каза!

Бу хәлне ишетүчеләр кайгыга калды, ә партизаннарның күбесе әле һаман сөенешәләр, шау-гөр килеп сөйләшәләр иде. Нинди генә кеше юк монда, нинди генә кием кимәгәннәр алар... 1941—1942 елның коточкыч авыр кышына да түзгән кешеләр бит алар. Хәрби кием, румын, немец киеме... Башларында пилотка, колакчынлы бүрек, папаха, шлем... Аякларында күн итек, күн башмак, ботинкаларның нинди генә фасоны юк...

Йөзләренә, кыяфәтләренә карасаң — йөрәк әрни. Бар кичергән газап-михнәтләр һәркайсының йөз-кыяфәтендә көзгедәге кебек чагыла. Язмыш аларның барысын да тигезләгән, бер төсле иткән шикелле. Яшьләрне картлардан, хатыннарны ирләрдән аеруы да кыен. Барысы да карт чырайлы — ачлык рәхимсез шул. Берәүнең дә чыраенда алсулык дигәннең әсәре дә юк.

Билгеле, бу кышкы газап-михнәтләрне һәркем үзенчә кичерде, туңды-өшеде, ач яшәде, безне дошман әзәрлекләгәндә хәлдән таеп егылганчы туктаусыз аяк өстендә булды, Севастополь язмышы, үз язмышы турында, туганнары турында уйлады. Без зур өмет, зур ышаныч аркасында гына бирешмәдек, дисәм ялгыш булмас, югыйсә, шул кадәр кеше түзә алмаслык шартларда дошман белән көрәшерлек хәлдә була алыр идекме!

Рациянең ватылуы тора-бара башкаларга да билгеле булды һәм Филипп Филипповичның зур батырлык күрсәтеп бирегә очып килүе безнең хәлне үзгәртмәгәнлеген, Севастополь белән һаман да элемтә урнаштырып булмавын бөтен кеше аңлады.

Әмма без элемтәсез яши алмый идек һәм бу хәл белән килешеп тә булмый иде.

Филипп Филиппович, бик кәефсез кыяфәттә, ниндидер өмет белән, ватык машинасын карарга кереште. Мин дә аның янына килдем — бервакыт мин дә ВВС гаскәрләрендә хезмәт иткән идем, очу эшен беркадәр беләм.

Самолетның моторы шәп, бензины бар, әмма бер җире бик яман: җиргә төшеп утырган чакта аның пропеллеры челпәрәмә килеп юкка чыккан. Ә ансыз очып китеп булмый.

Самолет янына штаб начальнигы килде, күз карашыннан өметле бер нәрсә бар кебек аңлашыла иде.

— Я, нәрсә, Алексей Петрович? — дидем мин ашыгып.

— Миңа әйттеләр: фронтның алгы сызыгы тирәсендә немецлар

ягына шушындый ук самолет егылып төшкән, диделәр. Кызыл әрәмәлеге өстенә төшкән. Винты исән булырга тиеш.

Яшь очучы:

— Кайда ул? — дип малайларча җитезлек белән Алексей Петрович янына йөгереп килде.

— Ачыкларбыз, — дип, Щетинин китте дә бераздан безнең янга партизан Пономаренконы ияртеп килде.

— Миңа әйткәннәреңне боларга да сөйләп бир әле.

— Есть! Самолет Чәй йорты артында ята, пропеллеры штык шикелле тырпаеп тора, — диде Пономаренко.

— Анда бара беләсеңме, сержант?

Мин анда чаклы булган араны күңелдән чамалап карадым: айһай, шактый ерак җир бит ул. Әлбәттә, юлларына азык табыштырмый калмабыз, ә менә барып җитә алырлармы икән егетләр? Барысы да ачка киселгән. Бик аз вакыт эчендә йөз егерме километр җир йөреп кайтырга кирәк, өстәвенә җәйләү буйлап баткак йомшак кардан барасы. Аннары, йөге дә бит — мендәр күтәреп кенә кайтасы түгел, шактый көч кирәк.

Комиссар беравык уйланып торды да:

— Әгәр хатыннарны җибәрсәк, ә? — дип куйды.

— Хатыннарны? — дидем мин аның күзенә текәлеп.

— Уйлап кара әле, — диде ул.

Дөресен әйтергә кирәк: отрядлар кичергән авыр сынауларда хатын-кызлар ирләргә караганда чыдамлырак булып чыкты. Бер түгел, йөз тапкыр ышандым мин моңа. Беришесенә карарга да кызганыч: ябыклыктан күзләре зураеп эчкә баткан, аяклары нечкәреп калган, ә үзе берни булмаган кебек һаман атлавын белә, җилкәсенә санитар сумкасы, корал, гранаталар аскан. Ялга туктасак, без тизрәк җиргә авабыз, ә алар әле берсенең ярасын сүтеп бәйли, әле икенчесенә җимеш суы эчертә, өченчесен йомшак теле белән юатып китә.

Шулай итеп, хатыннарны җибәрергә булдык! Бу хәбәрне ишеткәч, беренче булып Дуся йөгереп килде:

— Ул винтны мин бер үзем дә күтәреп кайтам!

Македонский аны сүзеннән бүлде:

— Синең үз эшең бар, һәммәсенә дә тыгылма, белдеңме? — диде кырыс кына.

— Белдем, иптәш комиссар, — диде дә Дуся, елар дәрәҗәгә җитешеп, китеп барды.

Бу эшкә хатын-кызлардан өч кеше сайлап алдык: берсе — Симферопольныкы — Анна Михайловна Васильева дигән чал чәчле укытучы, икенчесе — аз сүзле, таза, чыдам медсестра Евдокия Ширшова, өченчесе — партизаннарга аш пешерү өчен иртәдән алып кичкә хәтле юкә бөресе җыеп йөри, төннәрен сакта тора торган юаш, тыныч табигатьле Анна Наумова дигән кыз. Юл күрсәтеп баручы итеп, әлбәттә, теге сержант Пономаренконы билгеләдек. Ә менә башлык итеп кемне җибәрергә? Операциянең нәтиҗәсе өчен партия кешесе буларак җавап бирерлек, яхшы абруйлы кемне билгеләргә?

Минем янга декабрь сугышларында тар-мар ителгән Алупка сугышчан группасының политругы Александр Поздняков килде.

— Мине җибәр, командир, — диде ул.

— Бәлки сиңа ярамас, бәлки синең эшең түгелдер ул, Александр Васильевич?

— Минем эш, минем «төп эш».

— Алайса, барыгыз, винтны алып кайтыгыз.

— Алып кайтабыз.

Аларның кайтуын көтү көннәре башланды... Филипп Филиппович белән ярдәмчеләре — ярдәмчелеккә байтак кеше табылды — самолетны төзәтәләр, очып китәр өчен тигез җир әзерлиләр. Партизаннар, самолетның очып китәчәгенә ышанып, туганнарына хатлар язарга керешге.

Тегеләр бишенче тәүлек дигәндә пропеллер күтәреп кайтып җиттеләр. Ләкин араларында Александр Васильевич юк иде...

Саша агай, Александр Васильевич! Мин сезне сугышка чаклы ук, Гурзуф совхозында өлкән механик булып эшләгән чакта ук очраткан идем бит әле. Безнең механика мастерскойлары атаклы князь Раевскийлар дачасы янында гына иде. Раевскийлар Александр Сергеевич Пушкинны кабул иткән кечерәк кенә дача йорты да яхшы сакланган иде.

Күккә таба сузылган биек, төз кипарисның шагыйрь үзенең шигырьләрендә мактап җырлаган кипарис икәнлегенә мин нигәдер ышанмый идем. Моның шул кипарис икәнен кем ничек исбат итә ала, янәсе? Ул елларда әле мин бик яшь идем шул, һәр нәрсәне исбат итүләрен ярата идем.

Мөгез кысалы күзлек кигән, интеллигентларча нәфис түгәрәк йөзле бу кеше — Пушкин музееның директоры — еш кына безнең мастерскойлар яныннан үтеп йөри, һәр вакыт безнең белән баш иеп исәнләшеп китә иде.

Көннәрдән бер көнне мин аның белән әлеге кипарис турында сөйләшеп киттем. Александр Васильевич аның шул кипарис икәнлеген миңа бик ансат исбат итеп бирде, кешенең белергә тырышуы бик яхшы сыйфат, ә үзең эзләп табып белсәң — тагы да яхшырак, диде. «Менә син үзең күрше генә була торып, музейга бер тапкыр да кереп караганың юк», — дигәнен дә өстәде.

Мин Александр Васильевич белән күрешкәли башладым. Ул миннән унбиш яшьләр чамасы олырак һәм йөз мәртәбә тәҗрибәлерәк иде: Себердә байтак еллар партия эшендә эшләгән, аңарчы гражданнар сугышына катнашкан, басмачыларга каршы көрәшкән. Кыскасы, безнең буынга рухи бер яктылык биргән якын тарихның тере герое иде ул.

Шушындый батыр кызыл комиссарның биографиясен Гурзуф кешеләренең белмәве миңа бик гаҗәп тоела иде, шуңа күрә мин җае чыккан саен аның турында үзебезнең механика цехы егетләренә сөйли башладым. Поздняков моны белгән дә, бер көнне очрашкач, ачулы гына төс белән: «Үткәндәгеләр яхшы анысы, ләкин иң яхшысы, иң мөһиме — менә хәзер, шушы минутта нәрсә эшләвең!» — диде.

Винт алырга бару — кызыл комиссарның героик тормыш юлындагы соңгы бер батырлыгы. Аларга җәйләү аша барырга туры килә. Тау башларында инде кар эреп беткән, әмма чокырларда әле ул бик хәтәр.

Җеп бөртекләренә хәтле чыланган, арып хәлдән тайган партизаннар Чәй йортына төшәләр, ике тәүлек буена фронтның икенче эшелонын йөреп чыга яздык дигәндә генә теге самолетны табалар. Кечкенә генә швед ачкычы белән, кулларын суя-суя, винтны күчәреннән салдырып алалар.

Тизрәк кайтырга ашыгалар, ял итмиләр. Поздняков хәлсезләктән чайкала-чайкала атлый, иреннәре чатнап кипкән, күзләре эчкә баткан. Башкалар белән беррәттән авыр йөкне күтәрешеп кайта... Ахырда хәле бетеп җиргә егыла. Иптәшләре аны күтәреп кайтмакчы булалар, ләкин Александр Васильевич каршы килә, сүнеп барган тавыш белән: «Бер минут та ял итмәгез, әмма винтны теләсә

ничек кайтарып җиткерегез. Мин бераз хәл алырмын, үрмәләп булса да кайтып җитәрмен», — ди.

Ул кайтып җитә алмаган, Демир-капу тавы итәгендә үлеп калган. Каршыларга дип киткән партизаннар аның салкын гәүдәсен генә күтәреп кайттылар.

Филипп Филиппович комиссарның кабере янында басып торганда, кипшенгән иреннәрен көчкә кыймылдатып: «Үлсәм үләм, барыбер Севастопольгә кайтып җитәм!» — дип пышылдады.

Кырым урманнарында отрядтан отрядка даннары таралган геройлар булды. Ә менә Александр Васильевичны бик аз кеше белә иде. Ул кеше күзенә артык чалынмый торган, тыныч табигатьле, физик яктан шактый көчсез бер кеше, санитар землянкаларында иң күп ятучы да ул иде.

«Хуш, бәхил бул, якташ. Исән калсам, әлбәттә, дача-музейга барырмын, сине — авыр елларда мин яшь коммунистка өлкән иптәш булган чын кешене — беркайчан да онытмам».

Филипп Филиппович гел самолет тирәсендә кайнаша, самолет җирдән күтәрелеп китәргә тиешле мәйданда арлы-бирле йөри, баш бармагына төкерек сөртеп алга таба суза да җилнең кай яктан кай тарафка таба исүен чамаларга тырыша.

Менә очып китәр өчен бөтен нәрсә әзер инде. Хатлар, разведка мәгълүматлары самолетка урнаштырылган, зинһар, безне онытмагыз, дигән гозерләр дә әйтелгән.

Филипп Филиппович дулкынланудан агарынган йөзе белән соңгы тапкыр кешеләргә борылып карый. Ул аларның: «Тырыш инде, кадерле Филипп Филиппович!» дигән ялварулы күз карашларын күрә. Очучы егет тамак кыргалап ала да карлыккан тавыш белән:

— Винт яныннан китегез! — дип команда бирә.

Мотор калтыранып эшли башлый. Менә пропеллер бер әйләнде дә туктап калды, яртылаш кирегә әйләнде — аннары тагы бер әйләнде, ике... Һәм урман өстенә ышанычлы, тигез гөрелте таралды.

Филипп Филиппович егетләрчә ялт кына кул селтәде дә самолетын юлга алып чыкты. Мотор каты гүләп эшли башлады, самолет кызу гына кузгалып китте һәм, җирдән күтәрелә барып, алга таба омтылды.

Мин винтның ничек әйләнүен тавышыннан сизеп тордым, һәм кинәт күңелгә шик килеп, йөрәк кысылып куйды — моторның тарту куәте һава агымыннан көчсезрәк иде. Аның иң соңгы җегәр белән көчәнеп әйләнүен күреп, тоеп торам: аланнан тарлавык эченә ыргылган һава агымына каршы торырлык көче юк иде аның... Ике тау арасындагы упкын самолетны безнең күз алдыбызда үз эченә суырып ала башлады. Менә аның көпчәкләре карт имән башларына тиеп-тиеп китте дә... самолет караңгы упкын эченә төшеп чумды, дөбер-шатыр иткән тавыш кына ишетелде...

Минем дә йөрәк туктап калган шикелле булды, аннары чигәләрне авырттырып-авырттырып тибә башлады. Җиргә ничек басканымны да тоймастан, самолетка таба чаптым. Бөтен кеше, тавышсызөнсез калып, шунда йөгерде.

Самолет челпәрәмә килгән иде: койрыгы кырыкка бөкләнеп яньчелгән, канатлары, юри эшләнгән сыман, берсе-берсенә килеп кушылган. Филипп Филиппович — исән калган бит! — киемнәре теткәләнгән, бите-башы канга буялган хәлдә, самолетны ут кабудан саклап, бензин багы тирәсендә мәш килә.

...Яз көннән-көн кызулый бара, шаулап-гөрләп килә ул. Бөтен урман эчендә сагыз-сәмих исе аңкый, агачларда бүртеп-тулышып

бөреләр ачыла. Чулт-чулт итеп тамчылар тама. Колак төбендә Бетховенның тугызынчы симфониясе яңгырап тора сыман. Мин аны беренче тапкыр Ялтада Җәйге бакчада ишеткән идем. Оркестрга Натан Рахлин дирижерлык итте. Сугыш башланырга биш сәгать кала булган иде бу хәл.

Филипп Филипповичның күз төпләре каралып-көеп калган. Чырае аның ничектер олыгаеп-картаеп киткән, бил каешын инде ул иң соңгы тишегенә эләктереп куйган. Егет безнең күз алдыбызда сызакибә бара, мине җибәрегез, дип ялвара, фронт сызыгы аша узам мин, яңадан фанер самолетта яныгызга көпә-көндез очып килермен, ди.

Бу хакта Северский да уйлый, мин дә уйланам. Нишләргә? Бу эштә без байтак кешебезне югалттык бит инде: фронт сызыгын үтеп чыгарга тырышуыбыз гел уңышсызлыкка очрады. Әйтерсең безнең элемтәчеләребезне Нептун тереләй йотып тора иде.

— Ә мин, менә күрерсез, үтәм,— ди очучы егет.— Мин инде фронт сызыгын арлы-бирле йөз генә тапкыр үтмәгәнмендер. Югарыдан җирдәге һәрбер сукмакка чаклы ап-ачык күренә, һәммәсе күз алдымда. Җибәрегез — үтәм! — ди.

Үзенең энә күзеннән дә үтәчәгенә, үзебезнең якка чыгып җитәчәгенә безне тәки ышандырды бит.

Шулай итеп, без аны бик куркыныч, авыр юлга озаттык.

Урманда гөрләвекләр, тау елгалары шаулап ага башлады. Кардан ачылган җир сәгать саен зурая, өскә таба үрмәли бара. Җәйләү башта каралып калды, аннары яшәрә башлады.

Күктә биектән-биектән Севастопольгә таба самолетлар очып китә, кайсы көннәрне иртүк, безгә канатын чайкап, кызыл йолдызлы очкыч та үткәли.

Беркөнне безнең өстә мотор гөрләгәне ишетелде. Һавада Севастопольдән безгә хәбәр китерүче самолет иде.

Партизаннар:

— Филипп Филиппович! — дип кычкыра, бүрекләрен чөя, хәтта елаша ук башладылар.

Самолет без алдан ук хәзерләп куйган Тарьер аланы өстендә бер-ике әйләнде дә, туп-туры төшеп, урман читенә килеп туктады.

Кабинадан җиңелчә зәңгәр комбинезон кигән егет килеп чыкты.

— Филипп Филиппович!

Яшь сержант-радист:

— Ике рация, дүрт комплект батарея китердем, — дип Северскийга рапорт бирде дә: — Элемтәгә керергә рөхсәт итәсезме? — дип сорады.

Шулай итеп, Севастополь белән безнең арада эфир аша элемтә җебе сузылды. Олы җиргә җибәргән беренче радиограммаларында партизаннар, таләп итеп, үтенеп, ялварып, Филипп Филипповичка Советлар Союзы Герое исеме бирүне сорадылар.

Һәм лаек булды ул аңа.

Менә бер заман сугыш та бетте, ә зәңгәр күзле егетебез Филипп Филипповичтан бер хәбәр дә ала алмадык. Кайлардан гына эзләтмәдек без аны, тик һәр җирдән җавап бер генә төрле булды: сугышта үлгән, диделәр.

Кырым музейларына Филипп Герасимовның теге авыр көннәрдә төшкән сагышлы-моңсу фотокарточкаларын элеп куйдылар. Музей карарга килгән кешеләргә: Герасимов кечкенә калибрлы винтовкадан да атып төшерерлек самолетта көпә-көндез немецлар өстендә очып йөргән, дип сөйләделәр.

Анысы хак сүз.

Әмма егет үлеп калган...

Еллар, юллар кебек, кушылып-югалып артта кала. Агачлардагы сугыш яраларын әкренләп кайры каплый, һәм кургаш ярчыклар белән тулган җәрәхәтле бу агачлар тамырларында килеш әкренләп картая, корый баралар. Еллар бер-бер артлы уза тора, элекке карт урман урынында инде яшь агачлар гөрләп үсә, теткәләнгән-сынган туйралыклар урынында зур имәннәр шыгырдап утыра.

Җәйләү дә курортчылар һәм экскурсантлар күзенә матуррак булып күренергә тырыша — кыяфәтен үзгәртә: урыны-урыны белән анда купшы наратлар үсеп килә.

Җил дә ниндидер бер көй чыгарып исә кебек. Ялтаның өстендә үк калкып торган Шишко кыясыннан бөтен диңгез өсте күренеп тора, тауларда мылтык аткан тавыш кабат-кабат кайтып ишетелә.

Кыя өстендә зур бер таш бар, шул ташка уеп партизаннарның исемнәре язылган.

Тар балаклы джинси чалбар кигән җитез экскурсовод егет ял итүчеләрне ияртеп йөри, аларга безнең заман, безнең героик тормышыбыз турында мәгълүматлар бирә — кат-кат сөйләп, ятлап бетергән сүзләрен тезеп кенә тора.

Менә сүнеп барган учактагы чаткы сыман ялтырап киткән тагын бер мәгълүмат:

— Мең тугыз йөз кырык икенче елның иң авыр бер чагында — апрель аенда — ачтан үлүче партизаннар янына яшь очучы, Советлар Союзы Герое Филипп Филиппович Герасимов очып килә. Тик соңрак сугыш бу патриотның гомерен өзә. Әмма ул батырның якты истәлеге беркайчан да безнең күңелләрдән җуелмас...

Шул вакыт кешеләр арасыннан берәүнең дулкынланган кыю тавышы ишетелә:

— Ничек ул алай «гомерен өзә...»

Дистәләрчә кеше тавыш килгән якка борылып карый, һи, агай-эне, шуны да аңламыйсызмы? — дигән сыман сәерсенеп куялар.

Экскурсовод егет әдәпле генә итеп аңлатып бирә:

— «Гомерен өзгән» — үлгән дигән сүз була ул, иптәш... Очучы Герасимов чираттагы бер һава сугышында һәлак булган.

Агара башлаган чәчле, зәңгәр күзле әлеге ир:

— Юк инде, үлгәннәр исәбендә йөрергә риза түгел әле мин! — дип, алгарак чыга да йөзе белән кешеләргә таба борылып: — Герасимов Филипп Филиппович ул мин булам! — ди. — Әйе, партизаннар янына «кукурузник»та очып баручы ул — мин идем. Герой исемен миңа биргәннәр иде! — ди.

...Бер көнне язу өстәлем өстендәге телефон шалтырады. Бер ир кеше дулкынланган тавыш белән шактый кычкырып:

— Исәнмесез, иптәш командир! Бу — мин, очучы Герасимов, Филипп Филиппович дигән егетне хәтерләмисезме? — диде.

Минем хәтта аякларым атлый алмас булды.

Менә хәзер мин шушы юлларны язып утырган чакта зәңгәр күзле бер әшче ир данлыклы Ленинград урамнарында йөридер, бәйрәм көннәрендә аның түшендә Алтын Йолдыз балкыганын бик аз кеше генә күреп беләдер.

## Севастопольчә, шәп эшлиләр

Көнбатыш тарафта, хәтта Севастополь тирәләрендә дә хәзергә әле дөнья тыныч. Ләкин бу тынлык озакка бармаячак — без аны белеп торабыз.

Көньяк кояшы эссесеннән кызган кайнар юллар танк, вездеход табаннары астында көн-төн гүелдәп-яңгырап тора, тып-тып басып

солдатлар атлый — барысы да Севастопольгә таба агыла. Дошман бөтен көчен атаклы диңгез крепосте өстенә ташлады.

Моңа каршы безнең иң көчле коралыбыз — нәфрәт һәм туктаусыз көрәш. Без — Севастополь кешеләре — дошманның тылында торып көрәшәбез. Туган шәһәребезгә бөтен көчебезне биреп ярдәм итәргә тырышабыз!

Хәзер инде безнең лагерьларда беркем юк диярлек, бары тик авырулар гына кала, алар да, агачка сөялеп булса да, сакта торалар.

Сугышчан группадагылар барысы да көньяк кояшында чуендай каралып янган какча, ябык тәнле, арыган-талчыккан, йокы аз тигәнлектән күзләре кызарган егетләр, ирләр. Менә алар чираттагы заданиене үтәп кайталар. Отряд командирына кыска гына итеп рапорт бирәләр, трофейларын тапшыралар — барыннан да бигрәк кулга төшерелгән дошман документлары кадерле, — шушы төндә үк ул документлар Кара диңгез флотының командующие адмирал Октябрьский һәм Аерым Диңгез буе армиясенең командующие генерал Петровның өстәлләрендә ятачак, — аннары инде партизаннар патрон, гранат, паеклар алалар, боз кебек салкын тау елгасы суында юыналар, уган сохари салып пешергән кайнар аш ашыйлар һәм шуннан соң ятып йокыга талалар.

Нәкъ кичке сәгать унда дошман күзеннән ерактагы аулак бер тарлавыкта гырылдап йоклаган тавышлар ишетелә башлый, аннары, командага буйсынгандай, берьюлы тынып кала. Бер сәгатьтән соң инде партизаннар яңадан юлга чыга — бер-бер артлы тезелешеп, текә сукмактан тауга үрмәлиләр! Менгән саен менә баралар, Демир-капу түбәсенә менеп җиткәч кенә беразга туктап, ял итеп алалар да яңгырап торган җәйләү сукмагына төшеп китәләр.

Кырым урманнарында июнь аендагы бер генә көнне рәсемгә төшереп алсаң да, искитмәле хәл күрер идең: эссе кояш астында юллар ут кебек кызган. Камыр шикелле йомшаган асфальтны автомашина, танк, солдат итеге эзләре чуарлап бетергән. Юлның як-ягыннан тиргә баткан немец патрульләре атлый. Әйләнә торган башнялы бронемашиналар вакыт-вакыт пулеметларыннан кургаш сиптереп алалар. Ә юлдан эчтәрәк кыр жандармериясе отделениеләре куакларга аткалап бара. Немец машиналары колоннасының ничек баруы да кызык: алда — броневиклар, артта — җиңел танклар, ә һавада самолетлар таудан килә торган юлларны пулеметлары белән «үтүкләп» бара. Юлдан тагы да арырак яшерен саклар куелган, аннан да ары — тагы бер «сак»: чәнечкеле тимер чыбыктан киртә корылган.

Үзе басып алган җирдә дошман әнә шулай хәрәкәт итә. Юлларны саклау өчен бик күп полкларын куйган ул.

Ләкин безне андый киртәләр дә туктата алмый: утыздан артыккырыклап партизан группасы — өчәр, дүртәр, бишәр кеше — ярыктан саркып чыккан су кебек, дошманның катлы-катлы киртәләре аша үтеп, күперләрне шартлаталар, снайперлар машина йөртүчеләргә атып, «Мерседес-Бенц» дигән зур машиналарны упкынга мәтәлдерә.

Юл буйларында сугыш әнә шулай дәвам итә.

Мин менә тагын Бакчасарай отряды командиры Македонский янына килдем. Аның кашлары кояшта янып, тагы да куерган, карашы үткенәя төшкән шикелле, кешеләрне үзенә тарта торган ягымлы елмаюы югалган, йөзенә тәвәккәл, кырыс бер төс чыккан.

Ул миңа кул биреп күрештә дә ачу белән әйтеп куйды:

— Ах, ләгънәтләр, Бакчасарай станциясенә эшелоннарын ките-

реп тутырганнар да үз өйләрендәге кебек рәхәтләнеп бушатып яталар бит...

— Нишләргә кушасың соң?

— Евпаторияныкыларның бик шәп килеп чыкты бит, ә? — дип хәйләкәр бер төс белән күзен кысты ул.

Әйе шул, Евпатория отряды командиры Даниил Ермаков бөтен Кырымга шауларлык эш башкарды. Шактый катлаулы операция иде ул! Разведчиклар Яңа Бодрак авылы тирәсендә дошманның зур бер автоколоннасы барлыгын, иртәгә таң алдыннан бу автоколоннаның Севастопольгә таба кузгалачагын белеп кайталар. Командующийның урынбасары Северский Төньяк Кавказ фронты штабы белән элемтәгә керә.

Һәм шуннан соң эшкә дә тотыналар: пулемет, автоматлар белән коралланган партизан группасы алдан ук үзәк юл тирәсенә килеп урнаша.

Өсләрен брезент белән каплап, өч рәткә тезеп куелган дошман автомашиналары кузгалып китәргә хәзерләнә.

Команда булуга, шоферлар стартерларга баса, йөзләгән дизельмотор җир селкетеп гүли башлый.

Немец сакчыларыннан, ичмасам, берсе дә күтәрелеп күккә карамый, Чатыр-Даг ягыннан килгән гөрелтегә колак салмый.

Безнең очучылар колоннаны шундук күреп алалар һәм эшкә дә керешәләр! Немец машиналары өстенә бер-бер артлы томырылып кына торалар. Шул мәхшәрдән файдаланып, партизаннар түш белән шуыша-шуыша юл буена ук килеп җитә.

Исән машиналар бомбадан качып котылырга маташкан бер вакытта нишләргә белмичә мәш килгән фашистлар өстенә партизаннар кургашы ява башлый.

Колоннаны бөтенләе белән яндыралар, тар-мар итәләр. Эшне — Севастопольчә итеп! — бик шәп башкаралар.

— Евпаториялылар бик оста эшләгәннәр шул. Әйдә, планыңны сөйләп бир, Михаил Андреевич, — дидем мин.

Планны бөтен яклап уйладык, безгә бары тик бер радист табасы да фронт штабының ризалыгын гына аласы калды.

Мин Северский янына бардым, җибәрәсе хәбәрләрне тиз-тиз генә шифр теленә салып, радио буенча штабка, маршал Буденныйга тапшырдык.

Аннан җавап бик кыска булды — эшкә керешегез, авиация җибәрербез! — диделәр.

...Пакгауз чормасында тузан исе, тычкан исе, бурсыган ашлык исе аңкып тора. Урталыктагы ашлык киптерү миченең морҗасы ышыгына, рациясен сырмасы белән каплап, яшь кенә радист егет яткан. Иван Иванович Суполкин калай түбәнең канаты астындагы кысан почмакка кереп урнашкан: тимер юл араларына сибелгән кечкенә генә сигнал утларын күзәтеп ята. Станциядән арырак, караңгылык томаны эчендә, утларын томалаган шәһәр барлыгы сизелә, якындарак водокачка шәүләсенә охшаган бер нәрсә беленеп тора.

Тышкы баскыч авызында Дуся, автоматын таза ботлары өстенә куеп, көнбагыш «чиртеп» утыра.

Кешесез калган бу зур буш бинада чикерткәләр чырылдаша, талгын гына исеп торган җилдә купкан түбә калае кыштырдый. Партизаннар килеп яшеренгән бу пакгауздан тышта исә фронт якынындагы тимер юл станциясенә хас тынычсыз тормыш дәвам итә: әле маневрдагы паровоз кычкыртып куя, әле машина йөртүчеләр сигнал

бирә, кайдадыр солдатларның вагоннан ниндидер авыр әйберләр бушатканы ишетелә. Көнбатыш якта тоташ стена сыман булып җәелгән ут шәүләсе балкый һәм ут-ялкын эчендә кайнаган фронтның куәтле сулышы ишетелгәли.

Менә кемдер пакгаузга таба килә. Дуся автоматын кысыбрак тота, бөтен гәүдәсе белән алга таба иелә төшеп, караңгыга текәлә:

— Тома, синме бу?

— Мин, мин, — дип, сулышы капкан румын баскычтан күтәрелә.

Томаның берничә сәгать буе күзәтеп йөрү нәтиҗәсендә ниләр күргәнлеген җыйнаулашып аңлаша торгач, шактый нәрсә ачыклана. Байтак нәрсәләр күргән ул... Станциядә туп, снаряд, солдатлар төягән эшелоннар тора, ди. Биредә Севастополь янында сугышучы немец гаскәрләре өчен китерелгән йөкләрне бушата торган төп пункт икән — поездлар фронтка якын ук бармый. Әлбәттә, зенит пушкалары җитәрлек, шулай да артык күп түгел, өстәвенә, ул пушкалар ачык җирдә торалар икән.

Радист егет бу мәгълүматларны туп-туры Төньяк Кавказ фронтының хәрби һава көчләре штабына «суга».

Партизаннар хәлиткеч минутны көтә башлыйлар. Дуся, Иван янына килеп, киеренкелектән каткан бармакларын сугышчан иптәшенең дәү учына сала, тынып кала. Тома исә, бу хәлне күреп, көнләшүдән:

— Минем куллар — кипяток, Дуся, — дигән була.

— Карале, безнең янга кил, — дип чакыра аны Дуся, бәләкәй румынны үз янына сыендыра.



...— Самолетлар юлга чыккан, ун минуттан безнең өстә булачаклар, — дип хәбәр итә радист егет.

Иван Иванович:

— Таралышыгыз, бер-берегездән ераграк китегез, — дип команда бирә.

Көнчыгыш яктан көчәя барган самолет гүләүләре ишетелә башлый, якында паровоз кычкыртып куя. Менә моторлар тавышы бөтен тирә-юньне баса.

Бомбалар шартлавыннан пакгауз тетрәнеп куеп, беркадәр җиргә иңә.

— Иван, куркам! — дип, Дуся кычкыра да аның янына йөгерә.

— Әй, җүләр! — дип ачуланып ала аны Иван һәм гомерендә беренче тапкыр бомбежкага эләккән батыр партизанны үзенә сыендыра.

Пакгауз түбәсенә дөңгер-дөңгер итеп нәрсәләрдер килеп төшә, түбә калайлары тетрәп-тетрәп китә.

Бинадан берничә метр гына читтәрәк дөрләп ут кабына, тирәюнь көндезге кебек яктырып китә.

Снаряд төягән эшелон яна икән анда, пакгаузның бер почмагы да җимерелеп төшкән.

Самолетлар киткәч тә әле һаман гөрс-гөрс снарядлар шартлый, немецлар, куркудан, күрәсең, һаман зениткалардан аталар.

Төтен эчендә, шартлап торган снарядлар янында таң аттыралар. Иртәнге сәгать дүрттә Хәрби Һава Көчләре штабының самолетларны юнәлтү пункты белән бәйләнешкә керәләр: аннан бомбага тотуның нәтиҗәләре хакында төгәл мәгълүмат бирүне сорыйлар.

Төтен таралып беткәч, тирә-юнь ап-ачык күренә башлый. Әнә ниндидер бер склад янып ята, станциядә җан әсәре дә калмаган кебек. Водокачка бер якка янтайган, тимер юлда ташлар актары-

лып беткән, вагоннар ауган-түнгән, янган-көйгән. Симферопольгә бара торган юлны бүлеп, бер паровоз линиягә аркылы килеп төшкән.

Тоташ хәрабәгә әйләнгән станциягә, сиреналарын чинатып, санитар машиналар чабышып килә, — румыннар булса кирәк. Санитарлар, һавага карана-карана, вагоннардан яралыларны җыялар.

Ташлары актарылган платформаларда тыз-быз килеп тимер юлчылар йөгерешә.

Ул арада станциягә бер-бер артлы йөк машиналары агыла башлый. Бомбалар актарып бетергән, төтен, көек исе таратып яткан станция җирендә немец һәм румын саперлары күренә. Ашыгыч рәвештә станцияне төзәтү эшенә керешәләр. Кич җиткәндә инде юлларны җимерек вагоннардан арчып бетерәләр. Беренче маневр паровозы үтеп китә.

Фронт безнең партизаннарга шул урыннарында калырга, иртәгә кичкә хәтле шунда торырга куша.

Тома, өс-башындагы тузаннарын каккалап, эре генә кыяфәт белән төзәтенгән итенә дә, иптәшләре белән саубуллашып, разведкага китә.

Тимер юлда көн озын кәйләләр тукылдый, сварка аппаратлары ышылдап тора. Каяндыр бик зур кран китертеп, юлга аркылы ауган паровозны күтәртәләр.

— Эт җаннар! Моторлары күп шул, күрәсеңме ничек бик тиз рәткә китерәләр,— ди Иван Иванович, ачуыннан төкеренеп.

— Эшли беләләр.., — ди Дуся.

— Күрсәтербез әле без аларга, — ди Иван Иванович.

Көн бик озак уза, Тома Апостол да һаман кайтмый. Дуся борчыла башлый.

— Эзләп килим, — ди ул.

Иван, аның белгеннән тотып:

— Бәлки, үзе дә кайтыр, — ди.

— Иван, син минем курыкмаганымны беләсең бит инде, баш түбәмдә хәзер бомба явып тормый, мондый гына җирдә мин — судагы балык кебек. Беренче генә йөрүем түгел. Белешеп кайтырга кирәк. Әнә анда кетәләр, — ди Дуся, радист егеткә ишарәләп.

— Бар алайса, — дип, Иван Иванович риза була.

Дуся чыгып китә. Вакыт уза да уза, Иван һәрбер кыштырдаган тавышка борчылып колак сала.

Төн җитә. Ниһаять, аяк тавышы ишетелә.

— Дуся, синме бу? — дип Иван баскычка ташлана.

— Тома кайтты, — ди румын.

— Кайда йөрдең син шул хәтле озак?! Дусяны күрмәдеңме?

— Ой, Ивани... Ник җибәрдең, ай-ай! Бер сольдат, ике сольдат, күп сольдат... — дип сөйләп китә Тома.

Ул үзе патрульләргә килеп капкан икән. Аны комендатурага алып киткәннәр, кем син, каян киләсең, нигә ротаңнан аерылдың? — дип сорау ала башлаганнар. Тома күзен дә йоммый алдаша, бер-ике мәзәк тә сөйләп ала. Шуннан соң аны эшкә кушалар, аннары ашаталар да тизрәк үзеңнекеләр янына кайт, дип чыгарып җибәрәләр.

Тома безнең самолетларның төнге һөҗүме нәтиҗәсендә станциядә нәрсәләр җимерелгәнлеген сөйләп бирә, немецлар инде станциядә күп нәрсә эшләп тә өлгергәннәр, явызлар, ди.

Олы җиргә безнекеләрдән яңа радиограмма китә. Фронт боларга төнге сәгать унбердә, пакгауз чормасыннан төшеп, отрядка кайтып китәргә куша.

Ә Дуся һаман юк та юк. Иван Иванович тып-тын гына утыра бирә.

— Кузгалырга вакыт, — ди радист егет. Ул инде үз эшен эшләгән, мондый хәтәр урыннан тизрәк ычкынасы килә аның. — Безнекеләр моны көл итәчәк бит, пакгаузның тузаннары гына очачак. Нигә һаман бүкән шикелле селкенми утырабыз? Барыбызны да харап иттермәкче буласыңмы?! — ди ул Иван Ивановичка.

— Җитәрсәнә! — дип кычкыра Иван Иванович.

— Марш кирәк, марш... Македонский көтә, — дип, Тома аны кулыннан тартып торгыза.

— Их, Дуся, Дуся... — дип кенә әйтә ала Иван Иванович.

Ике сәгать утыз минутта безнекеләр станцияне тагын бомбага тоталар.

...Дусяның соңгы язмышы байтак еллар узганнан соң гына билгеле булды.

Ул чормадан төшә дә, җайлы вакытны туры китереп, платформага чыга — өстендә юка гына кофта, зәңгәр юбка, аякларында тәбәнәк үкчәле туфли. Җимерек станция турысыннан узгач, сакланып кына карана-карана, мастерскойларга таба китә.

Шул вакыт бер читтән:

— Һальт! — дип кычкыралар.

Дуся йөгерә башлый.

Тагын: «Һальт!»

Вышт-вышт итеп пулялар сызгырып үтә.

Дуся, аягы яраланган хәлдә, рельслар аркылы йөгерә... Арттан тагы аталар, тагын бер пуля аның кулбашын пешереп уза. Дуся йөгерә-йөгерә биек көнбагыш басуы эченә барып керә, яраларыннан кан аккан хәлдә, шуышып китә... Төн уртасы җиткәнче шуыша ул, аннары хәлдән таеп, бите белән җиргә каплана... Яңадан аңына килгәч, башын калкытып, йөзен Севастополь ягына таба бора да каты итеп:

— Иптәшләр! — дип кычкыра, ыңгыраша башлый.

Шул тирәдән генә куркынган бер хатын-кыз тавышы:

— Кем ул? — дип эндәшә. Дуся тавыш килгән якка борылып карый. Аннары, терсәкләре белән җиргә таянып, җирдән кузгала башлый... Менә ул торып баса, кофта изүен аерып җибәрә дә бер адым алга атлый...

— Иптәш, сез яралангансыз бит, — дип, әлеге хатын аның янына йөгереп килә.

Дуся тагын бер-ике адым атлый да җансыз хәлдә гөрселдәп җиргә ява...

## «Тарау»

1942 елның дүртенче июлендә Кырым ярыматавында гадәттә булмаган гаҗәеп бер тынлык урнашты...

Көнбатыш яктагы сугыш гөрелтесенә без инде ике йөз илле көн буена күнегеп, ияләшеп беткән идек, бу юлы әлеге тынлык вакытлыча гынадыр дип фронт тарафына колак салып тыңлап тордык. Ләкин... тынлык һаман дәвам итте. Ара-тирә генә автоматтан яисә пулеметтан тырррт-тырррт иттереп аткан тавыш ишетелә дә, ул да тынып кала иде.

Героик Севастополь оборонасы һәм аның нәтиҗәләре турындагы Информбюро хәбәрләрен без авыр бер тынлыкка калып тыңлап тор-

дык, бу хәтәр хәбәргә йөрәге түзмичә, кайберләребез хәтта елап та алды.

Шәһәрне саклаучы морякларның исән калганнары, берничәшәр кешелек төркемнәргә оешып, дошман киртәләре аша безнең якка чыктылар.

Без алар белән төнлә учак янында таныштык. Араларыннан берсе әкрен генә болай дип җырлап та алды:

Раскинулось Черное море,
Лишь волны бушуют вдали, —
Огромно народное горе,—
Враги в Севостополь вошли...

Тынлык, тынлык. Моңарчы безгә өметле хәбәрләр ишеттереп торган кечкенә радиоалгычка борчылып, кайгырып күз салабыз, чөнки хәзер немец танклары Ростовка таба җир җимереп баралар.

Минем дә арыган йөрәк түзмәде. Кырым урманының баш врачы Полина Васильевна Михайленко, мине мәҗбүр итеп диярлек, отрядларны Георгий Северский командалыгына тапшырттырды һәм үземне Бакчасарай отрядының санитар землянкасына салды.

Македонский миңа бик илтифат күрсәтә, минем белән ипләпҗайлап кына сөйләшә. Севастопольнең дошман кулына бирелүен Михаил Андреевич, әлбәттә, бик авыр кичерә. Бервакыт мин аның ялгызы гына бүрәнә өстендә күзләрен тутырып көнбатыш якка таба карап утырганын күрдем. Ул тарафта бит тугыз ай буена сугыш тынмады, ул тавышлар безгә: «Севастополь исән!» дип әйтеп тора иде. Ә хәзер, кемнәрнеңдер калган гомерен санаган кебек, бу тирәдә бары тик күкеләр генә моңаеп кычкыра. Михаил Андреевичның күзләрендә шул кадәр дә өмет-сагыш — менә хәзер үк фронт авазлары ишетелә башлар да Македонский бөтен урман эчен яңгыратып: «Севастополь исән, дошманга бирешми әле!» — дип кычкырып җибәрер төсле иде.

Кырымның урманнарында да, авылларында да тынлык, дошман кулына эләккән Севастополь дә тынып калган. Штурм көннәрендә янып бетмәгән нәрсәләр генә пыскып ята.

Разведка мәгълүматларына караганда, мондый тынлыкка фашистлар да аптырап калганнар. Алар туктаусыз Севастопольгә ябырылдылар һәм бу каланың диварлары янында фон-Манштейнның өч йөз меңлек сайланма гаскәрен кырдырдылар. Мондый җиңү җиңелүдән дә яман, әлбәттә.

Немецларның үлеләрне күму командалары көн-төн туктаусыз эшләп тора. Йөзләгән самолет Кырым аэродромнарына тезеп куелган цинк табутларны Германиягә ташый.

Полк һәм дивизияләрне ашыгыч рәвештә тулыландыралар, коралландыралар.

Ә шуннан соң нәрсә? Дошманның эчкәрге тылында калган без, партизаннар белән, нишләргә уйлыйлар алар? Әлбәттә, Гитлер хәзер Кырымда зур армия тотмаячак, аны башка фронтларга җибәрәчәк. Бу армияне моннан тиз алыр микән соң ул? Бәлки, башта безнең бөтен урманны буйдан-буйга «тарап», «сөреп» чыгарлар, Таврия урманнарындагы партизаннар хәрәкәтен тагын бер тапкыр бетерергә тырышып карарлар.

Манштейн безгә каршы кыш буе көрәшеп тә, уңышка ирешә алмавы өчен үч кайтармый калмаячак, әлбәттә.

Тик шунысын төгәл белеп торырга кирәк: җәза отрядлары урман һәм тауларга кайчан, нинди көч белән, нинди оператив планнар белән киләчәкләр?

Командующиебез Георгий Северский иң яхшы разведчикларны эшкә кушты.

Яшь врач Николай Осипович Эльяшев партизаннарның яшерен бер разведчигы итеп Симферопольдә калдырылган иде. Ул немецча яхшы гына сөйләшә, ә Севастополь оборонасы чорында румынча да өйрәнде. Үзе ул музыкант та, матур гына тавышлы, сөйкемле, ачык йөзле егет — кешеләр белән яхшы сөйләшә, аралаша белә.

Ул немецлар басып алган Симферопольдә яши. Сугышка хәтле гади бер эшче егет булган, Совет заманында укып югары белем алган Эльяшевка танышлары, хәтта якыннары да дошманга сатылган бер кеше итеп карыйлар.

Эльяшев бик шәп хирург, Кырым якларын яхшы белүче, Европа культурасын үзләштергән, рус җанлы кеше буларак (офицерлар компаниясендә ул теләсә нинди артистның да борынына чиртерлек итеп җырлый) немецларның ышанычын казана. Кирәк булса, ул рус сувенирларын да табып бирә, кәеф ача торган урыннарны белә, үзе һәр вакыт шат күңелле, тапкыр сүзле. Искиткеч карьерага ирешә: Кырымда хәрәкәт итә торган румын берләшмәләрендәге бөтен санитария службасының консультанты, зур бер хәрби госпитальдә лаборатория башлыгы ул.

Бу соклангыч рус докторының кулында урмандагыларга, Совет властена ярдәм итә торган, бик оста оештырылган яшерен разведка «чылбыры» булса да, бер гестапочы да, румын сигуранцасының бер контрразведчигы да аннан шикләнә алмый.

Менә Северский кулына төгәл мәгълүматлар килеп керде: зур «тарау» дигәннәре 16 июльдә иртән башланачак. Безне — Северский командалыгындагы сигез йөз партизанны — юк итәргә тулысы белән 18 нче пехота дивизиясе, румыннарның 1 нче тау укчылары дивизиясе һәм бик күп полиция отрядлары киләчәк икән.

Әллә ничә мең кешелек бу көчкә ничек каршы торырга?

Ни эшләргә, ни чара кылырга? Безнең отрядлар урнашкан бөтен урман өстенә шушы мәсьәлә килеп төште. Аны Георгий Северский, комиссары Василий Никаноров, отряд командирлары Македонский, Зинченко, Макаров, Ермаков, Чуссилар хәл итәргә тиеш...

Эльяшевтан тагын бер мөһим хәбәр бар: һөҗүмне бик кызу тотарга уйлыйлар, максатлары: партизан отрядларын, камап алып, штурмлаучы полклар көче белән заповедниктан кысрыклап чыгару һәм Хейролан сыртлыгына китереп терәп, шунда кырып бетерү икән.

Менә командирлар белән комиссарлар Пескура елгасы буендагы аланга җыелганнар. Як-якта яссы ябалдашлы биек нарат агачлары. Көн мунча эче кебек эссе, бөркү. Бу оператив җыелышка килүчеләр туктаусыз тәмәке тарталар, бер читтәрәк бер-берсенә сүзсез генә карашып торган Северский белән Македонскийга күз салгалап алалар. Боларның әле төгәл бер карарга килмәгәнлекләре сизелеп тора.

Георгий Леонидович Северский — чик буе гаскәрләрендә кадровый командир булып хезмәт иткән кеше. Миңа аның белән күптән, 1932 елда, Дагстанда чакта ук танышырга туры килгән иде. Ул вакытта мин тау укчылары полкында кече командирлыкка укыйм, ә Северский, срогын тутырганнан соң, безнең күршедәге пограничниклар дивизионында хезмәт итә иде. Безне гарнизон клубының сәхнәсе очраштырды. Икебез дә «артистлыкка» язылып, репетициягә йөри башлаган идек.

Тәнәфестә Северский тизрәк буфетка йөгерә — аның кесәсендә һәрвакыт акчасы була, ә миңа авыз сулары чыгарып кына торырга туры килгәли иде. Бер көнне ул миңа: «Әйдә, аша!» — дип җилкәмә төртте. Француз булкасы белән чәй колбасасы — минем өчен

төштә генә күрә торган тансык азык булды. Полкта күбрәк киптерелгән Каспий балыгы гына эләгә иде.

Еллар үтеп, мин менә партизаннар командиры булып киттем. Минем күз хәтере ярыйсы ук яхшы икән. Бервакыт Югары Аппалах урман хуҗалыгына баргач, күземә озын буйлы, бик ыспай гәүдәле бер кеше чалынды. Күрүгә үк танып алып:

— Булкаларың өчен рәхмәт! — дип кычкырдым.

Северский миңа әйләнеп карады да гаҗәпләнеп:

— Дагстан, Буйнак, менә бит син, ә! — диде.

Аның үз-үзен беркадәр артистларча тотуы монда, урманда да сизелә иде. Юмор тойгысын югалтмыйча, ниндидер дәрт-гайрәт белән бирә ул командаларны.

Иң яраткан кешесе — Македонский. Басман-тауга бик күп юлсукмаклар салынган, бер уйлаганда анда качарлык-сыенырлык урын да юк, ә менә Македонский зур бер партизан отрядын ике йөз илле көн буена шул тау ышыгында качырып яши. Ничек эшли алган ул аны?

— Маневрда хикмәт,— ди Михаил Андреевич елмаеп.

Менә хәзер дә, бик җаваплы карар кабул итәр алдыннан, Георгий Леонидович аңардан ничек итеп дошманның борын төбендә үк йөри алуларының хикмәтен төпченеп сораша.

Северский, Македонский янында китеп, бер башы инеш өстенә чыгып торган черек бүрәнәгә барып утырды. Яр астына вак таш кисәкләре ыргыткалый-ыргыткалый, тагы уйланырга кереште.

Ә тирә-як тып-тын, ара-тирә карт нарат башлары гына ышылдап куя.

Северский бүрәнә өстеннән капыл гына торды да ике сүз белән:

— Вихманны китерегез! — диде. Янына Вихман килгәч: — Фашистларның махсус батальоны кайда хәзер? — дип сорады.

— Югары Аппалахта инде, — диде тегесе.

Бөтен кешегә билгеле: җәза отрядларының беренче дулкыны Севастополь урманнарын үтәли «тарап», «сөреп» чыккан, җир өстендәге һәрбер «җыерчык»ны капшап узганнар, җәйләүдәге сыртлыкларны танклар тапаган. Батальон белән батальон тоташып диярлек барганнар, роталар янәшәсендә тау кәҗәсе үтәрлек тә ара калмаган.

Фашист батальоннары җәйләүдән алып Симферополь — Бакчасарай автомагистраленә хәтле, шул рәвешчә, «сөреп» узалар, таудагы һәр ярыкны тикшерәләр, тау тишекләре авызына гранаталар ташлыйлар. Карательләрнең беренче линиясе артыннан, ике километр чамасында, икенче линия килә, аннары өченчесе.

Шулар арасында махсус ялтерен батальон хәрәкәт итә. Аның бурычы Северскийның штабын, радистларны, барлык служба башлыкларын пленга алырга тиеш.

Северский, кешеләрне үз янына чакырып, кулын изәде: командирлар һәм комиссарлар якын килеп, Северский белән Вихманны чолгап алдылар.

Георгий Леонидович һәр сүзен өзеп-өзеп:

— Мин карар кабул иттем! Хәзер үк Хейролан сыртлыгына марш башларга! — диде.

— Анда безне эсэсчылар көтеп тора ич! — диде комиссар Никаноров сәерсенеп.

— Көтә бирсеннәр. Без анда ук барып җитмибез, чак кына җитми калабыз. Фашистларның күләгәсе булып басабыз... Үз күләгәңне үзең таптый алмыйсың бит. Беренче булып Македонский отряды атлый, аннары Симферопольныкы... Отрядларыгызга таралышыгыз, план турында ләм-мим. Вихман монда кала.

Леонид Вихманны тәвәккәл, аек акыллы булуы өчен Северский бик ярата иде. Менә хәзер язмышың кыл өстендә торган бер вакытта бу ышаныч тагы да кирәк. Бәлки, шуңадыр, командир рәсмилекне бөтенләй онытып, әкрен генә:

— Леня, дускай... — диде. — Сине морякларың белән монда калдырам. Махсус батальонны Севастопольчә каршы алырсың. Аңладыңмы?

— Так точно, Георгий Леонидович.

— Үзең белгәнчә тәвәккәлләрөхсәт итәм! Менә шулай, дускай, — дип, Северский лейтенантны туганнарча якын итеп кочаклап үпте. — Сиңа ышанам, Леня.

...Тып-тын урман эченнән, аякларын сакланып кына баса-баса, йөзләгән партизан атлый. Аяк киемнәрен, котелокларны — гомумән шалтырап, шакылдап тавыш чыгарырдай бөтен нәрсәне парашют кисәкләре белән чолгаганнар...

Ми кайнарлык эссе, бөркү. Урман сугышчылары җайга гына һаман атлыйлар, күзләргә әче тир тула. Төп колоннаның як-ягына дозорлар — иң батыр, иң тәҗрибәле, корыч нервалы, соңгы патронын үзенә ата алырдай тәвәккәл егетләр куелган.

Сукмак әкренләп-әкренләп Аспортка — элекке турбазаның янган кисәүләре генә калган бер аланга төшә. Бу аланны урталай ярып юл уза. Аланнан ары — урман, урманнан соң — Хейролан сыртлыгы. Анда фашистларның яшерен ут сызыгы. Алар анда партизаннарны көтә.

Северский кулын күтәрүгә, барысы туктап, тынып калдылар.

Тып-тын, шылт иткән тавыш та юк!

Менә шул тынлыкка әкренләп чит авазлар кушыла башлый. Алар якынлашып киләләр. Кыштырдаган, шаулаган тавышлар арта, көчәя бара — карательләрнең беренче сафы килә.

Кул сәгатенең текелдәве йөрәк дөпелдәве белән кушыла.

Хәзер, шушы мизгелдә үк, Аспорт аланыннан җил кебек омтылып узып китәргә кирәк.

Өлгерербезме?

Северский, автоматын атарга әзер тотып, нык адымнар белән аланга төште, аның янында комиссар Никаноров белән автоматчылар группасы. Аннары аланга Македонский чыкты да сабыр гына борылып, кул изәде... Һәм бөтен партизан халкы, тавыш-тын чыгармыйча, бу хәтәр аланны узып, аргы урманга барып керде.

Партизаннардан соң нәкъ биш минуттан алан кырыенда немецларның мотоцикллы разведчиклары күренде. Алар як-якка карандылар да күккә берничә ракета чөйделәр.

Аланга, диңгездәй шаулап, солдат массасы килеп тулды. Утыз градуслы эсседә немецлар тәмам пешкәннәр. Башларыннан пилоткаларын салып ташладылар. Кайберләре хәтта чишенеп ялан тән калды.

Немецлар, урманга таба төзәп, тирә-якларына пулеметлар урнаштырдылар да ялга туктадылар.

Текә тауларда йөреп, эсседә аңгыраеп хәлдән тайган бу карательләрне кырып салырга бик җайлы вакыт та югыйсә — ярамый шул! Атып кына кара — ун меңләгән солдат һәм офицердан торган бу карательләр машинасы шундук хәрәкәткә килеп эшкә керешәчәк һәм бер генә партизанның да башы исән калмавы бар...

Беренче колонна карательләре ике сәгать чамасы ял иттеләр, кояштан ышыклану өчен урман эченәрәк керделәр, партизан отрядлары да, алардан бер километр эчтәрәк, ике сәгать чамасы посып

ятты, тыннарын да чыгармады. Мондый түземлелекнең бик каты тәртип саклаганда гына булуы мөмкин.

Көтмәгәндә Пескурада ут давылы кузгалды.

Вихман микән бу?

Шорт-шорт гранаталар шартлый, автоматлар тырылдый башлады, биш-алты минуттан соң дөп иткән тавыш ишетелде, тагын дөп итте, тагын...

— Безнең миналармы әллә? — дип, комиссар Северскийга карады.

— Молодец, Леня, кирәкләрен бирә... — диде Георгий Леонидович. — Барыбызга да әзерләнергә! — дип шыпырт тавыш белән генә команда бирде.

Безнең отрядлар артыннан... немецлар да кузгалдылар.

Партизаннар тауга менә бара, алар артыннан карательләр килә. Тагын ике мең метр менгәннән соң — Хейролан сыртлыгы. Партизаннар артыннан килүче немецлар Хейролан аръягындагылар белән ракета чөешәләр.

Партизаннар бик борынгы оборона сызыгына — эре-эре шома таш өемнәренә килеп җиттеләр. Сыртлык буйлап бик тигез итеп өйгән булганнар аны, очлары төньяк-көнчыгышка таба борып салынган. Әллә ничә гасыр элек скифлармы, тавр лармы Хейролан сыртлыгы аръягында күкселләнеп күренгән иркен Әлмин үзәнлегенә үтәргә маташучыларның юлларына аркылы төшкәннәр, күрәсең.

Туктарга!

Северский хәрәкәтне туктатты, тынлык саклап ташлар ышыгына ятарга боерык бирде. Һәркем ялан кул белән диярлек җирне казыштырып — солдат күрәге бик аз — үзенә ятарга җайлырак урын әзерләде.

Бәлки гомернең соңгы чиге инде шушындадыр?!

Немец разведчиклары өч йөз метр чамасы якын килеп, партизаннар эз калдырып узган сукмакларны карыйлар — аларны инде күздән ычкындыру юк.

Нәкъ шул вакытны Пескура ягында тагын гөрселдәгән каты шартлау авазлары ишетелде, аннары автоматлар тырылдады.

Кинәт һавага ракеталар очты, немец разведчиклары башта, нишләргә белмичә, аптырабрак калдылар, аннары барысы берьюлы Аспортка таба төшеп киттеләр.

Аңлашылмый бу!

Соңыннан ачыкланды ул хәл: карательләр, партизаннар безне алдадылар, дип уйлаганнар. Эздән яздыру өчен кечерәк бер төркемне Хейролан ягына җибәргәннәр, ә төп массалары ниндидер хикмәтле юллар белән эзәрлекләүдән котылып, Пескурада торып калган, дигән нәтиҗә ясаганнар.

Кояш Аппалах сыртлыгы өстендә елтырап алды да тиз арада аның артына төшеп күмелде. Урман эче дә караңгылыкка чума барды.

Көньякка хас төсмерләре белән төн җитте — күктә эре-эре йолдызлар җемелди, тарлавыклар эче дөм-караңгы, тау битләре чакчак кына яктырыбрак беленеп тора.

Урман эче кинәт берничә урында яктырып китте — немецлар учак яга башладылар. Алар тукталган төштә урман өстендә һавага аллы гөлле ракеталар атылып тора, — җәзачы немецлар, бер генә минут та утсыз торудан куркып, туктаусыз ракета чөяләр. Кайдадыр Чучель үткеллеге ягында кызыл ут шәүләсе балкып тора — анда, күк исе таратып, урман яна иде.

Хәзер үк немецларның беренче сафы аркылы шыпырт кына үтеп китеп, артларына төшәрлек юл табарга кирәк.

Македонский үзе янына юл табу остасы Дмитрий Кособродскийны чакырып ала.

Дима агай — ул инде шактый олы кеше, без аның үзенә дә шулай дип эндәшәбез — Македонский каршына килеп басты. Юка гәүдәле, кылыч борынлы, сабый балаларныкы шикелле кечкенә генә аякле бер кеше ул.

— Дима агай, хәлне күреп торасың инде.

— Җиңел түгел.

— Башта икәү генә тәвәккәлләсәк, ничек булыр?

— Тәвәккәлләми нишлисең, — ди Дима агай, болай үзара гына хәл-әхвәл сөйләшкән сыман, карабинын иңенә аса. — Әйдә алайса, кузгалыйк, Македонский.

Киттеләр.

Ике тау килеп кысылган төшне чыннан да юкка гына тарлавык дип атамаганнар — шул хәтле тар, өстәвенә сынган-ауган агачлар белән тулган, гүр эче шикелле караңгы, юеш.

Дима агайның күзләре мәче күзе кебек — төнлә дә яхшы күрә. Тарлавыкның як-ягында, бер-берсенә тавыш биреп-эндәшеп, немецлар тора. Әнә шулар уртасыннан үзеңне сиздермичә шыпырт кына үтеп китәр өчен нинди дер тылсым иясе булырга кирәк.

Өч йөз метр чамасы шуышып узгач, кире борылдылар.

Кайтып, Северскийга: «Узарга мөмкин!» — дип доложить иттеләр.

Северский, тавыш-тын чыгармый гына, командирларны җыйды.

— Һәр партизанны кисәтеп әйтеп чыгарга ун минут вакыт бирәм: кем дә кем берәр тавыш чыгара — атып үтереләчәк! — диде ул.

Борыла-сырыла шуышкан озын бер елан сыман, колонна алга үрмәләде. Берәр чыбык кисәге сынудан да куркып, тыннарны кысып, тарлавык төбеннән пластунча ятып шуыштык.

Төн уртасы авышканда сигез йөзләп партизан инде «Конка»га җитте (текә тау тезмәләреннән берсе шулай дип атала иде). Беренче карательләр линиясенең тылы иде бу.

Ярым уяу хәлдә йокладык, урман юлларындагы ат аягы тавышларын да ишетеп яттык.

Әмма бер могҗиза булды инде: карательләрнең беренче дулкыны партизаннарга кагылмыйча үтеп китте.

Алда икенче дулкын тора. Анысы, тавышланып, һавага ракеталар чөя-чөя, Чучель сыртлыгыннан төшеп килә.

Безнең отрядлар яңадан Аспортка төшә. Дикъкатьне бер генә секундка да йомшартмыйбыз. Безнең разведчиклар — иң тәҗрибәле партизаннарның күзләре урман киегеннән дә яхшырак күрә, колаклары тау кәҗәсеннән дә яхшырак ишетә.

Тын да алмыйча тыңлап ятабыз. Бер минуттан румын атлы гаскәренең ике эскадроны узып барганын шәйләдек. Атларын юрттырып Аспорт юлы буйлап үтеп киттеләр. Кайдадыр шушы тирәдә моторлар гөрелди башлады... Северский гаҗәп бер тизлек белән колонннаны яңадан Хейролан ягына күчерде. Урманга кереп кенә җиткән идек — Аспорт аланына фашистларның машиналары килеп тулды. Партизаннар тагын теге борынгы таш өемнәре ышыгына яттылар. Кыскасы, кичәге хәлләр яңадан кабатланды.

Карательләрнең икенче дулкыны хәтәррәк килә иде. Соңгы сугышка хәзерләнә башладык — башка чарабыз юк.

Кояш Чатыр-Даг турысына менеп җитте, партизаннар кесәләрендәге гранаталарны бушаттылар, «партизан артиллериясе»нә запаллар куелды.

Кинәт, җир астыннан калыккан кебек, Леонид Вихман пәйда булды.

— Бик мөһим документлар бар! — дип, моряк, көч-хәл белән сулый-сулый, кыр сумкасын командующийга сузды да шундук җиргә авып, үлгән кебек йокыга да китте.

Тәрҗемәчене чакырып китерделәр. Кыйммәтле кәгазьләр арасыннан заповедникны «тарау» өчен төзелгән оператив карта килеп чыкты. Анда немецларга хас пөхтәлек белән бөтен җәза батальоннарының юлы сызып чыгылган, аларның теге яки бу урынга кайчан барып җитүләре күрсәтелгән иде.

— Тизрәк тәрҗемә ит, — дип ашыктырды командующий.

«16.00. Дүрт йөз уналтынчы батальон, Аспортта туктый, сәгать икедә ял итә».

Әйе, кичә нәкъ шулай булды.

«Аспорт-Бешуй юлын тикшерергә... Атлы гаскәр һәм Тунештаның танк группасы».

Әйе, Аспортта хәзер танклар.

Һөҗүм итүче беренче дулкын турында мондый мәгълүматлар бар: «Беренче колоннада катнаша: 23 нче тау укчылары батальоны, 3 нче тау укчылары батальоны, 14 нче пулемет батальоны, резерв группасы һәм 2 нче тау укчылары батальоны. Һәр батальон операцияне күрсәтелгән схема буенча башкара. Батальоннарның төп хәрәкәтенә эләкми калган җирләр аерым группалар тарафыннан «тарап» чыгыла. Һәр батальонда пулемет батальоныннан бирелгән 35-әр пулеметчы булырга тиеш. Бу пулеметчылар, төп хәрәкәткә параллель рәвештә, группалап хәрәкәт итәләр...»

Кулга төшерелгән кыр сумкасыннан төп приказга карата язылган кушымта да килеп чыкты, анда: икенче колонна Аспорттан ары китмәскә, Хейролан группировкасының тылын сакларга тиеш, диелгән иде.

Менә монысы ярый! Чыннан да шулай микән? Планда шулай диелгән диюен дә, чынлыкта ничек булыр.

Северский тиз генә командирлар киңәшмәсе җыеп, аларны трофей документларның эчтәлеге белән таныштырып чыкты да:

— Ничек уйлыйсыз сез, иптәшләр: карательләрнең икенче дулкыны Аспортны сөреп узармы, юкмы? — дип сорады.

Тугыз айлык көрәш тәҗрибәсе андый хәлнең булмаячагын әйтеп тора иде.

Берләшмә комиссары һичбер икеләнүсез:

— Немецлар алар — педант халык, нәкъ планда язылганча эш итәчәкләр, — диде.

Бу фикер белән командирлар да килешкәч, Северский:

— Алай булгач, шушыннан кузгалмыйбыз! — дип соңгы карарын әйтте.

Хейролан сырты итәгендә газаплы, авыр ике көнне уздырдык. Төнлә салкын үзәккә үтә, көндез кояш әлсерәтә. Кечкенә куаклар ышыгында эссе, бөркү, тамак кибә, эчәсене китерә — ә тирә-якта бер тамчы су юк.

Трофей документларда әйтелгәннәр дөрес булып чыкты. Карательләрнең икенче дулкыны Аспортны сөреп узмады, беренчесе исә, фронт буенча ун километр иңлегенә җәйгән җәтмәсенә бер балык та эләкмәвенә аптырап, күрәсең, тагын ни эшләргә белмичә, туктаган урынында тик тора, чөнки планда әйтелгәннәрнең барысын да эшләгәннәр иде инде алар.

Көтелмәгәндә өченче дулкын да барлыгы беленде. Бу хакта Эльяшев та, башка подпольечылар да безгә хәбәр итмәгәннәр иде.

Бу дулкын — арттан чистартып баручы бер нәрсә сыйфатында — полиция батальоннары һәм румын полкларыннан тора икән.

Бу колонна бик кызу хәрәкәт итеп Аспортка килеп җитте һәм менә хәзер тәмам арып хәлдән тайган партизан отрядлары белән күзгә-күз очрашуы мөмкин иде.

Коточкыч кыен бер хәл килеп туды, аның буласы алдан көтелмәгән, шуңа күрә дә бик куркыныч, бик хәтәр иде ул.

— Немецлар кай төштә? — дип сорады Северский.

Иван Иванович белән Тома тиз генә разведкага китеп барды — Дуся үлгәннән соң алар гел бергә йөри торган булдылар.

Икесе дә бик тәвәккәл егетләр — кыргый кабан үтә алмаслык җирдән дә үтә алырлар. Бер сәгатьтән, еш-еш сулап, Иван Иванович Северский янына шуышып килеп җитте.

— Фрицлар заповедниктан китеп баралар, валлаһи.

Симферополь отряды разведкасы да әйләнеп кайтты. Аның командиры Христофор Чусси:

— Немец батальоннары Саблы янында, Симферопольгә таба китеп баралар, — дип хәбәр итте.

Ә өченче колонна Аспортны аркылы чыкты.

Безнең өчен бердәнбер юл — бу колоннаны өзеп узып китү.

Менә иң алдан Македонский отряды кузгалды. Беркадәр фронт сызыгына җәелебрәк, бакчасарайлылар Аспортка, полицайлар һәм румыннарның каршысына баралар.

Бакчасарай отряды артыннан Митрофан Зинченко командалыгындагы Севастополь отряды, алардан соң Симферопольныкы кузгалды...

Менә румыннарның сөйләшүләре дә ишетелә инде.

Партизаннар румын ротасы белән йөзгә-йөз дигәндәй килеп очраштылар.

Каршыларына көтмәгәндә партизаннар килеп чыгуына Антонескуның «гайрәтле» гаскәре шул хәтле шаккатып калды — яшен суккандай булды.

Македонский, Томаның яктыгына төртеп: «Исәнләш!» — диде.

Румыннар колоннасыннан офицер чыгып, Апостолның сәламенә каршы җавап кайтарды.

Румыннар аңгыраеп калгандай тын гына тора бирделәр.

— Шушы ун минут эчендә сезгә беркая да кузгалмаска, урыныгызда гына торырга кушты командир, — диде Тома.

Ниһаять, офицер телгә килде:

— Бу хәл турында сүз таратмавыгызны үтенәм. Без кузгалмаска риза.

— Без сүз таратмабыз.

Шулай итеп, һәркайсыбыз үз юлыбыз белән китеп барды.

1942 елның унтугызынчы июнендә немец командармы фон-Манштейнның «зур тарау» дигәне әнә шулай уңышсызлык белән бетте. Әмма шулай да Симферопольдә рус телендә чыга торган «Штимме дер Крым» газетасы: «Кырым заповеднигындагы партизан отрядлары юк ителде, аларның калдыкларын урындагы подразделениеләр эзәрлекли», — дип лаф орды.

Ике көн ял иткәннән соң Северский Пескура янындагы аланга отрядларның командирлары белән комиссарларын җыеп, сугышчан заданиеләр бирде:

— Митрофан Зинченко, Байдар үзәнлегендә тавышыбызны катырак ишеттерү максаты белән ике сугышчан группа төзергә. Македонский Әлмин һәм Белбек үзәннәрендә операцияләр җәеп җибәрә. Христофор Чусси Алушта үткелендә хәрәкәт итә. Евпатория отряды командиры Даниил Ермаков...

Шулай итеп, сугышчан группалар яңадан эшкә кереште.

Х. ЯХИН тәрҗемәсе.

## Мансур Гаяз

*Шагыйрь Мансур Гаязның иҗаты Бөек Ватан сугышы елларында бигрәк тә активлаша. Аның фронт газеталарында басылган шигырьләрен сугышчылар яратып укыйлар.*

*Егерме алты яшьлек солдат 1943 елның 19 ноябрендә Белоруссиянең Витебск өлкәсендә барган каты сугышта һәлак була.*

### Оясыз калган сыерчык

Җем-җем килә тамчы бөртеге,
Уйсу җиргә күлләр җыйнала.
Эзләп кайтты кошлар төркеме
Сагындырып көткән ояга.
Тик тапмады кошчык оясын,
Таныш кеше дә юк, өйләр дә;
Һәм тотынды аннан, моңаеп,
Үз телендә нидер сөйләргә.
Дошман килде, кошкай, бу илгә,
Бар нәрсәне өеп яндырды;
Сабыйларның яшен агызып,
Кешеләрне өйсез калдырды.
Авыл булган монда кайчандыр,
Кеше дә юк хәзер, өйләр дә,
Тик, күрәсең, көйгән агачлар
Элек бакча булган җирләрдә.
Аһ, кайда соң матур ямьле яз,
Хәтфә кебек яшел болыннар,
Җиргә нурын коеп шат кояш
Тормыш шаулап торган урыннар?..
Оч син моннан, назлы кошчыгым,
Биек таулы Урал ягына,
Җыйнак, матур, җылы оялар
Анда сезне күптән сагына.
Оч син иркен Идел буена,
Мактаулы, киң Казан артына,
Анда булган эшче дусларның
Сәлам әйт син миннән барсына.

Бик күңелле анда, күрерсең,—
Минем туып-үскән урыннар,
Алма үсә торган бакчалар,
Чәчәк үсә торган болыннар·
Мәхәббәтем төшкән кызыма —
Сөйгәнемә сәлам илтерсең.
Рәхәтләнсен кошлар җырына,
Канатлансын күңеле, җилкенсен.
Җиткер аңа бу як хәбәрен,
Авырлыгын сөйлә көрәшнең,
Сагыну белән тулы егетнең
Төшләренә, диген, керәсең.
Пәрдәләрен иплән ачар да
Савытларын гөлнең күчерер,
Көйләр эзләр моң-җыр башларга,
Бәлки мине искә төшерер...
Кит син кошчык, тыныч якларга —
Кайда йөзми дары төтене,
Кайда уйный киек үрдәкләр,
Очып йөри кошлар төркеме.
Оч син шунда, кайда тормыш, ямь,
Һәм чайкала кырда игеннәр,
Кайда үсә баллы клевер,
Кайда чәчәк ата сиреньнәр.
Оч син матур Казан артына,
Анда минем үскән якларым,
Кайда кече сеңелем көн итә
Көтеп миннән сәлам хатларын.

Апрель, 1943

# «ОКОП ДӘФТӘРЕ»ННӘН

*Үзбәкстанда, борынгы Шәһрисябз каласының зиратында гөлләр белән каймаланган фронтовик кабере бар. Ватан сугышында алган яралар нәтиҗәсендә дөньядан бик иртә киткән татар шагыйре Гиз-эль Габид күмелгән анда.*

*Г. Габид (Гиз Лотфый улы Габидуллин) — татар һәм үзбәк укучыларына азмы-күпме билгеле шагыйрь. Аның кайбер шигырьләре «Алар сафта», «Беренче карлыгачлар» исемле җыентыкларда басылды.*

*1968 елның февралендә бу юлларның авторына Шәһрисябз шәһәрендә Г. Габидның тууына 50 ел тулу юбилеенда катнашырга туры килде. Тантана аның үзе укыткан Пушкин исемендәге мәктәп бинасында үтте. Г. Габид белән бергә эшләгән укытучылар шагыйрьнең коллективта зур ихтирам казанган укытучы булуын сөйләделәр.*

*Г. Габид сугышның башыннан ахырына кадәр кулына корал тотып, солдат булып көрәшкән.*

*«...Габид иптәш үзенең шигырьләрендә сугыш чынбарлыгын дөрес итеп чагылдыра, — дип искә ала шагыйрьнең көрәштәше һәм каләмдәш дусты Г. Әпсәләмов, — сугышның авыр, ямьсез, кыен якларына күз йоммый. Шуңа күрә, аның шигырьләрен укыгач, сугыш бик җиңел әйбер, анда бөтен нәрсә ансат бирелә икән, дигән хата фикер тумый. Бу исә безнең поэзия өчен дә, гомумән, әдәбият өчен дә бик мөһим».*

*Г. Габид Ватан сугышы елларында лирик һәм оптимистик хисләр белән сугарылган йөзгә якын әсәр иҗат итеп калдырды.*

*Татарстан китап нәшриятында шагыйрьнең «Окоп дәфтәре» исемендә шигырьләр җыентыгы басып чыгарырга әзерләнә. Анда Г. Габидның фронт газеталарында басылган һәм әлегә кадәр беркайда да дөнья күрмәгән әсәрләре тупланды.*

*Шул җыентыкка керәчәк яңа табылган кайбер шигырьләрне укучыларга тәкъдим итәбез.*

Ә. СИНЕГУЛОВ.



*Рәсемдә: Г. Әпсәләмов (беренче рәттә, уңнан беренче) һәм Гиз-эль Габид (икенче рәттә, сулдан беренче) фронтовик дуслары белән.*

# Гиз-эль Габид

## Үтеп барышлый...

Яудан кайтып, үтеп барыш яуга...
Без тукталдык сезнең шәһәрдә.
Күп торылмас кебек Ярслауда —
Көтә безне ерак сәфәрләр.
Иркәм, сине тәүге күргән кичтән
Биләп алдың минем хыялны,
Син уяткан җылы, якты хисләр
Күкрәгемә инде сыялмый.
Тирән сагыш белән сиңа карыйм,
Канат җилпеп куя өметем.
Әмма саклый микән туар тарих
Безнең өчен уртак бер битен?
Боз кыршавы бүген җирне буган,
Дөнья чумган өшеп кайгыга.
Урамнарда зыкы гыйнвар туган,
Ә күңелдә минем май гына...
Йөрәгемдә чәчәк аткан язның
Эх, исертә мине хуш исе.
Чын күңелдән сиңа рәхмәт, кызый,
Уятуың өчен бу хисне.

## Яз[1]

Күрми калдым бер язны да,
Килсә дә яз ике кат.
Тирәмдә иде сазлык һәм
Гариплэнгән табигать.
Сандугачлар иялэшмиләр
Хәзер бу урманнарга.
Асыл чәчәкләр чәчмиләр
Үләннәр аланнарга.
Күктә йолдызлар сизелми
Калкалар һәм сүнәләр.
Теңкәгә тиеп безелди
Черкиләр һәм пулялар.
Минометлар, авыр туплар
Көне-төне гөрселди.
Була ямансу минутлар —
Мөмкин түгел көрсенми.
Монда кәккүк бердәнбер кош
Сайраучы иртә таңда.
Тик аны да әрнү катыш
Тыңлыйсың анда-санда...

---

[1] Кыскартып басыла.

Нәкъ шулай минем хәтердә
Яз күренеше калган.
Беләм мин — язлар хәзер дә
Ямьлерәк була анда.
Быел тагын чәчәк аткач
Гөлләр, булмам янында.
Тагын карармын көньякка,
Моңсу булган чагымда.
Ай моңнарын түккән кичтә,
Искәндә төньяк җиле,—
Төшер син дә мине искә,
Онытма, дустым, мине.
Кош теледәй хат язып сал,
Ягымлы, җылы итеп.
Озак көтеп алган хаттан
Булмасын күңел китек.
Хатларыңны еш яз, иркәм,
Кушып кайнар хисеңне:
Мин бит йөрәгемдә йөртәм
Синең якты исемне.

## Тыныч Май

Канлы сугыш кырларында
Дошманнарны җиңгән кылычтай,
Җемелди яз нурларында
Сугышчан һәм тәүге тыныч Май.
Күкнең зәңгәрсу әлəмен
Ертмый инде үлем уклары,
һәркайда яшәү аһәңе,
Илнең тыныч төзелеш утлары.
Кысыр җирләр күрә төрән,
Басуларда уҗым яшәрә.
һәр кешедә өмет тирән
Киң колачын җәеп яшәргә.

...Бу иртәне төшебездә
Нәкъ шушылай күрә идек без.
һәм дәртләнеп өнебездә
Атакага керә идек без.
Бердәм басып бара сафлар,
Йөзебездә балкый горурлык.
Тагын кайда шундый саф бар
Йөзләр өчен бирәү торырлык!
Көрәш ярсыган кырларда
Дошманнарны җиңгән кылычтай,
Җемелди язгы нурларда
Сугышчан һәм тәүге тыныч Май!

Чулпан Җәлилова

# АВГУСТ КӨННӘРЕНДӘ БЕРЛИНДА

1974 елның 19 августында, ГДР Язучылары союзының чакыруы буенча, әнием белән Мәскәүдән Берлинга барырга чыктык. Миңа бу истәлекле урыннардан гомеремдә беренче мәртәбә үтәргә туры килде. Поезд тәрәзәсеннән әтием кайчандыр коллыкта йөргән, һәлак булган җирләргә — хәзер кояш нуры астында балкып яткан Польша, ГДР җирләренә карап бару минем күңелемдә тирән сагыш уятты. Мин инде күптән бу якларга омтылдым, инде күптәннән минем әтием соңгы тапкыр баскан ташларга орынасым килә иде.

Еш кына миннән: «Әтиеңне хәтерлисеңме?» — дип сорыйлар. Аны соңгы тапкыр күргәндә, миңа дүрт яшь иде. Шуннан соң әтиемне бик озак еллар буе күзалдыма китердем, көттем, үземнең бала чагым хәтереннән иң күңелле, иң якты көннәребезне берәм-берәм чүпләп алдым. Аның мине ничек циркка алып барганнарын, Казанда вакытта Язучылар союзына эшкә яки опера театрына алып барганнарын, Ялтада диңгез буенда ял иткәндә минем белән ничек әвәрә килүләрен яки Мәскәүдә безнең ишегалдындагы бөтен бала-чагаларны ничек итеп уенчык автомашинада әйләндерүләрен — барысын-барысын минем сабый аңым, ничектер, үземдә саклап калган. Ә бер көнне бигрәк тә ачык хәтерлим. Ул көнне без, таң белән бәйрәмчә киенеп, Казан тирәсенә, әтинең дуслары торган бакчага барырга чыккан идек. Вокзалда әтиемнең кәефе кинәт үзгәреп китте, әнием елый башлады — бу сугышның беренче көне иде. Тагын авыру хәлемдә йокы аралаш әтием белән саубуллашуны, аның ягымлы йөзен һәм минем өчен бөтенләй ят тоелган хәрби киемен томанлы гына хәтерләп калганмын.

Еллар үтте. Сугыш бетте. Әтием... әйләнеп кайтмады. Әниемнең, әтинең туганнары һәм дусларының сөйләгәннәре аша аның образы минем җанымда гел яңара торды. Дөрес, алар үткән саен бала чакта хәтеремдә калганнарны бу сөйләүләрдән, аның шигырьләрен, хатларын укыганнан туган тәэсирләрдән аеру кыенлаша барды.

Әмма болар бөтенесе бергә минем өчен бик тә якын, бик тә кадерле булган кешене йөрәккә якынайта гына төште.

Беренче мәртәбә «Моабит шигырьләре»н укыгач, мин аның ихтыяр көчен, хисләренең тирәнлеген тоеп тетрәнгән идем. Аның рухи газапларын, шигъри васыятьләрен уку миңа коточкыч авыр булган иде. Шул шигырьләр туган якларга алып барган поезд тәгәрмәчләре дөбердәвен тыңлый-тыңлый, хәтеремә таныш юллар килә:

**Төштә миңа нәни кызым килде,**
**Чәчләремне сыйпап тарады.**
**— Ай-һай, әти, озак йөрдең... — диеп,**
**Күзләремә сөеп карады.**

Ул чакта әтиемнең Алман иле турында шигырен укыганнан соң мин, — бәлки яшьлек самимилеге күңел колачын чикләгәндер, — аның фашист төрмәсендә утырган хәлдә дә немецларны Гейне, Маркс, Шиллер, Бетховеннарны мәңге яшәтергә чакыруын аңлый алмаган идем.

**Ишетегез бөек хаклык сүзен,**
**Төрмәләрне безнең ачыгыз!**

Бу минем өчен бик зур сабак — чын мәгънәсендә бөек батырлыкның, аңсыз нәфрәт белән сукырларча беркайчан да эшләнми торган батырлыкның бик зур сабагы булды.

Менә хәзер без аның җәзалап үтерелгән җиренә, шундый шигъри юллар язылган җиргә барабыз. Утыз ел вакыт үткән. Кичке утлары балкыган Берлинның Көнчыгыш вокзалына поезд әкрен генә килеп туктый. Вакыт инде бик соң булса да, безне бик күп кеше каршы алды. Башта без бик күп чәчәкләр, ачык йөзләр һәм җылы карашлардан хәтта каушап калдык. Безне ГДР Язучылар союзыннан, антифашистик комитеттан, Тормоз заводының Муса Җәлил исемендәге бригадасыннан иптәшләр каршылады. Шушы табигый, дусларча якынлык, туганнарча кайгыртучанлык без киткән соңгы көнгәчә күренде һәм сизелде.

Берлинда без бик күп кешеләр белән очраштык. Кайда гына булсак та, Муса Җәлилнең тормышын, иҗатын белгән, аның истәлеген хөрмәт иткән кешеләрне күрергә туры килде: Тормоз заводында Муса Җәлил исемендәге бригада, Берлин язучылары һәм нәширләре, Герман-Совет дуслыгы җәмгыяте һәм антифашистик комитет членнары... Әни белән икәү калгач, без Берлин урамнарын урап бик озак йөрдек. Кулга алынганчы, бәлки әти үзе дә шунда булгандыр, туган ил хакында, безнең хакта җыр көйләп уйлангандыр. Без гаять борчылып һәм дулкынланып 25 нче августны көттек. Моннан 30 ел элек әтиемнең һәм аның көрәштәшләренең башын нәкъ шул көнне кисkәннәр бит...

Иртән сәгать тугызда Германиядәге Совет консулы машинасында без Көнбатыш Берлинга юл алдык. Андагы Плетцензее төрмәсендә җәзалау үткәрелгән. Бер катлы баракта хәзер фашизм коллыгы елларында һәлак булганнар истәлегенә мемориал ачылган. Машина Көнбатыш Берлин урамнары — башка дөнья, башка дәүләт җире буйлап әкрен генә бара. Биредә, Моабит һәм Шпандау «таш капчыгында» Җәлил һәм аның көрәштәшләре утырган. Плетцензеенең кирпеч комплексларына якынлаштык. Төрмә капкасы янына бик күп халык җыелган. Яныбызга Көнбатыш Берлин дуслык җәмгыятеннән, «Фашизм вакытында эзәрлекләнүчеләр» җәмгыятеннән иптәшләр килә. Арада Көнбатыш Берлиндагы поляк, чех, болгар миссиясе вәкилләре дә күп. Чәчәкләр, чәчәкләр... Венок тасмаларында Җәлил батырлыгына соклану сүзләре... Сәгать унда элеккеге төрмә эченә керәбез. Тәбәнәк баракның соры стенасында: «1933—1945 еллардагы Гитлер диктатурасы корбаннарына» дигән язу. Тантаналы һәм кайгылы веноклар шунда куела. Кояшлы якты көн, кызыл чәчәкләр... һәм шыксыз төрмә стенасы.

Кичәне Көнбатыш Берлинда безнең консулыбыз Тищенко ачты. Герман-Совет дуслыгы җәмгыяте вәкиле, Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең каһарманлыгы алдында таң калуын белдереп, бу батырлыкны онытмаска чакырып сөйләде.

Менә йөрәкләрне әрнү һәм курку белән кысылырга мәҗбүр иткән иң авыр минутлар: без баракның эченә керәбез. Шәрә һәм салкын цемент идән. Ярым караңгы, тәбәнәк һәм кысан таш бүлем. Биредә кешеләр башын кискәннәр. Тамакка төер утыра... Барабызның да якыныбыз Мусаның да, аның көрәштәшләренең дә гомере шунда өзелгән. Күңел, ирексездән, аның горур шигъри юлларын кабатлый:

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш язымна.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла.

Әнием белән мин кызыл чәчәкләр веногын шушы кыргый бүлмәнең идәненә куйдык.

Тимер ишекле икенче бүлмә. Шундый ук кысан, шулай ук хәтәр, куркыныч. Унбер татар батырын соңгы тапкыр бергә алып кергәннәр, алар соңгы мәртәбә бәлки шунда саубуллашканнардыр... үзләрен соңгы минуткача батыр тотып, елмаеп!.. 1973 елның сентябрендә биредә чех герое, антифашист Юлиус Фучикның үлүенә 30 ел тулуны да шулай билгеләп үткәннәр.

Плетцензеены үтеп бер квартал киткәч, без Моабит төрмәсе янында туктадык. Аны яңадан төзекләндерелгән диләр, әмма калган ташлары аның күпме кайгы, күпме кыюлык күргән! Җәлилчеләрнең соңгы көннәре турында эзләнүләре белән Леон Небенцаль безнең һәммәбезгә билгеле инде. Тормыш иптәше Ильза белән аның безгә карата кайгыртучанлыгы һәм ягымлылыгы беркайчан да онытылырлык түгел.

Алда әйтелгән заводның Муса Җәлил исемендәге бригадасында без көне буе булдык. Иртән Берлин күленә сәяхәт ясаганнан соң, алар безне үзләренең эшләре, планнары белән таныштырдылар. Әнием белән алар үзләрендә моннан биш ел элек очрашкан иде инде. Хәзер иске дусларча кочак җәеп күрештеләр. Соңыннан заводның музеен карадык. Анда заводның фотодокументлардан торган тарихы, антифашистик көрәш, сугыштан соңгы күтәрелеш һәм соңгы еллардагы уңышлар киң яктыртылган.

Шундый ук әчкерсез очрашуларның берсе Берлин язучылары белән булды. Алар арасында безнең совет укучыларына «Голый среди волков» («Бүреләр арасында шәрә бер кеше») романы буенча яхшы таныш булган Бруно Апиц та бар иде. Ул — фашизмга каршы кыю көрәшүчеләрнең берсе, гитлерчылар концлагереның әлектәге тоткыны.

Берлинда без ГДРның культура министры ярдәмчесе иптәш Хелке белән очраштык һәм Муса Җәлилнең Моабит шигырьләрен немец телендә беренче китап итеп чыгарган нәшрияттә булдык. Баш редактор иптәш Грюнер һәм аның хезмәткәре Кошут Җәлилнең тулырак басмасы әзерләнәчәген әйттеләр.

Ун көнлек сәяхәтебездә без Гарц белән Дрезденда да булырга тиеш идек. Дрезден безне үзенең Цвенгер сарае һәм картиналар галереясе белән генә түгел, барыннан да бигрәк, җәлилчеләргә хөкем карары чыгарылган, аларга суд булган урын буларак та кызыксындырды.

Биредә сугыштан соң элеккеге төрмә бинасы өр-яңадан үзгәртеп корылган һәм политехника институтына бирелгән. Хәзер аның якты, киң залларында йөзләрчә немец студентлары белем ала. Теге куркыныч еллардан төрмәнең эчке өлешендәге ямьсез таш кое гына истәлеккә калдырылган. Биредә кешеләрне күпләп кырганнар. Гильотина урынында — фашизмга каршы көрәштә һәлак булганнарга истәлек язылган зур таш. Таш өстендә — тере чәчәкләр. Бинаның урта бер җирендәге тәбәнәк пьедесталга бронзадан эшләнгән дүрт кеше сыны куелган: алар үлем алдыннан соңгы минутларын кичерәләр, үлемне куркусыз каршылыйлар. Биредә студентлар укуга тантаналы төстә кабул ителә, алар үзләренә бу бәхетнең күпме кан түгеп яулануы турында уйланалар. Институтның партия комитеты члены моның бик зур тәрбия чарасы булуын сөйләде.

Югарыга карасаң, фашистларның җәлилчеләрне хөкем иткән суд залы тәрәзәләре күренә. Алар судта үзләрен кыю тотканнар, Җәлил ялкынлы һәм горур сүзләр әйткән, шуңа да аңа сөйләргә ирек бирмәгәннәр. Кызганычка каршы, ул чакның архивлары юк ителгән яки бомбага тотканда янган булса кирәк. Әмма Дрезден язучылары һәм Германия-Совет дуслыгы җәмгыяте членнары эзләнү алып барачакларын, суд утырышы язмаларын табарга теләүләрен әйттеләр.

Дрездендагы иптәшләр белән очрашу безнең өчен бик истәлекле булды. Барыннан да бигрәк, аларның ярдәмчел булырга әзерлеге, Җәлил иҗаты белән чын күңелдән кызыксынулары куандыра. Очрашуда яшь шагыйрьләр дә, сугыш дәһшәтләрен кичергән сәнгать фәннәре докторы Китарина Шерифус кебекләр дә бар иде. Ул 1944 елның 13 февралендә Америка самолетлары Берлинны коточкыч бомбалаганда шәһәрдә булган.

Гарцта һәм Дрезденда узган дүрт көнлек сәяхәттән соң без тагын Берлинга кайттык һәм менә инде аның белән саубуллашабыз. Ә әйтәсе сүзләребез шул: синең күп катлы яңа комплексларың, яңа кварталларың яңа Германиянең яңаны төзү рухына чын мәгънәсендә тәңгәл. Яңа илеңнең һәр почмагында кешеләрнең үзләре тудырган,

иҗат иткән һәр нәрсәне сакларга, аның кадерен белергә чын мәгънәдә тырышулары күренә һәм сизелә. Без синдәге иске дуслар һәм бу килүдә табышкан яңа дуслар белән хушлашабыз. Бу кайгылы да, авыр да август көннәрендә алар безнең рухны күтәрде. Бик зур, бик тирән рәхмәт аларга!

**Леон Небенцаль,**
Германия Демократик
Республикасы журналисты.

# МУСА ҖӘЛИЛ ЭЗЛӘРЕННӘН

Совет әдәбиятының халык белән бердәмлеге Бөек Ватан сугышы елларында бигрәк тә ачык күренде. Кулына корал тоткан ватандашлары белән берләттән совет язучылары да үз каләмнәрен туган ил хезмәтенә багышладылар. Меңнән артык әдипләр, шагыйрьләр армия сафларына китте. Берәүләре корал тотып сугышка керде, икенчеләре фронт газеталарында эшләде. Аларның 400 дән артыгы сугыш кырында ятып калды...

Бу сан эчендә героик язмышлы Муса Җәлил дә бар иде. Мәгълүм ки, шагыйрь үз Ватанының хөрмәтенә, зурлавына лаек булды. 1956 елның февраль аенда аңа Советлар Союзы Герое исеме, 1957 елда Ленин премиясе бирелде.

Муса Җәлил — шагыйрь һәм көрәшче иде. Ул дошман кулына әсирлеккә төшкәч тә, хәтта шыксыз камерада үлем көтеп ятканда да, кешелек бәхете өчен, фашизмның караңгы көчләренә каршы көрәшне үзенә генә хас корал белән — ут һәм ялкын сулап торган шигырьләр белән дәвам иттерде. Берлинның Лертер урамындагы хәрби төрмә камерасында язылган шигырьләр җыентыгы — «Моабит дәфтәре» — моңа ачык дәлил.

Муса Җәлил белән бер камерада утырган бельгияле Андре Тиммерманс саклап калган, Советлар Союзында басылып чыккан һәм шуннан соң бик күп телләргә тәрҗемә ителгән «Моабит дәфтәре» — хәзер алдынгы кешелек дөньясының уртак хәзинәсе ул. Бәхетле очраклыклар аркасында Муса Җәлилнең бу хезмәте югалмый калды. Ләкин шагыйрьнең үзе турында, аның тоткынлыкта узган соңгы көннәре турында мәгълүматлар ул чакта бик аз иде әле. Муса Җәлил биографиясенең соңгы битләрен ачыклау өчен совет кешеләренең, беренче чиратта татар белгечләренең һәм шулай ук чит илдәге иптәшләрнең даими эзләнүләре кирәк булды. Бу эзләнүләргә миннән дә билгеле бер өлеш керде һәм моның белән мин үземне бик бәхетле саныйм.

1955 ел ахырында «Прессе дер Советунион»да баш редактор булып эшләгән чорымда мин «Советлитератур» журналыннан Муса Җәлил турында Юрий Корольков язган беренче мәкаләне укыган идем. Шагыйрьнең язмышы мине шунда ук үзенә җәлеп итте. Иң тәэсирлесе шул булды: журналда Җәлил шигырьләренең берничәсе немецчага тәрҗемә итеп бирелгән иде. Арада «Алман илендә» исемлесен дә укыдым һәм аны мин пролетар интернационализм хисенең гүзәл чагылышы итеп кабул иттем. Шуннан соң миндә бер теләк — мәкаләдә китерелгән кайбер даталарны, мәсәлән, шагыйрьнең анда 1944 елның 10 январенда дип язылган үтерелү көнен ачыклау һәм нәтиҗәне инде үзем таныш булган әлеге мәкалә авторына хәбәр итү теләге туды. Эшкә тотындым.

Плетцензее төрмәсендә үтерелгән кешеләрнең картотекасы сакланып калган булырга тиешлеге миңа мәгълүм иде. Мин профессор Каулга мөрәҗәгать иттем, аңардан әлеге картотека карточкаларның фотокүчермәсен алып бирүне сорадым. Көнбатыш Берлин суд палатасының генераль прокуроры 1956 елның 23 октябрендә картотекада Җәлилнең теркәлмәгәнлеген хәбәр итте.

Дрезден район прокуратурасына мөрәҗәгать итүем дә уңышсыз булды. Гәрчә Җәлил группасы нәкъ менә шушындагы хәрби суд тарафыннан үлемгә хөкем ителгән

булса да, 1939 елдан алып 1945 елга хәтле чорда үтерелгәннәрне теркәү кенәгәсендә Җәлил исеме чыкмады. Шулай ук республиканың башка архивларына мөрәҗәгать итү дә нәтиҗә бирмәде.

Ни эшләргә? Мин «Моабит дәфтәре»н коткаручы Андре Тиммерманс белән элемтәгә керергә булдым.

Берничә атна да үтмәгәндер, фашизмга каршы көрәшчеләр комитеты ярдәмендә, 1956 елның 15 маенда миңа хат килеп төште. Хаттан шулар мәгълүм булды: Совет гаскәрләре тарафыннан тоткынлыктан азат ителгәч, Тиммерманс үз иленә кайтып киткән һәм «Моабит дәфтәре»н Брюссельдәге совет илчелегенә кертеп тапшырган. Моннан соң ул бу шигырьләрнең нинди язмышка дучар булуын да, Мусаның үтерелүен дә ишетмәгән. Гомумән, 1944 елның августында Шпандау хәрби төрмәсенең душ бүлмәсендә юынып ятканда Мусаны очратып, аның белән бераз сөйләшеп торганнан бирле шагыйрь турында Тиммермансның һич ни ишеткәне юк икән.

Кыскасы, хаттан миңа шул нәрсә ачыкланды: Ю. Корольков мәкаләсендә күрсәтелгән үтерелү датасы, димәк, чынбарлыкка туры килми. Өстәвенә, кызыксындырырлык ситуация: Тиммерманс — Советлар Союзындагы әдәбият эшлеклеләренә таныш исем. Алай гына да түгел, ул Муса турындагы пьесаларның персонажы булып киткән. Ә менә үзе бу турыда һич ни белмичә туган шәһәре Тирлемонтта яши бирә. Ул хәтта Лертер урамындагы хәрби төрмәнең 382 нче камерасында бергә утырган иптәшенең танылган шагыйрь булуын да белми калган, кешелек дөньясы өчен үзенең нинди кыйммәтле шигырьләрне коткарып калуын да белмәгән.

Бу ситуациягә беренче мәртәбә үзгәреш кертүче Константин Симонов булды. Язучылар конгрессы уңае белән Бельгиядә булганда Константин Симонов Андре Тиммермансны эзләп таба һәм 1957 елның сентябрь аенда «Литературная газета» да үзенең Бельгия патриоты белән сөйләшүе турында язып чыга. Нәтиҗәдә Мусаның төрмәдәге тормышыннан яңа детальләр мәгълүм булды. Мин дә Җәлилгә бәйләнешле рәвештә «легион»нар турында мәгълүмат туплый башладым. Ул чакта минем карамакта әлеге мәсьәлә турында көнбатыш чыганакларыннан башка һич ни юк иде. Аларны исә тәнкыйть күзе белән карап яңадан бәяләргә туры килде.

Мәгълүм ки, Гитлерның Советлар Союзына каршы «яшен тизлегендәге сугыш» идеясе барып чыкмагач, фашист гаскәрләренең кайбер башлыклары, Розенберг министрлыгы совет хәрби әсирләрен туган илләренә каршы сугышырга оештыра башлыйлар. Бу эшне тормышка ашыруда Розенберг Германиядәге милләтче ак эмигрантлар комитетына — «Идел-Урал»га таяна. Соңгылары, Розенберг кушуы буенча, Идел белән Урал арасында төзеләчәк татар-башкорт дәүләте өчен диген булып, хәрби әсирләр арасыннан татарларны, башкортларны легионда хезмәткә димлиләр. 1942 елның май ахырында Волхов фронтында әсирлеккә төшкән Муса Җәлилне «легион»га тартуга аерата зур әһәмият бирелә. Чөнки шагыйрь — танылган, дәрәҗәле, сүзе — үтүчән.

«Легион»га керү Җәлил өчен күченеп йөрү иреген — төрле лагерьлардагы йөзләгән яктәшләры белән очрашу мөмкинлеген тудырачак, әлбәттә. Ләкин шул ягы четерекле: гитлерчылар аның чын ниятен фаш итүләре мөмкин, аннары ватандашлары каршында да яхшы түгел, хыянәтче дип уйлаулары бар. Авыр хәлдә кала Муса Җәлил. Ниһаять, яшертен алып барыласы көрәш ихтыяҗларыннан чыгып, ул нацистлар белән «килешеп» эшләргә ризалык бирә. Максат шундый: ватандашларны фашист пропагандасы йогынтысына бирештермәү, аларны фашизмга каршы актив көрәшкә оештыру.

Җәлил һәм аның тирәсенә тупланган татар патриотлары җәелдереп җибәргән яшерен эш нәтиҗәне озак көттерми. «Легион»ның Радомдагы батальоны фронтка дип җибәрелгәч, юлда ук поляк партизаннарына кушыла, Едельня лагерендагылары әллә кая китеп тә тормыйлар, шул урында ук баш күтәрәләр. Ләкин Җәлил группасына кереп яшеренгән шымчы тиздән эшне таркатуга ирешә. 1943 елның 10 август төнендә шагыйрьне Радомда кулга алалар һәм башта Варшавага, аннан Берлинга алып китәләр. Җәлилнең көрәштәшләре дә Радомда, Берлинда һәм башка лагерьларда кулга алына.

1957 елның ноябрь аенда Лейпцигта ГДР һәм СССР тарихчылары комиссиясе тарафыннан оештырылган конференциядә, икенче бөтендөнья сугышы тарихы мәсьәләсен тикшерү уңаеннан, мин дә үзем җыйган азмы-күпме материалларым белән кат-

нашкан идем. Минем информация тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты. Бередә мин иптәш Эрих Мюллер-Милштат кебек минем эзләнүләрне кайнар рәвештә хуплаучы тарафдарларны таптым. Бу чорда Эрих «Култур унд фортшритт» нәшриятында баш редактор булып эшли иде. Ул Җәлилнең сайланма шигырьләрен бастырып чыгарды, җыентыкка соңгы сүз язды. Аннары Җәлилнең байтак шигырьләрен немец теленә тәрҗемә итүче дә ул булды. Муса Җәлил турындагы «Кызыл ромашка» исемле телефильмның сценарий авторы да — ул. Шушы ук чорда мин Җәлил буенча эзләнүләр алып баручы яңа иптәшләр белән, башлыча татар белгечләре белән, элемтәгә кердем.

1957 елда яшьләрнең бөтен дөнья фестивале барган чакта мин, турист сыйфатында Мәскәүдә булып, шагыйрьнең тормыш иптәше Әминә ханым һәм кызы Чулпан туташ белән таныштым. Көннәрдән бер көн шулай язучы Юрий Корольков, Җәлил турында фильм төшерергә ниятләнеп йөрүче режиссер Ромм, Җәлилнең немец теленә тәрҗемәчесе Франц Лешницер һәм мин бергә Җәлил квартирасында утырабыз. Кинәт телефон шалтырый. «Известия» редакциясеннән икән. Бельгиядән килгән кунак Җәлил гаиләсенә барырга чыгып китте, каршылагыз, диләр.

Кунагыбыз — Андре Тиммерманс булып чыкты. Аны Язучылар союзы Мәскәүгә чакырган булган. Шулай итеп, мин үзем белән хатлар алышып торган кешене көтмәгәндә күреп таныштым.

1949 елда ГДРда «Соңгы сәгатьләр» исемле китап басылып чыкты. Аның авторы Плетцензее төрмәсе пасторы Гаральд Пелхау сугышка, фашизмга каршы кеше буларак, үзенең әлеге китабында бик күп батыр көрәшче-антифашистларның соңгы сәгатьләре турында тәэсирле итеп сөйләп биргән иде. Китапта минем өчен дә әһәмияте булган кайбер күрсәтмәләр килеп чыкты. Ләкин турыдан-туры Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә кагылышлы мәгълүматлар бередә дә юк иде. Шулай да берничә айдан соң Пелхау, соравыма җавап итеп, миңа католик динен тотучы Юрытко хатын җибәрде. Хаттан күренгәнчә, Юрытко Муса Җәлилне күреп белгән һәм аны «сабыр, күркәм» холыклы кеше дип атый.

Шпандау төрмәсендә Җәлил белән бер камерада утырган итальян хәрби әсире дә шагыйрьне бик хөрмәт иткән. Юрытко Гетенең «Фауст» исемле әсәрен укырга китереп биргән, хәтта бервакыт Мусаның хатын да төрмә каравылчыларыннан яшереп ирекка алып чыккан. «Җәлил, — дип яза аннары Юрытко, — ватандашларын рус солдатларына каршы сугышмаска чакырып прокламацияләр бастырып тараткан, шуның өчен аны үлемгә хөкем иткәннәр».

Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен җәзалау көнен төгәл генә Юрытко да хәтерләми икән. Аныңча бу җинаять 1944 елның көз айларында булырга тиеш.

1958 елның август ахырында татар язучысы Шәйхи Маннур Казаннан минем янга килеп чыкты. Аның нияте Җәлил турында роман язу өчен Берлиннан материал җыю, туплау иде. Ул Юрытконы эзләп таба. Ләкин Җәлил укыган «Фауст» югалган булып чыга. Аның каравы, Дантеның «Илаһи комедия»се — Мусаның камера иптәше укыган китап Шәйхи Маннур кулына төшә. Юрытко әйтүенчә, итальян әсире исә төрмәдән котылып чыккан була.

Димәк, итальян әсирен табарга мөмкин. Шунда ук җае да килеп чыкты: китапның тышлык битендә карандаш белән беленер-беленмәс кенә язылган сүзләр табылды. Аларны 37 яшьлек итальян әсире Рениеро Ланфредини язган икән. Язуда әсир хатынының исеме, яшәгән урыны күрсәтелә. Ләкин ул төгәл адрес булмый. Моннан соң күп еллар үтеп, адресатлар торак урыннарын берничә мәртәбә үзгәртсәләр дә, миңа, итальян почтасы аша эзли торгач, тегеләрне эзләп табу мөмкин булды.

Шул нәрсә ачыкланды: Ланфредини, туган иленә кайткач, үз башыннан үткәннәрне язган һәм китап итеп чыгарырга булган. Ләкин бастыру өчен бик күп акча түләргә кирәк булганга күрә, китап дөнья күрми калган. Шушы язмаларга таянып, ул минем барлык сорауларга җавап бирде.

«1944 елның 5 июнендә, — дип язды ул, — мине Шпандау төрмәсенә күчерделәр һәм 53 нче камерага яптылар. Бередә Муса Җәлил һәм Булатов әфәнде утыра иде. Алар мине бик үз итеп каршыладылар һәм без шунда ук дуслашып киттек. Яңа дуслар миңа үзләренең моннан 6 ай элек үлемгә хөкем ителүләрен, хәзер менә үлем көтеп ятуларын сөйләделәр. Ләкин аларга карап болар үлемгә хөкем ителгән дип һич әйтерлек түгел иде. Алар тыныч иде, хәтта күтәренке күңелле иде. Ул чакта мин аларның

тагын бернича иптәше белән танышкан идем. Алар да бер үк эш өчен — фашистларга каршы пропаганда өчен кулга алынганнар.

53 нче камерада мин бер ай чамасы яттым. Аннары мине 153 нче камерага күчерделәр. Бирeдә мин Җәлил белән Булатовның тагын өч иптәше белән очраштым. Гомумән, үлемгә хөкем ителгән татарлар нибарысы 12 кеше иде.

1944 елның 25 августында иртәнге сәгать 6 да ике немец сакчысы камера ишеген ачтылар, русларның исемнәрен аерым-аерым атадылар һәм камерадан чыгарга боердылар. Ни өчен? — дигән сорауга «белмибез» дигән җавап биреләе. Ләкин тоткыннар эшнең нәрсәдә икәнен шунда ук аңлап алдылар. Алар миңа шушы сүзләрне әйттеләр: «Синең үлемнән котың очкан иде, менә без үләргә киттек...»

Алар барлык әйберләрен камерада калдырдылар. Чыгып барганда мин Җәлилнең иптәше белән үзара сөйләшүен ишетеп калдым. Соңыннан мин Юрыткодан: «Татарларны нишләттеләр?» — дип сорадым. Ул миңа: «12 кеше барысы да 10 сәгатьтә асып үтерелде», — диде. «Кайсы җирдә икәнен сезгә әйтә алмыйм». Шулай да үзе соңыннан миңа хәбәр итте: «Татарлар елмаеп, чын батырларча үлделәр».

Бу вакыйга турында, барыннан да элек үтерелү көне турында, мин «Литературная газета»га язган идем. Мәкалә «Муса Җәлилнең соңгы көннәре» исеме белән 1959 елның январь санында басылып чыкты. Шулай ук әлеге мәкалә татарчага тәрҗемә ителеп, Лейпцигтагы конференциядә ясалган информация тексты белән бергә «Совет әдәбияты» журналында да басылды.

1965 елның май аенда Татарстан АССР язучылар союзы мине Казанга кунакка чакырды. «Татарстан язучылар союзы идарәсе,— диелгән иде ул чакыру кәгазендә,— шагыйрь һәм герой Муса Җәлил турындагы Сезнең материалларыгыз белән бик кызыксына. Хәзер безнең илдә шагыйрьнең тууына 60 ел тулу көненә хәзерлек бара, шушы уңайдан Сезнең килүегез бик хуш булыр иде».

1965 елның июль аенда мин бернича көн Татарстанда булдым, нефть үзәге Әлмәтне күрдем, Җәлил шәһәрен, Дуслык нефть үткәргеченең башланган урынын карадым...

Җәлил Ватанының экономик күтәрелешен күзәтүдән туган тәэссоратлар белән тулы көннәр иде алар. Без бик күп сөйләштек. Муса Җәлил һәм аның язмышы турында, социалистик немец дәүләте турында сөйләштек. Әйе, Мусаның «Алман илендә» исемле шигырендә сурәтләнгән социалистик немец дәүләте турында сөйләштек.

**Борыгыз муйнын комсыз карчыганың,**
**Кояш чыксын Алман җиренә.**
**Күтәрелсен Тельман трибунага,**
**Маркс, Гейне кайтсын иленә.**

Бүгенге немец дәүләтендә, — дидем мин әлеге сөйләшүләр вакытында, — Җәлилнең хыялы тормышка ашты: анда «Тельман трибунага күтәрелде», анда Маркс, Гейне гражданлык хокукы алды, анда Муса Җәлил һәм аның иҗаты, аның иптәшләре югары хөрмәткә, игътибарга лаек булды.

Сөйләшүләрдә минем тыңлаучыларым исәпсез-хисапсыз иде. Чөнки Казан телестудиясе мине меңләгән тыңлаучылар каршына чыгарды. Мин бу трибунадан үземнең эзләнүләрем турында, ГДР турында, «Кызыл ромашка» исемле телефильм турында сөйләдем.

Казаннан киткәндә миңа эш тапшырдылар. Бу вакытта Татарстан китап нәшрияты Җәлилнең тууына 60 ел тулу көненә аның тормыш юлы, иҗат эшчәнлеге турында зур күләмле альбом чыгару эзерлеген алып бара иде. Альбомдагы текстлар татарча, русча гына түгел, бәлки өстәмә рәвештә немец телендә дә басылырга тиеш, диделәр.

Әлбәттә, текстларны немец телендә дә язу — бу ГДРда алып барылган эзләнүләрне тану билгесе иде. Бу — «Моабит дәфтәре»н китап итеп тә чыгарган ил — ГДР булуын тану билгесе иде.

«Рус теленнән соң,— дип әйттеләр миңа татар иптәшләрем,— немец теле — безнең милли шагыйрьнең әсәрләрен укучыга җиткерүче беренче чит тел».

Альбом өчен текстны немец теленә тәрҗемә итү — Эрих Мюллер-Милштат, Франц Лешницер һәм минем тарафтан башкарылды.

Германия — Советлар Союзы дуслыгы җәмгыяте үзәк идарәсендә Муса Җәлилнең 60 еллыгына хәзерлек буенча комиссия төзелде. Бу датаны үткәрү тантанасында

катнашу өчен немец язучылары союзы делегациясе — Эрих Мюллер-Милштат, Вилли Лееин һәм мин кунакка чакырылдык. Без моны зур хөрмәт билгесе итеп кабул итеп, Мәскәүгә килдек һәм язучыларның Үзәк йортында оештырылган Җәлил күргәзмәсен ачуда, аннары Чайковский залында үткәрелгән тантанада катнаштык. Делегациянең бер әгъзасы буларак, мин немец халкының алдынгы вәкилләренең Муса Җәлилгә мөнәсәбәте турында сөйләдем һәм Татарстан язучылар союзы рәисенә «Кызыл ромашка» телефильмының күчерелмә нөсхәсен тапшырдым. Бу фильм шунда ук язучыларның Үзәк йортындагы зур залда күрсәтелде һәм Җәлил образын кинога алу буенча беренче омтылыш буларак алкышлап каршыланды.

Советлар Союзында үткән бу көннәр киеренке хезмәт көннәре булды. Алар безгә иске дуслар белән — беренче чиратта, Әминә һәм Чулпан Җәлил белән, аннары бик күп яңа дуслар белән, Җәлилнең көрәштәшләре белән очрашу шатлыгын китерде.

Шушы килүендә Андре Тиммерманска дәүләт бүләге бирелде.

1969 елның май аенда Совет-Германия дуслыгы җәмгыяте чакыруы буенча Әминә Җәлилова ГДРга килде. Без аның белән Потсдам, Веймар-Бухенвальд, Дрезден шәһәрләрен карадык, Муса Җәлил исемендәге бригада эшләгән заводта булдык. Очрашулар вакытында алган тәэсирләре турында Әминә Җәлилованың «Фюр дих» журналында мәкаләсе басылып чыкты. Менә ул мәкаләдән бер өзек: «Мин хәзер Мәскәүдә. Күңелем белән бик озак әзерләнгән һәм үземә бик хуш килгән сәяхәт миңа күп нәрсә бирде. Барыннан да элек, мин шуңа ышандым: Муса Җәлилнең немец халкына булган тирән ышанычы акланган. Мин ГДРда Германия белән таныштым. Бирегә хәзер Маркс һәм Гейне рухы тантана итә, биредә социализм кояшы балкый. Биредә мин яңа дуслар таптым — чын дуслар, ышанычлы дуслар. Ә бит кешеләрнең йөрәген җылытырлык дуслыктан да зуррак хәзинә — дөньяда, минемчә, юк».

1968 ел башында Эчке эшләр министрлыгында эшләүче иптәшләр миңа хәбәр иттеләр: фашист башкисәрләр Плетцензее төрмәсендә башкарылган үтерүләрне Берлин-Шарлоттенбург ЗАГСында теркәп барганнар икән. Әлеге архив ГДР башкаласы территориясендә булганга күрә, үлеләрне теркәү кенәгәсеннән кирәкле битләрнең фотокүчермәсен алу озакка сузылмады. Бу документ Җәлил язмышын өйрәнүчеләр өчен бик әһәмиятле табыш булды һәм күп нәрсәгә тулысынча ачыклык кертте. Мәсәлән, Җәлилнең көрәштәшләре 11 кеше булган икән. Р. Ланфредини раславына таянып, Җәлил һәм аның иптәшләре асып үтерелгәннәр дип йөртелә иде. Соңгы документта исә үлемнең сәбәбе «башын кисеп ташлау» дип күрсәтелә. Җәлил һәм җәлилчеләр барысы да шундый үлемгә дучар була. Үтерү 12 сәгать 6 минутта башлана, 12 сәгать 36 минутта тәмамлана. Муса Җәлил 12 сәгать 18 минутта үтерелә...

1968 елның 15 февралендә Совет-Германия дуслыгы җәмгыяте йортында бу яңа документны Курт Тиме һәм мин җәмәгатьчелеккә җиткердек. Хәбәр Совет илендә зур кызыксыну уятты: аны радиодан тапшырдылар, бу турыда үзәк һәм бигрәк тә татар газеталары тулы информация бастылар. Аларда ГДРда совет патриотлары батырлыгын ничек олылау турында сүз барды. Муса Җәлил шигырьләрен немец телендә кичәләрдә сөйләү, мәктәпләрдә, институтларда өйрәнү күрсәтелде. Җәлилнең тормыш юлы, иҗат эшчәнлеге турында «Кызыл ромашка» исемле телефильм төшерелгә алынды.

Яңа табылган документларның фотокүчермәсен мин татар Язучылары союзы идарәсенә җибәрдем. Шулай итеп, ун елга сузылган эзләнүләр нәтиҗәсез калмады. 1956 елда Муса Җәлил турында беренче мәкаләне укыгач, мин үз алдыма шундый бурыч куйган идем: шагыйрь язмышын дәлилләп күрсәтерлек документларны Совет илендәге иптәшләргә табып бирергә. Бу документлар, күргәнебезчә, әллә кайда еракта да ятмаганнар икән. Ә менә аларны табар өчен нинди бормалы, әйләнеч һәм озын юл үтелде. Хәер, үкенечле түгел. Бу юл мине Җәлилнең көрәштәшләрен табарга, шагыйрьнең соңгы көннәрен ачыкларга ярдәм итте. Үтелгән юл мине Җәлилне өйрәнүчеләр белән очраштырды, миңа Советлар Союзында, ГДРда яңа дус-ишләр табарга ярдәм итте. Аларга карыйм да мин, Әминә Җәлил сүзләрен кабатлыйм: «Кеше йөрәген җылытырлык дуслыктан да зуррак хәзинә — дөньяда юк».

**«Кызыл йолдыз билгесе астында. Истәлекләр» дигән китаптан. Берлин, 1974, 307—317 битләр.**
**Немецчадан ШӘРӘФ ӘХМӘДУЛЛИН тәрҗемә итте.**

**Исхак Зәбиров,**

*филология фәннәре кандидаты*



# ҖӘЛИЛ ДУСТЫ

**1944** елның 25 августында палач балтасы, ун җәлилче белән бергә, Әхмәт Симаевның да башын чабып өзә.

Мин дә соңгы елларда җәлилчеләрнең героик тормышларын, эшчәнлекләрен тырышып өйрәндем. Аларның кайберләре белән үзем торган якларда — Урта Азия республикаларында еш очрашырга туры килде һәм килә. Бу чыгышта мин журналист һәм шагыйрь, Муса Җәлил оештырган яшерен оешманың актив җитәкчеләреннән берсе Әхмәт Симаев турында белгәннәремне әйтергә телим.

...Әхмәт Симаев профессиональ журналист булган, газетада мәкаләләр, зарисовкалар, очерклар һәм шулай ук шигырьләр дә бастырган. Хәзерге вакытта аның илле шигыре язылган дәфтәрләр танылган әдәбият белгече һәм язучы, Муса Җәлил иҗаты һәм тормышы турында беренче җентекле хезмәтләрне язган фәннәр кандидаты Гази Кашшаф архивында саклана. Шигырьләр 1931—1940 елларда язылганнар, күбесе әлегәчә беркая да басылмаган. Алар тематик төрлелеге белән игътибарга лаек. Аны туган як табигате дә («Кышкы пейзаж», «Яз башы», «Кырда»), производство алдынгыларының батыр хезмәте дә (партиянең XVII съездына багышлап язылган «Бригадир Кугушев», «Стаханов» шигырьләре), халыкара коммунистлар партиясе җитәкчеләренең эшчәнлекләре дә («Тельман турында») дулкынландыра. Шулай ук үз әсәрләрендә ул Ленин һәм Киров образларын да сурәтли. Күпчелек шигырьләренең төп темасы социалистик ватанның чәчәк атуы өчен тырышкан гади совет кешесенең фидакарь хезмәтен гәүдәләндерү була.

**Партсъездга салют биргән кебек,**
**Җирне ертып шартлый амонал,**
**Амоналга ярыш ачкан кебек,**
**Удар куллар эш дип яналар! —**

Шулай диелә аның «Бригадир Кугушев» шигырендә. Туган җирләрдәге үзгәрешләргә, Мордовия АССРдагы татар авылында колхоз кешеләренең эшенә ул «Кырда» исемле шигырен багышлый:

**Туган җирләр!..**
**Ник соң танып булмый!..**
**Әллә дөнья шулай үзгәргән,**
**Әллә һәр җир бердәй матур күренә**
**Шатлык белән тулган күзләргә!!**

Стахановның хезмәттәге батырлыгын ул революция юлбашчысы даһи Ленин образы белән бәйли:

**Стаханов!**
**Сине Ленин үзе**
**Еллар сөреме аша күргәндер.**
**Сиңа карап, даһи: «Социализм**
**Бусагасы шунда!» дигәндер...**

Утызынчы еллар илебезнең промышленностенда да, авыл хуҗалыгында да зур үзгәрешләр чоры була. Партия, ышанычлы адымнар белән, халкыбызны социализм төзүгә китерде. Эчке һәм тышкы дошманнар, әлбәттә, моның белән килешергә теләмәде. Германиядә зәһәрле елан — фашизм баш күтәрде, социалистик строй дошманнары астыртын диверсияләр оештырдылар, партия һәм халыкка чын күңелдән бирелгән кешеләрне — коммунистларны юк итәргә теләделәр. Илне социалистик үзгәртеп коруның иң кызган чорында Ленин көрәштәше С. М. Киров явызларча үтерелде. Ленин үлгәннән соң халкыбыз өчен иң зур югалту иде бу. Әхмәт Симаев та моны бик

авыр кичерә һәм «С. М. Киров үлеменә» дигән шигырендә ил дошманнарына нәфрәтен болай белдерә:

**Сыйнфый дошман**
**һаман суза әле**
**Калтыравыклы салкын кулларын,—**
**Имгәк микроб кебек,**
**Тетрәтергә теләп**
**Коммунизм молекулларын...**
**Эх, вәхшиләр!**
**Бу бит җан биргәндә**
**Бер йотым су сорау шикелле...**

Әйе, халык дошманнарын котылгысыз һәлакәт көтә, ә коммунизм җиңелмәс көч! Моны социалистик Ватан, халкыбыз Бөек Ватан сугышында тагын бер кабат гамәлдә раслады. Әмма Әхмәт Симаев үзе дә шул дәһшәтле сугышның корбаны булды...

Немец пролетариаты юлбашчысы, халыкара эшчеләр хәрәкәтенең күренекле җитәкчесе Эрнст Тельманның әхлакый сыйфатлары, аның искиткеч батырлыгы шигыйрьне илһамландыра һәм ул 1937 елда түбәндәге шигырен яза:

**Җырым!**
**Әгәр сорасалар**
**кайдан чыгуыңны,**
**«Кем җырлады» диеп**
**әйтсәләр —**
**Иң электән**
**СССР яшьләреннән**
**Эрнст Тельманга син**
**әйт сәлам.**
**Шулай әйт син,**
**Аның көрәшчән йөрәге**
**Ярдәм, ышаныч сизеп киерелсен!**
**Ә соңыннан**
**(тагын сорасалар)**
**Танып кына җавап бирерсең.**

Бәлки Әхмәт Симаев Берлин төрмәләрендә — Моабитта һәм Тегельдә — җәфа чиккәндә Эрнст Тельманның да бер үк төрмәләрдә үзе белән бергә утырганын ишеткәндер. Бәлки аның турында сугышка кадәр үк язган шигырен шунда иптәшләренә укыгандыр.

Әхмәт Симаев язганнар, Муса Җәлил поэзиясе кебек үк, тирән интернациональ рухлы көрәш җыры булып яңгырый. Алар сак һәм уяу булырга, капиталистик чолганыш барлыгын истән чыгармаска, совет халкының тыныч тормышын нык сакларга чакыра («Саубуллашу», 1939).

Әхмәт Симаев Җәлил белән сугышка кадәр үк таныш булган. Шуңа да аның иҗатына Муса йогынтысы зур. Фашист тоткынлыгында да аның үз иптәшләренә иҗади ярдәме булганын әйтеп тә торасы юк. Яшерен оешма таркатылганчы, аның членнары кулга алынганчы, алар язган бер генә әсәр дә, Муса Җәлил карап чыкмас борын, хәрби әсирләргә, легионерларга тәкъдим ителмәгән. Чөнки алар «Идел-Урал» комитеты хезмәткәрләре арасында хыянәтчеләр булуы мөмкинлеген яхшы белгәннәр. М. Җәлил бер үк вакытта цензор да, остаз да булган. Ватанга каршы, Советлар Союзына яла ягa торган пычрак язмаларны әсирләр арасына чыгармау өчен Муса һәр мөмкинлектән файдаланган.

Муса Җәлил кебек үк, Әхмәт Симаев та электән үк публицистика белән актив шөгыльләнгән. Мәскәү өлкәсендәге Воскресенск район газетасы «Коммунист» редакциясендә җаваплы секретарь булып эшләгәндә ул бик күп мәкаләләр, хәбәрләр, репортажлар, фельетоннар һәм хикәяләр язган. Аларны укыганда авторның зур оптимист, нечкә юморлы, шат күңелле, тыйнак һәм принципиаль кеше булуын сизеп торасың. Алар чын журналистларча оста язылган, конкретлар, фикер ягыннан ачыклар. Ул иҗат тормыш һәм кешеләр турында кайгыртучанлык хисләре белән сугарылган, ул һәр әсәрен чын гражданин һәм чын кеше буларак яза.



«Коммунист» газетасында (1940 ел) «Еларсың да, көләрсең дә» рубрикасы белән басылып чыккан «Балык күзе» исемле кечкенә фельетонда, мәсәлән, Симаев район азык-төлек сәүдәсе управляющиен тәнкыйтьли: управляющий җәмәгать туклануы турында аз кайгырта, ашханәләрдә — усал күзләре акаеп торган, кибеп беткән балык кына... Бервакыт управляющий төш күрә. Имеш, кипкән балыклар, борчак гарниры астыннан башларын чыгарып, аңа ялваралар: зинһар өчен, меню тәрләндерелсен, кешеләребез мескеннәрне гаепсезгә урынсыз каһәрләмәсен!.. Үткен күзле журналистның мондый материаллары, замандашларының сөйләвенчә, һәр вакыт уңай нәтиҗә бирә торган булган — кимчелекләр үз вакытында бетерелгән.

«Соңгы почтадан» дип исемләнгән редакцион мәкаләсендә Әхмәт Симаев күп тиражлы «Куйбышевец» газетасы редакторының «оста комбинациясен» фаш итә. Ә редактор исә «Правда» газетасында басылып чыккан фельетонны, анда сөйләнгән кешеләрнең исем-фамилияләрен генә алыштырып, үз газетасына урнаштырган икән.

Телгә алынган бу ике материал гына да Симаевның журналистлык хезмәтенә ничек җаваплы каравын ачык раслый.

Әхмәт Симаевның теге яки бу кешеләргә язган хатларын да чын-чынлап дулкынланмыйча уку мөмкин түгел. Аларда да Муса Җәлил белән характер уртаклыгы ярылып ята. Тормыш иптәше Валентина Листопад һәм кызы Людмилага кадровый хезмәттән һәм фронттан язган хатлары зур ярату хисе, гаҗәеп ягымлылык, тирән ихтирам, кайгыртучанлык белән тулы (Гази Кашшаф архивында Ә. Симаев язган 9 хат бар).

> «Валя, ходай хакы өчен, сәламәтлегеңне һәм кызыбызны саклый күр,— дип яза ул 1941 елның 2 мартында.— Сезне ничек яратуымны, ничек күрәсе килүемне аңлыйсыңмы син?! Синең яхшы ана булачагыңа мин һичкайчан шикләнмәгән идем».

Аның һәр хатында — бәхет турында матур хыяллар, һәр хатында ул әнисенең хәле турында сораша, аны «бер минут та истән чыгармавы» турында әйтә.

Менә фронттан язган хатларының берсе:

> «15. XI-41 ел. Сәлам! Фронт. Төн салкын һәм караңгы, якынча тыныч. Тик ара-тирә, җирне тетрәтеп, еракка ата торган орудиеләр гөрселдәвә генә тынлыкны боза. Землянкада тыгын, төтен тулган һәм караңгы. Егетләр, берсе өстендә берсе диярлек, йокыга талганнар. Әмма аларның йокылары тыныч түгел, әледән-әле сискәнеп уяналар, төшләнеп мыгырдыйлар. Төн озын, ә аларның йокылары кыска. Тиздән яктыра башлаячак, таң яктысы белән гөрселдәү, шартлау авазлары белән утлы көн, сугышлы көн туачак! Кыш, сугыш, фронт...
>
> Күптәнге яшьлек гадәтләре әле дә онытылмаган, барысы да йокыга китеп, землянка эче тынгач, берүзем калып уйланырга яратам. Уйланам, уйланам, сиңа бик матур хат, синең борчылуыңны, сагышыңны аз гына булса да киметерлек, сиңа минем йөрәк җылымны, ашкынып торган рухымның бер кисәген алып барырлык хат язасым килә. Моңа кадәрге борчулы уйларың бөтенләйгә бетсен иде...
>
> Моңа кадәр инде сиңа билгеле булганнардан, әлек йөзләрчә мәртәбә кабатланган сүзләрдән башка тагын нәрсә языйм соң? Мин хәзергә исәнсау, бик сагындым, сине бик-бик күрәсем килә.
>
> Кадерле Валя! Мөгаен, син минем фронтта икәнемне, Мәскәү янында гына икәнемне белмисеңдер. Бу синең ноябрьның 3 ендә язган хатыңнан күренеп тора. Мин аны 12 сендә алдым. Хат бәлки мине очраклы гына тапкандыр һәм миңа ул кинәт, көтмәгәндә генә килеп төште. Аңа кадәр,

5 октябрьдан бирле, синнән бер хат та алганым юк иде. Сиңа моның өчен чиксез рәхмәт хисләремне әйтер сүзләр таба алмыйм.

Әйе, Валя, минем фронтка килгәнемә тиздән бер ай була. Октябрь урталарында Воскресенск аша уздык. Төн уртасы иде. Поезддан төшәргә дә, вокзалга йөгереп барып, берәр кеше аша сиңа сәлам җибәрергә дә мөмкинлек булмады. Бик теләгән идем, булдыра алмадым. Үкенеч. Аннан ике көн Загорскида тордым. Ул да Мәскәүдән ерак түгел. Телеграмма сугарга теләгән идем, акча булмады.

Редакциядә эшләр ничек бара? Фронтовиклардан нинди хәбәрләр бар? Хәзергә шул. Сәламәт булыгыз, минем кадерлеләрем. Адрес: Действующая армия, полевая почтовая станция 305, п/я 83...

Валя, бәйрәмне ничек үткәрдегез? Редакциядә кемнәр эшли? Көз көне бәйрәмдә Саша белән төшкән рәсемне җибәр.

Синең Сима. 15.XI.41 ел».

Әхмәт Симаевны әлегә фронтка җибәрмәгәннәр. Ул «тормыш сөючән, ирекле халкыбызга ерткыч фашистлар таккан сугышны» бик авыр кичерә, аны «совет кешеләренең үтерелүе, яньш көлгә әверелгән шәһәр һәм авыллар» зур кайгыга сала. Әмма ул озакламый үзе дә фронтның алгы сызыгына әләгә. Редакция хезмәткәре, гаиләләренең дусты Анитага, сугыш трагедиясен сурәтләп, Әхмәт болай яза:

«9 январь, 1942 ел. Көнбатыш фронт. Исәнме, минем «иске» дустым! Анита, синең миңа, фронтка язган хатыңны яңа елга кадәр үк алган идем. Җавап итеп кечкенә генә открытка да салдым. Үпкәләмәгәнсеңдер шаять (әгәр дә әле ул барып җиткән булса), чөнки син минем кайда икәнлегемне дә, ни эшләвемне дә беләсең. Озын итеп хат язу өчен бик сирәк очракта гына вакыт табарга мөмкин. Хатыңның эчтәлеге хәзер төгәл генә хәтердә юк. Әмма ул бик җылы һәм кызыклы иде. Ышан, ул мине, мөгаен, син уйлаганга караганда да күбрәк шатландыргандыр... Син моны аңларсың, тыңла менә: сугыш, фронт, кыш... Иң рәхимсез сугыш, иксез-чиксез, мәрхәмәтсез сугыш. Һәр көн тетрәткеч тәэсирләр белән тулы, кайчагында кинәт кенә үзеңне вакыт агымыннан читләшкәндәй тоясың, таң вакытын кичке эңгер-меңгер белән бутыйсың, үз-үзеңне оныласың... һәм менә шундый минутта сиңа кинәт хат килеп төшә, — хатыныңнанмы, дустыңнанмы, туганыңнанмы, барыбер ул биниһая кадерле, чагыштыргысыз җылы һәм якын, ул дәһшәтле сугыш кырына, өермә белән бергә, әле улап, әле усал чинап, әле сызгырып, әле эчпошыргыч үкереп үлем биегәндә электәге тормыш сулышын алып килә. Кинәт күз алдына, нәкъ чынбарлыктагыча булып, җанга якын күренешләр килеп баса һәм үткән көннәр искә төшә...

Ә аннары сугыш, рәхимсез, бар нәрсәне юкка чыгара торган дәһшәтле сугыш. Менә шуңа күрә дә синең хатның эчтәлеген онытканмын. Гафу ит, үзеннән-үзе онытылган...

Мин моңа кадәр үк тормышның зур һәм реаль китабын җитәрлек актарган кеше. О, Анита, нинди акылсызлык, нинди кара вәхшилек бу сугыш дигән нәрсә, кешелек дөньясына нинди коточкыч фаҗига алып килә ул! Һәм менә мин сугышам, син һәм синең кебек меңнәр теләгәнчә итеп сугышам.

Шуны да әйтим: минем тынгысыз күңелне канәгатьләндерерлек нәрсәләр кирәгеннән артык. Рәхимсез сугышам, гайрәт белән, тырышып сугышам, чөнки мин яшәргә бик телим, хыялланырга, өметләнергә, тәзергә, иҗат итәргә, сиңа язган бу хатка җавап һәм синнән, Валядан, башка туганнардан, дуслардан бик күп хатлар алырга телим.

Анита, соңгы берничә көнне мин Мәскәү янында ук диярлек үткәрдем. Әмма Мәскәүгә, бигрәк тә сезгә, кайтырга һич тә мөмкинлек булмады. Бик кызганыч, ә өйгә кайтасы бик килгән иде. Анита, үтенеп сорыйм, ешрак, тулырак итеп яз. Мине барысы да кызыксындыра, син моны үзең дә аңларга тиешсең. Шуны да әйтим: хәзер сез берникадәр тынычлана аласыз, сугыш чукмарларының зәхмәте суынды, безгә дан!

Әйе, күрәселәре әле аларның алда, хәлләре яман, бик яман. Бонопартның «якты» даны кебек үк, бөек өченче империя дип аталган нәрсә дә Россия кары астында күмелеп калачак...

Бәхетле һәм сәламәт булыгыз.

Сәлам белән — Симаев».

Әйе, Әхмәт Симаев сугыш вакыйгаларын читтән күзәтүче генә түгел, ул, кулына корал тотып, алгы сызыкта фашизмга каршы көрәшә. Һәм аңардагы оптимизмга сокланмый мөмкин түгел, ул фашизм өермәсенең туздырылачагына, җимереләчәгенә шик тотмый. Аның Анитага язган хаты халкыбызның, барлык сугышчыларның гомумиләштерелгән уй-тойгылары, фикере ул.

Бик табигый, бу вакытта иң авыр сынау көннәренең әле алда икәнлеген күз алдына да китермәгән ул.

Муса Җәлил һәм Әхмәт Симаевның фронт юллары төрлечә. Әмма шунысы характерлы: аларның уй-хисләре, фашизмга нәфрәтләре, якын кешеләренә мәхәббәтләре бер төрле. Җәлилнең Чулпанга язган хатлары Симаевның кызы Людмилага булган хисләре белән аваздаш. Бу хатларда тормышка тирән мәхәббәт, якыннары, туганнары, дусларына карата зур кайгыртучанлык, совет кешеләренең тыныч тормышын җимергән фашизмга чиксез нәфрәт гәүдәләнә.



Алар икесе дә, яшерен оешманың башка членнары да, соңгы сулышларына кадәр якыннарын, дусларын, туган илнең язмышын исләреннән чыгармыйлар.

Әхмәт Симаевның гаиләсенә соңгы хаты 1942 елның февралендә язылган. Бу вакытта инде ул дошман тылында. Мөгаен, ул анда командование заданиесе белән җибәрелгән булгандыр.

«19 февраль, 1942 ел. Сәлам! Кадерле Валя! Мин инде бер айдан артык дошман тылында. Әлегә исән-сау. Белеп торам: миннән хат килмәгәнгә син бик нык борчыласың. Гафу ит, сөеклем, мин гаепле түгел, моннан почта йөрми, бу хатны да бик очраклы мөмкинлектән чыгып кына язам, аның сезгә барып җитәчәгендә дә ышанычым юк...

Ничек яшисез? Люсяның, әнкәйнең хәле ничек?.. Җавап килмәячәген белсәм дә, мине борчыган кайбер сорауларны язам. Хәтта мин адресымны да әйтә алмыйм. Шулай да тиздән мин үзебезнең якка кайтырга тиеш, бәлки хәтта күрешербез дә. Әлегә мин туган җиребездә булсам да, үз илебездә түгел.

Хәзергә шул, мине гафу ит. Элеккечә сине, Люсяны, әнкәйне күрү теләге белән хыялланып яшим...

Хушыгыз, хушыгыз, минем кадерлеләрем, якыннарым, сөеклеләрем. Сине кочаклап бик каты итеп үбеп калам. Сәлам белән әтиегез һәм Сима. 1942 ел, 19 февраль, Смоленск өлкәсе».

Сугышчыларның фронттан язган хатлары героик көрәшләрне, ул чорда халкыбыз кичергән чиксез авырлыкларны сурәтләгән кадерле сәхифәләр алар. Ул хатларда явыз дошман белән рәхимсез сугышта совет солдатының Ватан өчен, азатлык һәм бәйсезлек өчен үз-үзен аямас көрәшче, чын батыр булып формалашуы гәүдәләнә.

Җәлил легиончыларының берсе үзенең истәлекләрендә Әхмәт Симаевны түбәндәгечә искә ала. «... Әхмәт Симаевны да безнең янга керттеләр... Ул үзенең Мәскәүдән икәнен һәм журналист булганлыгын, 1942 ел башында... парашют десанты белән... дошман тылына төшкәнен, ике айлар бик каты сугышкан булуларын, бик мөһим разведкага баргач, яраланып немецларга эләгүен сөйләде».

Аннары истәлектә яшерен оешмага ничек килеп эләгүләре язылa, җәлилчеләрнең, аерым алганда Ә. Симаевның, патриотик эшчәнлеге сурәтләнелә. «1943 елның башларында Әхмәт Симаев М. Җәлилнең комитет членнары өчен язылган хатын укытты. Хәтеремдә калганча, аның эчтәлеге болай иде: Безнең комитет авыр шартларда оештырылды һәм күп кыенлыклар белән эшләп килә. Әле җитәрлек үк булмаса да, кадрлар артты һәм арта бара. Легион һәм лагерьлар арасында элемтә булдырылды. Боларны беренче уңышлардан санарга кирәк. Безнең листовкалар легиончылар арасында кулдан-кулга күчеп йөри. Аларда Ватанны сөю хисе тагын да арта, дошманга нәфрәт көчәя. Фронтка китүче легион батальоннары, беренче батальон үрнәгендә, Совет Армиясе ягына чыгып, немецның үз коралын үзенә каршы юнәлде-

рәчәкләр. Алар арасында туган иле өчен җанын бирергә әзер торучы егетләр күп. Башка яшерен оешмалар белән элемтә булдырылды, озакламый коралды партизан отрядлары белән элемтәгә керәчәкбез...»

1943 елның августында, бер сатлык җанның хыянәте аркасында, Җәлил һәм аның иптәшләре кулга алына. Аларны Берлинның Александр-плац урамындагы төрмәгә ябалар, аннан Моабит төрмәсенә күчерәләр. Әхмәт Симаев та, М. Җәлил, А. Алиш, Р. Саттар, Г. Курмаш һәм Берлиндагы яшерен коммунистик оешманың башка җитәкчеләре кебек үк, фашист тоткынлыгында да иҗат эше белән шөгыльләнә. Туган илгә исән кайткан иптәшләрнең сөйләве буенча, Әхмәт Симаевның өч-дүрт шигырь дәфтәре булырга тиеш. Кызганычка каршы, алар илгә кайтмады. Мөгаен, кулга алу вакытында алар фашистларга эләккәндер һәм юк ителгәндер...

Әхмәт Симаевның геройларча үлеме совет халкына фашист Германиясе тармар ителгәннән соң ук билгеле булды. Әмма җәлилчеләрнең ничек җәзаланып үтерелүе турындагы документлар соңыннан гына табылды. Хәер, аңа кадәр Татарстан дәүләт музеена Көнбатыш Берлинда яшәүче доктор Каул бер документ — Әхмәт Симаевның үлем җәзасына хөкем ителүе турында карточка җибәргән иде.

Аннан язучы, публицист, Германия-Совет дуслыгы җәмгыяте Үзәк советы члены Леон Небенцаль тырышлыгы белән барлык җәлилчеләрнең җәзалап үтерелүе турындагы документлар табылды.

Бу документлардан (1944 елның 26 августында тутырылган 2972 номерлы үлем җәзасы турында белешмә) күренгәнчә, Әхмәт Симаев та, башка җәлилчеләр белән бергә, 1944 елның 25 августында 12 сәгать 24 минутта, Муса Җәлил, Гариф Шабаевтан соң җиденче кеше булып, җәзалап үтерелә. Җәлилче-патриотның гүзәл гомере шулай киселә.

Бөек Ватан сугышы тәмамлангач, хәрәкәттәге Кызыл Армиянең тылны саклау буенча НКВД гаскәрләре политбүлеге Мәскәү өлкәсе, Воскресенск шәһәренә, ВКП(б) райкомы исеменә, 15/2-4718 номерлы хат җибәрә. Бу хатта кызылармеец, чик сакчысы Козазаевның Германиядә совет журналисты Симаевның үлеме турында язу табуы хәбәр ителә һәм Козазаев хаты белән ул язуның копиясе бирелә. Менә ул: «Мәскәү өлкә газетасы редакциясенә. Түбәндә китерелә торган текст белән минем шушы хатымны урнаштыруыгызны үтенәм. Мин, полевая почта 14845-р хәрби часте кызылармеецы Козазаев, биредә, Германиядә, К. шәһәрендәге политик төрмәләрнең берсендә очраклы рәвештә киҗе-мамык тәрәзә пәрдәсенә юлыктым. Аңа рус хәрефләре белән нәрсәдер язылган иде. Мин аларга игътибар итмичә булдыра алмадым. Бу язуның текстын китерәм: «Монда Симаев, 1944 елның 12 февралендә икенче герман империя хәрби суды тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителгән мәскәүле журналист, утырды. Без, унбер рус кешесе, (җәлилчеләр күз алдында тотыла. — И. З.) барыбыз да политика өчен үлем җәзасына хөкем ителдек. Кем дә кем бу юлларны укыса һәм исән-сау Россиягә кайтса, Мәскәү өлкәсе, Воскресенскида яшәүче хатыным Валентина Листопадка яки Мәскәүдә яшәүче туганнарыма хәбәр итүен үтенәм. Симаев, 12 февраль, 1944 ел».

Безнең якын дустыбыз һәм туганыбыз иптәш Симаевның исемен белә алмадым, чөнки бозылган. Шуңа күрә сездән һәлак булган иптәшебез турындагы югарыдагы текстны урнаштыруыгызны, газета аша туганнарына, хатынына хәбәр итүегезне үтенәм. Адресы (урамы һәм йорты) язылмаган. Козазаев, 21 июнь, 1945 ел. Германия, Дрезден шәһәре. Копиясе дөрес: ... подполковник Помитяев».

Гази Кашшаф архивында 1945 елның 20 июнендә Совет Армиясе капитаны Лукъянов язган тагын бер хат саклана. Анда да, Симаевның хатынына адреслап, Әхмәт Симаевның фашист суды тарафыннан үлемгә хөкем ителүе һәм аның геройларча үлеме турында әйтелә.

Күренекле калмык шагыйре, М. Горький премиясе лауреаты Давид Кугультдинов Муса Җәлил турында болай язган иде:

«Ул үзен тоткын иткән коточкыч дәһшәттән көчлерәк булды. Чөнки ул хәзерге белән киләчәкне тоташтыра торган чорның бер өлеше иде. Аның җиңелмәс көче дә шунда. Муса Җәлил һәлак булды, әмма аның тормышы, аның шигырьләре кешелек дөньясы җыры булып калды».

Бу сүзләр, һичшиксез, Муса Җәлилнең дусты һәм көрәштәше Әхмәт Симаевка да карый.

# Саҗидә Сөләйманова

## Җәлил

Иңбашына соры шинель салган,
кирза итек кигән чолгаулап, —
көн тудисә
                    Җәлил шәһәрендә
һәр вахтага чыга шул солдат.

Сәламлиләр: шагыйрь бит бу диләр.
Кайберләре әйтә: сугышчы.
Данлы исеме белән
                    шагыйрьгәме,
солдаткамы Җәлил бурычлы?

Шагыйрьләр бит бармый үтерергә,
сугышчылар бара һөҗүмгә.
Солдат ата яуда дошманына,
ә шагыйрьләр төзи үлемгә.

Үлемнәрдән өстен
шагыйрьләрдә
иман шиксез,
йөрәк калкансыз —
кояшка һәм кылычларга ачык,
ояламый анда ялган сүз.

Үз чалымын, үз адымын танып,
эшче Җәлил — нефть төбәге
һәр вахтада үз сафына ала
солдат җанын, шагыйрь йөрәген.

## Җәүдәт Дәрзаманов

### Пистолет монологы

> Нишлим, нишлим, соңгы минутымда
> Пистолетым итте хыянәт...
>
> М. Җәлил.

Газраилең синең булалмагач,
Хыянәтче диеп атадың.
Мин корал тик, үз илем юк минем,
Кемдә булсам — шунда ватаным.

Бәхәсләшмим, өзгәләнү катыш
Һәрбер әйткән сүзең дәлилле.
Кичерегез, мин киләчәк өчен
Саклап алып калдым Җәлилне.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**СЕНТЯБРЬ, 1974 ел**

Двигатель белән тизлекне үзгәртү коробкасын сынау тәгәлләнгәннән соң, Дәүләт комиссиясе аларны Кама автомобиль заводы эшләячәк йөк машиналары өчен производствога тәкъдим итте.

Сынаулар Ерак Төньякта, Урта Азиядә, Кырымда һәм Кавказда — 40 градус салкынлыктан 40 градус җылылык температурасы шартларында үткәрелде. Ярославльдә ясалган двигательләр үзләрен Кама Батырларына чын-чынлап лаек йөрәк итеп күрсәттеләр — алар салкында токтарлыксыз кабынды, эсседә дә суыткыч система менә дигән итеп эшләде. Тизлекне үзгәртү коробкасы да гаять зур көчәнешне уңышлы кичерде.

**«Правда», Мәскәү.**

5 сентябрьдә Чаллыда партиянең Татарстан өлкә һәм Чаллы шәһәр комитеты активы җыелышы булды.

Кама автомобиль заводлары комплексының беренче чираты объектларын төзү барышы турында докладны КПСС өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Табеев ясады. Актив җыелышында СССР Министрлар Советы Председателе урынбасары, СССР Госстрое председателе И. Т. Новиков, КПСС Үзәк Комитетының машина төзелеше бүлеге мөдире В. С. Фролов, СССР Энергетика һәм электрификация министры П. С. Непорожный, СССР автомобиль промышленносте министры А. М. Тарасов, ВЛКСМ Үзәк Комитеты секретаре Д. Н. Филиппов, СССР Минмонтажспецстрой Главкасының баш инженеры В. М. Гончаров һ. б. лар чыгыш ясадылар.

Җыелышка шулай ук КПСС Үзәк Комитетының сектор мөдире В. М. Фролышев, РСФСР Госпланы председателе Н. И. Масленников, транспорт төзелеше министрының беренче урынбасары Н. Д. Соснов, СССР Госснабы председателе урынбасары А. А. Станиславов, СССР монтаж һәм махсус төзелеш эшләре министры урынбасары К. К. Липодат, СССР нефть һәм газ предприятиеләре төзелеше министры урынбасары Г. Н. Судобин, СССР элемтә министры урынбасары И. С. Равич, СССР һәм республика министрлыкларының, ведомстволарының җаваплы хезмәткәрләре катнашты.

**«Советская Татария», Казан.**

Львов инструменталь заводының төп продукциясенә— тешле тәгәрмәчләр ясау өчен кулланыла торган фрезларга Дәүләт сыйфат билгесе бирелде. Бүген продукциянең беренче партиясе Чаллыга җибәрелде. Быел Кама автогиганты Львов маркасы белән чыгарылган җитмештән артык исемдәге инструментлар алачак.

Завод продукциясе барлык союздаш республикаларга һәм дөньяның 25 иленә җибәрелә...

**ТАСС, Львов.**

Безнең әдәбият Горький традицияләрен уңышлы дәвам иттерә. Бу традицияләрнең берсе — тормыштагы яңа, әһәмиятле күренешләрне оператив яктыртып бару. Сугышчан публицистика, очерк алымнары белән язучыларыбыз халкыбызның фидакарь, бөек хезмәтен чагылдырган елъязма иҗат итәләр. Аларның күбесе үз иҗатларын КамАЗ, БАМ, зур электростанцияләр төзүчеләр белән якыннан бәйләде.

**«Правда», Мәскәү.**

Үзара экономик ярдәмләшү Советына кергән тугандаш социалистик илләр — Венгрия Халык Республикасы, Германия Демократик Республикасы, Куба Республикасы, Монголия Халык Республикасы, Польша Халык Республикасы, Румыния Социалистик Республикасы, Чехословакия Социалистик Республикасы делегацияләре Чаллыда булды.

Делегацияләрне СССР Госснабы председателе урынбасары В. М. Лагуткин, КПСС Үзәк Комитеты инструкторы Н. И. Лыков озатып йөрде.

Бигеш аэропортында кунакларны КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Т. Троицкий, КПССның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Р. Беляев, «Камэнергострой» производство берләшмәсе начальнигы В. А. Фоменко каршы алды.

Тугандаш илләрдән килгән кунаклар КамАЗның беренче карлыгачы — ремонт-инструменталь заводы белән таныштылар, автогигантның башка корпуслары төзелешләрендә булдылар, Чаллы шәһәрендәге торак төзелешләрен карадылар.

Партия өлкә комитеты секретаре М. Т. Троицкий делегация членнарына авыр йөк машиналары эшләп чыгарачак автогигантны төзү барышы турында сөйләде. Кунаклар СССР Госснабының Татарстан район материаль-техник тәэминат идарәсенә караган «Камснаб» универсаль склад-базасын зур кызыксыну белән карадылар.

**«Советская Татария», Казан.**

Төзелештәге партия оешмасында 600 дән артык политик мәктәпләр һәм семинарлар партия укуларына кереште. Экономик мәгариф челтәре 37 мең кешене берләштерә. 400 гә якын коммунистик хезмәт мәктәпләрендә тугыз мең кеше белем ала. Яңа уку елына әзерлек оешкан төстә бара, марксизм-ленинизм тәгълиматын эффектлы үзләштерүне камилләштерү буенча барлык мөмкинлекләрдән файдаланыла.

**«Социалистическая индустрия», Мәскәү.**

Киржач шәһәрендәге «Красный октябрь» заводы инженерлары «КамАЗ» автомашиналарына туктау сигналы һәм борылыш сигналы өчен ике режимлы фонарьлар конструкцияләделәр.

Моңа кадәр әле автомобиль фонарьлары көндез дә, төнлә дә бер генә режимда эшли иде. Ә төнлә кеше күзенең яктылык сизү сәләте югарырак була. Инженерлар, шушы үзенчәлекне искә алып, илебездә беренче тапкыр яктылыкның төрле режимнарында эшли торган фонарь уйлап таптылар. Моңа фонарьларда махсус оптик системалар куллану нигезендә ирешелде.

Киләчәктә мондый фонарьлар барлык төр автомашиналарда булачак.

**ТАСС, Владимир өлкәсенең Киржач шәһәре.**

Чаллы шәһәре яшьләре хунта властена каршы азатлык өчен көрәшүче Чили халкына теләктәшлек белдерәләр.

Шушы көннәрдә ремонт-инструменталь заводында Чили патриотларына теләктәшлек митингысы булды. Митингны РИЗ комсомол оешмасы секретаре

Б. Бочкарев ачты. Токарь Б. Вепрев бер көн эшләгән акчаны Чили патриотларына ярдәм фондына бирергә карар кабул итүләре турында сөйләде.

«Комсомолец Татарии», Казан.

Кама автогигантының ремонт-инструменталь заводында яшь фрезерчыларның алтынчы бөтенсоюз конкурсы үткәрелде. Үндүрт союздаш республика һәм Россия Федерациясе вәкилләре — зона ярышларында җиңеп чыгучылар — шушы белгечлек буенча чемпион исеме алу өчен ярыштылар.

Конкурсның шартлары — теорияне яхшы белү, катлаулы детальләрне тиз һәм яхшы сыйфатлы итеп ясау. Жюри Витебск шәһәрендәге Киров исемендәге станок төзү заводы фрезерчысы Анатолий Вороновны җиңүче дип тапты. Икенче урын Кыргызстан ССР вәкиле Геннадий Матюшовка бирелде. Өченче урынга Мәскәүдән Анатолий Петров чыкты.

ТАСС, Чаллы шәһәре.

Октябрьск шәһәрендә кызу темплар белән «Автоприбор» заводы төзелә. Бу предприятиедә автомашиналар өчен двигательләр, спидометрлар, электромоторлар һәм башка приборлар эшләнәчәк. Шундый утызга якын приборлар һәм аппаратлар «КамАЗ» автомобильләре өчен китәчәк.

«Автоприбор» заводлары комплексы 1975 елда сафка баса.

ТАСС, Башкортстан АССР.

Тимерчелек производствосының 5 нче ярдәмче цехы корпусында 2 сентябрьдә технологик җиһазларны монтажлау башланды. Бирегә 700 дән артык станок урнаштырылачак. Цехка илебездә һәм чит илләрдә эшләнгән иң яхшы үрнәкләр туплана. 5 нче корпусның проект куәтләре Мәскәүдәге Лихачев исемендәге автозаводта һәм Горький автозаводында ясалган. Корпуста елына 6 мең тонна штамплар әзерләнәчәк.

КамАЗның беренче карлыгачы — ремонт-инструменталь заводы эстафетасы тимерчелек заводы коллективына күчте.

«Советская Татария», Казан.

Куйбышев шәһәрендәге «Электрощит» заводы продукциясе төзүчеләр арасында бик популяр. Анда металл түбә конструкцияләре ясала. Алар гадәти түбәләргә караганда җиңел һәм төзелеш эшләрен кыска срокта башкарып чыгарга мөмкинлек бирә. Мондый конструкцияләр беренче тапкыр СССРның 50 еллыгы исемендәге Волга автомобиль заводы корылышында кулланылды.

Хәзер завод коллективы җаваплы заказны үти — Кама автомобиль комплексы өчен металл түбәләр әзерли.

ТАСС, Куйбышев.

Кама автомобиль комплексы төзелешендә хезмәт ресурсларын файдалану буенча Россия Федерациясенең крайлары, өлкәләре, автономияле республикалары идарә җитәкчеләре киңәшмәсе булды. Анда төзелеш подразделениеләре, автомобиль комплексы заводлары өчен кадрлар әзерләүне тизләтү мәсьәләләре каралды.

Киңәшмәгә КПСС Үзәк Комитеты инструкторы Д. Ф. Проценко һәм РСФСР Министрлар Советы Дәүләт комитеты председателе урынбасары И. Е. Быков катнашты.

«Советская Татария», Казан.

Мидхәт Миншин

# АК ЕФӘК

Таһирә Тәминдарова дәрестән күтәренке күңел белән чыккан иде. Буш сәгатьтә укучыларның дәфтәрләрен тикшереп алды: унынчы классларның язма эшләре бик әйбәт тәэсир калдырды. Әмма тәнәфес вакытында күңелсез хәбәр кереп әйттеләр: соңгы дәрестә бер малай тәртип бозган. Моның өчен кемнең-кемнең — класс җитәкчесенең йөрәге өзгәләнмәсмени. Унынчы класста укыйлар бит инде, унынчы класста, барысы да буйга җиткән егетләр, кызлар. Аларга «Тик утырыгыз!» дип әйтүе дә оят шикелле. Ә нишлисең? Әйтәсең, ачуланып та куясың.

Дәрестә үз-үзен матур тотмаган укучыны иптәшләре дә ярыйсы ук кыздырып алдылар. Таһирә Гарифовна тынычланып китте, — шулай инде ул: укытучы балаларга үпкәләп озак йөри алмый.

Таралыша башладылар. Шунда бер кыз өстәл янына килде, кулында — язучы Әмирхан Еникинең хикәяләр җыентыгы.

— Таһирә Гарифовна, менә «Кем җырлады» дигән хикәяне укыгач, мин гел сезне уйладым, — диде ул. — Анда Таһирә исемле кыз сурәтләнгән, аның җырларына кадәр китерелгән. Без сезнең җыр яратуыгызны да, сугышка катнашуыгызны да беләбез, әллә сез ме ул?!

Укытучы бер мәлгә әллә нишләп китте, тик үзен кулга алды. Дулкынлануын укучысына сиздермәскә тырышты. «Теге яки бу китапның геройлары кемнәр? Алар хәзер нишлиләр?» дигән сорауны ул беренче генә ишетми. Мондый сорауларга җавап биргәндә сәгатьләп сөйләргә туры килгәне дә бар. Карале, шундый сорауларны турыдан-туры аның үзенә бәйләделәр.

Укучы үз соравына үзе җавап биргәндәй әйтеп куйды:

— Хикәядәге җырчы кыз, фронтовик кыз Таһирә сезне бик тә хәтерләтә.

— Бәлки хәтерләтәдер дә, әмма минем кебек кызлар аз булганмыни. Ул сугыш еллары бит, сеңелем. Менә Әмирхан ага үзе дә ничек язган:

«Хәер, кем җырласа да барыбер түгелмени, тик җыр булсын. Җыр туктамасын. Татар җыры, Таһирә җыры, туган ил җыры...

Сарман буйларында киң ялан,
Печәннәре җитәр бер заман шул,
Печәннәре җитәр бер заман...

Таһирә еш-еш сулыш алды, яшь бөртекләрен тыеп калырга тырышты.

Укучы кыз, үзенең хаклыгын расларга теләгәндәй, хикәянең соңгы җөмләсен кычкырып укыды.

«Караңгы төндә каршы очраган эшелонның вагон ишегенә сөялеп ялгызы гына моңаеп җырлаган кыз исә чыннан да... Таһирә иде».

Укытучыга барысын да аңлатып бирергә туры килде. Казан шәһәренең Татарстан урамындагы 80 нче урта мәктәбенә кадәр нинди генә юлларны урамады ул.

...Кояшлы матур көн иде. Идел киңлекләре, Казан тирәсендәге күлләр, урманнар кемнәр күңелен генә үзенә тартмый икән. Студент кызларның йөрәкләре атылып чыгардай чиккә җиткән. Бөтен табигать тантана иткәндә, кияүгә чыгарга әзерләнгән кыз кебек чибәрләнәсе, бизәнәсе урында, утын сараена бикләнеп имтиханга әзерләнеп ят, имеш... Тик берни эшләр хәлең юк. Иртәгә чит ил әдәбиятыннан имтихан. Бу фән үзе очсыз-кырыйсыз диңгез кебек. Моңарчы гел «5»легә укып килгән Таһирә дә, Ольга да, Рита да шүрлиләр. Менә син Гетенең «Фауст»ын гына өйрәнеп кара. Укыган саен үзеңнең бик аз белгәнеңне абайлыйсың, укыган саен серен тирәнрәк ачасың.

Таһирә, Ольга, Рита — өчесе дә Владимир Ильич Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студентлары, булачак әдәбиятчылар. Берсе билеттагы сорауларны кычкырып укый, калган икесе җавап бирергә тиеш. Кемнең җавабы төплерәк — бергә-бергә анысын да ачыклап алалар.

Утын сараенда кызлар имтиханга әзерләнә. Яктылык күбрәк керсен дип, сулышка җиңелрәк булсын дип, ишекне ачып җибәргәннәр. Утын сараенда Шекспирлар, Гетелар, Гейнелар, Диккенслар, Флоберлар, Байроннар турында бәхәсләшәләр.

Кинәт урамда шау-шу күтәрелде. Кызлар, китапларын шырпы әрҗәсе өстендә калдырып, ачык ишек янына килделәр, колакларын торгызыбрак тыңлый башладылар, әмма бернәрсә дә аңламадылар. Тавыш-гауга күтәрелгәннән-күтәрелә. Кызлар аннан-моннан күлмәкләрен рәтләделәр дә урамга атылып чыктылар.

Репродукторлар беркетелгән баганаларны халык сырып алган. Шау-шу, чыр-чу арасында кемнең нәрсә сөйләгәнен дә аңлый алмыйсың, тик әледән-әле кабатланган бер сүз — «сугыш» дигән сүзне Таһирә бик тиз ишетеп алды. Аның күз аллары караңгыланып китте, гүяки бөтен күк йөзен кара болыт каплады. Тамагына төер утырды, янында басып торган Ольгага нәрсәдер әйтергә теләде, теле тотлыкты.

Әле генә бит алар Гейненың «Германия» поэмасын соклана-соклана укыдылар, шагыйрьнең үз иленә, үз Германиясенә булган мәхәббәтен уртаклашып утырдылар, Гейне Германиясен алар да ярattылар, ә совет халкына кул күтәргән Германия кемнеке соң ул?! Кемнеке?! Кешегә изгелек эшләү өчен теләсә нинди газапларга әзер торган Фауст, син кайда бүген! Нигә син Европаны таптап килүче шул вәхшиләрнең юлларын кисмисең? Фашист танклары, фашист самолетлары синең сихри кодрәтеңә дә бирешмимени?! Кешеләрнең елау тавышларын, Европаның ыңгырашуын ишетәсеңдер ич, Фауст!

Аякларына гер асканнармыни — кызлар, авыр-авыр атлап, көчхәл белән яңадан утын сараена керделәр. Шырпы әрҗәсе өстендә Гете, Гейне китаплары. Ә күңел күзе еракларак төбәлгән. Колакка туп шартлаулары, пуля сызгырулары, япь-яшь балаларның ачыргаланып кычкырган тавышы ишетелә сыман.

— Безнең семья ишлесен бик ишле, әмма барыбыз да диярлек кызлар, — диде Таһирә. — Бердәнбер абыебыз, ул да авыру. Димәк,

мин үзем сугышка китәргә тиеш. Әйе, әйе, мин сугышка китәргә тиеш.

Ул каударланып калын дәфтәренең бер битен ертты, кулына ручкасын алды, ашыгып-ашыгып яза башлады.

«...мине фронтка җибәрегез...»

Рита белән Ольга да гариза яздылар.

«Мине, Казан дәүләт университетының өченче курс студенткасын...»

Өч гаризаның өчесенең дә ахырына бер дата куелды. «22 июнь, 1941 ел».

Утын сарае тәрәзәсен зеңләтерлек итеп, көр тавыш белән Таһирә җырлап җибәрде.

Кара да гына урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә.
Кара урманны чыккан чакта
Кисеп алдым пар усак,
Ай, аерылмаек дус булсак.

Җырның сүзләрен рәтләп белмәсәләр дә, Ольга белән Рита Таһирәгә кушылды.

Ай, аерылмаек дус булсак.

...Кызларның гаризаларын комсомол җыелышларында, митингларда кычкырып укыдылар, әмма үзләрен фронтка җибәрмәделәр. Хәрби комиссариатта озын гына буйлы майор моның серен бик гади аңлатты.

— Илнең бүгенгесе никадәр авыр булса да, аның киләчәге дә бар ич, — диде ул. — Сез дә моңа шикләнмисездер. Димәк, яңа буыннарны үстерү хакында кайгыртмыйча булдыра алмыйбыз. Ил хәтле илгә солдат та, укытучысы да кирәк.

Кызларны колхозга эшкә җибәрделәр. Буразнада ялгыз калган тракторлар, покосларда калган чалгылар, авыл өйләренә иңгән моңнар, урамнарның әле берсендә, әле икенчесендә «я кайтырбыз, я кайтмабыз» дип кабатланган җырлар...

Кырларда игеннәр өлгерде. Бер кешене бишкә генә түгел, уңга бүлсәң дә, эш җитәрлек. Казан кызлары яулыкны арттан бәйләп, җиң сызганып печән чаба, урак ура, ат белән көлтә кертә, атлы машина белән ашлык суктыра, дәүләт амбарларына икмәк ташый. Тик шулай да фронтка җибәрүне сорап язган гаризаларын хәтерләреннән чыгармыйлар. Бер кузгалган күңелне яңадан үз урынына утырту авыр икән шул.

...Таһирәнең әнисе — тугыз бала анасы — авырып урында ята иде, тормышлар авыр, туйганчы бәрәңге дә эләкми. Ә кызның телендә бер сүз: «Сугышка китәм». Повестка килгән көнне «бәхет кошы» тоткан сыман, кая басканын белмичә йөрде. Аналар күңеле сизгер: балаларының күз карашыннан ук бөтенесен белеп тора, Маһикамал апа да кызы Таһирәнең йөрәгендә ниләр көйрәгәнен күрә иде, аларны сүндерергә уйламады, җиләктәй кызыңны сугышка чыгарып җибәрү җиңел, дип кем әйтер, түзде, хәтта үзенең авыруын да яшерергә тырышты.

«Исән-сау кайтуларыңны күрсәм иде, кызым», — дип кабатлады ана, — исән-сау кайтуларыңны...»

Юлга җыену артык мәшәкатьле булмады. Солдат кешегә күпме кирәк соң?! Капчыкка Лев Толстойның «Сугыш һәм тынычлык» дигән эпопеясы беренче булып урнашты. Аны Таһирә моңарчы да берничә кат укып чыккан иде, кайбер бүлекләрен яттан белә, әмма соңгы көннәрдә әсәр үзенчә бер киңәшчегә әверелде, аптырап калган чак-

ларда, ниндидер сорауларына җавап таба алмаганда Таһирә аңа ябыша, Наполеонны җиңгән батырлар гүяки кызны юатырга телиләр, «Мәңгелек данга күмелгән рус җирен беркем дә таптап мәсхәрәли алмас», диләр кебек.

Таһирә университетка барды, фәннәр кыясының ап-ак колонналарын кочаклый-кочаклый саубуллашты. Идел ярына төште. Туфлиларын салып, ялан аяклап су чәчрәтә-чәчрәтә, шактый барды. Аннары кушучлап Идел суын алды да күккә чөйде. Тамчыларның төрле якка сибелүен, су өстендәге алкаларның уйнаклап тәгәрәшүен хозурланып күзәтте.

Идел, Идел,
Тагын язлар килер.
Бозлар киткәч,
Мин дә кайтырмын.
Беркайчан да истән чыгармамын
Ярларыңда биргән антымны.

...Хәрби киемнәр кызларны алыштырып куйгандай итте. Күзгә каршына киләләр дә үзләрен-үзләре танымыйлар. Сары чәчле, вак кына сипкелле Таһирә кашларын җыерып, үзенә аеруча текәлеп карап торды.

— Әле ярый, сипкелләрем бар, югыйсә, үз-үземә «исәнмесез» дип әйтә яздым, — диде ул.

Кемдер «сипкелле, диләр сине, сөйкемле, диләр сине» дип өстәде. Бер-берсенә бармак белән төртеп күрсәтә-күрсәтә рәхәтләнеп көлештеләр, әйтерсең лә алар башында бернинди хәсрәт тә, күңелдә бернинди үзгәлэнү дә юк, фронтка түгел, ә үзешчәннәр концертына әзерләнәләрмени. Кешенең табигате шундый инде, аның серләрен беркайчан да аңлап бетерә алмассың, кайберәүләр үлгәндә дә елмая, көлә. Дөньяда бөтен нәрсә бергә урелгән: шатлыгы да, кайгысы да, моңы да, сагышы да, җитдилеге дә, мутлыгы да. Әле генә кычкырып елаган кеше онытылып-онытылып көлеп җибәрсә дә гаҗәп түгел.

Кызлар йөзендәге шаянлык-шуклык моңсулык белән алышынды. «Сугышка җибәрегез» дип әйтү бер хәл, инде аның чын сулышын тою икенчерәк икән, иңнәргә гүяки сугышның бөтен дәһшәте, фаҗигасе китереп басты. Таһирә дә сискәнеп куйды. Алар мизгел эчендә яшьлекләре, беркатлылыклары белән хушлаштылар, бик тә кырыс һәм күп төрле билгесезлекләр белән уралган киләчәк каршына бастылар.

Башта Горький шәһәренең Сормово районында элемтәчеләр хәзерләү курсында укыдылар. Аннан — ут сызыгына.

Таһирә — элемтәче. Разведчиклар һәр һава һөҗүме турында иң беренче элемтәчеләргә хәбәр итәләр, тегеләре — штабка. Минут кына түгел, секундның өлешләре дә исәптә. Аз гына каушау да, аз гына соңгару да һәлакәткә китерә.

Опухлики станциясенә гитлерчылар бик зур һава һөҗүме әзерләгән. Күктәге самолетларны санап бетерә торган түгел. Хәлнең әле бер, әле икенче якка үзгәрүен элемтәчеләр штабка хәбәр итәргә көчкә-көчкә өлгерәләр. Бөтен әйләнә-тирә тоташ ут эчендә. Андый нәрсәләр турында сөйләгәндә «ата улны, ана кызны белмәслек» диләр. Әмма элемтәче кызлар каушап калмадылар, һәр команданы үз вакытында артиллеристларга җиткерделәр, дошман самолетларының әле берсе, әле икенчесе кара төтен сузып җиргә дөмекте.

Бу сугыш бик күп яшь гомерне өзде. Менә шунда Таһирәнең күзләреннән яшьләр атылып чыкты. Дошманга булган үчнең, нәфрәтнең чиге юк иде. «Улыгыз һәлак булды, ирегез һәлак булды, кызыгыз һәлак булды» дип хат язудан да авыррак эш бар микән.

Кул карыша, каләм карыша, шуларны җиңеп хат язарга кирәк. Бу хатлар кемнәрне генә утка салмас.

Таһирә бер хат язып, өчпочмаклап кына куйган иде.

— Тизрәк штабка, — диделәр.

Бил каешын кыса төште, чәчләрен рәтләп пилоткасын киде дә йөгерде.

— Иптәш командир...

Аңа устав кушканча бөтенесен әйтеп бетерергә туры килмәде. Дивизион командиры кулын изәде, үзе элемтәче кыз каршына атлады.

— Бүгенге һава сугышлары вакытында төгәллегегез һәм кыюлыгыгыз өчен рәхмәт белдерәм!

— Советлар Союзына хезмәт итәм!

Замполит сүзгә кушылды:

— Без сине сугышчан характеристика белән партия сафларына кабул итәргә, дигән фикергә килдек. Үзең ничек уйлыйсың?

— Сез лаеклы санасагыз, ышанычыгызны аклау өчен бөтенесен эшләргә әзер.

Таһирә фронтка киткән көндә Идел ярларында биргән изге антын хәтереннән яңартты.

1944 елның июлендә дивизион землянкасында аңа партия билеты тапшырылды.

Землянка. Ул туган йортны да, театрларны да, партия билеты тапшыра торган бик тә кадерле биналарны да алыштырды. Кызлар яшәгән землянкалар үзенчә пөхтә, үзенчә җылы, үзенчә якты. Үзләренең салам түшәкләрен дә шундый итеп җыеп куялар, аларга күз төшергәч, күңел ял итә, әтиеңне-әниеңне, хатыныңны, балаларны искә аласың. Иңнәрдән сугыш авырлыклары төшеп тора сыман. Землянка эченә сыеша алмыйча җыр яңгырый. «Ашказар», «Карурман», «Сарман», «Ямьле Агыйдел буйлары»...

Уйнагыз да, җырлагыз да,
Гармун кулларыгызда;
Алсу гөлләр чәчәк атсын
Йөргән юлларыгызда.
Яз җиткәч, китә Идел бозлары...
Фронтларда орден ала
Татарстан кызлары.

Һөҗүмнәр тынганда һәр вакыт җырга вакыт табыла. Бөтенесеннән дә Таһирә уздыра. «Карурман» бер кичтә әллә ничә тапкыр кабатлана.

Дус-иш белән бергә сугышканда,
Теләкләргә тизрәк җитәрбез.
Кара урманны үткән чакта
Кисеп алдым куш каен,
Ай, аерылмабыз, дускаем.

Шушы җырларны ишетеп бер көнне землянкага фронтовик-язучы Әмирхан Еники килеп керде.

Казан кызлары белән Казан әдибе очрашты. Җырлар беркайчан да булмаганча дәртлерәк, моңлырак, сагышлырак яңгырады.

Бергә булулары бик күңелле,
Әмма аерылышу бик яман.

Таһирә «Сугыш һәм тынычлык» романын кулына алды. Аның кайбер битләрен кычкырып укыдылар. Аннан сүз татар әдәбиятына күчте. Әмирхан Еники дә бүләксез килмәде. Берничә хикәясен укып күрсәтте. Шул чак «воздух» дигән тревога яңгырады. Әле

генә җыр җырлап, тере язучының үз авызыннан хикәя тыңлап утырган кызлар кырысланып киттеләр, секундлар эчендә киенеп, үзләренең постларына йөгерделәр.

Җиңү көнен Таһирә Ригада каршылады.

1945 елның июне. Җиңү салютлары яңгыраганнан соң бер ай вакыт үтте.

Балтик буе фронтының данлыклы элемтәче кызларын озату тантанасы. Алар сафка тезелде. Артиллеристлар җиңү яулашкан кызларга рәхмәт белдерде. Гимнастеркаларында сугышчан орденнар, медальләр балкыган кызларга дивизион командиры ап-ак ефәк бүләк итте.

— Моннан сез туй күлмәкләре тектерерсез, — диде ул. — Авыр сугыш елларында һәркайсыгызны да танадык, сез яраткан егетләрегезне бәхетле итә алырлык кызлар. Сез безнең арабызда солдатлар идегез, инде туйлар үткәрегез, уллар, кызлар үстерегез.

Кызлар дивизион артиллеристлары турысыннан уздылар. Кулларында — ап-ак ефәк. Юлларыгыз да шундый ап-ак, якты булсын, кызлар.

Кызларга берәр пот ак он да бирделәр. «Бусыннан туй ашамлыклары пешерерсез», — диделәр. Заманы шундый, икмәк тә, күлмәк тә бик кадерле иде.

Ак ефәк сандык төбендә берничә ел ятты. Таһирә кирза итекләрен, шинелен Казанында да шактый киеп йөрде.

Әтисе Гариф агай сүзне кыска тотты.

— Әгәр матур киенәсең, биек үкчәле туфлиларда йөрисең килсә, эшләрсең, «фронт бүләкләренә» риза булсаң, укырсың, — диде ул. «Исән-сау кайтуларыңны күрсә идем, кызым», дип калган Маһикамал апа да, теләкләренең үтәлүенә ничек кенә сөенмәсен, барыбер ире сүзеннән чыга алмады. Тормышлар кыен, бик кыен иде, фронтның үз авырлыгы, әле генә сугышта җиңеп чыккан халык алдында тагын да күп авырлыклар тезелгән иде.

Шинель киеп, кирза итек киеп университет залларына керергә оялмады ул. Хәер, студентларның күбесе — кичәге фронтовиклар. Аяксызлар, кулсызлар нихәтле. Студентлык кенәгәсенә бары тик «бик яхшы» билгеләре генә төште, ашкынган йөрәккә бер нәрсә дә комачауламый икән.

Диплом яклау алдыннан ак ефәк тә сандык төбеннән чыкты. Таһирә аны изге истәлек кебек кулына алды, ике кулын алга сузып тәрәзә каршысына килде, үзе сизмәстән елап җибәрде. Ак ефәк, ак юллар, хыяллар. Әнә аспирантурага чакыралар. Егете дә ышанып олы юлга чыгарлык. Фронтовик. Әмирнең әтисе — педагог Әхмәтсәгыйр агай җыр дигәндә «үлеп» китә икән, килен булып төшмәс борын ук Таһирәне үз итте. Бергәләп «Ашказарны», «Тәфтиләү»не җырлап җибәргәннәр иде, өйдә елашмаган кеше калмады.

Фронтовик дуслар бүләк иткән ак ефәктән күлмәк тектереп, бу йорт бусагасын атласаң да, үкенмәссең: кыз моны йөрәге белән тойды. Әмма мондый чакта кем икеләнмәс, шөбһәләнмәс. «Әй, ак ефәк, син мине бәхетле итәрсеңме, бәхетле итәрсеңме?» — дип пышылдады Таһирә.

Әллә кайдан, бик ерактан аваз ишетелгәндәй булды? «Сез әйбәт сугышчылар икәнегезне ут эчендә расладыгыз, яраткан егетләрегезне дә бәхетле итәрсез, кешене бәхетле итүчеләр үзләре дә бәхетле булалар. Кулыңда ак ефәк, юлың да шуның кебек ап-ак булсын, Таһирә!»

Туй үткәч, Таһирәне Татарстан Мәгариф министрлыгына чакырдылар.

— Аспирантура ишекләре синең алда ачык, — диде министр. — Фронтовик, дәрәҗәле диплом. Күкрәгеңдә медальләр.

Әле «Тәминдарова» дигән яңа фамилиясенә ияләшеп тә бетмәгән Таһирә аны бик тыныч кына тыңлады.

Министр кулындагы карандашын өстәлнең бер читенә куйды. Таһирә сизенде: ниндидер көтелмәгән сүз әйтергә җыена.

— Бик күп укытучыларыбыз сугыш кырында ятып калды, кадрлар җитми. Авыл җирләрендә бигрәк тә, — диде министр. — Әллә берничә елга гына булса да, авылда укытып кайтасызмы?..

Ике фронтовик — Таһирә дә, Әмир дә «бармыйбыз» дип бер генә сүз ычкындырсалар да, аларны беркем дә кыстамас иде. «Үзләренчә» яшәп карарга хаклары бар иде аларның, бар иде. Тик бу «үзенчә» илдән-җирдән аерылмаган иде, фронтовиклар карышып тормадылар, икәүләп элеккеге Норлат районына киттеләр.

Җыр яраткан эшчән Таһирәне Күгәй авылы халкы үз итте, якын итте. Мәктәпнең үзешчән сәнгать түгәрәкләре гөрли, район смотрларында, республика смотрларында җиңүчеләр — алар. Спектакльләрне Казан шәһәренең культура сарайларында күрсәтәләр.

Таһирә апалары укучыларны үзе укыган университет белән таныштыра, опера һәм балет театры спектакльләренә алып килә.

Таһирә Гарифовна Казанда укыта башлагач та Норлат белән элемтәләр өзелмәде, үзләре дә баралар, тегеләренең дә эзе суынмый.

Ул рус теле һәм әдәбиятын укыта, әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре белән бәйләү буенча фәнни эзләнүләр алып бара, еллар буена тупланган күзәтүләрен «Совет мәктәбе» журналында язып чыга, Мәскәүдә педагогик укуларда докладлар ясый. Ул үткәргән ачык дәресләргә өлкәннәр дә, яшь укытучылар да сабак алырга керәләр.

Эше күп, хәтта кунакка чакырган Ольга һәм Рита янына барырга да вакыт таба алмый. Юкка гына «РСФСР мәктәпләре отличнигы» дигән исемгә лаек булмады ул, сугыш бүләкләре янына тыныч тормыш көннәрендәге батырлык билгесе — Октябрь Революциясе ордены өстәлде.

Сугыш кырындагы җырлар да онытылмаган, аларга тыныч хезмәт җырлары кушылды.

Өч кызы — Лариса, Әлфия, Миләүшә генә түгел, йөзләрчә, меңнәрчә егетләр, кызлар аны олы юл башында торучы бәхет маягы санайлар.

...Укучы кыз «Кем җырлады» хикәясендәге Таһирә сезме, түгелме?» дип бүтән сорамады, класс җитәкчесенә сихерләнеп карап торды, аннары үзе уйлаганнарны китапның беренче битенә язып, укытучысына бүләк итте.

Укучы кыз класстан чыгып киткәч тә Таһирә япа-ялгызы шактый вакыт утырды. «Кем җырлады» дигән хикәяне яңабаштан укыды. Барысы да таныш, таныш, әйтерсең лә үзеңнең йөрәгеңнән өзелеп төшкән.

Кояшка карап торган зур-зур тәрәзәләр каршысына килеп, урамга караш ташлады. Киңәеп, матураеп барган Татарстан урамы гөрли. Троллейбуслар, трамвайлар, автомашиналар чаба. Җәяүлеләр ашыга.

Төрле төстәге шарлар, ленталар белән бизәлгән җиңел машиналар Таһирәнең игътибарын җәлеп итте. Туйга баралар. Әнә кызларының ак күлмәкләре дә күзгә чалынып китте.

Юлларыгыз да ак булсын, пакь булсын, кызлар!

Рим Кәримов

# ДРАМАТУРГИЯБЕЗ ГОРУРЛЫГЫ

1975 елның 15 сентябрендә татар совет драматургиясе классигы Таҗи Гыйззәтнең тууына 80 ел тула.

Таҗи Гыйззәт утыз дүрт әсәр язып, шуларның утыз өчесен сәхнәгә күтәрә алган драматург, сәхнәдә дистәләрчә рольләр уйнаган актер, иҗатта үз алымнарын урнаштырган, драматургиясе яшь әдипләр өчен мәктәп дәрәҗәсенә күтәрелгән каләм иясе.

Аның драматург, артист һәм җәмәгать эшлеклесе булып күтәрелеп чыгуы хезмәт иясе халкы тормышында Бөек Октябрь социалистик революциясе тудырган яңарышның ачык бер мисалы була ала. Яшүсмерлек чорын байлар, муллаларда батраклыкта уздырган крестьян егете Октябрь революциясен эшче булып каршылый. Кулына корал тотып, совет властен саклаша, зур тормыш һәм көрәш мәктәбе үтеп актер, драматург булып җитешә. Һәм ул үз әсәрләрендә революциягә кадәрге авыл тормышы, крестьянның азатлык-бәхет өчен яуга күтәрелүе, ниһаять, яңа тормыш төзү өчен көрәше турында дулкынланып һәм дулкынландырырлык итеп сөйли алды.

Мондый уңышларның сере авторның драматургик талантында гына түгел, ә шул катлаулы чорның үзе белән бергә үзгәргән, үскән кешеләрнең берсе булуында, көн тәртибенә куелган иң актуаль мәсьәләләрне әсәрләрендә кыю рәвештә күтәреп һәм гражданлык җаваплылыгы тоеп хәл итәргә тырышуында иде. Туган илгә, халкына мәхәббәте, ил язмышы өчен һәр даим борчылып яшәве тынгысыз иҗатчыга кулын хезмәттән аерырга ирек бирмәде.

Гомеренең үткәне һәм хәзергесе турында уйланып, 1939 елда ул үзе болай дип язды:

«Мин үземнең барлык үсешем өчен Советлар властена бурычлымын. Октябрь революциясеннән соң мин актер һәм драматург булдым. Мин үземнең пьесаларымда Октябрь чорында һәм коллективлашу чорында крестьяннар кичергән грандиоз переворотны сурәтлим. Минем уйларым һәм хисләрем халык белән» [1].

Драматургның иҗат мирасын игътибар белән күздән кичереп әсәрләренең тематикасын, алынган тормыш материалын тикшереп чыксаң, Таҗи Гыйззәт пьесалары илебез кичергән иң катлаулы чорларның художестволы елъязмасы икәнен күрергә була.

«Наемщик», «Ялкын», «Чаткылар», «Ташкыннар», «Бишбүләк»... Бу әсәрләр идеятематик яктан бер-берсенә бик якын торалар, хронологик яктан караганда, әзлекле тарихи вакыйгаларга нигезләнгәннәр. «Наемщик» музыкаль драмасы Россиядә крепостной хокукның бетерелүенә бәйле вакыйгаларга корылган, «Ялкын» узган гасырның 70 нче елларында Казан губернасында булып узган крестьян күтәрелешләре хакында

[1] «Совет әдәбияты» журналы, 1939 ел, 1 сан.

сөйли. «Чаткылар» драмасы нигезендә Столыпин реакциясе чорындагы тарихи вакыйгалар ята. Биредә крестьяннарның патша хөкүмәте уздырган җир политикасына каршы көрәше тасвирлана. «Ташкыннар» трилогиясендә исә драматург үз алдына тагын да масштаблырак һәм катлаулырак бурычны куя: илебездә барган тарихи вакыйгалар фонында татар крестьянының ни рәвешле Бөек Октябрь социалистик революциясенә, яңа тормышка килүен күрсәтә. Һәм, ниһаять, «Бишбүләк» драмасында гражданнар сугышы чоры, татар крестьяннарының Октябрь революциясе казанышларын саклап калу өчен алып барган көрәше гәүдәләнә.



Драматургиябезнең алтын фондына кереп калган бу әсәрләрнең барысы да социаль конфликтка нигезләнгән. Тормыш материалы, әсәрдә күтәрелгән теманың шул чорның асыл сыйфатын билгеләүче үзәк мәсьәлә булуы үзе шуны таләп итә. Тормыш дөреслегенә һәм тарихи чынбарлыкка турылыклы булу, аны художестволы сурәтләүдә анык партияле мөнәсәбәт — Таҗи Гыйззәт иҗатына хас төп сыйфатларның берсе. Тарихи-революцион темага язылган пьесаларында автор тормыш дөреслеген сәнгатьчә сурәтләүдә драматургиябез өчен яңа казанышлар яулый, гади хезмәт кешеләре арасыннан күтәрелгән, заманның прогрессив идеалларын үзләштергән герой образларын тудыруга ирешә. Шунысын әйтергә кирәк. Таҗи Гыйззәт крестьян тормышының авырлыгын, аяныч чынбарлыкны күрсәтүне төп максат итеп куймый. Авыл хезмәт иясенең бөлгенлеге изүче көчләргә каршы көрәшнең зарурлыгын китереп чыгаручы нигез итеп тасвирлана. Иҗатында аңлы рәвештә сайланган бу юл Таҗи Гыйззәт әсәрләрен яңалык, бәхетле киләчәк өчен көрәшүче сәнгатьнең алгы сафына куйды, әдәбиятыбызда тарихи чынбарлыкны чагылдыруның яңа алымнарын урнаштыруда зур уңай йогынты ясады.

Таҗи Гыйззәтнең драма әсәрләренә сюжет катлаулылыгы хас. Әмма әйтергә теләгән фикернең ачыклыгы, характерларның пәрдәдән-пәрдәгә эзлекле рәвештә үстерелә килүе әсәрләрне бербөтен итә, сюжет җепләрен чуалтырга ирек бирми. Чөнки төрле коллизияләр драманың төп конфликтыннан аерылып китмиләр. Һәр персонаж вакыйгага карата үз мөнәсәбәте белән килеп керә. Хәл ителергә тиешле мәсьәләгә карашында, шуңа катнашуында аның характеры ачыла, тулылана бара. Геройлар әсәрдә тасвирланган чордан аерып алып булмаслык дәрәҗәдә конкрет тарихи шартларда яшиләр. Әйтик, «Ташкыннар» драмасында тормышка буйсынып, гаделсезлекләргә күз йомарга тырышып яшәгән Биктимер карт социаль тигезсезлек тарафыннан тудырылган бәлаләр үз җилкәсенә өелә барган саен, крестьян психологиясенә хас йомыклыгын җиңә барып, революцион көрәшкә якынлаша.

Биктимерның семья әгъзалары да һәркайсы үз язмышларын кичереп, социаль бәрелешләр юлына керәләр. Драмада катлаулы сыйнфый көрәш атмосферасы һәр персонажның илдә барган вакыйгаларны үзенчә аңлавы, максатына үзенчә омтылышы фонында, шулар аша тудырыла.

Биктимер, Гайнавал, Нургали, Гөлчирә акрынлап, эчке каршылыкларын җиңеп, Мирвәли һәм Артамоновлар юлына басалар. Көндәлек авыл тормышын, андагы үзгәрүләрне драматург илдә барган зур политик вакыйгалар белән бәйләнештә тасвирлый. Шул рәвешчә, авылдагы төрле социаль катлауларның үзара мөнәсәбәтләрендәге каршылыкның асыл сәбәпләре ачылып китә. Автор шулай ук авыл халкының революцион көрәшкә килүендә эшче сыйныф вәкилләренең, большевикларның (Мирвәли, Артамонов) ярдәмен, аларның җитәкчелек ролен күрсәтүгә зур әһәмият бирә. Шуның белән Биктимер, Гайнаваларның Шәүлихан семьясына каршы көрәшкә күтәрелүе крестьянның сыйнфый аңы үсүе нәтиҗәсе булып кабул ителә. «Ташкыннар» драмасын шушы ике семья арасындагы конфликтка нигезләп, Таҗи Гыйззәт илебездә беренче импе-

риалистик сугыш еллары һәм революция чорындагы социаль каршылыкларның бөтен катлаулылыгын кешеләр язмышы аркылы күрсәтә алды.

Кешеләр арасындагы шәхси мөнәсәбәтләрнең социаль нигезләрен эзләү Таҗи Гыйззәт драматургиясенә гомумән хас сыйфат. Ул барлык әсәрләрен шушы принципка таянып язды. Һәм башка драматурглардан да шуны таләп итте. «Гамир Насрый иҗаты турында» исемле мәкаләсендә Таҗи Гыйззәт болай ди: «...Драма әсәрләребезнең конфликтлары нинди дә булса иҗтимагый, дәүләт интересларын алга сөрү нигезендә булырга тиеш. Югыйсә... әсәрдә нигез ташы булырлык идея көрәше булмаганлыктан, автор примитив рәвештә ясалма конфликтлар уйлап чыгара»[1].

Таҗи Гыйззәт «...авыл тормышыннан алынып язылган драма әсәрләрендә кыз белән егет арасындагы мәхәббәтне төп тема итеп, шул чорның политик, экономик шартларын томалап калдыруга» каршы чыкты. «Татар тормышын башка милләт хезмәт ияләре тормышыннан аермаска»[2] чакырды. Дөрес, кыз-егет мәхәббәтенә бәйләнешле вакыйгалар үстерелешен эченә алган әсәрләр Таҗи Гыйззәт иҗатында да бар. Мәсәлән, «Чаткылар», «Ялкын», «Наемщик» драмаларын шундыйлар рәтенә кертергә мөмкин. Ләкин бу әсәрләрдә мәхәббәт коллизиясе ярдәмче вазифаны үти. «Чаткылар»дан Маһи, Гаяз һәм Сабир мөнәсәбәтләрен алып карыйк. Авыл кулагы Сабир Маһины үзенә алырга омтыла. Ләкин Маһи тимерче егет Гаязны сөя. Ярлы егете Гаяз Сабирны сөйгәненә өйләнергә йөргәне өчен генә дошман күрми бит. Барыннан да элек, ул аның сыйнфый дошманы. Әсәрдәге бу мәхәббәт тарихы хезмәт иясе крестьяннарның кулак сыйныфка каршы, шуның аркылы патша монархиясенә каршы күтәрелүен тасвирлау өчен сюжет кору чарасы гына булып урын ала. Бу мәхәббәт әсәрдә изүче һәм изелүче катлаулар арасындагы көрәшне активлаштыручы этәргеч рәвешендә килеп керә кебек. Шулай итеп, кешеләр арасында булган шәхси мөнәсәбәтләр сыйнфый бәрелешләр драмасына үсеп китә.

Халкыбызның тарихи үткәнен тасвирлауда Таҗи Гыйззәтнең иҗат принциплары ачык. 1937 нче елның 5 нче ноябрендә «Ташкыннар»ның премьерасыннан соң язган истәлегендә ул, беренчедән, «...хезмәт иясе крестьяннардан көлеп, аларның тормышларын комедия рәвешендә бозып күрсәтүгә», икенчедән, «...артистларның автор ялгышларын тагын да күпәртеп уйнап килүләренә» каршы чыга, «...мин авыл тормышының үзем белгән, үзем яшәгән чорларын бөтен тулылыгы белән чагылдырырга тырышам»[3],— ди.

Драматург әдәбиятта гына түгел, гомумән сәнгатьтә батырлык, кыюлык, тырышлык һәм эзләнүне расларга тырышты. Һәм башкаларны да шуңа өндәде. Бу җәһәттән Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар» әсәрен Башкорт дәүләт театрында сәхнәгә куючы режиссер Имашевка язган хатыннан түбәндәге юлларны китерү урынлы булыр: «Ташкыннар» әсәрен уйнаганда артык кайгы-хәсрәт якларына басым ясап, әсәрдәге батырлык пафосын җуюга барылмасын. Бигрәк тә Биктимер карт образында сак булырга кирәк. Соңгы пәрдәләрдә көрәшкә сәләхиятле булган көчле крестьян картын китереп бастырырга кирәк. Уңай рольләрне башкарырга көчле артистларны куегыз»[4].

Мәгълүм булганча, укучы, тамашачы, әсәрдә яки сәхнәдә үз теләк, омтылышларын тапса гына, күңелен сафландырып, дәртләндерә алган көрәштәш образлар белән очрашса гына сәнгать әсәрен кабул итә. Тамашачыны тәрбияләү ягыннан, аны сәнгатькә якынлаштыру җәһәтеннән Таҗи Гыйззәт драматургиясе зур урын тота. 20 нче еллар ахыры, 30 нчы еллар башы — татар театры репертуарының тематик яктан шактый чуар, драма әдәбияты һәм сәхнә сәнгатенең яңалык, «заманчалык» эзли-эзли реалистик нигездән тайпылгалап, төрле формалистик «изм»нар белән авырып алган чагы. Кәрим Тинчурин «Совет драматургиясенең бүгенге хәле» исемле мәкаләсендә тирән борчылу белән болай дип язган иде: «...Тормыш, тарих дөреслегеннән аерылып, каһарманнарны әкият батырларына әйләндерү кызыл романтизм була алмый, ...әсәрдәге каһарманнарның характерлары өстендә эшләү мәсьәләсенә килгәндә, бу турыда эшләр бигрәк тә начар тора. Һәрбер каһарманның үткәндәге, бу көнге, иртәгеге характеры күренеп торырга тиеш. Шулай булганда гына каһарман чын кеше, тамашачыда тирән тәэсир кал-

---

1 «Совет әдәбияты», 1951 ел, 5 сан, 119 бит.
2 «Совет әдәбияты», 1936 ел, 4 сан, 41 бит.
3 Истәлек. Драматургның архивында саклана.
4 Хат 1938 елның 8 февралендә язылган, шулай ук драматургның архивында саклана.

дыра ала торган кеше булып чыгачак. Бездәге драма әсәрләрендәге каһарманнарның унысыннан бер кеше ясап булмый»[1].

Шушындый борчулы эзләнүләр чорында Таҗи Гыйззәтнең тарихи-революцион темага язылган драмаларының сәхнәдә үзәк урынны алулары гаять әһәмиятле иде, алар театрыбыз эшендә социалистик реализм принципларының ныгып урнашуына ярдәм иттеләр.

Таҗи Гыйззәт әдәбиятка театрдан килгән драматург. Һәм монда ул театрыбыз корифее Кәрим Тинчуринның реализм мәктәбе принципларын үзләштерә, әдәби осталыкка өйрәнә. «Миңа Тинчурин школасы белән барасың, Тинчурин алымнарын кулланасың, диләр. Кәрим ага минем артистлык ягыннан гына түгел, драматург булу ягыннан да остазым. Мин башка драматургларга да аңардан өйрәнергә киңәш бирер идем»[2],— ди ул. Таҗи Гыйззәтнең тарихи-революцион темага язылган драмаларында Горький һәм Тренев пьесаларының да йогынтысы сизелә.

Таҗи Гыйззәт барлык әсәрләрендә дә диярлек заманның актуаль проблемаларына мөрәҗәгать итте, аның һәр яңа әсәре яңа тормыш өчен көрәш сафына басты. Совет авылы темасына язылган пьесалар үз вакытында әнә шундый көрәшче әсәрләр булдылар. «Ил үскәндә», «Бөек борылыш», «Чулпан», «Фамилиясез тимерче», «Мактаулы заман» һәм башка пьесалар совет авылында яңа социалистик мөнәсәбәтләр урнаштыру чорын чагылдыралар. Аларда бу процессның катлаулы һәм каршылыклы булуы ачыла, авылдагы социалистик ярыш шартларында крестьян психологиясендәге үзгәрешләр, яңа кеше формалашуы күрсәтелә.

Утызынчы еллар өчен бу тема үзенең сәнгатьчә чагылышын табарга тиешле яңа тема иде һәм Таҗи Гыйззәт иҗатының бу юнәлешендә дә эзләнүләрен тормышны ныклап өйрәнүдән, һәр яңалыкның асылын төшенергә, аның үсеш тенденцияләрен ачык күрергә тырышудан башлый. «Колхоз минем иҗат мәктәбем» исемле мәкалә бастырып, «авылдагы тормышны, социаль үзгәрешләрне, элекке аерым хуҗалык, хосуси милекчелек крестьяныннан яңа кешеләр туып килүен күрергә» омтылуын әйтә. «...Элеккеге патша хөкүмәте авылында үткәргән унбиш ел гомерем минем йөрәгемдә онытылмаслык ач-ялангачлык, җәбер, золым, күз яшьләре белән истә калсалар, бүгенге авылда күргән шатлыкларым мәңге онытылмаслык хатирәләрен исемдә калдырдылар. Бу тәэсирләр минем иҗатыма әйтеп бетергесез көчле, тирән йогынты ясадылар»[3],— ди ул.

Совет авылы темасына язылган бу әсәрләр утызынчы елларда гаять популярлашалар. Профессиональ театрларда, шулай ук республикабыз үзешчән сәхнәләрендә иң күп куелган әсәрләр булып, агитацион драмаларга әвереләләр.

Бу уңайдан бер күренекле вакыйганы искә алып китик. Кискен сыйнфый көрәш аша кумәкләшеп килгән колхоз тормышын чагылдырган «Мактаулы заман» әсәре сәхнәгә куела. Сыер, үгезләр турында язылган дип, театрга шикләнебрәк кабул ителгән бу комедия академия театры сәхнәсендә искиткеч зур уңыш белән бара башлый. Махсус эшелоннарга төялеп Арча, Кукмара районнарыннан колхозчылар спектакль карарга киләләр. Составның алдына кызыл комачка «Мактаулы заман»ны карарга киләбез» дип языла, вокзал каршында митинглар оештырыла, урамны шаулатып оркестр уйный. Бу көннәр совет сәнгате бәйрәменә әверелә. Эш шунда ки, бу еллар татар совет театры үз йөзен, башкару стилен эзләгән, заманча яңгырашлы репертуар булдырырга тырышкан, тамашачы белән якыннан аңлашырга, үзара нык-лы мөнәсәбәт урнаштырырга омтылган еллар иде.

Совет чынбарлыгын гәүдәләндергән, театрда һәм драматургиядә хезмәт темасын алга чыгарган әсәрләр бу елларда инде шактый күренә башлый. Шулар арасыннан «Мактаулы заман», «Кандыр буе» (Кәрим Тинчурин әсәре), «Габбас Галин» (Ш. Камал әсәре) кебек драмалар татар театры һәм драматургиясендә социалистик хезмәт темасының үстерелеш юлын билгеләүче әсәрләр булдылар. Әдәби һәм театраль тәнкыйть тә ул вакытта ук бу пьесаларның сәхнәгә менү фактын югары бәяли. «Өч постановкадан соң театр тарафыннан 200 тамашачы, язучылар, артистлар катнашы белән поста-

---

[1] «Совет әдәбияты», 1933 ел, 2—3 сан, 107 бит.
[2] «Совет әдәбияты», 1936 ел, 4 сан, 41 бит.
[3] «Совет әдәбияты», 1933 ел, 8—9 сан, 71 бит.

новка турында киңәшмә, фикер алышу үткәрелде. Киңәшмәдә «Мактаулы заман» әсәре һәм аның постановкасы тамашачылар тарафыннан да хаклы рәвештә макталды. Чыннан да, Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә «Мактаулы заман»ның куелуы театр һәм татар совет драматургиясе өлкәсендә булган күренекле бер вакыйгага әйләнде»[1].

Таҗи Гыйззәт драматургиясе тематик яктан бай, жанр ягыннан төрле. «Таймасовлар», «Төнге сигнал», «Изге аманәт», «Чын мәхәббәт» драмаларында халкыбызның сугыштагы һәм хезмәттәге батырлыгы гәүдәләнә, социалистик Ватәнны саклап калу өчен аяусыз көрәше күрсәтелә. «Таймасовлар», Бөек Ватан сугышы алдыннан сәхнәгә менеп, тамашачыда патриотик тойгы тәрбияләү җәһәтеннән зур эш башкарды. Сугыш кырларында чын батырлыклар күрсәткән якташларыбыз образларын гәүдәләндергән «Изге аманәт» һәм «Чын мәхәббәт» сугыштан соңгы елларда театрларыбызның озын гомерле спектакльләре булдылар.

Таҗи Гыйззәт комедия остасы да иде. 1940 елда сәхнә күргән «Кыю кызлар» комедиясе Гадел Кутуй сүзләре белән әйтсәк «...узган гасырның 80 нче елларындагы татар тормышының энциклопедиясе»[2] булып калды. «Кыю кызлар» комедиясенә югары бәя биреп, Муса Җәлил болай дип язган иде: «Кыю кызларның уңышы шунда — иске татар мәдрәсәсен һәм аның руханиларының бозык семьяларын оста, үткен сатира каләме аша җанлы итеп күз алдына китереп бастыра алуында. Иске татар мәдрәсәсен болай җанлы итеп сурәтләгән театр әсәре бездә әле булганы юк иде»[3].

Татар театры сәхнәсендә беренче музыкаль комедия либреттосын иҗат итүче дә Таҗи Гыйззәт булды. Сүз «Башмагым» музыкаль комедиясе турында бара. Драматург Таҗи Гыйззәт һәм композитор Җәүдәт Фәйзи 1941 елның ахыры, 1942 елның башында бергәләп «Башмагым» музыкаль комедиясен язалар һәм февраль аенда беренче татар опереттасы дөньяга туа.

«Башмагым» — тамашачыларда искиткеч зур популярлык казанган спектакль. Аның Казан театрларында 500 мәртәбәдән артык уйналуы, Свердловск, Киев, Харьков, Улан-Удэ, Ташкент, Самарканд сәхнәләрендә уңыш белән баруы шул хакта сөйли.

Таҗи Гыйззәтнең музыкаль театр сәнгатен үстерү өлкәсендәге хезмәтләре моның белән генә чикләнми. Мәгълүм булганча, 20 нче еллар ахырында һәм утызынчы елларда театрларыбыз репертуарында музыкаль драмалар һәм музыкаль комедияләр шактый зур урын алалар. Бу — табигый хәл, театрыбыз үсешендә яңа бер этап иде. Чөнки халкыбызның үз театрында опера һәм оперетта тыңларга теләве заман тудырган яңа бер ихтыяҗ булды. Әле ул вакытта опера театры булмаганлыктан, Татарстанда бу вазифаны да драма театрлары үтәп барырга тиеш иделәр. Мирхәйдәр Фәйзи, Кәрим Тинчурин әсәрләре, Таҗи Гыйззәтнең «Наемщик», «Бишбүләк», соңрак «Башмагым» музыкаль комедиясе музыкаль театрыбызның репертуарын тәшкил иттеләр, опера театрыбыз өчен җырлек һәм музыкаль кадрлар хәзерләүдә үзенә күрә бер мәктәп булдылар. Күренекле композиторыбыз Җәүдәт Фәйзи 1970 елның 13 нче сентябрендә радио аша ясаган бер чыгышында болай дигән иде: «Таҗи Гыйззәт үзенең «Наемщик» драмасы белән Сәйдәшевнең чын иҗат юлын ачты. Һәм зур композитор булуын халыкка танытты. Төрле характерлы образларга бай, төрле контрастлы эпизодлардан торган «Наемщик» әсәре Салих Сәйдәшевның киң колачлы һәм үзенчәлекле талантын җәелдереп җибәрергә бөтен мөмкинлекләрне тудырды. Күңеле белән музыканы сөйгән, сәнгать төрләрен тирәнтен аңлаган Таҗи Гыйззәт иҗатын музыка авазлары белән дә тулыландыруны зарури эш дип карады һәм ялгышмады. Шуңа күрә драматург Таҗи Гыйззәт турында сүз барганда музыка сәнгатен телгә алмый кала алмыйбыз. Киресенчә, сүз музыка турында бара икән, без Таҗи Гыйззәт исемен композиторлар белән янәшә куеп, зур ихтирам белән телгә алабыз».

Таҗи Гыйззәт әсәрләре инде менә илле ике ел буена сәхнәдән төшмичә уйналып киләләр. Шул гомердән бирле аның драма һәм комедияләре куелмаган бер генә сезонны да таба алмыйсың. Ә үзешчән сәхнәләр өчен ул элек-электән иң популяр драматургларның берсе булды.

---

[1] «Совет әдәбияты», 1936 ел, 3 сан, 67 бит.
[2] «Красная Татария», 1940 ел, 12 январь.
[3] Сайланма әсәрләр, Казан, 1956 ел, 3 том, 293 бит.

Халкыбызның данлы тарихи үткәнен, заман темасын, чорның кичектергесез мәсьәләләрен үз вакытында театрда гәүдәләндерү — әдәбиятның һәм сәнгатьнең мактаулы, авыр бурычы. Коммунист язучы Таҗи Гыйззәт утыз елдан артыгракка сузылган иҗат гомерендә шушы юлдан тайпылмыйча, көрәшче драматург, артист һәм актив җәмәгать эшлеклесе булып узды. Һәм хәзер дә аның әсәрләре театрыбыз сәхнәләрендә сәнгатебезнең шушы бурычын үзеннән соң килгән иҗатчыларның әсәрләре белән тигездән бүлешеп башкаралар.

## Таҗи Гыйззәт

# ИДЕЛ БУЙЛАРЫ

ЮЛЪЯЗМАЛАР

Май аеның соңгы көннәре. Ульянов шәһәреннән киткәннән соң безнең пароход йөрешен тизләтте. «Якты чакта Жигули тауларын күреп калыйм», дип ашыга торгандыр, ахры. Бер тәүлектән артык яуган яңгырдан соң, яз кояшы бүген шактый кыздырды. Бар тереклек, бар үсемлек тәрләренә яшәү өчен кирәк булган шифаларын биреп арыды, күрәсең, кызгылт тәскә кереп, кичкә таба авышты. Мондый көннәрдә табигатьтә тынычлык хөкем сөрүчән булганга, бүген дә әйләнә-тирәдә җил дә, давыл да, шау-шулы авазлар да ишетелми. Чал сакаллы Идел өстендә бер генә хәрәкәт, бер генә кыймылдау билгеле күренми.

Ялтырап яткан Идел өстен чуарлатып, салмак кына саллар ага. Тирән тубаларга, чоңгыл урыннарга көймәләре белән балыкчы бабайлар утырганнар да, кайсы кармак, кайсы җәтмә, кайсылары җылым салалар. Ара-тирә кыр казыдай баржалар таккан буксир пароходлары, әллә каян аваз биреп, безнең белән исәнләшеп узалар. Яр буенда таулар, урманнар, түйра таллыклар, хәтфә төсле яшел болыннар, иген кырлары, җимеш-яшелчә бакчалары кала.

Гигант һава корабларын озата барган истребительләр шикелле, безнең пароход артыннан төркем-төркем карлыгачлар, акчарлаклар ияргән.

Көчле пароход гәүдәсенең кысрыклавы нәтиҗәсендә ике якка аерылган сулар шәүләләнеп китәләр дә, бара-бара көчле дулкыннарга әйләнеп, Идел өстендәге чүпчарларны читкә куалар.

Кояшлы, матур көн булганга, яшьрәк юлчылар бөтенләй каюталарына кермиләр, көлешә-көлешә палубада сөйләшеп йөриләр. Бертөрлеләре сугыш, халыкара хәлләр, аерым дәүләтләрнең политик платформалары турында төрле бәхәсләр, әңгәмәләр алып баралар. Хәрәкәткә саран картлар, йомшак креслоларга кырын ятып, газета-журнал, китап укыйлар. Карчык-корчыклар булса, яшьләргә акыл өйрәтеп, үгет-нәсихәт укыйлар. Аскы катта да тормыш кайный, һәркем үз эшендә, кайсы юына, кайсы кырына, кайсы тәмләп чәй эчә. Кайсы булса гырлый-гырлый йоклый симертә. Тик бер татар кызы гына пароход койрыгында чалкан яткан да:

**Стенада ике табель,**
**Берсе календарь микән,**
**Әллә ранин, әллә үлгән,**
**Әллә пленда микән,**

— дип моңлана. Тавышы көчле булмаса да, ул татар көйләренең көчле аһәңнәрен, тирән тойгыларын искитәрлек оста итеп йөрәккә сала. Җырларының мәгънәләренә

караганда, фронтта булган иң якын кешесенең язмышы турында кайгыртып моңланганы аңлашыла. Әйе, немец илбасарлары тарафыннан безгә көчләп тагылган бу сугыш бик күпләрне сагынып җырлатырга, бик күпләрне ачы күз яшьләре белән елатырга мәҗбүр итте.

...Ставрополь пристаненнан китү белән зәңгәр һава итәгендә түтәл-түтәл булып Жигули таулары күренә башлый. Алар әле синнән 4—5 километр ераклыкта булсалар да, искитәрлек манзара булып торалар. Син анда җиткәндә үзенең бишегендә тирбәтеп килгән пароходны да, матур Иделне дә истән чыгарасың, аңа кадәр уйлап килгән уйларыңнан онытылып, яңа хыял дәрьясына чумасың. Иделнең сул ягындагы яшел болынлыклар, туйра таллыклар, куе камышлыклар, алар арасында ялтырап яткан зәңгәр күлләр сине җәлеп итәргә теләсәләр дә, тылсымлы көч белән әсирләнгән күңелне, Жигулига табынып өлгергән күзләреңне аерып ала алмыйлар. Син фәкать аның турында уйлыйсың. Аның турында сөйлисең, аның турында чыгарылган әкиятләрне тыңлыйсың.

Жигули тауларының билгән урыны зур түгел, ул бары тик туксан километр чамасындагы җир өстенә тупланган таулар ярыматавыннан тора.

Бу тауларга бирелгән Жигули исеменең тарихын болай аңлаталар: кайчандыр бу таулар арасында яшәгән юлбасарлар Идел өстеннән килүче сәүдә көймәләренең берсен тотып алганнар да хуҗасының акчасын сораганнар. Хуҗа бирмәгән һәм яшергән җирен дә әйтмәгән. Шуннан соң юлбасарлар теге хуҗаны чишендереп «янган пиннек» бәйләме белән сугалар. Акчаларының кайдалыгын әйттерәләр. Янәсе, менә шул вакыйгадан соң тауларга Жигули («жечь на вениках») исемен биреп калдыралар.

Жигули тауларының иң биекләре дә өч йөз метрдан артмый. Алар биеклеккә зурлык белән түгел, табигать байлыкларына, матур манзарага бай булулары белән дан алганнар. Аларның һәркайсы нинди дә булса бер вакыйгага, тарихи геройлар исеме белән бәйләнгән. Мәсәлән, «Патша курганы», «Каравыл кышлагы», «Стенька Разин», «Федька түбәсе» һәм башкалар дип йөртеләләр.

Аларның иң биеге һәм иң матуры — «Каравыл кышлагы». Аның түбәсенә менеп караганда, әйләнә-тирәдәге йөз километрдагы авыллар, шәһәрләр, хәтта ачык һавалы көннәрдә Ульянов шәһәре дә күренеп тора, диләр. Борынгы заманнарда, Идел өстеннән килгән дошманнарны карап тору өчен, бу тау каравыллык урынын үтәгән булса кирәк. Шуның өчен дә аңар «Каравыл кышлагы» дип исем биргәннәр.

Жигули табигый матурлыгы белән безне сокландырган кебек, ул үзенең тарихта тоткан урыны белән дә ихтирамыбызны җәлеп иткән җирләрнең берседер. Без, әлбәттә, аңа иске тарихчылар тарафыннан бирелгән «юлбасарлар оясы» дигән хурлыклы исем белән килешә алмыйбыз. Без аны дворянчылыкка корылган рус самодержавиесенең коллык богауларын өзәргә омтылучы, халыкка ирек даулаучы «лачыннар оясы» диеп таныйбыз. Чөнки халык иреге өчен көрәшүче Стенька Разин, Федька Шелудяклар беренче кат көч җыйнарга Жигулига килгәннәр, беренче кат шушы таулар арасыннан чыгып, патша гаскәрләренә, бояр көймәләренә һөҗүм иткәннәр. Кайберләре соңгы минутларында шул тауларга килеп сыенган, ачы язмышларының соңгы кәсаларын шунда эчкән.

Менә хәзер безнең алдыбызда түземсезлек белән көтеп алган таулар дөньясы. Әйтерсең лә алар оста архитекторлар планы белән төзелгән. Әйтерсең лә уңган куллы ташчылар тарафыннан киртләч-киртләч итеп берсе өстенә икенчеләре өелгән. Әйтерсең лә бу таулар Алып батырларга Иделдән күккә менеп йөрер өчен баскыч итеп куелган. Әйтерсең лә бу таулардагы мәгарәләр яктан-якка үтеп йөрү өчен аскы юллар итеп уелган. Әйтерсең лә бу таш кыялар әкияттәгечә җен-пәриләр, албастышүрәлеләр кебек золымлы көчләр һөҗүм итмәсеннәр дип биек тау итәкләренә корылма итеп куелган. Бу тауларның өсләрендә, тирән чокырларында, тау араларында нинди генә агачлар, нинди генә җимешләр, нинди генә үсемлекләр үсми! Икешәр йөз ел яшәгән карт имәннәр дисеңме, очына кадәр бер генә ботак та чыгармыйча үскән зифа буйлы наратлар дисеңме, яфракларыннан баллар тамып торган таза гәүдәле юкәләр дисеңме, каты чаганнар, чәере элмәләр, карулы карамалар, яшел чыршылар, исле артышлар, ап-ак каеннар, тынгысыз усаклар, уяу тирәкләр — монда бары да, бары да үсәдер.

Бу яшеллек, бу матурлык, бу тынычлык дөньясына барып керү белән күңелгә кызу кояштан әлсерәгән тәнгә рәхәт салкынлык, борынга хуш исләр бәркелә. Шушындый гүзәл илдә яшәүче халкыңа: «Без бәхетле!» дип кычкырасы, дөнья җәннәтедәй Идел буен сайлап утырган бабаларыбызга мең-мең рәхмәтләр әйтәсе килә.

Әйе, Идел буе илебезнең, тарихи бөек кешеләребезнең тормышы, халыкларыбызның бәхете өчен, бүгенге рәхәте өчен көрәшүләре белән бәйләнгән.

Даһи Ленин, Максим Горькийлар, Хөсәен Ямашев, Габдулла Тукаевлар Идел буенда тудылар, Идел буеның икмәк-тозын ашап, тәмле суын эчеп үстеләр. Ләкин моннан ике генә ел элек шушы бөек патриотлар Ватанына, матур Идел буйларына, ата-бабаларыбызның сөякләре күмелгән мөкатдәс җиребезгә немец оккупантлары канлы кулларын суздылар. Халкыбызның хезмәт даны, гасырлар буе көрәшеп түккән каны бәрабәренә алган ирегебезне буарга теләп, канга сусаган ач шакаллар төсле, Идел буена ыргылдылар. Кайбер урыннарда алар, кеше каны эчеп кипкән тамакларын басар өчен, Идел суын ятып эчтеләр. Сасы тиргә баткан күлмәкләрен Идел суында юдылар.

Ул чакларда Идел буенда авыр кайгы, ачы хәсрәт көннәре иде. Шулай да ул төшенкелеккә бирелмәде, куркыныч астында баш имәде. Алдагы җиңүләребезгә халыкны өндәде. Катерлар, буксирларга, пароходларга төялгән сугыш коралларын, илебезнең бик күп мактаулы улларын аркасында ташып, дошманның хурлыклы һәлакәтенә көч хәзерләде.

**2 июнь, 1944 ел.**

## Сталинград

Бүген дә көн аяз һәм кояшлы иде. Көньяк һавасының дымсыз, кырыс җиле, күккә таба чаптырып үскән тирәк яфракларын калтыратып, сөзәк ак-сары таулар өстеннән күренеп торган ерак Дон далаларына җәелгән иген кырларын әкрен генә дулкынлата иде. Чынлап та, Идел буйлап түбән таба төшкән саен һава алмашынган кебек, әйләнә-тирәдәге табигать бизәкләре дә үзгәрә бара. Бу тирәләрдә инде безнең Урта Идел буена хас булган матур таулар, яшел урманнар, туйра таллыклы болыннар азая, тәнне кытыклап иркәли торган йомшак җилләр дә кырыслана. Хәтта Идел суының төсе дә үзгәргән кебек тоела. Болганчык сары булып күзгә күренә. Безнең пароходыбыз, боларның берсенә дә исе китмичә, һаман үз эшендә, җитез хәрәкәтләр белән һаман алга омтыла иде.

Бервакытны салонда матур музыка авазы ишетелде. Икенче берәүләр көчле лирик тавыш белән җырлап җибәрделәр. Бөтен пассажирлар зал тирәсенә җыр-музыка тыңларга җыйналды. Фашист тырнагыннан коткарылган шәһәрләрнең берсенә баручы артистлар коллективы тарафыннан юлчыларга бирелә торган концерт башланды. Юлчылар, кайсы-кайда урынлашып, җыр-музыка тыңларга керештеләр. Концерт бай, программасы чикләүсез иде. Рус, Европа классик музыкасыннан бик күп үрнәкләр бирү белән бергә, хореография, бию номерлары да башкарылды. Бик күп санда халык көйләре, совет композиторларының популяр җырлары үтәлде. Бөтен җыйналган халык йотлыгып тыңлады. Һәрбер артистның башкаруыннан соң көчле кул чабу, алкышлаулар Идел буен яңгыратты.

Менә бервакытны халык арасыннан кемдер «Сталинград» дип кычкырды. Бу исемне ишетү белән, бөтен юлчыларның тәннәрендә ниндидер дәрт, күзләрендә кызыксыну көче уянды. Бөтенесе җитез адымнар белән палубага йөгерде.

Сталинград әле ерак иде. Шулай да аның янган кара торбалары, корган агачлары, анда-монда утырып калган җимерек бина почмаклары кайчандыр гигант бер шәһәр урыны икәнен төсмерләтә иде.

Юлчылар арасында Сталинград турында сөйләшү-бәхәсләшү, сүз көрәштерүләр китте. Ярый әле, бәхеткә каршы, безнең арада Сталинградны биш бармагы кебек белүче бер карт бар икән. Ул күп кенә аңлашылмаучылыктан коткарды. Турысын әйткәндә, безнең өчен ул чын-чыннан экскурсовод хезмәтен үтәде. Сугышка кадәр кай җирдә нинди заводлар, нинди урамнар, нинди культура йортлары булганын,

хәзерге көндә алар урынында таш-тимер өемнәре генә калганын сөйләп бара торгач, килеп җиткәнебезне дә сизми калдык. Пароход, көчле аваз биреп, пристаньга килеп туктады.

Элекке Царицынның революциягә кадәр күренеше турында бер сәяхәтче болай дип яза: «Без извозчик алдык та күрергә мөмкин булган җирләрен тиз генә карап чыктык, дөресен әйткәндә, бу шәһәрдә карарлык бернәрсә дә юк.

Сәүдә мәйданына чыга торган берничә тәртипле урамына салынган таш йортлар, берникадәр яхшы магазиннар, сәүдә складлары, гимназияләр, башка мәгариф-агарту йортларының булуы бераз шәһәр төсен биреп тора. Булган нәрсәсен тузан-пычракка күмелгән базар мәйданы йотып тора. Хәтта монда салынган чиркәүләр дә гади авыл чиркәвеннән аерылмый. Кеше күзен үзенә тартырлык бер собор да юк. Берничә урамнан кала башкалары түшәлмәгән. Тимер юл челтәрләре, пристане булуга карамастан, гомумән Царицынның ярмаркалы бер авылдан артык җире күренми»...

Чыннан да, Царицын шундый бер артта калган шәһәрләрнең берсе булган булса да, гражданнар сугышы елларында Царицын дөнья империализмының төрле яктан оештырылган һөҗүменә отпор биреп, Бөек Октябрь социалистик революциябезнең уңышларын саклап калучы шәһәрләребезнең берседер.

Аннан соң бик күп еллар, бик күп айлар үтте. Алар Сталинград өчен яңадан-яңа уңышлар, яңадан-яңа казанышлар китерделәр. Аның әйләнә-тирәләренә «Трактор», «Кызыл Октябрь», «Баррикада» кебек гигант заводлар салынды. Иске Царицын шәһәре яңабаштан төзелеп, илебезнең иң матур, иң гүзәл шәһәрләренең берсе булу дәрәҗәсенә иреште.

## Хәйран шәһәрләрне вәйран иткәннәр

Инде өч елга тартылган Ватан сугышы безнең илебез өчен бик күп афәтләр, бик күп җимерелүләр китерде. Шуларның берсе итеп Сталинград шәһәрен алырга туры килә. Бу матур шәһәр немец машинасының иң коточкыч ударларын корыч коймa булып каршылады. Авыр газапка чиксез корбаннар биреп, немец армиясенең һөҗүмен туктатты. Аның һәлакәтен тәэмин итте. Хәзерге көндә ул көчле җир тетрәүдән хәрабә хәленә килгән шәһәр хәлендә. Барлык йортлары, барлык корылышлары җимерелгән. Шәһәр читендәрәк кайбер исән калган өйләр очраса да, алар снаряд, бомба, осколок кисәкләре белән чуп-чуар булып тишкәләнгән.

Кайбер урамнарында хәзер дә җәяү йөрерлек түгел, өем-өем кирпеч таулары, бөгелгән-сыгылган тимер балкалар, баганалар, астан актарылып чыгарылган водопровод торбалары аунап ята.

Сугышка кадәр булган 48200 йортның берсе дә калмаган, бар да егылган, бар да ишелгән.

Елына 77 миллион пассажир йөртә торган көчле трамвай юллары, канализация, элемтә, телеграф, электроятылык бирүгә хезмәт иткән төзелеш корылмалары — бар да чәрдәкләнеп ватылган, актарылып әйкалган, яндырылып көйдерелгән. Шул хәрабә, шул өемнәр арасында янган карават башлары, сабый балалар бишегенең кисәкләре, ванна, газ плитәсе тимерләре, челтәрләнеп тишелгән чиләк, табак, савыт-саба кысаларының да аунал ятканнарын күрәсең. Бу шәһәрдә ут күрмәгән, үз тәненнән пуля-снаряд үткәрмәгән бер генә тимер, бер генә таш кисәге дә күрмисең. Ишек тоткалары, вывескалар, бульвардагы эскәмияләр, урам фонарьлары, тимер капкалар, рәшәткәләр — бары да бөгәрләнеп янган, бары да тетелгән.

## Шәһәр җанлана

Шундый авырлыклар кичергән бу шәһәр әкренләп терелә, җанлана бара. Пароходлардан төшүгә тауга таба менеп киткән асфальт юллар, ыспай тротуарлар, алар тирәсенә ике яклап утыртылган яшел агачлар, сезонлы үсемлекләр гөрләп үсеп

утыралар. Вакытлыча салынган су сату киосклары, сәүдә лареклары матур итеп төсле буяуга буялган. Бөтен җирендә пакьлек, чисталык аңкып тора, бер генә җирендә дә чүп-тузан әсәре күренми.

Тауны менеп җитүгә, шәһәрнең үзәк өлеше башлана. Урам чатларында ак перчаткалы милиционерлар, бер яктан икенче якка чыгып йөрү өчен күрсәтелгән урыннар. Сквер, бульварларга яңа эскәмияләр куелган. Шактый гына яңа йортлар җиткерелгән. Азрак көч куеп торгызырга мөмкин булган әүвәлге биналарны төзәтергә керешелгән. һәр йортта, һәр ишегалдында җырлый-җырлый кирпеч салучы ташчыларны, ишек-тәрәзә рамнары куючы столярларны, өрлек-түшәм салучы балтачыларны күрәсең.

Ишелгән-җимерелгән йортларның аскы катлары барысы да эшкә кертелгән. Ишегалларындагы исән калган утын сарайлары, складлар, таш коймалар оста итеп торак йортына әйләндерелгән, яисә кечкенә учреждениеләргә вакытлыча кереп эшләрлек хәлгә китерелгән.

Шәһәр халкының беренче ихтыяҗын үтәү өчен кирәк булган водопровод, икмәк заводы, электр станциясе, трамвай юллары салынган. Кинолар, театрлар, китапханә, уку заллары, фән-техника югары уку йортлары, мәктәп, ясленәр, мунча, парикмахерскаялар ачылган. Сталинградтан эвакуация белән киткән халык, туган шәһәрләренең җимерелеп ватылуына карамастан, башка җирдәге яхшы тормыш шартларын ташлап, һәр көн саен поездлардан, пароходлардан төшеп, үз шәһәрләренә кайталар. Нинди дә булса берәр почмак табып, урнаша баралар.

Сталинградның завод-фабрикаларында, көннән-көн яраларын төзәтеп, цех артыннан цехларны эшкә кушалар. Шулар арасында немец оккупантларының ике каты һөҗүмнәрен үз күкрәгенә алган «Кызыл Октябрь» заводы, «мин терелдем» дигән шикелле, һәр көн саен гудок биреп, эшчеләрен эшкә чакыра. Ул хәзер фронт өчен, тыл өчен кирәк булган машиналарны бирә бара. Шулай ук «Трактор» заводлары да әкренләп тереләләр, кирәкле продуктларны бирәләр. Немец юлбасарлары бу шәһәрне бетерергә, җир йөзеннән юк итәргә тырышсалар да, кара максатларына ирешә алмадылар.

Кешеләр еллар үткән саен күп нәрсәләрне, вакыйгаларны онытырлар. Ләкин фашизмга һәлакәт китергән Сталинград шәһәрен — данлы Җиңү шәһәрен мәңге онытмаслар. Ул турыда томлап-томлап китаплар язарлар. Аерым геройларга багышлап легендалар корырлар.

**4 июнь, 1944 ел.**

---

Бу юлъязмалар Таҗи Гыйззәтнең шәхси архивыннан (ул хәзер Татарстан дәүләт музеенда саклана) алып басыла. Тел ягыннан аерым төзәтүләрне искә алмаганда, юлъязмаларга үзгәреш кертелмәде.

**РЕДАКЦИЯ.**

Мөхәммәт Мәһдиев

# ЮГАРЫГА КАРАП ФИКЕР ИТ...

*1974 ел прозасына бер караш*

Татарстан язучыларының сигезенче съездыннан соң әдәбиятның авыр артиллериясе булган проза жанры нинди уңышларга иреште, нинди яңа проблемалар күтәрде? Әдәбият, башлыча проза, яңа елга нинди әсәрләр белән килде?

Темалары буенча тикшереп караганда, 1974 елда дөньяга чыккан проза әсәрләрендә берничә юнәлеш өстенлек иткән. Алар арасында, беренче чиратта, Бөек Ватан сугышына, беренче бишьеллыклар чорына, сугыштан соңгы авыл һәм интеллигенция тормышына багышланган әсәрләр күзгә ташлана.

Сүзне эшчеләр сыйныфына багышланган әсәрләрдән башлап китәсе килә. Чөнки бездә бу теманы яктыртуның шактый бай традициясе бар. Беренче бишьеллыклар чорында татар агае Магнитогорск, ДнепроГЭС төзеде, Төркстан—Себер тимер юлын салды, Березникида, Донбасс шахталарында эшләде... Октябрь революциясе тарафыннан коллыктан азат ителгән татар егете, илебезнең башка халыклары белән берлектә, социализм төзелешләрендә хезмәт батырлыгы күрсәтте. Заманында бу тема безнең әдәбиятта иң актуаль темалардан санала иде. Егерменче-утызынчы елларда чыккан әдәби альманахларны, газета-журналларны актарып карагыз: ул чагында шахтерлар, төзүчеләр, урман кисүчеләр, шәһәр-завод салучылар турында бик күп язылган.

Шахтерлар тормышы — татар совет әдәбиятында түрдән урын алган тема. Хәер, язма әдәбиятта гына түгел, халык авыз иҗатында да бу шулай. Моның хикмәте нәрсәдә? Очраклы хәлме бу? Һич тә очраклы хәл түгел. Тарихка мөрәҗәгать итик: Россиядә капиталистик мөнәсәбәтләр киңрәк тамыр җәйгән, Россия бөтендөнья сәүдә-экономик мөнәсәбәтләренә ныграк тартылып кергән саен, аның промышленносте үскән. Промышленностьның үсүе авылдан меңләгән эш көчләре суырган. Промышленностька борын төртергә омтылган авыл егете башта ук үз сәләтенә туры килерлек эш эзләгән. Күмер учакларына исә нәкъ менә көрәк, кәйлә, тачка тотарлык таза куллар кирәк булган. Шуңа күрә техник яктан артык катлаулы булмаган күмер чабу эшенә татар авылларыннан бик күп ирләр киткән. Шахтер хезмәтен яктырту буенча әдәбиятыбызның бай традицияләре бар һәм бу тема әле дә булса татар әдәбиятында үз булып, тормышчан булып яңгырый. Шахтерлар гына түгел, урман кисүчеләр, төзүчеләр, юл салучылар, промышленностьның кул көче таләп итә торган башка өлкәләрендә дә татар егете актив булган һәм әдәбиятта алар турында да күп язылган. Төзүчеләр турындагы әсәрне дә татар укучысы үз итеп, йөрәгенә якын итеп каршы ала. Узган ел «Казан утлары» журналында шундый әсәрләрдән Г. Ахуновның «Ардуан батыр» повесте һәм Хәким Хәйруллинның («Канатлар талмасын» исемле повестьның авторы Хәниф Хәйруллин бөтенләй башка кеше) «Ургыл» романы басылган.

Башта «Ардуан батыр» повесте турында берничә сүз. Әсәр композицион төзеклеге, тасвирланган вакыйгаларның тыгызлыгы белән күңелне җәлеп итә. Әсәрнең баш герое Мирсәет Ардуанов мәкерле эчке дошман белән берөзлексез көрәштә, ул һәрвакыт пәкенең үткен ягына басып йөри. Повесть башланганда ук кыю, масштаблы башлана. Масштаблылык үзенә махсус стиль таләп итә һәм автор аны таба алган. Автор, вакланмыйча, вак детальләргә артык әһәмият бирмичә, катлаулы вакыйгалар арасыннан иң зурысын әйдәүче линия итеп алып бара. Нәрсә соң монда төп проблема? Төп проблема, мөгаен, чабаталы авыл егетләренең, рус һәм башка милләт вәкилләре белән берлектә, совет эшчеләре сыйныфы булып формалашуыдыр. Аларның эшче исемен алу өчен физик һәм рухи имтихан бирүләре мәсьәләседер. Заман темасымы бу? Бүгенге татар укучысы өчен, югары техника белән коралланган промышленность объектларында эшләүче егетләр-кызлар өчен бу тема искермәгәнме? Юк, искермәгән. КамАЗ һәм БАМ төзи торган укучы өчен нәкъ менә заман темасы бу. Чөнки язучы беренче бишьеллыкларның героик хезмәт сәхифәләре аша бүгенгө көнгә күпер сала. Березники, Магнитогорск, ДнепроГЭСлар — алар бүгенге КамАЗ, БАМ кебек гигант төзелешләрнең башлангычы. Г. Ахуновта, язучы буларак, заман рухын тою, сиземләү көчле: безнең прозада эшчеләр сыйныфы темасының тарихи күперен, заманнар бәйләнешен ул үз вакытында тойды.

«Ардуан батыр» повестеның журнал вариантына автор «Саубуллашу сүзе» дигән үгет-нәсихәтле бер бүлек өстәгән. Автор әйтерсең лә укучыны кисәтә: «Менә, ди, мин сезгә Мирсәет Ардуанов турында сөйләдем, әмма сез белеп торыгыз, монда уйлап чыгарылган берни дә юк, монда бөтенесе булган хәл», ди. Әмма укучы Мирсәет Ардуановны болай да яратып өлгерде бит инде. Аны хезмәт сөючәнлеге, балаларча чиста күңеллелеге өчен яратып өлгерде.

Эшчеләр сыйныфының бай тарихи үткәнен яктырту юнәлешендә татар әдәбиятында киләчәктә бик кызыклы әсәрләр туар дип уйларга тулы нигез бар. Ш. Маннурның укучылар арасында зур кызыксыну уяткан «Агым суларга карап» әсәре турында әле фикер алышулар кызып кына бара иде — «Казан утлары» журналында Х. Хәйруллинның «Ургыл» исемле романы басыла башлады.

Хәким Хәйруллин үзе катнашкан вакыйгаларны, үзенең чорын, үзе яшәгән җирне тасвирлый, матур гына исем белән укып бетергесез озын беренче әсәрен — роман яза. Болай авторның нияте, күтәргән мәсьәләсе изге: Бөек Ватан сугышы елларында яшүсмерләрнең Себер күмер учакларындагы хезмәт батырлыгы турында ул. Бу теманы күтәрергә кирәкме? Әлбәттә, кирәк. Уракчүкечле кара сукно фуражкалар киеп узган безнең яшьлегебез бит ул! Шуның өстенә шахтер темасы! «Ургыл»дагы Якуплар, Хәмзәләрнең яшьлегенә, шахтер данына кызыгып, көнләшеп романның эченә кереп китәсең һәм шунда ук аптырап каласың: автор кеше образларын тудыра алмаган, аерым персонажларның телләрен, индивидуаль характерларын бирә алмаган, вакыйгаларны тасвирлаганда үзенең төп юнәлешен ачыклый алмаган, унынчы битен язганда, тугызынчы биттә нәрсә булганын оныткан... Бик буталчык урыннардан безне дә, үзен дә коткару өчен, автор тизрәк күмер штрекләренә алып төшеп китә һәм коры тел белән производство процессын аңлата башлый. Ул ара-тирә берәр авария, берәр мәхәббәт маҗарасын тигезләп сибеп бара. Больница, имгәнү, авырулар да шулай тигез сибелгән. Проза секциясе утырышларының берсендә: «Язучы үз әсәрләрен салкын кан белән язарга тиеш», дип әйтүчеләр булды. Икенче берәүләр, аларга каршы чыгып: «Юк, язучы кайнарланып язарга тиеш», диделәр. Әмма ни генә булмасын, бернәрсә бәхәссез: язучы үз темасын яратырга, геройларын, бу әсәрне укыячак кешеләрне яратырга тиеш. Шул ярату булмадымы — язучы һөнәрчегә әйләнә дә кала. Бит санын, табак санын, геройлар санын салкын кан белән генә исәпләп язып утырганда, кешене дулкынландырырлык әсәр туа алмый. «Ургыл» романы, кызганычка каршы, укучыларны дулкынландырмады. Дөрес, әсәр гел уңышсызлыклардан гына тормый. Автор шахтерлар тормышында шул чор өчен хас булган киеренкелекне, шахта җитәкчеләренең гади шахтер язмышы өчен кайгыртуларын бирә алган. Урыны-урыны белән авыл малайларының эшче сыйныфына әверелгәндәге кичерешләрен, аларның эчке дөньяларын матур гына тасвирлый алган.

Авторга, үзенең Хәмзәсен һәм Якубын үзәккә алып, ихтимал, берәр табак зурлыгында хикәя язып карарга, матбугатта үзен сынап карарга кирәк булгандыр. Кыскасы, «Ургыл» татар прозасының уңышы да, казанышы да санала алмый.

Узган елгы прозада Бөек Ватан сугышы темасы аеруча зур урын алды. Бу юнәлеш, беренче чиратта, Хисам Камаловның «Һәркемнең гомере бер генә» романында ачык сизелә. Бөек Ватан сугышы темасы ул — заман темасы, һәм язучыларның еллар узган саен аңа ешрак мөрәҗәгать итүләре бик табигый күренеш. Җир шарында фашизм бүген дә бетмәгән. Фашизм бар, адольфлар әле дә бар, аларның бүрекләре генә икенче. Фашизмга карата нәфрәт хисе кичерү яңа бүрекле адольфларга җир шарын бүгенге көндә канга буярга юл куймас өчен кирәк. Шуңа күрә Бөек Ватан сугышы темасы әдәбиятта әле озак яшәр.

Татар язучылары Ватан сугышы темасына 1941 елның 22 июнендә үк тотынганнар иде. Сугышны, аның авырлыгын яктыртуда әдәбият төрле этапларны үтте. Сугышның беренче айларында татар егетләрен акбүз атка атландырып, кылыч тактырып «мессершмит»лар белән коралланган Германия армиясенә каршы көрәшкә җибәрүче әдипләребез дә булды. Дошманны бик булдыксыз, аңгыра, көчсез, иске одеялга чорналган, каткан, бетле йолкышлар гына дип язучылар да булгалады. Әмма зур совет әдәбияты, аның Шолоховлары, Леоновлары, Фадеевлары, Симоновлары бар иде. Алар дошман көчле диделәр. Дошман соңгы техника белән коралланган, дошман мәкерле, тәҗрибәле диделәр.

Еллар узган саен, фронт темасына язучы әдипләр саны арта барды. Бу темага караган әсәрләрнең сыйфаты яхшыра барды. Алтмышынчы елларда рус совет әдәбиятына үзләре окоп тормышын күргән Бондаревлар, Субботиннар, Быковлар килде. Алар сугыш материалын солдат блиндажыннан, сугышның алгы сызыгыннан, миналы кырлардан алдылар. Аларның бу темага язылган әсәрләрендә кызыл җеп булып түбәндәге фикер сузылды: фашизм безгә каршы баштанаяк коралланган, сугыш тәҗрибәсе булган куәтле армияләр җибәрде. Совет солдаты дүрт елга сузылган авыр сугышта **көчсез, булдыксыз дошман белән түгел, ә куәтле дошман белән сугышты.** Совет солдаты куәтле, тәҗрибәле дошманны җиңде. Х. Камаловның «Һәркемнең гомере бер генә» романын укып моның шулай икәнлегенә кабат ышанасың. Язучының элеккеге әсәрләрендә дә сугыш темасы, солдат хисләре төп юнәлеш булып килә иде. Бу юлы шагыйрь укучылар алдына зур күләмле проза әсәре белән чыга. Автор зур төгәллек белән алгы сызыктагы солдат тормышын тасвирлаган зур полотноны әсәр биргән. Романда сугышчан бурычын һәр минутта башкарып торучы батальон бар, кырыс солдат көндәлеге бар.

Оборона сызыгында рус, татар, казакъ, үзбәк, кыргыз һәм башка милләт вәкилләре бар. Һәрберсе бер характер, һәрберсе үзенчә уйлый, үзенчә гамәл кыла, үзенчә батырлык эшли, үзенчә үлә. Әмма аларның барсы өчен дә уртак бер бурыч бар — әлеге нык дошманны ватаннан бәреп чыгарырга кирәк. Бу егетләр сугыш дәрте белән яшәгән, сугышка мораль әзерлекле коеп куйган сугышчылар түгел, болар сөйгән ярларыннан, сөйгән даласыннан, урман-кырларыннан вакытлыча гына аерылганнар. Алар — тыныч хезмәт кешеләре. Һәм майор Мостафиннан алып солдат Тәкәнәевкә кадәр аларның барысы да искиткеч гуманистик рух белән сугарылган. Алар бу көрәштә үлемнең котылгысыз икәнен беләләр. Порошинның самоходка каршына шуышып китәр алдыннан лейтенант Сөенчалинга блокнотын бирүен хәтерләгез:

— Иптәш лейтенант, өйгә хат язарсыз,— ди ул шуышып китәр алдыннан.

Автор үлем картиналарын биргәндә үзенә карата рәхимсез, ул конфетланмый, сугышта солдат та, командир да бер үк хәвеф астында икәнен күрсәтә. Солдатча тасвирлый. Совет сугышчыларының корыч ихтыярын, фашистларга булган нәфрәттән тыш, солдатка командирның ихтирамы, аңа винтик дип түгел, ә шәхес дип каравы тәэмин итә. Үлгән солдатның кенәгәләрен актарганда, комбат аларның балалары ничә булуы белән кызыксына.

— Шавлинның биш, Нурмановның тугыз, Кәбиров молодец, өйләнмәгән,— ди.

Шушы зур трагедиядән — иң ышанычлы, якын солдатлары үлүдән — комбат үз күңеле өчен энә очы кадәр генә юаныч таба. Кәбиревтән ятимнәр калмый, ичмасам, менә молодец! Сержант Юлтисов соңгы сулышы алдыннан янчыгын биреп үлә. Буш вакытларында ногыт салып фал ачарга яраткан икән, бичара. Монда да комбат кырыс, таләпчән командирдан яхшы күңелле, гуманлы яхшы атага әйләнә дә кала. Узган ай числосы белән өлкән сержант итеп оформить итик, балаларына пенсиясе күбрәк булыр, ди. Солдат белән командир арасындагы сокланырлык мөнәсәбәтләрне тасвирлый алуы — Х. Камаловның зур осталыгы.

Совет солдатларында җиңүгә омтылыш, сугышчан оптимизм тәрбияли торган көчләрнең тагын берсен автор солдатның җир-

гә, газиз туган иленә бәйләнгәндә күрә. Үлем белән күзгә-күз торып карашканда да солдат, аз гына вакыты булдымы, өен, балаларын, сөйгән ярын, әнисен, урман-кырларын искә төшерә. Автор романда солдат юморын мул кулланган. Һәркем үзенең томан артында калган, тыныч көннәрендәге кызык хәлләрен искә ала, шуларны сагынып сөйли. Усал, ләкин сокланырлык чибәр Гаффә белән яшәгән Тәкәнәев хатынының явызлыгын сөйли — әмма сагынып сөйли. Замполит Ваһапов та үкенеп бетә алмый: бервакыт квартира хуҗасының кызы Гөлфәндә, әтиләре кунакка киткәч, Ваһаповның бүлмәсенә кереп яткан. Ваһапов төн буе газапланып чыккан, янына барып ятыргамы, юкмы? Барып ятмаган, намусы тотып калган...

Автор солдат юморын гына түгел, солдат ачуын да шактый кыю сүзләр белән бирә. Һәм бу хәл һич тә әдәби әсәрне тупасландырмый, киресенчә, әсәрнең реализмын тирәнәйтә генә. Атышуның дошман һөҗүменең иң авыр, иң хәтәр секундларында солдатлар җан ачысы белән фашист адресына яман сүзләр әйтәләр, шуның белән дошманга булган нәфрәтләрен бушаталар. Әйе, фашизмга нәфрәт җиңүгә ярдәм итүче көч булган. М. Шолохов дөрес әйткән: ул нәфрәтне солдатлар штык очларында йөрткәннәр. Х. Камаловның совет солдатлары турындагы романын укып чыккач, уйга каласың. Сугышта фәлән миллион кеше үлгән дигән сүз ул абстракция түгел, ул әнә шул якты күңелле Тәкәнәевләр, тугыз балалы Нурмановлар, искиткеч гуманлы капитан Барановлар һәм башка бик күп әйбәт, юньле егетләрнең үлеме дигән сүз. Романның Бөек Җиңүнең утыз еллыгы алдыннан чыгуы әнә шул һәлак булган миллионнарча исемсез геройларга һәйкәл дип кабул ителергә тиеш.

Билгеле, романны артык озынга сузылган кайбер эпизодлардан чистартасы бар әле. Барановның сугыш вакытында ике тапкыр Фира белән, ике тапкыр Таминдаров белән очрашуы бераз гына халык әкиятләрен хәтерләтә. Барановның сугыш уңкынлыгында Фира белән булган семья тормышы романга берни дә өстәми. Әсәрдә кешеләр, аларның званиеләре, ранглар бутала.

Солдат темасына язылган яңа проза әсәрләре, гомумән, эмоциональлек белән аерылып торалар. Р. Төхфәтуллинның «Акбүз ат» әсәре лирик-эмоциональ тонда язылган. Беркем дә онытылырга тиеш түгел! Ватан өчен җанын биргәннәрнең исемнәре мәңгелек — «Акбүз ат» әсәренең төп идеясе әнә шул. Талха Гыйниятуллинның «Солдат үлеме» дигән хикәясе исә икенчерәк алым белән — үлем белән көрәшеп яткан гади солдатның саташуын тасвирлау алымы белән язылган. Дөрес, монда автор фантазиясенә бернинди рамка, норма юк. Саташкан кеше ниләр күрмәс! Әмма бу хикәяне тетрәнмичә уку мөмкин түгел. Солдат Кинъягулов синең күңелеңә уелып керә. Никадәр самимилек анда, никадәр рухи байлык, никадәр гадилек! Шул кеше һәлак була. Хикәянең бөтен эчке куәте — фашизмга карата тирән нәфрәт уятуда.

Яшь көе сугышта катнашканнарга, батырларча һәлак булган солдатларга истәлек төсендә И. Беляевның «Солдат төймәсе» исемле әсәре басылып чыкты. Әсәр күпләрнең игътибарын җәлеп итте. Чөнки ул бүгенге кырык сигез-илле яшьлек ирләрнең сугышчан яшьлекләренә дан җырлый. И. Беляев бу әсәрендә үзенең сугышчан яшьлегенә кире кайткан, шул чорны лирик буяуларда күз алдына бастырган. Юк, автор сугышны түгел, ә данга күмелгән яшьлеген, дусларын сагына, яшь чактагы идеалларга турылыклы булырга чакыра. Монголиянең табигатен, дала күренешләрен биргәндә И. Беляевның каләме аеруча көчле, әсәрне гомумән тыныч кан белән уку мөмкин түгел. Бу — романтик, эмоциональ әсәр.

Прозада авыл темасы, элекке кебек, әле дә активлыгын югалтмый. Узган ел бу темага багышланган байтак әсәрләр дөнья күрде. Аларда төрле чорлар, төрле мәсьәләләр, төрле характердагы геройлар алына. Ләкин һәрберсендә, әлбәттә, язучының үзе, ул тасвирлаган чор һәм тасвирланган вакыйгаларга язучының бүгенге көндә нинди мөнәсәбәттә булуы күренә. А. Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» повесте моннан утыз еллар элеккеге сугыш чоры колхозын тасвирлый. Авыр чор, кыен чор. Шул авыр чорны бүгенге язучы нинди караштан чыгып бәяли соң? Әнә шул авыр чор кешеләренең рухи дөньяларына, алардагы бөек патриотизм хисләренә, әхлакый сафлыкларына соклана ул. Әсәрнең исеме дә символик характерда — язгы кәрваннар. Язгы юл өзеклегендә глубинкадан симәнә алып кайтучылар — сугыштан соң булачак матур киләчәгебезнең, тук, имин тормышның язгы хәбәрчеләре Ибраһим да, Әдилә дә — еллар авырлыгын сыкранмый җиңә алган романтиклар. Автор укучыны авыр еллар картинасы белән шаккатырырга да теләми. Ул игътибарын күбрәк кешеләр арасындагы саф хисләргә, рухи ма-

турлыкны сурәтләүгә бирә һәм дөрес эшли.

В. Нуруллинның «Әгәр син булмасаң...» дигән повестенда бик гади дә һәм беркатлы да, авырлыкларны гел үзенчә генә җиңеп чыгарга өйрәнгән Равил Нәҗметдинов тормышы тасвирлана. Авторның бу героен беренче танышуда ук яратып өлгерәсең. Ни өчен? Яшүсмерләргә хас тәвәккәллеге, Равилчә итеп яшь кызга гашыйк була белгәне өчен. Эшчән булуы, авыр хезмәттән курыкмавы өчен. Автор тасвирлана торган чорының һавасын төгәл белә, чорны ачык буяулар белән бирә. Әйе, безнең заман геройлары алар — Равилләр, ярым ятимлектә үскән, брезент тышлы бишмәт, тишек итек киеп мәктәптә белем алган, төнге сменада колхозда эшләгән яшьләр. Алар да ярата, сөя белгәннәр, кызлар ул заманда да сылу, серле, сихри булган. Яшүсмердә уянган беренче саф хисләр тормыш авырлыкларын җиңәргә этәргән. Еллар узган, әнә шул Равилләр арасыннан хезмәт батырлары, эшлекле галимнәр, дәүләт кешеләре, акыллы партия җитәкчеләре күтәрелеп чыккан. Равил Нәҗметдиновлар тормышның зур юлына баскан.

Әсәрнең сюжетына көчләп тагылган берәр нәрсә булса — ул семья мәсьәләсе. Равил Нәҗметдиновның семья тормышында бәхетсез булуын сюжет линиясе һич тә таләп итми. Андый ихтыяҗ юк, аның ике хатын алып аеруы повестька берни дә өстәми. Аннан соң, үзенең геройларын калкытып куюю максатыннан чыгып булса кирәк, В. Нуруллин образларын табигый агыштан кинәт кенә зур орбитага китереп чыгарырга ярата. Авыл малаена хас булган байтак сәерлекләр эшләп йөргән, гамәлләрендә ярыйсы ук системасыз булган (әлбәттә, яраттыра торган!) Равилнең Дәүләт премиясе алу дәрәҗәсенә ирешүе укучыда бераз елмаю уята уятуын. Чөнки Равилне болай да ошатты инде укучы, саф күңелле егет ул, мәкерне белми икән ул! Геройга, аны табигый барышыннан чыгарып, көчләп лауреат лаврларын тагу — артык. Моңа ихтыяҗ юк.

Ул яктан караганда, М. Юнысның «Тозлы җил» повестендагы Габдрахман образы кызыклы. Габдрахман да тормышның төрле сюрпризларына үзенчәлекле мөнәсәбәттә, барысын да ул үзенчә, Габдрахманча сәеррәк хәл итә. Ләкин әсәрдә аңа гадәттән тыш «нагрузка» йөкләнмәгән, ул — ышандыра торган герой. «Тозлы җил» — якты, саф күңелле яшьләр турындагы әсәр. Баксаң, бернинди тискәре персонажсыз, бернинди каршы шәхессез менә дигән кызыклы әсәр язып була икән. Әсәрнең төп герое — татар прозасында моңарчы бер генә тапкыр да очрамаган кызыклы тип. Аның язмышы бик кызык: колхозда эшләү, алтын медаль белән урта мәктәп тәмамлау, хәрби авиация, авария, госпиталь, МГУ һәм Одессадагы диңгезчеләр резервына килеп эләгү. Герой эзләнә, адаша, абына, торып китә һәм тагын ялгыша, тагын эзләнә. Ул романтик шәхес, тормыш ваклыкларыннан качып, ул бөегрәк идеалларга омтыла. Колхоздан чыккан малайның күңелен Франсуа Вийон шигырьләре дә, Пикассо картиналары да җәлеп итә. Һәм Габдрахман тормышта үз урынын, җәмгыятькә иң зур файда китерерлек урынны эзли. Габдрахман тирәсендә — Валерия, Феликс, Баграт, Маштаков, Өметгали. Төрлесе төрле милләттән, һәрберсенең кабатланмас индивидуальлеге, үз йөзе бар. Баграт һәм Феликсларны якты күңелле шәхес булганнары өчен кимчелекләре белән дә яратасың. Тормыш бик бай икән... Баграт, Феликс, Өметгали кебек егетләр МГУда гына түгел, безнең арада да байтактыр, без аларны күрә генә белмибездер. Алар мещаннар түгел, киләчәк тормышка матур максатлар белән атлаучылар. «Тозлы җил» повестеның прозага алып килгән уңышының тагын берсе шунда, бу әсәрнең буеннан буена кешене рәнҗетми торган, теш ыржайтып мыскыл итми торган ягымлы көлү бара. Безнең әдәбиятка бик кирәк сыйфат ул. Без еш кына елмаюдан качабыз, ә менә М. Юныс мөлаем генә итеп елмая, төнгә каршы ашамыйча йокыга ятарга туры килгәндә дә, Одесса вокзалында носильщик булып бер әбәтлек акча эшләү нияте белән йөргәндә, күрәчәгенә каршы, дипломат кызы Валерия белән очрашып алар чемоданын күтәреп йөргәндә дә, ул елмая белә. Ничек шулай була ала? Чөнки Габдрахманның кешеләргә, безнең җәмгыятькә мөнәсәбәте якты, күңеле яхшылык белән тулы. «Тозлы җил» — студентлар, диңгезчеләр турындагы әсәр генә түгел, ул фәлсәфи-романтик повесть. Анда тормышның бик күп мәсьәләләре күтәрелә.

Халыкка, туган ягына яшьләрчә гашыйк, бүгенге тормышта үзенең урынын эзләүче, уйланучан геройны «Тау агы повесте» әсәрендә Әхсән Баянов иҗат итте. Ә. Баянов — әдәбиятта, гомумән, новатор, һәр әсәренә ул яңа ачкыч таба, яңа форма эзли, яңа композиция кора. Үзенең тасвирлау предметына ул җаваплы карый, өстән-өстән генә штрихлап биргән образны анда күрмәссең. Ә. Баяновның геройлары тормышта очрый торган гадәти кешеләрдән бераз гына калкурак,

бераз гына философрак, шагыйрь җанлырак. Аның әсәрләренең канвасында һәр чак шигырь, җыр, музыка элементы була, бу хәл язучының гомумән тормышка карашыннан, иҗат манерасыннан килә. «Тау ягы повесте»нда да шулай. Дөрес, беренче абзацта ук Идел ярларын тасвирлау бераз куркытып куя. Чыннан да бераз сәеррәк бит: «Шулай да, диварлар киңлектә эвклидча түгел, ә Лобачевский геометриясендәге шикелле — кырлары бер-берсенә тоташмаган өчпочмаклар булып бәхет һәм кайгыларның, җиңү һәм җиңелүләрнең, бер сүз белән әйткәндә, тормышның — үткәннәрнең һәм киләчәкнең чиксезлеген күрсәтеп тора шикелле». Дөресен әйтик, безнең әдәби тел — стиль чараларының кабул ителгән нормаларына ничектер сыеп бетми кебек бу. Монда нинди дер трюкачлык юкмы, форма белән мавыгу юкмы? Юк икән, әсәребезнең төп герое үзе яңачарак кеше икән. Детдомда тәрбияләнеп, рус урта мәктәбен тәмамлап, армиядә хезмәт срогын тутырган, хәзер кан тартуы буенча туган туфрагын, нәсел-ыруын эзләп кайткан, бер авыз сүз татарча белмәгән татар малае Тәбрик Тугашевның тирәлекне кабул итүе, шуның фикерләве икән бу. Әсәрдә әнә шул эзләнүчән, яхшы күңелле егетнең сабыйлык чоры турында сүз бара. Егет повестьның беренче битеннән үк юньле мәгънәле кешеләрнең игътибар үзәгенә алына. Военком да, Тугаш карт та, Гөләндәм дә — барысы да киң күңеллеләр, кешелеклеләр. Бу бик табигый, чөнки тормышыбыз, Совет җәмгыяте үзе шундый. Алар Тәбрикне туган туфрагына ныклап бастыралар, тормышта үз юлын күрсәтәләр. Бәхет нәрсә ул? дигән сорауга җавап табарга ярдәм итәләр. Бәхет — кешеләргә яхшылык эшләүдә, иленә намуслы хезмәт күрсәтүдә икән. Ә. Баяновның композицион яктан үзенчәлекле, җыйнак повесте әнә шул идеяне уздыра.

Билгеле, әсәрнең табигый агышына бераз гына комачау иткән нәрсәләр монда да бар. Шулардан мин икесен аерып алып күрсәтер идем. Беренчесе — Тугаш карт образы. Автор моны үзе дә сизгәндер, артык галим, артык философ карт ул. Аны гади бер авыл карты дип белүдән бигрәк, тарих-этнография буенча докторлык диссертациясе язып та, диссертациянең очына чыга алмыйча пенсиягә чыгып авылга кучкән бер галим дип кабул итәргә мөмкин. Аннан бик галимнәрчә, бик «мудрый» гына сөйләшә ул. Дөрес, авылларда андый крестьянча, аксакалларча акыллы картлар була, әмма болай ук әдәби сөйләшмиләр алар. Кыскасы, Тугаш картның сөйләшенә, теленә язучы үзе катышкан, аның өлешенә кергән.

Икенчесе — авторның үз геройларына мөнәсәбәте. Автор кайбер геройларына аерым алганда, Фәхретдингә карата бик шәфкатьсез. Кешене шулай беткәнче каһәрләү кирәкме икән? Фәхретдиннең бит бөтен бәхетен фашизм җимергән. Сугыш башланмаса, матур семья кормас идемени ул? Ярата иде бит ул хатыны Көлемсәрне.

Автор үзенең әсәрендә Тугаш карт булып сөйли, Тәбрик булып уйлый, әмма Фәхретдин булып карамый. Аның фаҗигасен автор нигә аңламый? Фәхретдин сугыш газабын күреп, фашист әсирлеге кичергән. Сугыш гарасатыннан кайтып кергән Фәхретдиннең ике баласы белән яраткан хатыны икенче кеше кулында. Солдат **шулай итеп бөтен яктан бәхетсез калды**. Автор бераз гына гуманлырак булса, әйтик, Фәхретдин яхшы кеше буларак газапланса, әсәрдә тасвирланган вакыйгаларның чынлыгы, эмоциональлеге тагын да тирәнрәк булыр иде, һәм повесть отар гына иде. Шулай да, «Тау ягы повесте» — тапталмаган сукмак, прозада яңалык, авторның уңышы.

Яңалык дигәннән, Ф. Хөснинең «Алтын эзләүчеләр» повесте да — безнең прозада яңа тема. Казанның ул чоры — НЭПманнар, милләтчеләр мыжгып торган елларын без Һ. Такташның кайбер шигырьләре һәм Тинчурин комедияләре аркылы сиземлибез. Ф. Хөсни әнә шул катлаулы елларны, сәүдәгәрләр, аферистлар, спекулянтлар белән тулган Казанны тасвирлый Сизелеп тора, повестька тотынганчы, Ф. Хөсни бик күп документларны, шул чорның атмосферасын күз алдына китерерлек газета төпләмәләрен актарган, материал җыйган. Бераз маҗаралырак итеп язылган бу повесть безнең алдыбызда тарих пәрдәсенең бер читен ача һәм егерме өченче ел Казанының бер кисәген күрсәтә: анда НЭПманнар, сәвит бетмәсме дип өметләнеп яшәүче сәүдәгәрләр, мещаннар. Әдәбиятта бу темага язылган әсәрләр дә кирәк, алар да яшәргә хаклы. Ихтимал, Р. Төхфәтуллин да хаклыдыр: Ф. Хөснинең бу повестенда бүгенге тормышка күпер салынмаган, диде ул үзенең бер чыгышында. Ф. Хөснигә әсәрне заман белән бәйләү өчен бик зур мөмкинлек калган: повестьның башында ялтырап күренеп алган «Чека Вәли»гә җитәрлек «нагрузка» бирелмәгән.

Соңгы еллар прозасында укытучылар тормышына игътибар көчәйде. Укытучы һө-

нәре, шахтерлар кебек, татар халкы өчен традицион, тарихи профессия. Татар совет әдәбиятында укытучы тормышын сурәтләгән күп санлы әсәрләр, бу әсәрләрнең матур традицияләре бар. Жанрлар буенча килгәндә, укытучы образы поэзиядә еш рак күренде шикелле. Дөрес, укытучы образы шигъри әсәрләрдә еш кына трафарет белән бирелде: ул, һичшиксез, хатын-кыз, ул, һичшиксез, чал чәчле, ул, һичшиксез, сине мәктәп баскычында каршы алучы. Прозада укытучы образы бераз башкачарак, тормышчанрак төсмерләнде. Моны татар совет әдәбиятында заманында Г. Кутуй башлап җибәргән иде. Д. Зөбәерованың күптән түгел басылып чыккан «Кыр чәчәге» повесте шулай ук укытучылар тормышына багышланган. «Кыр чәчәге» — әдәби эшләнеше, сюжет-композиция чаралары буенча шулай ук кызыклы, укыла торган әсәр. Д. Зөбәерова үзенең геройларына җаваплы һәм сак мөнәсәбәттә, ул — әдәби геройларына һәр вакытта да гашыйк булып, сокланып, яратып яза. Кешеләргә карата гуманлы булырга, яхшылыкның кадерен белергә, илгә игелекле булырга — «Кыр чәчәге»нең төп идеясе әнә шул. Повесть, һичшиксез, үзенең укучыларын тапкандыр, аның төп герое Ләйсән исемле коеп куйган педагог кызны яратучылар аз булмагандыр. Әмма Д. Зөбәерованың «Куш өянке шаһит»ы моңа караганда күп көчле һәм тормышчанрак иде. Ни өчен шулай чагыштырам, чөнки язучы һәр әсәре белән алга таба үсәргә тиеш, дип исәплим мин. Бер әсәрең белән ялтырап килеп чыгып, алдагы әсәрең шуннан күп түбән булса, димәк, син иҗат эшенә җиңел карый башлагансың, үзеңә-үзең артык ышангансың. «Кыр чәчәге» повестена «Куш өянке шаһит» дәрәҗәсенә җитәргә нәрсә комачаулаган соң? Минемчә, бу — әсәрнең исеменнән үк башлана. Автор үзенең яраткан Ләйсәнен — тормышта гадәллекне яклаучы, хезмәт сөючән, күркәм табигатьле укытучы кызны кырау тимәс, җилләр екмас кыр чәчәгенә тиңләштерә һәм адым саен бу чагыштыруны укучының исенә төшереп бара. Чагыштыру укучының миенә тәмам сеңсен дип, бер заман тигәнәк белән параллельгә кадәр барып җитә, аннан арыш арасыннан баш калкыткан кыр чәчәгенә тиңләштерелә. Бер дә ялгансыз чүп үлән була инде Ләйсән дигәнебез.

Инспектор Ләйсән — әйбәт кыз. Бу образ күңелдә кала, ул — якты, намуслы шәхес. Әмма аны бик юктан гына эшеннән азат итәләр. Мәктәп, РОНО системасында алай булмый шикелле. Әсәрдә кешенең тормыштагы урыны, дәрәҗәсе мәсьәләсе шулай ук бәхәслерәк аспектта куелган. Ләйсәннең министрлыкка эшкә чакырылуын автор зур бәхет дип күрсәтә булса кирәк. Ә нигә Ләйсән укытучы булып эшләсә, бәхетле булмас идемени?..

Миндә бу әсәрдәге тагын бер эпизод канәгатьсезлек хисе уятты. Анда педагог Сәфәр абзый бар. Әнә шул педагог (тәрбияче), сугыштан кайткач, үзенең хәрби киемнәрен мичкә яккан. Уңай герой өчен характерлы сыйфат түгел бу. Ул бит әсирлектә булмаган, концлагерьның буй-буй пижамасын киеп кайтмаган, хәрби киемнән кайткан. Белмим, Сәфәр агай ничек нәфрәт белән карагандыр ул киемгә (нигә аны сугышка нәфрәт белән бутарга?), әмма фронтовиклар хәрби киемне зур горурлык белән киеп йөриләр иде!

Соңгы елларда безнең прозада детектив әсәрләр күренә башлады. Бу жанрда аеруча актив эшләгән кеше — Мәгъсүм Насыйбуллин. Узган ел аның детектив хикәяләрдән һәм «Телсез шаһитлар» исемле бер повестьтан торган китабы дөньяга чыкты. Моннан тыш, аның байтак әсәрләре көндәлек матбугат битләрендә басылды. М. Насыйбуллин күп яза, үз жанрында актив эшли. Аның бөтен иҗаты өчен төп сыйфат — әсәрләрнең бөтен буена сузылган бер идея бар: совет җәмгыятендә бер генә җинаять тә җәзасыз калырга тиеш түгел. М. Насыйбуллинның прозасында, мәсәлән, «Телсез шаһитлар» повестенда, диалог әйбәт бирелә, автор сөйләменнән башка да без вакыйгаларның кискенләгән, тикшерүче белән җинаятьче арасында барган психологик киеренкелекне, тикшерүче белән шаһит арасында барган логик, аналитик әңгәмәнең җаваплылыгын сизәбез. Әлбәттә, М. Насыйбуллинга татар классик әдәбиятыннан тел-сурәтләү чараларына, әдәби стиль үзенчәлекләренә өйрәнәсе бар. Җөмлә төзегәндә М. Насыйбуллин шактый талымсыз калькалар ясый, аягыкулы имгәтелгән зәгыйфь җөмләләр бирә. Кайвакытта, җинаять бик тиз ачылмагае дип куркып, гади укучы өчен дә инде ачыкланган мәсьәләләргә автор юри күз йома, әсәрне суза. Авторга киләчәктә әдәби осталыкка бик нык өйрәнергә кирәк әле.

Байтак еллардан бирле сөйләп киләбез: безнең татар әдәбиятында хикәя жанры пассивлашып бара. Узган ел да хикәяләргә бай булмады. Өлкән буын прозаиклар үзләренең иҗат биографияләренә зуррак күләмле әсәр белән бер кат йомгак ясарга җыеналар. Урта буын прозаикларының тизрәк өлкән

буын дәрәҗәсенә менеп җитәсе килә, бу дәрәҗәгә алар бары тик роман, повесть белән генә ирешеп була дип уйлыйлар. Прозаиклларның яшь алмаш буынының сафлары исә бик сирәк; бүгенге яшьләрдән проза жанрында актив катнашып килгән бер Әхәт Гаффаров бар.

Проза үзенә алмаш хәзерләми диярлек. Прозаиклар отрядында өзеклек. Безнең өлкәннәр актив, алар артыннан 40—50 яшьлекләр бара, 20—30 яшьлек прозаиклар исә юк дәрәҗәсендә аз. Хикәя жанрының пассивлашуын, беренче чиратта, прозаикларның алмаш хәзерләмәүләре белән аңлатырга кирәк. Бу жанр алдагы елларда да җанланыр дип әйтергә әллә ни ышаныч юк. Узган ел «Казан утлары»нда күзгә күренерлек нибары 4—5 хикәя басылган. Игътибар итик: шуның икесе русчадан тәрҗемә (Т. Гыйниятуллин, А. Мифтахетдинов); берсе гомере буе драматургия өлкәсендә эшләгән Әнәс Камалныкы («Олы Әкбәрнең кече Әсгаре»), икенчесе нефть идарәсе җитәкчеләреннән булган Үзбәк Саттаровныкы («Айлы төндә»). Хикәя жанрында төп уңышлар әнә шулар. Газеталарның әдәби бүлекләре дә язучылардан хикәя көтә. Ләкин прозаиклар газетада хикәя белән бөтенләй катнашмыйлар диярлек. Узган ел, мәсәлән, «Социалистик Татарстан» газетасы урта кул яки аннан да түбәнрәк дәрәҗәдәге ике хикәя басты. Ул хикәяләрдә образлылык җитми, авторлар, укучы минем нәрсә әйтергә теләгәнемне аңлый күрсеннәр дип, тизрәк үгет-нәсихәт бирергә ашыгалар. Андый авторларга хикәя язарга А. Чеховтан, Ш. Камалдан, Г. Ибраһимовтан, Ф. Әмирханнардан өйрәнә алмагансыз, татар совет прозасы осталары К. Нәҗми, И. Гази, М. Әмир, Ә. Еники, Г. Бәширов, Ф. Хөсни кебек замандашлардан да үрнәк алмагансыз; инде Альберт Мифтахетдиновтан өйрәнегез дип әйтәсе килә. «Казан утлары»нда «Хан-Гәрәйнең сәер көннәре» дигән гаять үзенчәлекле хикәя басылды. Никадәр гадилек, никадәр самимилек аның геройларында! Безнең хикәяләрдә әле моңа кадәр Илдар кебек кырыс та, әдәпле дә, аз сүзле дә егетнең күренгәне юк иде. Светлана да — бөтенләй аерым, үзенчә матур, үзенчә көчсез, үзенчә сөйкемле. Һәм хикәянең ахырында, гайре табигый ситуациядә булсалар да, алар арасында берниндн банальность юк, бары тик кеше белән кеше арасында була торган күркәм, сокландыргыч мөнәсәбәтләр генә...

Уңышсызлыклар, кимчелекләр турында сүз киткәч, инде тагын бер ике мәсьәләгә тукталыйк. Арадан берсе — язучының теле. Бу мәсьәлә еш телгә алына, бу турыда күп языла. Проза секциясе узган ел язучының теле турында әллә ничә тапкыр сөйләшү үткәрде, галимнәр, язучылар бу темага кызыклы гына докладлар сөйләделәр. Тел мәсьәләсенә, шулай итеп, һәр вакыт игътибар биреп баралар.

Без, гадәттә, язучының төп коралы тел дибез. Әмма, фәлән язучының теле начар дип әйтәбез икән — ялгыш сөйлибез. Язучы икән, димәк, телне ул бик әйбәт, шул телдә сөйләшүче миллионлаган башка кешеләрдән бик күп әйбәт белергә тиеш.

Ләкин тел — язучы өчен үзмаксат түгел. Проза әсәре язучыларыбыз, бигрәк тә башлап язучылар, әсәрнең телен халыкчан итәм дип, мәсәлән, әсәр теленә халык мәкальләрен көчләп тутыралар. Персонаж никадәр күбрәк мәкаль сипсә, әсәр шул кадәр ота дип уйлыйлар. Алда телгә алынган «Ургыл» романында һәркем мәкаль белән генә сөйләшә. «Тырышкан — табар, ташка кадак кагар» кебек шомарып беткән мәкальләрне анда һәр битгә кимендә берничәне табарга була. Монысы телне халыкчан итәм дип тырышу булды. Икенче хәвеф тә бар: телне әдәби итәм дип, башлап язучы авторлар җөмләнең «эчен тышка әйләндереп» куялар. Әдәбият теориясендә бу — инверсия дип атала. Ләкин инверсия — әдәби чара. Инверсия — гомум кабул ителгән грамматик нормаларны үзгәртеп җөмлә төзү, стилистик фигура ясау дигән сүз. А. Пушкинда, мәсәлән, мондый җөмлә бар:

Швейцара мимо он стрелой
Взлетел по мраморным ступеням.

Җөмләдәге сүзләрнең урынын алыштырып куюу монда үзенчәлекле сурәт тудыра. Әмма инде, «әдәби» булсын дигән максат куеп, Г. Ибраһимовлар, Ш. Камаллар, Ф. Әмирханнар нигез салган салмак, саллы эслүбебезне арты алга әйләндергән җөмләләр белән бозалар икән, бик борчылырлык хәл бу. «Ургыл»да, мәсәлән, беткәнче инверсия. Автор, үзе тасвирлаганга кеше ышанмас дип шикләнгән сыман, һәр җөмләсен укучының теш казнасына китереп бәрә, аның һәр җөмләсе аерым, вагонеткадан коелган антрацит кисәге кебек, каты, вак... «Ургыл» һәм шуңа охшашлы проза әсәрләрен укыгач, ирексездән сорау бирәсе килә: язучы иптәшләр, сез ара-тирә Г. Ибраһимов, Ш. Камал хикәяләрен һәм романнарын укыйсызмы? Халык иҗаты әсәрләре тупланган китаплар сезнең шүрлекләрегездә бармы?

Ара-тирә генә булса да сез халык теленең җәүһәрләре тупланган әнә шул тылсымлы көзгегә, Н. Исәнбәт әйтмешли, бер карап аласызмы?..

Өченче бер хәтәр мавыгу — персонажларга китап теле, рафинад тел тагу. Безнең хикәя-романнарда инде надан тунеядец та Сәгъдичә, Хәйямча сөйләшә. Ул «аракы салмый», ә «шәраб авыз итә». Инде аны шешәдән стаканга салмыйлар, ә «коялар». Анда да касәгә коялар.

Тел ясау, телне рафинадлау Д. Зөбәерованың «Кыр чәчәге» повестенда да күзгә ташлана. Автор геройларның телен «ясау» белән артык мавыга, аның кешеләре бик конфетлы итеп сөйләшәләр, повестьнең башыннан ахырына кадәр мәкаль-афоризмнар гына сибәләр. Ләйсәнгә кунакка килгән Мәйсәрә апа ишектән керүгә, кофены бер-ике йота да, шундук өч мәкаль әйтә:

— Кеше ике нәрсәнең кадерен: икмәк һәм үз кадерен белергә тиеш. Үзен дөрес бәяләгәннәр егылмыйлар, абынганда еламыйлар. Бүгенге эшеңне иртәгә калдырма,— ди.

Менә мондый «рафинад телле» хатыннар әсәрдә байтак. Алар шул чаклы эрудитлар, мәҗлестә дә дөнья хәлен сөйләшмиләр, М. Кәрим, Ш. Маннур шигырьләрен генә яттан сөйлиләр. Тел-сурәтләү чараларына да бераз җаваплырак карыйсы булган авторның. Аның балалары «үсмерләнә башлыйлар», Ләйсәннең «кашлары бүртеп китә», анда печән «җиләттеләр», патефон «табалары» әйләндерәләр һ. б. һ. б.

Кайчандыр, кемдер, әдәби телебезнең күрәчәгенә каршы, «тәүге мәхәббәт» дигән сүз әйтеп ташлаган. Шуннан киткән... Хәзер ул прозага килеп керде. Тәүге очрашу, тәүге үбешү, тәүге хисләр. Сүз әрсез булып чыкты. Ул производство процессына кереп китте: тәүге смена, тәүге гудок. Беренче дигән, әүвәлге дигән сүзләребез, шулай итеп, хокукларын югалта баралар. Инде болай да булыр: тәүге хатын, тәүге класс, тәүге курс... Татарның аш пешерүче яки ашчы дигән менә дигән сүзе бар иде. Хәзер ул юк. Аш пешерүче хәзер пешекче дигән бик ямьсез сүзгә әйләнеп, безнең әдәби әсәрләргә килеп керде. Безнең романнарда хәзер күзеңнең нурын алырлык алсу йөзле, ак киемле аш пешерүче сылу кызларны «пешекче» дип йөртәләр! Тавык йолкыканда тавыкны пешекләү, мал суйган көнне хайванның баш-аякларын пешекләү дигән сүз бар иде. Яшь баланың бармак аралары пешеккән дигән сүз бар иде. Әмма аш пешерүченең мондый ямьсез сүз белән аталганы юк иде...

Инде алары җитмәгән, прозада архаизм күренә башлады. Тагын шул ук «Ургыл»ның теленә килик. Колхоз малае Хәмзә Себер елгасында баржа өстендә барганда таныш булмаган болынны күзәтә:

— Атлары да атлары! — ди Хәмзә,— Галә батыр дөлделемени!

Булачак шахтер әнә шулай Кышкар мәдрәсәсенең пишкадәме кебегрәк сөйләшеп әсәргә килеп керә. Потомственный шахтерларның әниләре, хатыннары да шулай бистә абыстайлары кебек сөйләшәләр:

— Мәслихәт, бик мәслихәт. Изге сәгатьләрдә, изге минутларда башын исән-сау алып чыгарга насыйп иткән булсын, ходаем!..

— Гөлбикә, бәгырем парәсе,— диде Нәфисә әби Талигага,— илнең фәрманы икән, зиһенең җый, хатыннарга башлык бул! Син кәндә (шахта икән монысы — М. М.) буйсын җиткергән кыз...

— Мәслихәт, бик мәслихәт, кызым. Мәшһүр кәнче яуларга язсын! Үзләремез биредә булса да, барчамызның күзе мәгърибтә, Шахтер мөкатдәс адәмдер, мөхтәрәмдер дип йөртерие мәрхүм картым...

— Май кап, килен! Алла мадәт бирсен! Шахтерга дивар да тәрәзә нәҗип вә дәрәҗә. Кәсафәтсез галип улып калкырга язсын!

Шахтер хатыны Фатыйма әби дә шулайрак сөйли: «Донбасста ук кәндә фәхер казанган ул. Җанны фида кылырмын аның өчен...»

Күптәнге шахтер Хәеретдин дә шулай «Исагуҗи», «Фәзаилшөһүр» теле белән сөйли. Бөек Ватан сугышының кырыс елларында промышленностьның ыклап тамыр җәйгән бер күмер шахтасына шундый кадими мәдрәсә теле — Истамбул шивәсе нинди могҗиза белән килеп кергәндер — аңламассың.

Хәким Хәйруллин әдәбиятта беренче тапкыр күренә. Андый яшь язучының иске архаизмнар белән мавыгуы үзе бер гаҗәп хәл. Әмма әдәбиятта шактый тәҗрибәсе булган Х. Камалов телендә дә шундый көтелмәгән искелекләр очраткач, гаҗәпләнү тагын да арта төшә. Уңышлы әсәр, солдатлар турында, сугыш турында язылган талантлы әсәр. Ләкин шул әсәрдәге сүзләрнең кайберен сугыш кырында түгел, өйдә өстәл янында утырганда да аңлап булырлык түгел: «Аңарга каршы әйтүдән фәтва күрмәде»; «Тәвәккәлгә тәгъзим кылыр идем»; «Көрчеккә тереләдек, фрицны песиемлибез»

һ. б. һ. б. «Чос», «сурайган», «үрәнеп киту», «вөҗҮД» сүзләренең дә бик еш кабатлануы окопка да, траншеяга да сыймый. Җөмлә конструкцияләрендә дә авырайтып җибәрүләр очрый. Әсәрнең күләмлелеге, масштаблылыгы телгә җиңел караш хисабына булырга тиеш түгел. Шуның өстенә, безнең проза теле быгырдый, шыгырдый, лыштырдый башлаган. «Ургыл»да, мәсәлән, гел шулай: антрацит берөзлексез кытырдый, шытырдый, лава быгырдый, шаптыр-шоптыр килә, бөтен штрек быгыр-быгыр килә, анда кыштырдый, тегендә пытырдый, берәүнең әбисе шырылдап кычкыра.

В. Нуруллинның «Әгәр син булмасаң...» повестенда да болар байтак. Аның Равиле ни өчендер велосипедны һәр вакытта да «шыдырдатып тормоз салып» туктата, мотоциклы да «пырт-пырт» (4 тапкыр) килеп кабына, әнисе малайны «борлыктыра», малай «ылҗырап утыра» һ. б. һ. б. «Ургыл»да кызлар «ислемай ягыналар», хатыннар суган утыртмыйлар, ә «чәчәләр» һ. б.

Прозада банальностьлар да күренеп китә. Монысы түбән дәрәҗәдәге укучыга адреслана, шулар арасында популярлык казану өчен эшләнә. Безнең прозада семья тормышы җимерелү тирәсендә әйләнүләр шактый еш очрый. Авторлар моның белән, әлбәттә, укучылар арасында популярлык казаналар, әмма нинди популярлык соң ул?..

Әсгат Рәхимовның «Тәзкирәм» исемле повесте 9000 данә тираж белән чыгып, берничә көн эчендә таралган да беткән. Әсәр авыл укытучысы турында, иреннән уңмаган бик әйбәт, тырыш, күркәм холыклы Тәзкирә турында. Иреннән нык уңмаган? Ире эчә икән. Әлбәттә, аерылышканнар. Әлбәттә, хатын бераз гына йомшаклык күрсәтсә, ир, башын бөгеп, семьяга кире кайтасы...

«Тапшырылмаган хатлар»да болар булган иде инде, Г. Кутуйга өстәп нәрсә дә булса әйтү кыен хәзер. Ә шулай да «Тәзкирәм» укыла. Автор анда татар әдәбияты өчен яңа алым тапкан — бер үк хәлләрне башта хатын, аннары ир тасвирлый. Рус әдәбияты, кинематограф өчен, әлбәттә, бу үткәндәге этап. «Тәзкирәм» ник укыла соң? Чөнки ул урта кул укучыга бик оста адресланган. Монда Тәлгат эчә, Тәзкирә газап чигә — вәссәлам! Тагын шунысы да бар, әсәрнең беренче яртысында бит саен Тәлгатнең шешә ачуы, стаканга аракы салуы тасвирлана. Шунысы кызык, кайда гына, кем белән генә эчмәсен, Тәлгат һәр вакытта да «кырлы стаканга тутырып» салып эчә, әйтерсең икенче төрле савыттан эчсәң, ул башка китми! Автор исә иң кирәклесен — сәләтле, чибәр егетнең ни өчен эчә башлавын ачмый. Китапны укып бетергәч сорау туа: бу семья ник җимерелде? Сәбәп нәрсә? Болар ник кушылмыйлар? Нәрсә тоткарлый? Болары иң гади укучыны да уйландыра торган сораулар. Ә сәнгать-әдәбият таләпләре югарылыгыннан торып сөйләгәндә, эш ничек? Моның «яңалыгы» әсәрнең соңгы җөмләсендә икән: «Аһ, эчмәгән булсам!» XIX йөз мәгърифәтчеләре әллә кайчан әйткән хакыйкать инде бу. Эчкән кешенең бәхете булмаганын М. Акъегетзадәләр, Ф. Халидиләр, Г. Ильясилар моннан да образлырак итеп әйткән иде инде. Аннан соң, әсәр ахырында мондый дидактик нәтиҗә ясап кую этабын безнең әдәбият шулай ук бик еракта калдырды. Моны инде Г. Камал «Бәхетсез егет» әсәрендә үк әйткән иде: «Дөньяда баланы бигрәк ата-ананың тәрбия итә белмәве харап итә!»

Бер очтан проза әсәрләрендәге вульгаризмнар турында да әйтергә кирәк. Бу мавыгу бигрәк тә башлап язучыларда күзгә ташлана. Әлеге «Тәзкирәм» әсәренең беренче абзацында «Бирәнең чыксын, эч» дигән җөмлә бар. Менә инде бу кереш! Кайда Ш. Камал традицияләре? «Муса ачуланган иде», «Яшь бала елый иде» кебек лирик ачкычлар кайда? Тупас башлау тупас хикәяләр тудыра. Тәзкирә бала таба. Бераздан баланы күкрәктән аера. Китә повестьта шуның патологиясе. Бала аерган хатынның кай җире ничек итеп шешә, ничек итеп сулкылдый!..

Я, кая бара безнең проза болай китсә? И. Газида, Г. Әпсәләмовта, Ф. Хөснидә, Ә. Еникидә, М. Әмирдә, Г. Бәшировта шундый берәр эпизод бармы? Аларның әсәрләрендә дә бит сөешәләр, кавышалар, туйлар ясыйлар, бала табалар...

Һәм соңгысы — әдәби әсәрләрдәге фактлар дөреслеге турында. Язучы әсәрендәге фактлар дөреслеге — язучының укучыга, әдәбиятка, ниһаять, үз эшенә ихтирамының күрсәткече. Бу, ахыр чиктә, культуралылык билгесе. Әгәр инде «Ургыл» романында тундрадан бер мөгезле кәҗә атып алып кайталар икән, мин шиккә калам. Укыганым бар иде: бер мөгезле хайваннар моннан фәлән миллион еллар элек, фәлән периодта гына яшәгәннәр икән. Хәзер җирдә алар юк икән (носорог белән буталмасын, мөгез аның борынында). «Әгәр син булмасаң» повестенда 1949 елда ук күк йөзендә реактив самолетлар ак юллар калдырып очалар — вакытлар, заманалар буталган... «Алтын эзләүчеләр» повестенда егерменче елларда ук Кабан тө-

бенә акваланг белән төшү турында сүз бара, әмма акваланнгы 1943 елда гына француз инженерлары уйлап тапты. Фактлар — үҗәт нәрсә, факт үзенә карата сак булуны таләп итә...

*

* *

Бер еллык проза турында гына барса да, сүз озынга сузылды. Чөнки уртаклашасы фикерләр байтак җыелган. Уңышлыклар турында да, кимчелекләр турында да... Шулай да узган ел прозасы әдәбиятыбызга якты күңелле матур геройлар, бай тематика алып килгән. Кайчандыр әле ике-өч ел элек кенә татар әдәбиятындагы жанрларны үлчәү тәлинкәсенә салып болай дигәннәр иде: бүгенге көндә татар әдәбиятында иң актив жанр — поэзия, проза исә кузгалуны, җанлануны көтеп ята. Бүген исә без зур ышаныч белән әйтә алабыз: проза жанры кузгалды. Көч җыеп, заман сулышын алып, бүгенге кызыклы бай тормышыбызның күп төрле мәсьәләләрен эченә алып аналитик фикер йөртүче үзенчәлекле геройлары белән кузгалды. КПСС ҮК документларында алдагы бишьеллык ул сыйфат бишьеллыгы булыр дип билгеләнә. Бу турыдан-туры әдәби процесска да карый. Узган ел прозасының бик йомшак бер урыны — ахиллес үкчәсе бар икән. Баксаң, узган елда без җәмгыятебезнең нигезен тәшкил иткән бүгенге эшчеләр сыйныфы турында телгә алып мактанырлык бер әсәр дә иҗат итмәгәнбез. Баксаң, безне сөт, май, икмәк белән тәэмин итә торган бүгенге колхозчылар, бүгенге колхоз турында телгә алып мактарлык бер әсәр дә иҗат итмәгәнбез. Прозада масштаблы геройларыбыз да бик аз. Колоритлы, укучы күңелендә еллар буе яши торган геройлар тудырасы иде. Әдәби геройларыбыз ваклана бармыймы?..

Әдәбиятыбыз үсә, тирәнәя, әмма шөкер итеп кул кушырып утырырлык түгел: күз алдыбызда Шолохов, Гончар, Бондарев, Симонов, Быков, Айтматов, Проскурин кебек исемнәр белән аталган бүгенге зур проза бар. Алардагы колачны, геройларының масштаблылыгын күреп торабыз бит! Әдәбиятның бүгенге дәрәҗәсен үз әдәбиятының үткәндәге хәле белән түгел, ә күз алдында югарырак дәрәҗәдә торган әдәбият белән үлчәргә кирәк. Үсеш бары тик югарыга таба тартылганда гына мөмкин...

Безнең прозаикларны зур төзелеш, промышленность, авыл хуҗалыгы, күп профессияле интеллигенция тормышы темалары көтә. Партия җитәкчелегендә коммунистик җәмгыять төзүче совет халкының күпкырлы тормышын хикәя, повесть, романнарда чагылдыру Татарстан язучылар союзының зур отряды булган прозаикларның даими бурычы булып кала.

## Гәрәй Рәхим

# КИЛӘЧӘККӘ УЗЫП БАРЫШЛЫЙ

*1974 елгы татар поэзиясе*

Соңгы елларда «Хезмәт кешесе — әдәбиятның төп герое» дигән лозунг көн тәртибенә торган саен катгыйрак куела башлады. Һәм бу аңлашыла да. Безнең илебездә дөньякүләм әһәмияткә ия зур төзелешләр күбәя, промышленностьның төрле тармаклары, авыл хуҗалыгы һәм гомумән халык хуҗалыгы зур тизлек белән үсә бара. Болар барысы да совет язучысын хезмәт кешесе турында яңадан-яңа әсәрләр иҗат итәргә рухландыралар. Бу җәһәттән безгә, татар язучыларына да, мәйдан җитәрлек. Илебез тарихында, алай гына да түгел, кешелек тарихында әлегә тиңе булмаган КамАЗның безнең республика территориясендә төзелүе үзе генә дә безгә зур мөмкинлекләр ача. Шуңа күрә дә соңгы вакытта татар шагыйрьләренең КамАЗ темасына һаман ешрак мөрәҗәгать итүләре табигый күренеш. Бүген инде безнең кулда бу темага язылган һәм шигъриятнең олы жанрына караган өч әсәр бар. Алар — Сибгат Хәкимнең «Дәверләр капкасы», Рөстәм Мингалимовның «Күз карасы» һәм Хисам Камаловның «Язмыш елмаюы» поэмалары. Шулай итеп, зур һәм олы темага өч поэма. Бу аз түгел.

Поэмаларны чагыштырып караганда, беренче булып күзгә ташланганы шул: алар өчесе өч алым белән, өчесе өч төрле стильдә язылган. Шагыйрьләрнең һәрберсе КамАЗга үзләренә генә хас булган поэтик ноктадан карый. Миңа калса, поэмалар шул төрлелекләре белән кызыклы да, алар КамАЗны төрле ракурсларда ачып, укучыга гаять киң колачлы КамАЗ образын төрле яклап күзалларга мөмкинлек бирәләр.

Сибгат Хәкимнең «Дәверләр капкасы» — лиро-эпик әсәр. Анда КамАЗның безнең тормышыбыздагы зарурилыгы тарихи планда ачыла. Шагыйрь бу әсәрендә социалистик җәмгыятьтә мондый гигант төзелешләр туунын алшартлары, социаль закончалыклары турында уйлана. Юк, КамАЗ борынгы Чаллы җирендә, ходай биргән бәхет булып, кинәт кенә күктән килеп төшмәгән. Гәрчә КамАЗны бүгенге яшь егетләр һәм кызлар төзесә дә, аның нигезе еракларга китеп тоташа. С. Хәким поэмасындагы бүгенге КамАЗ ул борынгы чорлардагы прогрессив ягалгыларның, революциягә кадәрге авыр елларда үз-үзләрен аямыйча көрәшкән революционер-демократлар идеяләренең һәм, ниһаять, революциядән соң ук туган ялкынлы Ленин Декретларының, Магниткаларның, ДнепроГЭСларның, Ватан сугышы елларындагы халык фидакарьлегенең дәвамы. Шул ук вакытта КамАЗ ул — бүгенге социалистик җәмгыятьтә генә туарга мөмкин булган прогресс казанышы да. Сибгат Хәкимнең әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелгән КамАЗы — узган дәверләрнең иң алдынгы казанышларын киләчәк дәверләргә үткәреп торучы заман капкасы ул. Поэмада автор нәкъ шундый сәнгатьчә киң гомумиләштерүләр ясый. Кайберәүләр ә бит поэмада КамАЗны төзүче конкрет кешеләр күренми дияр. Ләкин поэманың максаты төзелештә эшләүче аерым кешеләрне сурәтләү түгел, ә бу гигант төзелешнең, иҗтимагый факт буларак, җәмгыять тарихындагы урынын билгеләү, аның тарих агышындагы әһәмиятен күрсәтү.

Рөстәм Мингалимов үзенең «Күз карасы» поэмасында безгә бу гигант төзелешне бө-

тенләй икенче ягы белән күрсәтә. Шагыйрь КамАЗдагы көндәлек тормышның һәм хезмәт сулышының гомуми настроениесен эре буяуларда сурәтләп бирә. Бу поэманы мин бүгенге, төзелеп ятучы КамАЗның рухи репортажы дияр идем. Рөстәм Мингалимовның КамАЗы үзенең хәрәкәтчәнлеге, тиз үзгәрүчәнлеге, урамнар һәм төзелешләр шау-шуы, тулай торакларлагы тулары һәм гомумән КамАЗга гына хас грандиоз хәрәкәте белән фотогенично һәм киногенично булып күз алдына килә. Поэманы уку барышында укучы үзен шушы төзелеш эчендә йөргәндәй хис итә, үзен Чаллы шәһәре кешесе итеп тоя, машиналар, блоклар чыңгылдавын ишетә. Ләкин иң әһәмиятлесе шунда, автор артыннан төзелешкә кереп киткән укучы бу производство шау-шуыннан, туктаусыз хәрәкәт һәм тизлектән алҗымый, ә шулар белән горурлана. Чөнки ул боларның барысын да үз хезмәте җимеше, үзенең яраткан төзелеше, яраткан эше, үз куллары белән салган завод шавы итеп кабул итә.

Бу поэмада шулай ук, аерым образлар, характерлар ачып бирүгә омтылыш юк. Дөресе, монда байтак кына кеше исемнәре, фамилияләр бар. Ләкин алар поэмага КамАЗ төзелешендәге меңләгән төзүчеләрнең, дистәләгән милләт кешеләренең вәкилләре, ягъни шуларның аерым бер өлешләре буларак килеп керәләр.

КамАЗ турындагы поэмаларның өченчесе һәм күләм ягыннан иң зурысы — Хисам Камаловның «Язмыш алмаюы». Бу поэма авторы инде КамАЗга төзелештәге конкрет кешеләр күзлегеннән карый. Хисам Камалов төзүчеләр, монтажчылар, бригадирлар һәм башка профессия кешеләренең бу зур төзелештәге рухи чынгыуларын конкрет детальләр, вакыйгалар, үзара мөнәсәбәтләр аша күрсәтеп бирә. Без поэмада нәкъ менә КамАЗда гына күрергә мөмкин булган кызыклы образлар белән очрашабыз. Шундыйлардан прораб Нур Хәлкин, Илфат, Барометр, теоретик Әлтәф аеруча уңышлы. Поэма җиңелчә юмор белән өртелгән һәм бу әсәргә нур өстенә нур гына өсти. Тагын шунысын да әйтергә кирәк, әсәрдән авторның бүгенге көн экономика фәнен яхшы белүе сизелә. Ә бу хәл шагыйрьгә поэманы коры, нигезсез энтузиазмга гына кормаска, ә төзелешне бар итүче реаль факторларга, экономик факторларга таянып иҗат итәргә ярдәм иткән.

Әмма поэманың соңгы өлешләре канәгатьләндерми. «Дипломатия көче» дигән бүлектән соң бөтенләй икенче сюжет башлана һәм соңгы ике бүлек поэманы тәгәлләп куя алмыйлар. Автор бу әсәрен «лирик эскизлар» дип атаган. Күрәсең, ул үзе дә поэманың эскизлылыгын сизгәндер.

КамАЗ темасына бездә байтак кына шигырьләр дә иҗат ителә. Чаллының үзендә яшәүче яшь шагыйрь Мәхмүт Газизовның «Ак шәһәр» дигән шигырьләр циклы үзенең табигыйлеге белән игътибарны җәлеп итә.

Гомумән әйткәндә, соңгы елларда татар шагыйрьләре КамАЗ темасында аз эшләмәделәр. Ләкин бездә уңышлы әсәрләрне пропагандалау җитешми. Поэмаларның нибары берсе генә, Сибгат Хәкимнең «Дәверләр капкасы» гына, русчага тәрҗемә ителеп, Мәскәүдә басылып чыкты. Ә бит оештыру эшләре әйбәт куелган булса, «Күз карасы» һәм «Язмыш алмаюы» поэмалары да үзәк матбугатта яңгырарга мөмкиннәр иде. Үзебезнең республиканың көндәлек матбугаты да бу әсәрләрне пропагандалау буенча канәгатьләнерлек эшләмәде. «Язмыш алмаюы» газета яки журналда бирелсә, шушы поэмалар буенча радио һәм телевидение тапшырулары оештырылса һәм, ниһаять, матбугатта тәнкыйтьче оператив мәкаләләр белән чыкса, поэмалар укучылар күңеленә тирәнрәк үтеп кергән булырлар иде.

Тематик яктан караганда, бездә күп әсәрләр дуслык-иптәшлек, мәхәббәт, туган як, кешеләр күңелендәге яхшы, матур сыйфатлар, табигатькә сак мөнәсәбәт, тормыш-яшәешнең төрле яклары турында языла. Дөрес, без кайчакта бу темаларга язылган уңышлы шигырьләрне дә интим лирика, камерный әсәрләр дип, берьяклы бәяләп куйгалыйбыз. Ләкин совет кешесенең һәм материаль, һәм рухи яктан гармоник үсеше күзлегеннән караганда, мондый әсәрләр бүгенге замандашны, бигрәк тә яшьләрне коммунистик рухта тәрбияләүдә зур роль уйныйлар. Икенче яктан, бу хисләр шул ук КамАЗ төзүчеләргә, завод һәм фабрика эшчеләренә, колхоз-совхоз хезмәтчәннәренә дә хас ич. Бу темаларга багышланган уңышлы әсәрләр замандашыбызның рухи үсешен, күңел байлыгын, иҗтимагый мораль сафлыкка омтылышын күрсәтәләр. Нури Арсланов, Гамил Афзал, Хисам Камалов, Роберт Әхмәтҗанов, Ренат Харис, Рөстәм Мингалимов, Кадыйр Сибгатуллин, Флера Гыйззәтуллинаның соңгы вакытларда басылып чыккан китапларындагы шушы темага багышланган иң әйбәт шигырьләре һәм Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Зәки Нури, Шәүкәт Галиев, Марс Шабаев, Равил Фәйзуллин, Фәнис Яруллин кебек шагыйрьләрнең узган елда көндәлек матбугатта кү-

ренгән поэма һәм шигырь цикллары әнә шундый зур таләпләрдән чыгып язылганнар. Бу җәһәттән, Шәйхи Маннурның «Гомер белән гомер арасы» дигән яңа поэмасына аерым тукталып китәсе килә.

Соңгы елларда безнең өлкән шагыйрьләребез, бераз вакытка тынып торалар-торалар да, көтмәгәндә генә ялкынлы шигырь бәйләмнәре яки поэма биреп куялар. Күптән түгел Нури Арсланов һәм Әхмәт Исхак шундый бер иҗади күтәрелеш кичерделәр. Һәм менә аларга «Гомер белән гомер арасы» дигән поэма белән Шәйхи Маннур килеп кушылды. Мин бу әсәрне мәхәббәт турындагы поэма дип әйтмәс идем. Поэманың төп темасы — катлаулы гомер юлы үткән, дөньяның ачысын-төчесен күргән олы яшьтәге замандашыбызның тормыш-яшәештәге иң саф, иң матур, иң самими хисләрне еллар һәм чорлар аша тутыктырмыйча саклап баруы. Кайберәүләр әйтерләр, ә бит поэмада сагыш, моң, үкенү һәм башка шуңа охшаш күңелне телә торган урыннар бар диярләр. Дөрес, әсәрдә андый урыннар бар. Ләкин иң әһәмиятлесе шунда, андагы сагыш, моң һәм үкенүләр укучы күңелен изми, вакламый, сытмый, пессимизмга этәрми, ә, киресенчә, бу хисләр аны күтәрә, көнкүреш ваклыкларыннан югары менгерә, күңелдә яшәүгә, эшкә, мәхәббәткә һәм, ниһаять, Кеше булуга тыелгысыз дәрт өсти. Әсәрне укып чыккач, укучы дөньяда яшәвенә куана, хезмәтеннән һәм мәхәббәтеннән яңа, матур мәгънәләр таба башлый.

Дөресен әйтергә кирәк, без, язучылар, соңгы елларда бер-беребезнең уңышларын үз вакытында күрә белми башладык. Элеккерәк елларда көндәлек матбугатта берәр шагыйрьнең уңышлы, көчле әсәре басылып чыкса, аның кайнар эзләре буйлап шушы әсәргә сокланган, димәк, аны укучыга пропагандалаган мәкаләләр языла иде. Соңгы елларда бу күренеш сирәгәйде. Без еш кына хәтта аерым китап булып басылган әйбәт поэзия әсәрләренә карата да күз йомып калабыз. Һәм мин Кояш Тимбикованың «Татарстан яшьләре» газетасында Шәйхи Маннурның әлеге поэмасы турында фикер әйтеп чыгуын югарыда әйтелгән күркәм эшне дәвам итүнең яки тергезүнең матур бер үрнәге дип карар идем.

Шулай да соңгы вакытларда дөнья күргән поэмаларның байтагына уртачалык, поэтик ярлылык хас. Саҗидә Сөләйманованың «Фал китабы» поэмасы байтак тәнкыйтькә очрады. Поэма авторның шул исемдәге китабында да басылып чыккан. Дөресен әйтергә кирәк, шагыйрә бу китабында поэма остасы буларак түгел, ә кыска шигырь остасы буларак чыгыш ясый.

Саҗидә Сөләйманова поэзиясе, гомумән алганда, җиргә нык басып тора, аның романтикасы вакланмый, шигырьләре тормышта, хезмәттә һәм моральдә хатын-кызга нинди дер өстенлекләр булсын дип зарланмыйлар. Шагыйрә кыска шигырьләр өлкәсендә аеруча тырышып эзләнә, тапталган юлдан атламый, яңа темалар, бизәкләр, интонацияләр эзли. Аның «Бөтерелә, бөтерелә карлар», «Сыкылы-бәсле кыш иде», «Нәнәй истәлегенә» дигән шигырьләре җыентыкны бизәп торалар. Ә «Фал китабы» поэмасы Саҗидә Сөләйманова иҗатының чын йөзен билгели алмый.

Соңгы елларда поэма жанрында Дифгат Сирай аеруча актив эшләде. Берничә китап бастырып чыгарган бу автор әдәбиятта күптән эшләп килсә дә, әле һаман яшь шагыйрьләр исәбендә йөртелә. 1974 елда аның «Кеше турында җыр» дигән яңа җыентыгы басылып чыкты. Бу китапка, шигырьләр белән беррәттән, өч поэма тупланган. Бер китапта өч поэма; бу — уен эш түгел.

Дифгат Сирайның матбугатта авыл, җир кешеләре турында матур-матур гына әсәрләре күренгәли. Бу җыентыкта да «Үтим әле ерып үләннәрен», «Яшәргә тиешбез», «Әти булса, мин кем булыр идем», «Кеше өмете», «Иреннәр», «Күрмәдегезме» кебек уңышлы шигырьләре бар. «Каентубә» дигән поэмасы да авыл кешеләренең характерларын белеп, җир кешесенә карата җылылык белән язылган. Сюжет сызыгының көпшәгрәк һәм әсәрнең ялтырап торган яңа поэтик табышларга саранрак булуына да карамастан, поэманы укучы кабул итәр дигән ышаныч бар. Шагыйрьнең киләчәктә дә шушы әсәр юнәлешендәрәк эшләвен телисе килә.

Ләкин Дифгат Сирай иҗатының күңелне тырнап торган икенче бер ягы бар. Ул да булса, әсәрләрдә чама, логика хисен югалту, ялган романтикага бирелү, шигырь-поэмаларны тышкы эффектка гына кору һәм, ниһаять, әсәрне идея, художество эшләнешен күз алдында тотмыйча, җиңел кулдан гына язып ташлау. Авторның менә шушы җитешсезлекләрен иң ачык чагылдырган әсәре — җыентыктагы «Авыл поэмасы».

Исеменнән үк күренгәнчә, поэма авыл тормышына багышланган. Барыбызга да мәгълүм, бүгенге авыл тамырдан үзгәрә, колхоз производствосы промышленность нигезенә куела бара, ягъни социалистик хуҗалыкның

иң бөек үрләренә күтәрелә. Ил үсешенең бүгенге этабында авылдагы үзгәрешләр гаять кызу темплар белән бара, фәнни-техник революция авыл хуҗалыгында яңа тип хуҗалык системасы тудыра. Дифгат Сирайның «Авыл поэмасы»нда менә бу яңалыклар чагылыш тапмаган. Поэма кадәр поэмада бу үзгәрешләрнең авыл кешесенә, авыл тормышына ничегрәк тәэсир итүен дә күрсәсе килгән иде. Автор бүгенге авылны һаман искечә, сугыштан соңгы еллардагыча итеп күрә. Кызганычка каршы, безнең поэзиядә ул еллардагы авылны сурәтләүдә билгеле бер трафарет, схема яшәп килде. Бу схема буенча авылда таңга кадәр гармун моңы булуы, кешеләрнең тәрәзәләрне ачып җибәрүләре, таң җиленең пәрдәләрне селкетүе, гармун моңының авылның әле бер башында, әле икенче башында ишетелүе язылa. Бу — авыл турында язуның иң ансат ысулы. Дифгат Сирай поэмасын нәкъ менә шул трафаретка, схемага корган да. «Казан утлары» журналының 1974 елгы 1—6 саннары турында фикер алышуга багышланган җыелышта Зөлфәт бу поэманы бик нык тәнкыйть иткән иде. Чыннан да, кайбер уңышлы поэтик юллары булуга карамастан, поэма бүгенге укучыны һич кенә дә канәгатьләндерә алмый.

Бу урында яңадан «Хезмәт кешесе — әдәбиятның төп герое» дигән лозунг искә төшә. «Авыл поэмасы» гәрчә турыдан-туры хезмәт кешеләре, авыл кешеләре турында язылган булса да, үзенең художество эшләнеше түбән булу сәбәпле, бүгенге хезмәт кешесен төп герой дәрәҗәсенә күтәрә алмый.

Авыл темасына язылган әсәрләр турында сүз чыккач, башлыча шушы темада эшләүче ике шагыйрь — Кадыйр Сибгатуллин һәм Рәшит Гәрәй иҗатларына тукталып үтәсе килә. Ләкин монда бер искәрмә ясап китәргә кирәктер. Бу ике авторны мин авыл темасында эшләүчеләр дип шартлы рәвештә генә әйтәм, чөнки поэзия әсәрләрен темаларга бүлү шигъриятнең колачын тарайта һәм мондый бүлүләр белән артык мавыгу әдәби тәнкыйтьтә зур ялгышлар китереп чыгаруы мөмкин. Әлеге авторларның тематикалары киң, ләкин аларның төп темалары, ягъни беренче скрипкалары — авыл.

Кадыйр Сибгатуллин иҗаты соңгы берничә ел эчендә җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә тартып өлгерде. Аның авылдан, Балык бистәсе төбәгеннән килгән шигъри авазы тәнкыйтьчеләребез, язучыларыбыз һәм поэзия сөюче укучыларыбыз күңеленә хуш килде. Авторның «Әманәт» исемле беренче җыентыгындагы авылга багышланган шигырьләрне укучы яратып кабул итте. Шагыйрьнең төп уңышы шунда, ул авыл, җир, туфрак, икмәк, игенче дигән олы исемнәр белән шапырынмый һәм шул ук вакытта мескен мужик малае булып та кыланмый. Икенче төрле әйткәндә, К. Сибгатуллин шигырьләрендә авыл үзенең табигыйлеге белән матур. Ләкин шунысын да әйтергә кирәк, автор үз күз күременнән читтәрәк булган темаларга кереп киткәч каләмен шактый сүлпәнәйтә. Хәтта мәхәббәт турындагы шигырьләре дә һәм китаптагы фәлсәфи нигездә язылган «Утлар» поэмасы да югарыда санап кителгән әсәрләреннән шактый кайтыш.

Рәшит Гәрәй исә авыл турында күптән яза. Аның иҗатында бу тема һәр вакыт төп урынны алып килде бугай. Соңгы бер-ике елда Рәшит Гәрәй иң актив эшләүче авторларның берсе булды. «Социалистик Татарстан» газетасында һәм «Казан утлары» журналында аның шигырь цикллары әледән-әле басылып тора. 1974 елда шагыйрьнең «Юлдашым булсаң иде» дигән шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Гомумән, шагыйрьнең шигъри активлыгы мактауга лаек. Ләкин Рәшит Гәрәйгә, шушы сан активлыгын киметмәгән хәлдә, сыйфат активлыгын да арттыруын телисе килә. Дөрес, «Юлдашым булсаң иде» дигән китапта авторның «Туган якта», «Яшьлегемнең җитез чаптарлары», «Кырыс тормыш азмы сынаган» кебек кызыклы шигырьләре бар.

Гомер итим дигән егетләрне
Кырыс тормыш азмы сынаган.
Үз өстенә төшкән авырлыкны
Җиңү белән кызык бу заман.

(«Кырыс тормыш азмы сынаган»)

Кичтән ябып кергән капкаларны
Кемнәр инде чыгып ачканнар?
Яшьлегемнең җитез чаптарлары
Тезгеннәрен өзеп качканнар.

(«Яшьлегемнең җитез чаптарлары»)

Кызганычка каршы, мондый шигырьләр китапта азчылыкны тәшкил итәләр. Әгәр Кадыйр Сибгатуллинның поэтик авылын Рәшит Гәрәйнең поэтик авылы белән чагыштырып карасаң, Р. Гәрәй файдасына сөйләми торган аермалыклар күрергә мөмкин. Әйткәнебезчә, К. Сибгатуллин шигырьдә авыл кешеләрен, аларның күп төрле характерларын, авыл кешесе рухын җырлый. Рәшит Гәрәй исә күбесенчә авыл турында гомумән, ә үзе турында, үзенең авыл баласы булуы, авылны яратуы, авылны сагынуы турында сөйли. Шушы фикерне ул төрле вариантларда шигырьдән-шигырьгә, строфадан-строфага кабатлый. «Яратам, яратам» дип күп кабатлый торгач, аның авылны яратуы коры сүз генә түгел

микән, дип шикләнә башлыйсың. Моңа мисалларны «Юлдашым булсаң иде» дигән китаптан күпләп табып була.

Без поэзиябезне төрле формаларга бай дибез һәм моны хаклы рәвештә әдәбиятыбызның уңышы дип саныйбыз. Барыбызга да билгеле булганча, татар поэзиясенең борынгырак чорына көнчыгыш әдәбиятының уңай тәэсире шактый көчле булган. Ләкин бу традицияләрнең тәэсире һаман бер дәрәҗәдә генә тора алмаган. Татар әдәбияты үсә барган, татар поэзиясе халык иҗаты традицияләрен көчәйтеп җибәргән. Алдынгы рус һәм көнбатыш поэзиясе белән якыннан аралаша башлагач, алар тәэсирендә үзенең мөмкинлекләрен тагын да киңәйтә төшкән. Шул ук вакытта безнең поэзиядә көнчыгыш әдәбияты традицияләре дә бөтенләй сүнеп калмаган. Соңгы елларда бу процесс үзен тагын да ныграк сиздерә башлады.

Бу юнәлештә иң актив эшләүче шагыйрьләребезнең берсе — Нури Арсланов. Аның көнчыгыш поэзиясе традицияләрен киң кулланып язылган шигырьләре татар поэзиясенең мөмкинлекләрен киңәйтәләр. Н. Арслановның узган елда басылып чыккан «Талпыну» китабындагы бүгенге көн кешеләре, бүгенге заман тормышы турында көнчыгыш поэзиясе традицияләрен дәвам итеп язылган байтак шигырьләре замандашыбызның рухына авазлаш булып яңгырыйлар.

Гамил Афзал шулай ук еш кына көнчыгыш поэзиясе формаларына мөрәҗәгать итә. Инде олы буын язучылары рәтендә саналып йөрүче бу шагыйрь үзенең иҗатында сатира һәм лирика бизмәнен соңгы елларда лирика ягына таба авыштырды. «Көзге бакча» дигән яңа җыентыгын мин Гамил Афзалның байтак кына шигырь җыентыклары арасында рядовой бер китабы дип карар идем. Анда бүгенге колхоз председателен реаль образларда чагылдырган «Бер көн» дигән шигырь һәм «Яхшы», «Айлы төндә», «Мәрттән кайткач», «Балыкчылар», «Яшьтәшләр», «Бөгелмә аэропортында» дигән, тормышның үзеннән килгән һәм югары художество көченә ия булган әсәрләр арасында фикере кечкенә һәм баналь булган шигырьләр дә бар. Гомумән, соңгы елларда Гамил Афзал иҗатында бер-берсенә капма-каршы булган ике полюс үзен сиздерә. Бер полюста тормыш дөреслеген, чынбарлыкны шагыйрьләрне көнләштерерлек дәрәҗәдә табигый һәм сәнгатьчә итеп сурәтләп бирү, икенче полюста, бу темага да кагылмый калмыйм тагын дигәндәй, шигырьне җиңел кулдан гына язып ташлау. «Көзге бакча» җыентыгындагы «Йөрәк яна» дигән шигырендә автор, ике икең дүрт дигәндәй, гап-гади хакыйкатьне тырышып-тырышып тагын бер раслап маташа.

Тамырларда канны куа торган
Насос кына диләр йөрәкне.
Юк,
Йөрәк ул — сандугачлы урман,
Ак каенлы яшел тирәкле.

Агу тулы кара йөрәк була.
Сатлык йөрәк була — буш йөрәк.
Тимер йөрәк, кристалл йөрәк була,
Батыр йөрәк була, куш йөрәк.

Бу урында шунысын да әйтеп китәргә кирәк, соңгы елларда Әлмәт шагыйрьләре үзләренең төп темалары булырга тиешле нефтьчеләр темасын онытып баралар.

Яшь шагыйрә Флера Гыйззәтуллина әдәбиятка Әлмәт якларыннан килде. Аның «Чишмә юлы» дигән китабын шагыйрәнең беренче уңышы дияргә кирәк. Авторның лирик герое — сугыш еллары һәм сугыштан соңгы елларда армый-талмый хезмәт итүче гади, ләкин намуслы гражданин. Шагыйрә тормыш чынлыгын героик трагизм белән сугарып, купшы бизәкләр кулланмыйча һәм үзенә генә хас тирән хис белән сөйләп бирә. «Чишмә юлы» китабы автор турында хисси шигырьләр шагыйре дип әйтергә мөмкинлек бирә. Яшь авторга бу җәһәттән бер-ике киңәш тә әйтәсе килә. Ул, шигырьләрдәге хисси башлангычны югалтмаган хәлдә, алардагы интеллектуальлекне, фикер тыгызлыгын да арттыра барсын иде.

Поэзия әсәрләренең төрлесе укучыга төрлечә тәэсир итә. Бер төр шигырьләр узганнарны искә төшерә, икенчеләре күңелдә бүгенге уңышлар белән горурлану хисләре уята. Ә кайбер шигырьләр киләчәк турында уйланырга мәҗбүр итә. Ренат Харисның «Бизәк» һәм Роберт Әхмәтҗановның «Таң шәһәре» дигән җыентыклары укучыны киләчәккә карарга да этәрәләр. Бу китапларны мин эзләнүле китаплар дип бәяләр идем. Эзләнүле китаплар буларак, алар поэзиянең, тормышның, моральнең, нинаять, җәмгыятьнең киләчәге турында уйланырга мәҗбүр итәләр. Дөрес, шагыйрьләрнең һәр икесе ул киләчәкне үзләренең индивидуаль кичерешләре, үзләренә генә хас һәм үз күңелләренә генә якын булган поэтик табышлар, шигъри стиль һәм интонация белән күзаллыйлар. «Бизәк» һәм «Таң шәһәре» китапларын укыгач, татар поэзиясенең матур киләчәгенә ышаныч арта. Күңелдә шушы ышанычны тудыра яки ныгыта алу үзе генә дә бу китапларның дөньяга чыгуын тулысынча аклый.

Шигырьгә, гомумән поэзия әсәренә конкрет якын килсәң, аның һәр сүзе турында артык аек акыл белән уйлана башласаң,

шигырьдән әллә күпме гаеп табарга була. Мәсәлән, мин Роберт Әхмәтҗановның «Таң шәһәре» дигән җыентыгын бер утыруда укып чыктым һәм ул миңа ошады, Ләкин әдәби әсәр турында «ошады» яки «ошамады» дип кенә әйтү аның турында берни дә әйтмәү дигән сүз. Шуңа күрә мин бу китапны тагын бер мәртәбә, һәр сүзгә, һәр фразага игътибар итеп укып чыктым. Гомумән алганда, китап миңа бу юлы да ошады, ләкин икенче мәртәбә укыганда инде мин китапта күңелне борчыган урыннарны да күрдем. Аерым-аерым алганда авторның һәр шигыре тәэсирле, поэзиягә бай. Ләкин шагыйрь кайчакта шул тәэсирле, үзе генә тапкан поэтик детальләрне шигырьдән шигырьгә күчереп йөртә, кабатлана. Бу минем фикер генә түгел, моны инде тәнкыйтьчеләр авторга әйткәннәр. Чөнки ул китабындагы «Бер тәнкыйтьчегә» дигән шигырендә үз-үзен кабатлауны аклый. Мин үзем дә шагыйрьнеңниндидер бер үзенә генә хас булган, үзе генә тапкан ачышы аның традицион образына әверелүен, иҗатының берничә этабында күчәеп кабатлануын табигый бер хәл дип уйлыйм. Ләкин бер үк образның кабатлануы артык ешайса һәм кабатланган саен поэтик яктан көчәя бармаса, бу инде шагыйрь иҗатына нур өстәми. «Таң шәһәре» дигән китаптагы тургай образын мин әнә шундый образлар рәтенә кертер идем. Бу образ китаптагы 7 шигырьдә 16 мәртәбә кабатлана һәм ул һәр вакыт аерым бер деталь генә булып бара.

Кабатлап әйтәм, тургай сүзе кергән ул шигырьләрне мин һич кенә дә уңышсыз дияргә җыенмыйм. «Табигатькә дүрт җыр» дигән цикл аеруча актуаль һәм поэтик яктан көчле эшләнгән. Бу цикл бүгенге көннең иң зур проблемаларының берсенә шагыйрьнең олы шигъри авазы булып яңгырый.

Һәм, ниһаять, эш тургайда гына түгел, тургай шагыйрьнең зур иҗатында кечкенә бер мисал гына ул. Эш авторның иҗади принцибында. Үзең тапкан поэтик образны кирәгеннән артык кабатлауны яклау принцибының дөрес булмавында.

«Бизәк» — Ренат Харисның әле дүртенче генә китабы. Бу автор әле эзләнү юлында, аның кабатланырга вакыты юк. Шагыйрьнең бүгенге укучыны үсештә күрүе һәм зәвыгы үсә барган укучыга йөз тотып иҗат итүе куандыра. Ренат Харис иҗатта беренче планга фикер тыгызлыгын куя, укучы күңеленә яңа шигъри чаралар белән тәэсир итү юлыннан эзләнә. Аның шигырьләрендәге идея эчтәлегенең бүгенге көн, заман проблемаларыннан килеп чыгуы, шигырь формасында экспериментка якын эзләнүләре авторны бүгенге актив һәм житди шагыйрьләребез рәтенә куя. Дөрес, Ренат Харисның бөтен шигырьләре дә без үсештә дип елмаеп кына тормыйлар. Китапта формасы табылып бетмәгән, фикере булып та, хискә, йөрәккә, күңелгә кагылмый гына уза торган тәэсирсез әсәрләр дә очрый. Автор кайчакта шигъри җөмләне яки образны тел табигыйлеген бозу бәрабәренә катлауландыра. Мин шигырьдә катлаулы фикернең күбрәк булуы ягында, ләкин ул фикерләр табигый тел белән язылсын иде.

Җыентыкта кечкенә генә күләмле «Җитмеш икенче ел икмәге» дигән поэма урнаштырылган. Ренат Харис инде берничә поэма авторы. Аның поэмалары үзләренең кыска, тыгыз булулары белән отalar. Шул ук вакытта шагыйрь поэмаларында зур иҗтимагый нагрузкасы булган проблемалар күтәрә. «Җитмеш икенче ел икмәге» дигән поэма да әнә шул ягы белән отышлы.

Югарыдагы ике авторның китаплары киләчәк турында уйландыра дидем. Шул уңайдан поэзиябезнең киләчәге турындагы кайбер фикерләрне уртаклашасы килә.

Поэзия киләсе елларда нинди юлдан китәр, XX гасырның сиксәненче, туксанынчы, ниһаять, XXI нче гасыр башында поэзиядә нинди үзгәрешләр булыр? Бүгенге шигърияттә бу үзгәрешләрнең нинди яралгылары күзәтелә? Алдагы ун-унбиш елда укучы бездән нинди поэзия әсәрләре көтәр? Поэзиябезнең бүгенге темпларда, бүгенге формаларда һәм образлар системасындагы үсеше укучыны канәгатьләндерәме? Тәнкыйтьчеләрнең, әдәбият белгечләренең, ниһаять, безнең үзебезнең бу турыда уйланганыбыз, секцияләрдә, җыелышларда яки матбугатта фикер алышканыбыз бармы? Ә бит без күреп торабыз, бүгенге социалистик экономика һәм фән бик нык алга карап, киләчәкне истә тотып үсә. Матбугат хәбәрләренә караганда, хәзер безнең илдә халык хуҗалыгын үстерүнең алдагы 15 елга исәпләнгән перспектив планы төзелә икән. Фәнни-техник революциянең гаять зур үсеше, экономик перспективаларның колачы тарихта күренмәгәнчә киңәю, дөнья күләмендә алып барыла торган һәм берничә дистә еллар эзләнүне таләп иткән фәнни проблемалар, Советлар Союзы инициативасы белән инде тормышка ашырыла башлаган дөньякүләм коралсызлану политикасы, шулай ул алдагы унбиш-егерме елда ук кешелек дөньясы

өчен азык-төлекнең, энергетиканың, транспортның, туракның тарихта күрелмәгәнчә югары сыйфатлы һәм күп кирәк булачагы безне бүгенгебез, иртәгәбез, берсекөнебез яки алдагы бер-ике елыбыз белән генә түгел, ә киләчәк белән, бүгеннән ук алда торган сиксәненче, туксанынчы еллар белән яшәүне таләп итә. Бу проблемаларны хәл итү безнең тормышыбызны, көнкүрешебезне, экономикабызны, яшәү, эшләү, юл йөрү, ял итү ысулларыбызны бик нык үзгәртәчәк, үстерәчәк. Ә иң әһәмиятлесе, кешеләр мораль яктан, рухи яктан, үзләренә белемнәрне һәм әдәбият-сәнгатьне кабул итү, аңлау ягыннан бик нык алга китәчәкләр. Бу тенденция инде бүген үк сизелә. Үзебезнең әдәбияттан гына бер мисал. Соңгы елларда совет кешеләренең белем дәрәҗәләре бик нык үсү сәбәпле, әдәби иҗат эше белән шөгыльләнергә теләүчеләр саны һаман саен арта бара. Без бүген үк инде Татарстанда гына да яшь язучыларны өч йөзләп саныйбыз. Әле бу санга бары тик Язучылар союзы исемлекләрендә йөрүчеләр генә керә. Ә бу исемлекләргә кермәгән, теге яки бу матбугат битләрендә берничә әсәрен бастырган яки бастырырга хыялланып йөрүчеләрне дә искә алсак, бу сан кимендә бермә-бер артачак.

Әдәби әсәр язарга омтылучыларның күбесе югары белемле кешеләр. Алар әдәбият теориясе, әдәбият белеме, шигырь техникасы турындагы китапларны укыганнар, алар белән яхшы таныш. Ләкин мине шушы урында бер нәрсә борчый. Безнең бүгенге көндә яшәп килүче әдәбият теориясе, әдәбият белеме, шигырь техникасы таләпләрен кулланып, югары белеме булган теләсә кем урта кул шигырь яза алмыймы? Юк, мин бүгенге көндә әдәбиятыбыз алдында торган таләпләр йомшарды дип әйтәсем килми. Ләкин алар бер урында таптанмыйлармы? Дөресен әйткәндә, соңгы елларда бездә урта кул дип йөртелә торган шигырьләр бик күбәйде. Мин моны яшьләр иҗатына карата гына түгел, ә Союз члены булган шагыйрьләребез иҗатына карата да әйтәм. Ә урта кул дип йөртелгән шигырь ул әдәбият өчен, кем дигәндә, куркыныч әйбер. Бәлки бүгенге урта кул шигырь әдәбиятыбызның кайсыдыр этабы өчен әйбәт кенә шигырь булып исәпләнгәндер. Ләкин әдәбият тарихы аларны бүгенге көнгә кадәр үк алып килмәде, ә шигъриятнең киләчәк юлларын билгеләп, иң әйбәт шигъри әсәрләрне генә үз фондына алып бүгенге укучыга кадәр китереп җиткерде. Ә бүген языла торган урта кул шигырьне киләчәк фонына, сиксәненче, туксанынчы еллар, XXI нче гасыр башы фонына, икенче төрле әйткәндә, илебезнең тагын да югары үсеше фонына куеп карасак, алар безнең бүгенге әдәбиятыбызга ояттан башка берни китермәячәкләр.

Узган елның ахырында РСФСР язучылар союзы секретариатының Смоленск шәһәрендә бүгенге рус поэзиясе турышына багышланган күчмә утырышы булды. Бу җыелышта «Поэзия — безнең замандашыбыз» дигән канатлы сүз барлыкка килде. Әйе, поэзия — безнең замандашыбыз, безнең һәр әсәребез замандашыбыз кебек тирән фикерле, хезмәткә дәрт өстәүче, рухи яктан бай, мораль яктан чиста һәм, ниһаять, бөтен яктан да замандашыбызның коммунистик идеалларына туры килә торган булсын иде.

# РЕАЛИЗМ ТУРЫНДА

Әдәби ел йомгакларына багышланган мәкаләсендә[1] тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин: «Узган ел безгә теория мәсьәләләренә караган кызыклы хезмәтләр алып килде», дип яза. Әлеге кызыклы хезмәтләр рәтендә Ибраһим Нуруллинның «Реализм турында» исемле китабы[2] да санала.

Исеменнән үк аңлашылганча, И. Нуруллин хезмәтендә сүз реализм, конкретрак әйткәндә, мәгърифәтчелек, критик һәм социалистик реализм методларының асыл сыйфатлары һәм үзенчәлекләре турында бара. Бер иҗат методын икенчесеннән аера торган төп сыйфатларны конкрет күрсәтеп бирү, минемчә, авторның зур уңышы итеп саналырга тиеш. Чөнки нәкъ менә бер иҗат методын икенчесеннән аеру мәсьәләсендә мәктәп укытучылары да, югары уку йортлары студентлары да кыенлык кичерәләр. Дөрес, югарыда телгә алынган мәкаләсендә Ф. Миңнуллин иҗат методларының чиген И. Нуруллинча артык конкрет итеп күрсәтү белән килешеп булмый, хезмәттә теге яки бу иҗат методының үрнәге рәвешендә китерелгән әсәрләр үзләре үк ул иҗат методы кысаларына гына сыеп бетми, ди. Әйе, дәлил өчен китерелгән әсәрләрнең бер иҗат методы кысасына гына сыеп бетмәве мөмкин. Моның белән килешергә кирәк. Ләкин бит тормышта һәм табигатьтә бер генә нәрсә дә саф хәлендә яшәми.

Иң әһәмиятлесе шул: дәлил өчен китерелгән әсәрдә кайсы иҗат методының төп сыйфатлары өстенлек ала. Әсәр өчен сайланган тормыш материалына, тормыш факторына автор нинди позициядән, кем позициясеннән торып якын килә. Минемчә, мәсьәләне хәл иткәндә, дәлил өчен әсәр сайлаганда «Реализм турында» исемле хезмәт авторы нәкъ шушы моментларны исәпкә алган. Шуңа күрә аның фикерләре дәлилле һәм ышандыра.

Беркемгә дә сер түгел, татар совет әдәбияты белгечләренең хезмәтләрендә критик реализмның сферасын артык киңәйтү, аның барлыкка килүен XIX йөзнең икенче яртысына кайтарып калдыру тенденциясе көчле иде. Әмма соңгы вакытларда бу караш кискен тәнкыйть ителде. XIX йөзнең икенче яртысы татар әдәбияты тарихында мәгърифәтчелек реализмы методының формалашу, җитлегү дәвере итеп танылды. Шуңа да карамастан, автор бу мәсьәләгә кабат туктала. Чөнки юк-юк та критик реализмның сферасын киңәйтү тенденциясе һаман да сизелә әле. Ул бигрәк тә Урта Азия республикаларының әдәбиятчылары арасында киң таралган. «Реализм турында» исемле хезмәтендә И. Нуруллин Г. Кәримов, З. Кедрина, Ф. Касыйм-задә кебек әдәбият белгечләре белән бәхәскә керә һәм аларның үзбәк, казакъ, әзербәйҗан әдәбиятларының XIX гасырга караган чорларында үк критик реализм күрергә теләүләре белән килешми, чөнки бу мәгърифәтчелек чоры әдәбиятын танымауга, аны инкарь итүгә этәрә.

Галим татар мәгърифәтчеләре турында горурланып сөйли. Чөнки «мәгърифәтчелек реализмы — бөтен дөнья реалистик сәнгатенең бер этабы ул» (16 нчы бит). Әмма, шуның белән бергә, ул татар мәгърифәтчелегенең моралистик характерда булуын, аның Белинский, Чернышевский һәм Добролюбов исемнәре белән бәйле рус мәгърифәтчелегеннән шактый нык аерылуын да искәртә. Соңгысы революцион-демократик эчтәлекле

[1] «Казан утлары» журналы, 1975 ел. 8 сан.
[2] И. Нуруллин. Реализм турында. Татарстан китап нәшрияты, 1974 ел.

булса, «татар мәгърифәтчеләре җәмгыятьне үзгәртеп коруның төп коралы итеп мәгърифәтне алга сөрделәр» (10 бит), — дип яза И. Нуруллин. Бу карашның дөреслеге башка тикшеренүчеләр фикере белән дә раслана. Мисал өчен, Я. Абдуллинны тыңлап карыйк. «Казан утлары» журналының 1974 елгы 10 санында басылган мәкаләсендә ул болай яза: «Фән һәм гыйлемгә таянып кына кешеләр кешечә яшәешләрен һәм яңарыш юлыннан алга баруларын тәэмин итә алалар. Гыйлем һәм мәгърифәтне тарату, мәгърифәтчеләр фикеренчә, иҗтимагый яңарышка төп юнәлеш биргән көч тә һәм аның төп билгесе дә».

Шуннан чыгып, автор татар мәгърифәтче язучыларының дөньяга карашлары һәм әдәбиятның иҗтимагый ролен ничек аңлау мәсьәләләренә тукталa. 1905 елга кадәр татар язучылары арасында әдәбиятка педагогик күзлектән карау, аны әхлак төзәтү, кеше тәрбияләү чарасы итеп санау факты өстенлек итте. Ә бу, үз чиратында, мәгърифәтче язучыларны «кешенең иҗтимагый урынын, аның тирәлеккә бәйләнешен аңлауда каршылыклы концепциягә китерә» (11 нче бит). Бөек Горький фикере белән ныгытылган күп санлы дәлилләр әлеге тезис файдасына сөйлиләр, аның дөреслегенә ышанмый мөмкин түгел.

Автор мәгърифәтче язучыларның кеше образы тудыру һәм сюжет кору принципларын XIX йөзнең икенче яртысында формалашкан иҗтимагый һәм эстетик фикергә бәйләп аңлата. Дөрес, бу мәсьәләләр аның «XX йөз башы татар әдәбияты» (1966) дигән хезмәтендә һәм башка фәнни мәкаләләрендә чагылыш тапкан иде инде. Шуңа күрә биредә аларга күп урын бирелми. Ләкин сүзне белеп сайлау, аларның һәркайсын үз урынында куллану нәтиҗәсендә И. Нуруллин мәгърифәтче язучыларга хас образ тудыру алымнарын да һәм сюжет кору принципларын да тулы итеп күрсәтә алган. Моңа ышану өчен бер өзек китерү дә җитә: «Персонажларны тап икегә — уңай һәм тискәрегә бүлү, беренчеләренә ал, икенчеләренә кара буяуларны мул куллану — мәгърифәтче язучыларның кеше образы тудыру принциплары өчен менә нәрсә характерлы» (12 бит).

Әдәби персонажларны тап икегә бүлү һәм алар арасындагы конфликтта уңайларының җиңеп чыгу очракларына совет әдәбиятыннан теләсә күпме мисал китерергә мөмкин. Шулай булгач, соңгысы беренчесен гади кабатлауга кайтып калмыймы? Юк, гади кабатлауга кайтып калмый. Китабының 59 һәм 61—63 нче битләрендә тәнкыйтьче алар арасындагы аерманы да күрсәтеп биргән.

Мәгърифәтчеләр иҗаты өчен, бер яктан, үгет-нәсихәтчелек, дидактизм, рационализм, икенче яктан, реализм характерлы. Үгет-нәсихәтчелек, дидактизм һәм рационализмның чыганаклары һәркемгә билгеле, бу исбатлауны таләп итми. Шуңа күрә И. Нуруллин да аның турында җәелеп сөйләми. Аның каравы, мәгърифәтчеләр иҗатын реализмга этәрә торган факторларга җентекле анализ бирелгән. Чөнки «алар кешене тәрбия җимеше итеп тә карыйлар, димәк, тирәлекнең ролен азмы-күпме таныйлар» (11 нче бит). Моның уңышлы мисалы итеп З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романындагы Габделгафур шәкертнең тормыш төбенә төшү тарихы һәм сәүдәгәр хатыны Маһруйның юлдан язуына кагылышлы вакыйгалар күрсәтелә. Тирәлек тискәре персонажларга гына түгел, уңайларына да йогынты ясый. Бу тезисны дәлилләү өчен, автор «Хисаметдин менла» повестендагы Гайса, Хисаметдин, Әбүзәр бәк, «Яфрак асты яки Мәкәрҗә ярминкәсе»ндәге Гали Акчурин, «Бәхетле кыз» һәм «Җиһанша хәзрәт» әсәрләрендәге Гайшә, Габбас, Хәсән мулла образларына мөрәҗәгать итә. Алар туып-үскән гаиләләрне күздән кичергәннән соң, галим мондый нәтиҗәгә килә: «Китерелгән мисаллар бер нәрсәне раслый: мәгърифәтчеләр эстетикасында реализмга хас тирәлек төшенчәсе бар икән. Дөрес, биредә бу төшенчәнең кысалары... шактый тар. Әмма гаилә белән мәктәп «зур» тирәлекнең, ягъни кешене формалаштыра торган иҗтимагый мөнәсәбәтләр комплексының бер өлеше булып тора» (16 бит).

Мәгърифәтчелек реализмын өйрәнүче галимнәрнең күбесе: «Мәгърифәтчеләр гадәттә үзләренең геройларын экономик бәйләнешләрдән аерып күрсәтәләр, аларны рухи яктан, күбесенчә, әхлак ягыннан гына тасвирлыйлар» (17 бит) дигән караш үткәрәләр. И. Нуруллин да шушы караштa тора һәм бу аңа З. Бигиев әсәрләренә үзенчәлекле якын килергә ярдәм иткән.

Моңа кадәр әдәбият белгечләре «Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә» әсәренең сюжет нигезендә меңнәргә хуҗа булу өчен көрәш ята дип өйрәтеп килделәр. Ә бу, үз чиратында, романның төп герое Муса Салиховны каралтып күрсәтергә юл ача иде. 8 нче класс укучыларына тәкъдим ителгән дәреслектә, мәсәлән, Муса Салиховка вәгъдәсендә тормаучы намуссыз, икейөзле, акчага табынучы

өшәке кеше дигән ярлык ябыштырылган. Адвокат Андреев белән шымчы Шубин да үз кесәләрен калынайтучылар итеп кенә сурәтләнәләр. И. Нуруллин мондый анализ белән килешми, бик күп мисаллар ярдәмендә һәм үзенә генә хас төгәллек белән ул Муса Салихов өстенә ташланган гаепләрнең нигезсез булуын дәлилләүгә ирешә. Китапта адвокат Андреев белән шымчы Шубин образларына да яңача характеристика бирелгән.

Хезмәтнең критик реализмга багышланган икенче бүлеге дә фактик материалга нигезләнеп зур теоретик хәзерлек белән язылган. И. Нуруллин критик реализмга характеристика биргәндә олы авторитетлар фикеренә, аерым алганда, Ф. Энгельс билгеләмәсенә таяна. «Тормыштагы һәм кешеләрдәге аерым кимчелекләрне генә түгел, бәлки җәмгыятьнең үзен, аның нигезен тәнкыйтьли торган реализм ул — критик реализм», ди (8 бит).

Тәнкыйтьче критик реализм белән мәгърифәтчелек реализмы арасындагы аерманы күрсәтеп бирүгә аеруча нык игътибар иткән. Бу аңлашыла да. Чөнки критик реализмны билгели торган кайбер сыйфатларның, принципларның яралгыларын мәгърифәтчелек реализмы әдәбиятында да табарга мөмкин. Мәсәлән, кеше образын иҗат итүдә социальлек принцибы һәм шәхесне тирәлек тәэсирендә формалашкан итеп күрсәтү мәгърифәтчелек реализмы әдәбиятында да бар иде. Бу принципларның һәм сыйфатларның кайсы иҗат методында өстенлек алуын, хәлиткеч факторга әйләнүен билгеләү өчен, И. Нуруллин һәр ике иҗат методына караган әсәрләрдән конкрет мисаллар алып, аларны янәшә куеп чагыштырып карый һәм түбәндәге нәтиҗәгә килә: «Димәк, мәгърифәтчелек реализмы әдәбиятында социальлек принцибы тулы һәм эзлекле рәвештә тормышка ашырылмый әле. Критик реализм әдәбиятында исә идеаллаштырылган персонажлар, кагыйдә буларак, юкка чыга, язучылар тискәре персонажларны да юри каралтудан ваз кичә башлыйлар. Менә бу инде социальлек принцибының өстенлек алуы дигән сүз» (34 бит).

Югарыда әйтелгәннәр авторны «критик реализм әдәбиятында кешенең язмышын, чынбарлыкның үзендә булганча, экономик исәп-хисап, сыйнфый-социаль интереслар хәл итә» дигән дөрес нәтиҗәгә китерә. Ф. Энгельс критик реализмга биргән атаклы билгеләмәсендә «типик характерларны типик хәлләргә» куеп сурәтләүне күздә тота. Димәк, критик реализм өчен гади характерлар, гади хәлләр генә җитми. Аңа характерлар да, хәлләр дә типик булсын. И. Нуруллин, критик реализм белән мәгърифәтчелек реализмы арасындагы аерманы билгеләгәндә, бу категорияләрне хәлиткеч дип саный һәм аларның һәр икесенә дә аерым-аерым тукталып, мәгънәләрен аңлата. Минемчә, типик характер белән типик хәл төшенчәләренең мәгънәләрен аңлатып бирү унай күренеш. Чөнки бу категорияләр, беренчедән, ике иҗат методы арасындагы аерманы күрсәтергә ярдәм итсә, икенчедән, аларны белү студентларга, мәктәп укытучыларына һәм укучыларга да бик кирәк.

Үзен ышандырмый, инандырмый торган карашларга И. Нуруллин хезмәтендә урын юк. Мәсәлән, ул критик реализмның метод һәм әдәби юнәлеш буларак мәйданга килү вакыты һәм шартлары мәсьәләсендә совет әдәбияты белемендә ике караш яшәп килүен әйтә. Берәүләр, критик реализмның тууын мөмкин кадәр ераккарак чигереп, теләсә нинди тәнкыйтьләү һәм сатирик тасвирлауда критик реализм күрергә тырышалар. Бу карашның нигезсезлеген тәнкыйтьче хезмәтенең беренче бүлегендә үк күрсәткән иде.

Икенче тенденция тарафдарлары, киресенчә, критик реализмның барлыкка килү вакытын һәм формалашуын капиталистик мөнәсәбәтләрнең өстенлек алуына, буржуаз стройның җиңеп чыгуына бәйләп аңлаталар, ягъни алар критик реализмның формалашуын мөмкин кадәр безнең чорга якынайтырга тырышалар. Галим бу карашны да кабул итми, аның нигезсезлеген рус әдәбияты һәм капитализм стадиясен үтмәгән көнчыгыш халыклары әдәбиятлары мисалында раслый. «Критик реализмның ярапуын соңгы очракка кайтарып калдырсак, барыннан да элек рус әдәбияты бу схемага сыймас... Әлеге концепцияне кабул иткән очракта капитализм стадиясен үтмәгән яисә буржуаз мөнәсәбәтләре зәгыйфь булган Көнчыгыш халыкларының барысын да критик реализм әдәбияты тудыру хокукыннан мәхрүм итәр идек» (40 бит), диюе белән автор хаклы.

Европа һәм Америка халыклары әдәбиятында барган катлаулы процесслар да икенче концепциянең нигезсез булуын күрсәтә. Шуңа күрә тәнкыйтьче критик реализмның мәйданга килүен өч факторга (яшәп килүче җәмгыятьнең каршылыклары җитәрлек дәрәҗәдә кискенләшкән булу; иҗтимагый фикернең тиешле югарылыкка күтәрелүе һәм

реализм традицияләренең булуы) бәйләп аңлата. Әдипнең бу концепциясе зур игътибарга лаек. Чөнки ул аерым бер халык әдәбиятына гына нигезләнмәгән, бәлки дөнья әдәбиятларындагы катлаулы процесска туры килә. Бу концепция татар әдәбиятында критик реализмның метод һәм әдәби юнәлеш буларак формалашуын да үз эченә ала.

Тәнкыйтьче критик реализмның формалашуын 1905 елгы Беренче рус революциясе белән бәйләп карый. Минем карашымча, бу — бердәнбер дөрес аңлату. Чөнки моңа кадәр татар әдәбиятында критик реализмның метод һәм әдәби юнәлеш буларак формалашуы мөмкин түгел иде. Китапта аның сәбәпләре ачык күрсәтелгән.

Соңгы бүлектә сүз социалистик реализм турында бара. Дөрес, И. Нуруллин бирелә бу метод тирәсендә барган бәхәсләрне, фикер каршылыкларын хәл итүне җилкәсенә алмый. Шулай да социалистик реализмның яшәвен шик астына алучыларга карата авторның фикере ачык. Ул аның, әдәби юнәлеш һәм иҗат методы буларак, дөньякүләм әһәмияткә ия факт булуын раслый. Тәнкыйтьче бу методның кем тарафыннандыр уйлап чыгарылган директива да, әдәбият җилкәсенә тагылган догма йөге дә булмавын бик ачык һәм төгәл күрсәтә. Моңа ул мәгърифәтчелек, критик һәм социалистик реализм методларында кеше концепциясенең ни рәвешле тормышка ашырылуын анализлау һәм аларны янәшә куеп чагыштыру аша ирешә. Анализ процессында шул ачыклана: социалистик реализм да, критик реализм кебек үк, кешене иҗтимагый тирәлек — экономик, социаль һәм политик мөнәсәбәтләр продукты итеп карый. Ләкин моңа карап кына галим алар арасына һич тә тигезлек билгесе куярга җыенмый. Киресенчә, алар арасындагы аерманы күрсәтеп бирә. Социалистик реализм әдәбиятында кеше иҗтимагый хәлләрнең колы булып түгел, бәлки актив көч итеп, иҗтимагый үсешнең законнарын танып белгән хәлдә, тирәлеккә йогынты ясый, аны тиешле юнәлештә үзгәртә ала торган көч итеп тасвирлана. Моның дөреслеге күп санлы мисаллар белән раслана. Шулар арасында, минемчә, иң уңышлы сайланганнары Ш. Камал һәм Г. Ибраһимов әсәрләре. Чөнки бу әсәрләрнең беренче һәм икенче вариантлары арасындагы аерма, беренчедән, социалистик реализмны критик реализмнан аера торган сыйфатлар турында фикер йөртер өчен шактый материал бирсә, икенчедән, гадел җәмгыятьне раслаган әдәбият буларак, соңгыларында уңай герой алгы планга чыга.

И. Нуруллин совет әдәбият белеменең социалистик реализм теориясен үстерүдәге олы хезмәтләрне хөрмәт белән карый. Китапта, мәсәлән, социалистик реализм әдәбиятының җәмгыятьне социалистик үзгәртеп кору өчен көрәшүче пролетариат белән органик бәйләнгән әдәбият булуы да, аның марксизм-ленинизмга таянуы да, коммунистик партиялелеге дә, гуманизм һәм халыкчанлык белән сугарылган булуы да, тормышны тарихи-конкрет рәвештә һәм революцион үсештә гәүдәләндерүе дә исәпкә алынган.

Укучылар күргәндер, хезмәттә һәр мәсьәлә конкрет куела һәм автор күп санлы фактик материал арасыннан шул мәсьәләгә җавап бирергә, аны дәлилләргә ярдәм итәрдәен генә сайлап ала. И. Нуруллин өчен купшы сүзләр сөйләү, абстракция чит нәрсә.

Шулай да тәнкыйтьчегә киңәш йөзеннән әйтәсе фикерләр дә бар. Мәгълүм булганча, китап үз вакытында вакытлы матбугатта басылган мәкаләләрдән төзелгән. Шуңа күрә аңа композицион бөтенлек җитенкерәми, мәкаләләрнең мөстәкыйльлеге шактый нык сизелә. Бигрәк тә иллюстрация өчен китерелгән мәкаләләр гомумтеоретик характердагы материалның композицион бөтенлегенә куләгә төшерәләр. Бусы — бер.

Икенчедән, кайбер теоретик положениеләрнең, фикерләрнең цитаталарның кабатлану очраклары бар. Мәсәлән, критик реализм методына караган мәсьәләләрдә фикер бердәмлегенең урнашып җитмәве турында беренче бүлектә бик яхшы әйтелгән. Ләкин шушы ук фикер икенче бүлектә дә күренеп китә. Ф. Энгельсның реализмга биргән атаклы билгеләмәсе белән дә шул ук хәл. Укучы аны китапның 35 нче һәм 60 нчы битләреннән укый ала.

Китап киң катлам укучыларны, шул исәптән мәктәп укытучыларын һәм укучыларын да, күздә тотып язылган. Шунлыктан иллюстрация өчен китерелгән мәкаләләрдә, минемчә, мәктәп программасына кертелгән әсәрләр генә урын алырга тиеш иде. Бу очракта хезмәт тагын да отышлырак, тагын да файдалырак булыр иде.

Аннан соң, ниһаять, шуны әйтергә кирәк: китабының ахырында автор совет әдәбиятында социалистик реализм белән янәшә бүтән иҗат методларының яши алу-алмау мәсьәләсенә туктала. Галим, совет әдәбиятында декандентлык һәм критик реализм кебек иҗат методларына урын юк, дигән кат-

тый фикер әйтә. Бу — бердәнбер дөрес фикер, моның белән килешми мөмкин түгел. Ләкин романтизм турында сөйләгәндә, И. Нуруллин, ни өчендер, бу принциптан читкә китә һәм икеләнеп кенә булса да, «принципта романтизмның мөстәкыйль иҗат методы буларак яши алуы турында сүз алып бара алабыз» (72—73 битләр), дигән фикер үткәрә. Дөрес, бу аның махсус өйрәнү, тикшеренүгә нигезләнеп әйтелгән фикере түгел. Киләчәктә ул бу турыда кабат уйланыр дип ышанасы килә.

Әмма ни генә булмасын, И. Нуруллин бик кирәкле һәм файдалы эш башкарган. Иҗат методларыбызның һәм әдәби юнәлешләрнең барлыкка килү вакытын һәм шартларын укучыга популяр формада аңлатып биргән хезмәтләр күптән кирәк иде. Ышанып әйтә алам, бу хезмәт, күп санлы укучылар белән беррәттән, әдәбият тарихын өйрәнүче белгечләрнең дә өстәл китабына әверелер. Чөнки бездә әдәбият тарихын өйрәнүне иҗтимагый фикер формалашу тарихы белән алыштыру очраклары бар. Мәктәп укытучылары да аны шул формадарак аңлаталар. Бу турыда үз вакытында И. Гази болай дигән иде: «...әдәбият тарихны тирәнрәк аңлауга ярдәм итүче предмет булып килде, ул матур әдәбият әсәре итеп укытылудан бигрәк, сыйнфый көрәш тарихына иллюстрация рәвешендә укытылды» («Совет мәктәбе» журналы, 1964 ел, 8 сан, 30 бит).

И. Нуруллин бу хезмәтендә әдәбият тарихын өйрәнүнең үрнәген бирде һәм аның нигезенә иҗат методлары принцибын алып автор бик дөрес эшләгән. Бары тик шушы принцип кына безгә әдәбият тарихын әдәбият тарихы итеп өйрәнергә, аны иҗтимагый фикер формалашу тарихына иллюстрация ясау шаукымыннан сакларга мөмкинлек бирәчәк.

**Ш. АСЫЛГӘРӘЕВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

## Рөстәм Мингалимов

### Малайлар

Әй, сукты бәйрәм сәгате
Бәрхет тау башларында.
Мәйданга малайлар кереп
Көрәшә башладылар...
Көрәшәләр болыннарда,
Урманда-аланнарда.
Тәгәрәп өлгерә алмаш
Көрәшче агайларга!
Татарстан карап тора
Сабан туе кызганны:
Малайлар күккә менәләр
Балакларын сызганып.
Малайлар атта киләләр,
Тояклар җирне кага.
Көчле малайлар үскәнне
Хәбәр итеп дөньяга,
Тояклар җирне кага...

### Кояш хәтле Кояш

Чия хәтле Кояш булганы юк,
Ә Кояшның туган көне булган.
Ул бик күптән, куе-кызыл булып,
Кояш хәтле чия кебек туган.
...Кызыллыгын биргән чияләргә,
Бөрлегәнгә, алмаларга биргән.
Җанын бүлеп биргән яфракларга.
Куяннарда — аның җаны йөгерә.
Әти-әниеңне биргән сиңа,
Ап-ак тешләр биргән син тугач та.
Торналарда оча Кояш җаны,
Кояш җаны сайрый сандугачта.
...Җылы яфракларга битен куеп,
Пешә җиләк, лимон, апельсиннар:
Төсен шулай коя җиргә Кояш.
Озак еллар шулай кояр, кояр.

Бетә сыман булыр хәтта үзе
Соры көнбагышлар кырына коелып.
...Ләкин тагын кояш зурлык Кояш
күренә башлар куе-кызыл булып.

## Дөньяда бер эт бар иде

Дөньяда
Бер эт бар иде —
Кечкенә,
Йомшак кына,
Ак кына,
Тик маңгаенда
Кара тап бар чак кына.
Хуҗасы — шаян малай
Этне ярата иде,
Аны ашата иде.
Ә бер мәлне, нигәдер,
Яратмый да башлады,
Ашатмый да башлады,
Илтеп шәһәр эченә
Адаштырды ул аны.
Шушы көнне үк төнлә
Эте керде төшенә:
— Ашыйсым килде,
Кайттым! — ди.
Кечкенә,
Йомшак кына,
Ак кына,
Тик маңгаенда
Кара тап бар чак кына.
Икенче көнне дә төнлә
Эте керде төшенә:
Бер ишектән тибеп аны
Чыгардылар кешеләр.
Иртүк торды да малай
Китте эзләргә этен.
Югалту ансат икән дә
Аһ, читен, табу читен.
Эзли малай,
Тапмый этен
Бик күптән инде менә.
Бик күптән инде һәр төндә
Эте төшенә керә.
Йөгереп керә,
Я тик тора —
Кечкенә, йомшак кына.
Ак кына,
Тик маңгаенда
Кара тап бар чак кына.
Эзләмәсен малай аны,
Инде җирдә юк эт ул.
Кая киткән соң дисезме?
Төшкә әйләнде бит ул.

## Гөрләвекләр озатып...

Елга ягына йөгерә гөрләвекләр,
Йөгерә алар гөрләп, уйнап, ярсып.
Гөрләвекләр озатып мин йөгердем,
Инде калам яр өстенә басып.
Гөрләвекләр гөжләп суга коела,
Китүләре инде еракларга.
...Иркәләрләр алар балыкларны,
Кагылырлар барып корабларга.
Бик шатланып торам алар өчен,
Бераз гына шул чак үпкәм дә бар.
Уйнап-гөрләп бергә йөгердек тә
Хәзер мине ярда калдыралар...

## Хәй күршесе Хөсәен

Хәй күршесе Хөсәен
Хәйдән көлә көн саен:
— Әтиеңнән башка син
Сөйли дә белмисең! — ди.
— Әтиеңнән башка син
Йөри дә белмисең! — ди.
— Шуңа гел әтиеңә
Тагылып йөрисең! — ди.
Күп сөйләшеп тормый Хәй,
Машинага утыра.
Әтисе — машина йөртә,
Хәй карап кына тора.
Өйрәнеп кенә тора,
Ул аңлап кына тора.
Әле бер мәл Хөсәен
Хәй янына утырыр.
Машинаны Хәй йөртер,
Хөсәен карап торыр.
Елмаеп бераз гына
Хәй кабатлар көн саен:
«Машина йөртәсеңме,
Эйрәтимме, Хөсәен?»

## МӘСКӘҮДӘ, РСФСР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

Июнь аенда РСФСР язучылар союзы идарәсе пленумы бүгенге якут әдәбиятының торышы һәм үсеш проблемалары турындагы мәсьәләне тикшерде. Пленум эшендә Татарстаннан Сибгат Хәким, Зәки Нури, Гариф Ахунов (идарә членнары) һәм Равил Фәйзуллин (ревизия комиссиясе члены) катнаштылар. Үз әсәрләренә бүтән халыклар вәкилләрен дә бик кунакчыл рәвештә керткән якут әдәбиятының уңай якларын бәяләп һәм милли әдәбиятларны рус теленә тәрҗемә итү буенча әле хәл ителмәгән кайбер мәсьәләләргә басым ясап, пленум утырышларының берсендә Гариф Ахунов чыгыш ясады.

Шул ук пленумда РСФСР язучылар союзының чираттагы IV съездын 1975 елның декабрендә үткәрергә дигән карар кабул ителде. Съездга делегат итеп Россия Федерациясенең автономияле республикалары, крайлары һәм өлкәләре, милли округлары үз оешмаларында учетта торган һәр җиде язучының берсен сайларга тиешләр.

## ПУШКИН БӘЙРӘМЕ — ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Менә тугызынчы ел рәттән инде ул чәчәкле һәм кояшлы июнь аеның беренче атнасында бөтен ил күләмендә үткәрелә. Бәйрәм тантаналары быел да Псков өлкәсенең Михайловское, Горький өлкәсенең Болдино, Калинин өлкәсенең Брново исемле истәлекле урыннарында — заманында Пушкин яшәгән һәм иҗат иткән якларда узды. Күп санлы укучылар белән очрашуларда шагыйрьнең үлемсез бөеклеген зурлап илебезнең төрле республикалары әдипләре һәм чит илләрдән (Куба, Румыния, Югославия һ. б.) килгән кунаклар чыгыш ясадылар. Кайнар хисле һәм күркәм төсле шигъри веноклар Пушкинга күплап куелды. Татар халкы һәм татар поэзиясе исеменнән шундый сүзне Болдинода шагыйрь Әхсән Баянов, ә шагыйрьнең туган көнендә Мәскәүдә Пушкин бәйрәмен йомгаклау кичәсендә (П. И. Чайковский исемендәге концерт залы) шагыйрь Зәки Нури әйтте.

## БЕР КИТАПТА ДҮРТ МӘКАЛӘ

Дүрт мәкаләнең барысы да татар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләрен, аның аерым вәкилләре иҗатын яки аерым әсәрләрен җентекләп күзәтә: «Азатлык һәм бәхет жырчысы» — Габдулла Тукай турында, «Фатих Әмирхан хикәяләре һәм повестьлары» — шуларга төпле бәяләү сүзе, «Беренче рус революциясе уяткач» — Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр» романы турында уйланулар...

«Мирас һәм хәзерге заман» исемле бу китап — милли әдәбиятлар турында уйлануларның тулыландырылган икенче басмасы — Мәскәүдә «Советский писатель» нәшриятында быел чыкты. Анда безнең әдипләр иҗаты Урта Азия һәм Кавказның күренекле каләм осталары (Абдулла Кадыйри, Сәкен Сәйфуллин, Садретдин Айни, Габит Мөсрепов, Сөләйман Стальский) һәм борынгы әдәбият классиклары (Хакани, Низами, Җами, Навои) иҗаты белән янәшә куеп тикшерелә.

Китапның авторы — танылган галим, милли әдәбиятлар белгече Люциан Ипполитович Климович.

1809 елда язып алынган һәм 1812 елда Казанда рус телендә бастырып чыгарылган («Дворовой человек». Тимофей Беляев тәрҗемәсе) «Козы-Көрпәш һәм Баян-Сылу» исеме белән бүтән төрки әдәбиятларда да билгеле булган башкорт эпосын китаптагы дүртенче мәкалә аеруча җентекләп анализлый.

## ДЖЕЙМС ОЛДРИДЖ КАЗАНДА

Англиянең күренекле прогрессив язучысы, Халыкара Ленин премиясе лауреаты, хәрби корреспондент сыйфатында 1939 елдан башлап бик күп илләрдә йөргән, 1945 елда Совет гаскәрләренең Берлинны штурмлау шаһиты булган һәм бик күп әсәрләрендә фашизмга каршы батырларча көрәшне һәм Гарәп илләрендә милли азатлык көрәшен яктырткан, дәүләтләр һәм халыкларның үзара тыныч яшәү политикасын яклаган әсәрләр авторы («Намус эше», «Дингез бөркете», «Дипломат», «Аучы», «Чүл батырлары», «Аның үлгән теләмим»,

«Ил әсире» романнары, «Күп кешеләр турында» новеллалар китабы, «Кырык тугызынчы штат» исемле сатирик пьеса һәм күп санлы публицистик чыгышлар) Джеймс Олдридж бездә булды. Ул Татарстан әдипләре һәм журналистлары белән очрашты, Казанның истәлекле урыннарын карап йөрде.



*Рәсемдә (сулдан уңга): Шагыйрь Илдар Юзеев, «Социалистик Татарстан» газетасының бүлек мөдире Рәшит Гарипов, драматург Риза Ишморат, Джеймс Олдридж, Татарстан китап нәшрияты директоры Гарәф Шәрәфетдинов.*

## ҮТКӘНДӘГЕ ФОЛЬКЛОР ҺӘМ БҮГЕНГЕ ЗАМАН

Традицион фольклорның хәзерге яшәеше ни хәлдә? Бүгенге көн чынбарлыгы аның нинди яңа формаларын тудыра? Хәзерге композиторлар иҗаты аның белән нинди мөнәсәбәттә?.. — СССР Композиторлар союзында үткәрелгән фольклорчылар семинарында, Украина, Белоруссия, Молдавиядән, Россия Федерациясенең күпчелек автономияле республикалары, өлкәләре һәм крайларыннан вәкилләр белән бергә, Татарстаннан З. Сәйдәшева һәм И. Кадыйров иптәшләр катнашты, семинарда булучылар «Фольклор һәм бүгенге көн» темасы буенча фикер алышканнар, бу өлкәдә фәнни һәм практик эшләрне оештыруга бәйле консультацияләр алганнар һәм халык иҗатының яңа язмаларын тыңлаганнар.

## ТАТАР ҖЫРЫ ҺӘМ ШИГЫРЕ КИЧӘСЕ

Илебез башкаласы Мәскәүнең Үзәк концерт залында үткән бу кичәдә В. Шәрипова, И. Шиһапов, Т. Якупов чыгышлары яңгырады һәм Татар дәүләт филармониясенең инструменталь ансамбле уйнады.

## КӨН ТӘРТИБЕНДӘ: ДӘРЕСЛЕКЛӘР

Республикабыз Мәгариф министрлыгының методик советы, татар мәктәпләрендә 7—10 класслар өчен чыгарылган әдәбият дәреслекләре һәм хрестоматияләрен тикшерүгә багышлап, чираттагы утырышны Арчада үткәрде. Анда Балтач, Кукмара һәм, әлбәттә, Арча районнары мәктәпләреннән укытучылар, Татарстан китап нәшрияты вәкилләре, татар теле һәм әдәбияты буенча дәреслек авторлары (М. Гайнуллин, А. Әхмәдуллин, Н. Юзеев), Язучылар союзы һәм «Казан утлары» журналы исеменнән тәнкыйтьче Фарваз Миннуллин катнашты. Дәреслекләр чыгаруга бәйле файдалы киңәшләр өчен җәмәгатьчелеккә рәхмәт сүзе мәгариф министрыбыз М. И. Мәхмутов чыгышында әйтелде.

## ДУСЛАР ИЛЕНДӘ

Венгр Язучылары союзы эше һәм аның журналларының көндәлек эш практикасы белән танышып тәҗрибә уртаклашу... Матур әдәбият чыгара торган нәшриятларда эшлекле сөйләшүләр... Күп милләтле совет әдәбиятын пропагандалауга багышланган кичәләрдә чыгышлар... Будапешт, Самбот-

...ей һәм Шопрон калалары буйлап сәяхәт...

Әнә шундый программа белән атнадан артык эшләү өчен СССР Язучылар союзы идарәсе Венгриягә җибәргән делегация составында шул идарәнең секретарьларыннан берсе шагыйрь Зәки Нури бар иде.

Будапештның Чили дип аталган эшчеләр районы культура сарае һәм китапханәсендә, СССРның Будапешттагы фән һәм культура сараенда очрашканда татар әдәбияты, аның күренекле вәкилләре иҗаты, шагыйрьләребез Габдулла Тукай һәм Муса Җәлилнең киләсе елда билгеләп үтеләсе юбилейлары турында кызыксынулы бик күп сорауларга җаваплар бирелде.

## БЕЗДӘ ГАСТРОЛЬДӘ

*
* *

Әзербайҗан музыкаль комедия театры спектакльләре җәен Казанның Опера һәм балет театры бинасында күрсәтелде. Аның бай һәм күпкырлы программасында И. Кальманның «Сильва», «Марица» һ. б. әсәрләре, У. Гаҗибәковның «Аршин мал алан»ы, Ф. Лоуның «Минем гүзәлем Леди», Т. Кулиевның «Хәерле иртә, Элла», В. Долидзеның «Тифлис яучылары» һ. б. әсәрләр бар иде.

*
* *

Качалов исемендәге театрда Брянск шәһәренең драма театры Казан тамашачыларына «Чили трагедиясе» (Ю. Чепурин), «Аристократлар» (Н. Погодин), «Бургомистр әфәнде» (П. Лучин), «Йокыннан уян да җырла» (М. Дьяроваш), «Күзгә күренмәс ханым» (П. Кальдерон) һәм «Брянск урманыннан кайтаваз» дигән спектакльләрне күрсәтте.

*
* *

Чехословакияне фашист илбасарларыннан азат итүгә 30 ел тулуга багышлап СССРда үткәрелгән Культура көннәре уңае белән Казан консерваториясенең актовый залында Чехословакия халык армиясенең Үзәк оркестры Моцарт, Дворжак, Сметана, Нееллы, Штраус, Легар әсәрләрен башкарып берничә чыгыш ясады.

*
* *

Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында эстрада ансамбленә кушылып Мабель Люна (Перу) һәм Джимми Санти (Аргентина) җырлады. Румын органчысы Йозеф Герстенгаст исә Казан консерваториясе залында уйнады.

## ЗУР ЗАЛДА ЗУР КОНЦЕРТ

Аны Казанда «Сәнгать бәйрәме, сәнгатьтә дуслык бәйрәме» дип атадылар. Казанның иң зур залы Спорт сараенда СССРның халык артисты Клавдия Шульженко, РСФСРның атказанган артистлары Зоя Федорова, Алла Ларионова, Николай Рыбниковлар һәм татар сәнгатенең зур осталары Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Габдулла Рахимкулов, Айрат Арсланов, Зиннур Нурмөхәммәтовлар бергәләп чыгыш ясаган көннәр иде бу.

## ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘ

Бөтен дөньяга билгеле Муса Җәлил исеме Чаллы шәһәрендә күптән түгел ачылган яңа китапханәгә бирелде. Аның эшен башлап җибәрү тантанасында Муса эзләре буйлап йөреп китап язган фәннәр кандидаты Рафаэль Мостафин катнашты.

## КАЗАННАН ЕРАКТА

*
* *

Ташкент шәһәренең 184 нче мәктәбендә «Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре» дигән темага комсомол җыелышы... Шул ук каладагы 58 нче мәктәптә Пермь өлкәсенең Копчиков урта мәктәбеннән килгән эзтабарлар белән Муса Җәлил кичәсендә очрашу... 187 нче урта мәктәпнең актлар залында... Ташкентның Куйбышев районындагы мәктәп китапханәләрендә Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗатына багышланган иҗади семинар... Ташкент дәүләт университетының гыйльми китапханәсе залында Муса Җәлил әсәрләре турында төпле сөйләшү... Ташкент телевидениесе программасында «Чәнечкеле тимер чыбыкны өзгән шигырьләр» дигән тапшыру — шулай ук Муса Җәлил турында...

Боларның барысын да Җәлил һәм җәлилчеләр турында кандидатлык диссертациясе яклаган Исхак Зәбиров оештыра һәм үткәрешә. Һәр очрашуда диярлек — Җәлил әсәрләре, аның турындагы документлар күргәзмәсе, Мусаның көрәштәшләре (Гарәф Фәхретдинов), сугыш елларында аны күреп белүчеләр (М. Мохсынов, Х. Фәйзуллаев) иптәшләренең чыгышы, шагыйрь иҗатыннан үрнәкләр уку оештырыла.

*
* *

Муса Җәлил исемендәге интернациональ дуслык клубы пионерлары чакыруы буенча Карагандага барып Исхак Зәбиров пионерлар сараеның актлар залында, берничә мәктәптә, Дәүләт университетында, өлкәнең Сарани шәһәрендәге 7 нче мәктәптә чыгышлар ясады.

## ИҖАТКА — ИГЪТИБАР, ИҖАТКА — ТАЛӘП

Союзыбызның Әлмәт бүлегендә Мәхмүт Хәсәновның «Инженерлар» исемле яңа романы («Кама таңнары»ның икенче кисәге) тикшерелде. Каләмдәшләре аңа әсәрнең сюжет сызыгын камилләштерү, төп образларны тулы канлы итү юнәлешендә әле күп эшләргә кирәклеген әйттеләр.

Шул ук әдипнең «Казан утлары» журналында басылган «Хәдичә» дигән әсәрен исә Азнакай нефтьчеләренең профсоюз китапханәсендә үткәрелгән укучылар конференциясендә нефтьчеләр, тезүчеләр һәм культура өлкәсе хезмәткәрләре бергәләп тикшерде. Китап итеп чыгарганда аны тагын да киңрәк офыклы, тирәнрәк эчтәлекле һәм эшләнешен тагын да нәфисрәк итәргә дигән фикер шулай ук катгый белдерелде.

*

* *

«Татарстан яшьләре» редакциясе каршындагы «Яшьлек» исемле әдәби берләшмәнең чираттагы утырышы булды. Яшь прозаикларның хикәяләре турында фикер алышуларда Г. Рәхим, Зөлфәт, Ф. Сафин, Н. Хәсәнов, Ф. Хуҗиәхмәтова һ. б. катнашты. Яшь әдипләрдән Г. Кашапов, Р. Гыйззәтуллин, Н. Гыйматдинова әсәрләренә карата кызыклы фикерләр, файдалы киңәшләр әйтелде.

Утырыш, һичшиксез, авторларның үзләренә генә түгел, ә башка яшь иҗатчылар өчен дә файдалы булды.

## ТЕАТРЫБЫЗ — МӘСКӘҮДӘ

Башта урамнарда афишалар, газеталарда белдерүләр күп булды: «2 июльдән башлап 30 июльгә чаклы А. С. Пушкин исемендәге театр сәхнәсендә Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры спектакльләре күрсәтелә». Аннары театрга бик күп халык йөри башлады һәм ай буе диярлек шулай дәвам итте. Кыскасы, театрыбыз, Мәскәүгә инде бишенче тапкыр барып, быел башкала тамашачыларына тагын 12 пьеса буенча эшләнгән спектакльләрне уңышлы күрсәтте. Театр коллективы үзенең 1976 елда билгеләп үтеләсе 70 еллыгы бәйрәменә әнә шулай эшлекле хәзерләнә.

## ТУКАЙ КАЗАКЪ ТЕЛЕНДӘ

Алма-Атадагы «Җазушы» исемле нәшриятта Габдулла Тукайның сайланма әсәрләре 7000 данә тираж белән басылып чыкты. Китапның күләме 375 бит.

# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

Һәр елны шулай: газета-журналларга язылу кампаниясе башланыр алдыннан редакциягә журнал укучыларыннан килә торган хатларның саны бермә-бер арта. Хат авторлары барысы да диярлек, киләсе елда «Казан утлары»нда нинди яңа әсәрләр басылачак, дип сорап язалар.

Башка елларда укучыларыбызның бик урынлы бу сорауларына җавап бирү өчен редакция язучыларга мөрәҗәгать итеп, аларның алдагы елда журналга нинди әсәрләр тәкъдим итәргә теләүләре белән кызыксына иде. Бу ел исә язучыларыбыз, хатлар барып җиткәнче үк, редакциягә яңа әсәрләрен китерә башладылар. Атап әйткәндә, Тукай премиясе лауреатлары Гариф Ахуновның «Идел кызы» исемле яңа романы, Фатих Хөснинең «Язмыш» повесте, дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә», Атилла Расихның «Айлы төннәр» («Ямашев» романының икенче китабы) романнары, Барлас Камаловның «Йөрәкнең янулары», Эдуард Касыймовның «Өй артында шомыртым» исемле повестьлары килде. Болар өстенә тагын күп кенә прозаикларыбыз үзләренең яңа роман, повесть һәм хикәяләрен төгәлләү алдында торуларын һәм тиздән редакциягә китерәчәкләрен әйттеләр. Редакция шул күп санлы роман, повесть һәм хикәяләрнең иң яхшыларын сайлап сезгә — укучыларга җиткерү өчен хәзердән үк зур, җитди эш алып бара. Журналыбызның киләсе елгы саннарында проза әсәрләре мул һәм бай эчтәлекле булачак дип шикләнмичә әйтеп куя алабыз.

Һәр вакыттагыча, алдагы елда да поэзия әсәрләренә зур урын биреләчәк. Сез ярата торган күренекле шагыйрьләребездән Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Зәки Нури, Илдар Юзеев, Гамил Афзал, Әдип Маликов, Саҗидә Сөләйманова, Шәүкәт Галиев, Марс Шабаев, Әхсән Баянов, Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим һ. б. ларның яңа шигырьләре киләсе елда да укучыларыбыз күңеленә хуш килер дип ышанабыз.

Очеркистларыбыз да прозаиклардан һәм шагыйрьләрдән калмаска ниятлиләр. Аларның күбесе КамАЗ төзүчеләр, хезмәт алдынгылары, республикабыз казанышлары, фән һәм культура хезмәткәрләре турында кызыклы очерклар язулары турында хәбәр иттеләр.

Әдәби тел мәсьәләләренә, әдәбият белеменә һәм әдәби тәнкыйтькә кагылышлы мәкаләләр, яңа китапларга рецензияләр, күренекле рәссамнарыбыз, артистларыбыз һәм композиторларыбызның тормыш һәм иҗат юлын чагылдырган материаллар, ноталары белән биреләчәк иң яхшы яңа җырлар да редакция портфелендә байтак тупланды.

«Балаларга укыгыз» дигән бүлектә әдипләребезнең балалар өчен язылган иң әйбәт шигырь һәм хикәяләре, «Елмаеп-көлеп кенә» бүлегендә иң үткен сатира һәм юмор әсәрләре дә «Казан утлары»ның киләсе елгы саннарында даими урын алып барачак.

Кыскасы, шул: 1976 елда «Казан утлары» журналы тагын да кызыклырак, анда урнаштырылган материалларның сәнгатьчә эшләнеше тагын да югары сыйфатлырак булсын өчен редакция хезмәткәрләре һәм редколлегия әгъзалары хәзердән үк инде тырышып эшлиләр.

«Казан утлары» журналын тоткарлыксыз һәм вакытында алып барырга теләсәгез, аңа язылуны да соңгы срокка калдырмаска кирәк. Журналыбызга Советлар Союзының барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин. Ул Бөтенсоюз газета-журналлар каталогына 73210 номерлы индекс белән теркәлгән.

Язылу бәясе бер елга — 6 сум.

# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

Сезгә мәгълүм булганча, Татарстан республикасы башкаласы Казанда яшьләрнең яраткан газетасы — «Татарстан яшьләре» чыгып килә. Ул егетләрнең һәм кызларның якын киңәшчесе, сердәше һәм якын дусты булып санала.

Татар совет язучыларының һәм яшь каләм ияләренең мажаралы повестьлары, яңа хикәяләре, шигырьләре шушы газета битләрендә дөнья күрә. Яшьләр яраткан яңа җырлар да башлап «Татарстан яшьләре» газетасы битләрендә басыла. Газетада даими рәвештә «Әдәбият һәм сәнгать» дигән махсус сәхифә чыгып килә.

Фән һәм техника яңалыклары һәм планетадагы хәлләр белән кызыксынучылар, спорт сөючеләр, үзләрендә матур әхлак сыйфатлары тәрбияләргә омтылучылар, сатира һәм юмор белән мавыгучылар газетаның «Серләр дөньясында», «Сердәш», «Чемпионнар турында сөйлибез», «Шомбай» дигән бүлекләреннән һәркемне кызыксындырырлык язмалар укый алалар.

Хөрмәтле укучылар!

«Татарстан яшьләре» газетасына 1976 елга язылырга онытмагыз! Газетаның еллык бәясе — 3 сум 12 тиен. Аңа Советлар Союзының барлык почта бүлекләрендә язылып була. Подписка нинди дә булса сәбәп белән кабул ителмәсә, язылу бәясен түбәндәге адрес белән җибәрергә мөмкин:

*г. Казань, ул. Декабристов, 2. Областное отделение «Союзпечати», для подписки на газету «Татарстан яшьләре». Газетаның индексы — 51498.*

**«ТАТАРСТАН ЯШЬЛӘРЕ» ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕ.**


Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210